ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.2013



# МЕҢЬЕЛЛЫК КАЗАН





*Кремль урамы*





*Болак буе*





*Камал театры*

*Үткәнебез һәм бүгенгебез. Бер үк ноктадан бер гасыр аерма белән төшерелгән фоторәсемнәр.*

**Хажи Абдулла ДУБИН коллекциясеннән**

# Казан утлары
# Qazan utlari

2013

# 9
(1091)

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*
**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎: *Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 222-09-83 өст.1612.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*

**Факс** — (843) *222-09-83 өст.1612.*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Җәүдәт СӨЛӘЙМАН. Җан җебеннән үрдем күперләр. *Шигырьләр.* ....5
Рахман ШӘФИГУЛЛИН. Утлы дулкын. *Документаль бәян.* ....10
Ленар ШӘЕХ. Без сайлаган юллар хата түгел. *Шигырьләр.* ....28
Фәрит ИМАМОВ. Күләгә. *Детектив роман.* ....33
Гөлнур КОРБАНОВА. Юшкыннарны вакыт юа. *Шигырьләр.* ....96
Рүзәл МӨХӘММӘТША. *Хикәяләр.* ....100

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫННАН

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Таулар биеклегендә. ....111
Рәсүл ГАМЗАТОВ. Шөлдерле лачын турында җыр. *Шигырьләр.* ....112

ХӘТЕР

Эдуард ТРЕСКИН. Язмышның хикмәтле кулы. ....118
Рафаэль СӘХӘБИЕВ. Минем сәхнә укытучым. ....121
Нурихан ФӘТТАХ. Четерекле булды безнең заман. *Истәлекләр.* ....124

ФӘН

Марсель БАКИРОВ. Болгарга тоташкан тамырларыбыз. ....136
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ....155
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ....158

КИТАП КҮЗӘТҮ

Фәрит ХАТИПОВ. Канатлы биюче. ....151

КЛАССИК ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Николай ГОГОЛЬ. Борын. ....161

ШӘХЕСЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘР

Мәгъсүм ГӘРӘЕВ. Төшләренә дә кермәде. ....176

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөлгенә КӘРИМОВА. Сан алганда. *Шигырьләр.* ....183

КАЙТАВАЗ

Рәфикъ ЮНЫС. «Теге солдат» яки Яхшылык эшлә дә, суга сал... ....185

«Казан утлары» архивыннан. ....116
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....191

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть Р.ШАФИГУЛЛИНА «Пылающие волны»; детективный роман Ф.ИМАМОВА «Тень»; рассказы Р.МУХАМЕТШИНА; стихи Д.СУЛЕЙМАНОВА, Л.ШАЕХА, Г.КУРБАНОВОЙ, Р.ГАМЗАТОВА с предисловием Р.ЗАЙДУЛЛЫ.

«Память»: статья Э.ТРЕСКИНА, посвященная 100-летию Н.ДАУТОВА; Р.САХАБИЕВ. «Мой наставник»; Н.ФАТТАХ. «Мы жили в непростое время».

«Наука»: М.БАКИРОВ. «Наши булгарские корни»; Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».

Страницы из «Татарской энциклопедии».

«Книжное обозрение»: рецензия Ф.ХАТИПОВА на книгу Р.Батуллы «Одержимый танцами».

«Образцы классической литературы»: Н.ГОГОЛЬ. «Нос».

«Отклик». Р.ЮНУС. «Тот солдат» или Делай добро незаметно».

«Новые имена»: стихи Г.КАРИМОВОЙ.

Из фотоархива журнала.

Дневник общественно-культурной жизни.

На наших обложках: «Татары». Картина Сергея Широкова. Из коллекции Рауля Мир-Хайдарова; писательница Айгуль Ахметгалиева.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: story by R.SHAFIGULLIN «Fire wave»; detective novel by F.IMAMOV «Shadow»; stories by R.MUHAMETSHIN, poems by D.SULEYMANOV, L.SHAEH, G.KURBANOVA, R.GAMZATOV with foreword by R.ZAYDULLA.

«Memory»: article by E.TRESKIN dedicated to 100th anniversary of N.DAUTOV; R.SAHABIEV. «My mentor»; N.FATTAH. «We lived in difficult times».

«Science»: M.BAKIROV. «Our Bulgar roots»; F.GARIPOVA. «History of our villages».

Pages from «Tatar encyclopedia».

«Book Review»: review by F.HATIPOV on book by R.Batulla «Obsessed by dancing».

«Samples of classical literature»: N.GOGOL. «Nose».

«Response». R.YUNUS. «That soldier» or Do good unnoticed».

From photo archive of magazine.

Diary of social cultural life.

On our covers: «Tatars». Painting by Sergei Shirokov. From collection of Raul Mir-Khaidarov; writer Ajgul Ahmetgalieva.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 02.09.2013, график буенча 02.09.2013.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-2004. Тираж 3816.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Җәүдәт
Сөләйман

# ҖАН ҖЕБЕННӘН ҮРДЕМ КҮПЕРЛӘР

## Татар бишегендә татар баласы

**1**

**Күңел төшкәндә, татар, дип.**
**Сиңа бүген дөнья тар, дип.**
**Күзне соң кая саласы?**

**Җанда иман, күктә — Алла,**
**Киләчәккә өмет булып,**
**Бишектә — татар баласы...**

**2**

**Ачынма, Алыплар юк, диеп,**
**Сыкранма, бетә дип, татарлар,**
**Күке-милләт, әйдә, очынсын, –**
**Татар бишегендә татар бар!**

**3**

**Татар бишегендә татар баласы.**
**Татар бишегендә татар баласының**
**баласы.**
**Татар бишегендә татар баласының**
**баласының**
**баласы.**
**Ким дигәндә җиде бабасыннан килгән буын —**
**Татар баласының**
**онығының**
**онығының**
**баласы.**

Җәүдәт СӨЛӘЙМАН (1955) – *галим, ТР Фәннәр академиясе академигы, шагыйрь; «Сәләт» балалар һәм яшьләр оешмасы җитәкчесе. «Ямаулыклар», «Мин – минсез дөньяда», «Күләгәләр» һ.б. шигырь китаплары авторы. ТР Язучылар берлеге әгъзасы.*

**Шул бишектә теләр идем күрергә**
**Бишектәге татар баласының**
**баласының**
**баласын.**
**Шуннан инде теләр идем бездән ары**
**дөньяларның**
**Шушы матур шәкел белән барасын...**

**4**

**...Җиһан гомеренә тиңләшсәче**
**әлеге ике мизгел арасы...**

## Монологлар

*Нәфес монологы:*

**«Миңа, миңа, миңа гына**
**алтын-көмеш, асылташлар.**
**Берне, бишне,**
**...юк, унбишне,**
**Юк, юк — күбрәк,**
**санап түгел, учлап, көрәп...**
**Рух белән мин, нәфес, килештерәм.**
**Чүпрә булып рухны кабартам.**
**Акыл гына җанга тия, кисеп,**
**Акыл гына миңа арата!»**
**Нәфес үзе чама беләмени!**
**Дилбегә дә йөгән — аңа чит!**
**Рух-дилбегә бирә юнәлешен,**
**Акыл-йөгән куя аңа чик.**

*Рух монологы:*

**«Мин — өермә, буран, бозлы яңгыр,**
**Мин аҗаган, яшен, ут-көлтә.**
**Бер мизгелдә җанны утка салам,**
**Шул мизгелдә җанны боз итәм.**
**Нәфес бирсә дәрман,**
**мин дәрт бирәм,**
**Мин канатлар тагам кешегә.**
**Мин күтәрәм күккә сине адәм,**
**...Йә тәмугка сине төшерәм».**
**Рух ул җилкән язмыш карабына,**
**Җилкәнгә җил — нәфес куәсе,**
**Дөнья гизгән адәм-карабны**
**Акыл белә кая куасын.**

*Акыл монологы:*

**«Миннән өскә — зиһен патшалыгы,**
**мән-мәсләктә минем таяныч,**
**Фикер тегә**
**дөнья катламнарын,**
**Тегелмәгән дөнья — аяныч.**
**Күңел бит ул — иксез-чиксез куыш,**
**Шул куышка куык — мин акыл,**
**Куык эчләрендә и айкала,**
**Нәфес уты капкан рух-ялкын».**

Өч катламлы — нәфес, рух, акыл, —
Гүя бәлеш дөнья мичендә.
Адәм булып пешсен өчен бәлеш,
Күпме утлар кирәк эчергә...

***

Битлексез Җан —
мең сыйфатлы тамчы,
Җан битлексез күктән иңгәндә.
И әрни җан, тырный бәгырь катын.
Чит-ят булган битлек кигәндә.

Бер мизгелгә адәм кыяфәте,
Бер мизгеллек битлек, юктан — бар!
Шул битлекләр әйлән-бәйләнендә
Дәвам итә кәмит -дөньялар...

***

Адәм — мизгел. Дөнья — мизгел,
Мизгелләрне бәйли Җан.
Мизгелгә мизгел үрелеп
Тукыла бакый Җиһан...

***

Ник язылa озын шигырь,
Яратам бит кыскасын?
Берчак оныгым күрсен дип,
Күңелем карточкасын.

## Моцарт йортында. Венада

Моцарт йортында. Венада.
Үрелә көй-такыя...
Көмеш кылларга кушылып
Тибрәнә сыман дөнья.

Әле — күктә, әле — җирдә...
...көй канатлы —
көй — оча.
Өермә булып күтәрә,
Агымсу булып коча!

Көй тутыра бүлмәләрне,
Моцарт уйный...
Моң — тере!
Диварларда катлам-катлам
Мәңгелек көй хәтере.

Яңгырый көй ике гасыр —
Үрелгән алтын нурдан.
Шул көйләргә гашыйк икән
Син миңа якын туган...

...Кырык бишнең матур язы.
Вена. Фотода эти.
...Кинәт сызып үтте җанны
Ут булып — ре-ми-фа-си...

...Ике мең ун.
Апрель ае....
Күңелнең нечкә мәле.
...Минем жанны синең жанга
Ялгый Моцарт көйләре...

***

Канатларны — каурый-каләм иттем,
Җан җебеннән үрдем күперләр,
Йөрәк маен салдым ут-савытка,
Татар, диеп, әле бер дөрләр.

Татар диеп сөрән салдым миргә,
Тар-тар булып кайтты кайтаваз,
Татар үзе
үзен югалтканда
Татар иле кире кайталмас!

Сибелмәгән дөнья буйлап татар,
Аң-зиһенең, татар, сибелгән.
Башка берәү бишкә бүлми сине,
Син җаныңда, татар, бүленгән.

Күпме адәм татар диеп яши,
Рәшә икәнен дә белмичә.
Миллион татар рәшә була бирер,
Җаны белән: «Без — ил», — димичә.

***

Көмеш тәңкә булып йөзә өстә күбек,
Тәңкәләнми уйнап тирән диңгез төбе...

Минем күңел диңгез, уйлар дулкын кебек,
Бакый ягы тыныч, фани ягы — күбек....

***

Кайда татар? Кайда тел? дип,
Сорый татар баласы.
Моңлы татар шигырьләре —
Татар җаны оясы.

Юллап-юллап төрә татар
Җаннан саркыган сүзен,
Моңлы-сагышлы шигырьләр
Саклый татарның үзен.

Шигъри юл булып сызылган
Татарның яше-каны.
Энә очларында түгел.
Шигырь эчендә җаны.

Һәр аваздан саркыла моң,
Һәр авазы — бер гомер...
Халык үзе — шагыйрь дә ул,
Халык ул үзе — шигырь.

## Яз белән кыш бил алыша

Яз белән кыш бил алыша,
Март дәшә буран аша.
Яз сулышыннан уянып
Бөреләр пышылдаша.

Чаңгы эзе челтәр-челтәр,
Югалыр тиздән эзләр,

**Шунда калкыр умырзая —**
**Бәрхет керфекле күзләр.**

**Яз башында, кыш чигендә**
**Кар бер эри, бер ява,**
**Боз сөңге булып ката да,**
**Тамчылар булып тама.**

**Туй күлмәген кигән кызлар —**
**Актан-ак каен-каен...**
**Яз белән кыш әйлән-бәйлән**
**Уйный шулай ел саен.**

## Симетбашта кичке сабантуй!

**Сәлам сезгә, сәлам, якын дуслар,**
**Сәлам сезгә, сәлам кардәшләр!**
**Татар булган йөзләп төбәкләрдән**
**Сезгә бүләк — шигъри тәлгәшләр!**

**Кайттык әле, кайттык Симетбашка,**
**Татар җаны исән төбәккә,**
**Татар моңын, татар телен саклый,**
**Татар диеп типкән йөрәкләр.**

**Их, күңелнең канат кагулары,**
**Җыр-биюгә ничек чыдасын!**
**Сабантуй бит меңәр еллар үтеп**
**Безгә җиткән татар йоласы.**

**Без җыелдык төрле төбәкләрдән,**
**Күңелләрне били бер үк уй,**
**Ямьле булсын, гөрләп-күкрәп торсын**
**Симетбашта кичке сабантуй!**

**Ир-егетләр бил алыша — көрәш!**
**Сабантуйның җаны, безгә!**
**Көрәш-алыш — татар үзәгендә,**
**Ә татар ул бирмәс үзәген!**

**Ат чабышы — таҗы сабантуйның,**
**Оча атлар, гүли түгәрәк,**
**Әйтерсең лә утлы божра булып,**
**Ат-өермә килә тәгәрәп.**

**Симетбашта сабантуе гөрли!**
**Үз асылы аның, үз яме!**
**Яше-карты бер фикердә — рәхәт!**
**Бу бәйрәмнең бар бит үз тәме!**

**Без җыелдык төрле төбәкләрдән,**
**Бер үк теләк җанда, бер үк уй,**
**Елдан-елга гөрләп-күкрәп үтсен**
**Симетбашта кичке сабантуй!**



Рахман Шәфигуллин

# УТЛЫ ДУЛКЫН

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

*Остазым Калью Рудольфович Германның якты истәлегенә багышлыйм.*

Эстонияне Союзга кушу көйле генә яшәп яткан Киротарлар гаиләсенә дә көтелмәгән үзгәрешләр алып килде. Хаапсалу шәһәрчегендәге тимер юл станциясе башлыгы булып эшләүче Калью Киротарны да Совет Эстониясен ныгытырга сәләтле җитәкчеләр исемлегенә керттеләр. Әлбәттә, әлеге карарга килер алдыннан аларны жиде иләк аша уздырып, жиде бабасына кадәр тикшерделәр. Кемгәдер ачу тоткан, яки, кулыннан эш килмәсә дә, властька омтылган карьеристларны исәпкә алмаганда, эстоннар яңа хакимияткә буйсынырга ашыкмады, чөнки аларның рухы, яшәү рәвеше бөтенләй башкача иде шул. Совет гаскәрләренә дә, алар алып килгән властька да «оккупант» дигән ярлык тактылар. Калью сәясәттән ерак торса да, анык карарга килергә ашыкмады, вакытны сузарга тырышты. Ләкин тиздән аны Таллинга чакырып, соңгы тапкыр сөйләшергә булдылар.

Яна гына оешкан ВКП(б)ның үзәк комитетында башлыча руслар һәм элек-электән Россиядә, Грузиядә эшләгән финнар, эстоннар, кареллар да бар иде. Араларында Сталин өчен теләсә нинди адымга әзер булган «кызыл» житәкчеләр дә юк түгел. Мәскәүдә вакытның киеренкелеген аңлап булса кирәк, Балтыйк буе илләрендә тиз арада яңа җәмгыять оештыру бурычы куелды. Максат бер — көчле рухлы халыклардан тыңлаучан, күндәм көтү туплау. 1918 елда мөстәкыйльлек яулаган эстон халкы ирекнең никадәр кадерле икәнен аңлап өлгерде. Кыска гына вакыт эчендә үзенең милли рухын саклап кына калмады, көнбатыш илләре белән тыгыз элемтәгә кереп, яңа завод-фабрикалар ачуга иреште, балык тоту һәм аны эшкәртеп сату буенча нык алга китте. Кохтла-Ярве шахталары сланец табу күләмен арттырды. Килгән акча халыкның тормыш шартларын яхшыртуга тотылды. Милли зыялылар саны артты, талантлы белгечләр, житәкчеләр үсеп чыкты. Калью Киротар да шундыйларның берсе иде. Балык тотып сату белән

Рахман ШӘФИГУЛЛИН (1949) – *журналист, язучы; «Йозак» исемле китап авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чаллыда яши.*

шөгыльләнгән гаиләдә туып-үсте ул. Хаапсалуда гимназияне унышлы тәмамлагач, Тарту университетының юл төзелеше бүлегенә укырга керде. Әтисе Хельмут улын кеше итү өчен акчасын кызганмады. «Балык була да, бетә дә ул. Ә сина киләчәк турында уйларга кирәк. Белемле булу — зур бәхет», — диде.

Кальюо, ничектер, тимер юлны үз итте. Укыган чакта ул Финляндия, Швециягә барып, андагы тәҗрибә белән танышты. Укуын тәгәлләгәч, аны Хаапсалудагы станциягә баш инженер итеп билгеләделәр. Таллин белән ике арадагы тимер юлны заманча үзгәртеп коруга үзеннән зур өлеш кертте. Пассажирлар һәм йөк ташу бермә-бер артты. Ике йөз километрга сузылган тимер юл халыкның горурлыгына әверелде. Хаапсалуның егет-кызлары, жае чыккан саен Таллинга барып, күнел ачарга омтылды. Кальюны сонрак станция башлыгы итеп билгеләделәр. Власть алышынса да, хезмәт вазифалары шул килеш калды. Тик диверсия-мазар булмасын дип, поездларны озату өчен махсус хәрби группа билгеләнде. Хәзер менә Таллинга чакыралар. Хатыны табибә Хильди белән кызы Лайне аның белән барырга бик теләсәләр дә, Кальюо: «Күпмегә барасы, кайчан кайтасы билгеле түгел. Мәшәкатьләнмәгез, барысы да яхшы булыр», — диде.

Власть алышынгач Кальюның Таллинда булганы юк иде әле. Шәһәр үз урынында, вәләкин кызыл комачларга төренгән, Сталин портретлары белән «бизәлгән» Таллин иде ул бүген. Бөтен жирдә «Яшәсен Совет Эстониясе!», «Яшәсен эшчеләр белән крестьяннарның какшамас дуслыгы!», «Союздаш республикалар кочагында чәчәк атсын Эстония!» кебек лозунглар. Аларның урыс телендә булуына Кальюо башта сәер караса, соңыннан ана барыбер була башлады. «Язганнар икән, димәк, шулай кирәк», дип үз-үзен юатты. Алла аны язмышын хәл итәрлек очрашу көтә бит. Ул ни белән бетәр, Ходаем?

Озын төз гәүдәле, соры күзле, чәчләрен артка тараган утыз жиде яшьлек Кальюо Киротарны үзәк комитетның оештыру бүлеге мөдире кабул итте. Үзе эстон милләтеннән булса да, урыс сүзләрен еш куллана, тумышы белән Псков өлкәсеннән икән. Яше илле тирәсендә. Мәскәүдән килгән, совет властенең ышанычын аклагач, төрле житәкче урыннарда эшләгән, гәүдәсе бераз бөкрәйгән, күзләрендә салкынлык сизелә.

— Хэнрик Альбертович Вергалис, — дип таныштырды ул үзе белән. — Мин, эстон кешесе буларак, сезне аңлыйм...

Бераздан трубкасын көйрәтеп, авыз-борынынннан тәмле төтен исе чыгара-чыгара сүзен дәвам итте:

— Яңа властьны яратсаң-яратмасаң да, буйсынырга туры килер. Тимер юлы бүген Эстониянең генә түгел, СССРның язмышын хәл итә. Ул төзек булса, илебез имин булыр. Менә без уйладык та, сезне Ленинград Хәрби академиясенә укырга жибәрергә булдык.

Хенрик Альбертович сират күперләрен исән-сау кичсә дә, 1937 елгы ыгы-зыгы вакытында аңа да НКВД зинданнарында газап чигәргә туры килде. Ул аннан чәчләрен агартып чыкты. Өстәвенә, дулкынланып алса, сул як чигәсе тартыша. Моны күрсәтмәс өчен әңгәмәдәше янына якын барырга тырышмый. Ә бүген, кагыйдәсен бозып, Кальюо каршысына ук килеп басты. Башың юләр булмаса, аңлыйсың: яңа властьның куллары каты, үгетләргә яратмый. Тәкъдим бер була. Икенчесендә... Анысын Алла үзе генә белә! Бүлек мөдиренең милләттәшенә сүзсез генә шуларны житкерәсе килгән иде. Ул ялгышмады, Кальюо биредә тормышның гади булмаганлыгына бераз булса да төшенде.

Хенрик Альбертович, зур тәрәзә янына килеп, «Иске Таллин башнялары — «Тоомас Карт» сурәтен күзләде. Тәмәкесен тарта-тарта: «Әлбәттә, партиягә кабул итәрбез, хәрби офицер званиесе бирелер. Гомумән, безнең киләчәк

СССР һәм аның күпмилләтле халкы белән бәйләнәчәк. Сез халыкара хәлләрне аңлап, тәкъдимне кабул итәрсез дип уйлыйм. Безгә яңача фикер йөртүче җитәкчеләр кирәк...»

Калью мондый каты сөйләшүдән коелып ук төште, ләкин үзен кулга алып ризалык бирде. Шулай итеп, ул, халык әйткәнчә, «оккупантлар»га хезмәт итәргә дигән карарга килде.

— Дәүләт машинасына ялагайлар, сатлык җаннар гына түгел, акыллы эстон зыялылары да кирәк, — дип сүзен тәмамлады чал чәчле бүлек мөдире.

Ул саубуллашып ишеккә җиткәндә, Хенрик Альбертовичның «Элаку Совет Ээсти», ягъни «Яшәсен Совет Эстониясе!» сүзенә: «Элаку вапа Ээсти», «Яшәсен ирекле Эстония!» дип әйтеп харап була язды. Бүлек мөдире кабат Калью янына ук килеп, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Әйе, без барыбыз да ирекне яратабыз, ләкин моны теләсә кайда әйтергә кирәк түгел. НКВД машинасы астында калуың бар. Сак бул, энем. Безнең исән-имин булуыбыз милләткә, Эстониягә кирәк, — диде. — Тагын кабатлап әйтәм: күп сөйләшмә, уйлап җавап бир. Фикереңне хәтта иптәшеңә дә әйтмә!

Ишек төбендә аны хәрби киемдәге офицер каршылады. Ул төрле ведомстволарга алып кереп, рәсми документларга имза куйдыртты. Тагын моңарчы белмәгән җитәкчеләр белән аралашырга, аларның сорауларына җавап бирергә туры килде. Эшләрен бетереп урамга чыкканда, вакыт кичкә авышкан иде. Тормышның ачысын-төчесен күрмәгән ир СССР дигән империянең идеологиясен, яшәү рәвешен бөтенләй белми иде әле.

«Бик сак булырга кирәк икән», дигән фикер аның башына, йөрәгенә сеңеп калды. «Үзең, гаиләң, туганнарың исән булсын, дисәң, яңа власть белән яшәргә туры килер», дип уйлады ул.

Калью Таллинның үзәгендә урнашкан «Выру» ресторанына керде, җиңелчә закускалар алды, бәләкәй чынаяклардан кофе эчте. Кыска гына вакыт эчендә булып узган вакыйгалардан әле айнып җитмәгән тимер юлчыга тирә-ягындагы кешеләрнең бары да аңа карый, ни әйтерсең дип, ялгышканыңны сагалый иде кебек. «Вана Таллин» ликеры да җиңеллек китермәде. Кибетләргә кереп, гаиләсенә күчтәнәчләр алды да, Хаапсалуга баручы поездга утырды. Вагон эче халык белән шыгрым тулы. Элек эстоннар, сыра эчеп, юктан күңел табып, җырлап кайтсалар, хәзер моның эзе дә юк. Олысы-кечесе илләренең мөстәкыйльлеген югалтуны авыр кичерә. Өстәвенә, озын телләр төрле гайбәт тарата. Имеш, эстоннарны Себергә күчереп, биремә урысларны китерәчәкләр, ди. Эстоннар да фәкать урысча гына сөйләшәчәк имеш. Ике ай элек кенә Эстониягә совет гаскәрләре бәреп керде. Аннан Югары Советка сайланган «халык вәкилләре» бертавыштан СССРга кушылу тәкъдиме белән чыкты. Президент Константин Пятс Башкириягә сөргенгә озатылды. Каршылык күрсәтүчеләр әле дә булса кулга алына тора. Алда ниләр көткәнен фәкать Мәскәү Кремле хуҗалары гына белә, күрәсең. Шулай итеп, дәүләтнең бәләкәй генә гәүдәле Иосиф Виссарионович Сталин әмере белән хәрәкәткә китерелгән машинасы яшелле-зәңгәр сулы Балтыйк диңгезе буйларында яшәүче Киротарлар гаиләсен үзенә җәлеп итте. Аларның яшәешен дәвам иттерү яки туктату хәзер Калью кулында иде. Яңа сәясәткә салкын акыл белән карап эш иткәндә генә, зур сынауны хәвеф-хәтәрсез узарга мөмкин.

Поезд алга бара. Совет солдатлары станцияләрдә төшеп эчемлек һәм ашамлык мәсьәләсен хәл итәргә тырыша. Әзрәк кәеф-сафа коргач җирле халык белән аралашу башлана. Ләкин эстоннар каты тора. Җәелеп китүче юк. Менә җирән мыеклы ефрейтор гаҗәпләнеп тавышын күтәргән иде,

озын чәчен бик матур итеп үреп, ике якка җибәргән күзлекле хатын, ярым эстонча, ярым урысча:

— Сез гаҗәпләнмәгез, зинһар, безнең бит әле совет солдатларын беренче генә күрү. Вакыт узу белән өйрәнербез, анлашырбыз, сөйләшербез, дип җирән мыекны тынычландырды. Моны күзәтеп барган Кальюо, эченнән генә булса да, бу ханымга рәхмәтен җиткерде. Акыл, мәдәният, көчле рух кына явызлыкны җиңәчәк дигән фикерен куәтләде.

Хәрби Академия тыңлаучысы Кальюо Киротарның барлык туганнары салкын каршылады. Ул Таллинда булган хәлләрнен тиешлесен генә сөйләп, туганнарын тынычландырды:

— Мин бит бары тимер юлчы гына, эшем дә шуның белән бәйле булачак. Партиягә керүем, Ленинградка укырга баруым безнең өчен файдалы да булыр әле, — диде ул.

Алтмышның теге ягына чыккан әтисе, озак уйлаганнан соң, үзенен сүзен әйтте:

— Анысы шулай да булсын ди. Әнә староста Карлны тыңла: Сталин белән Гитлер, илләрне бүлгәләп, сугышмаска сүз бирешкән. Немецлар барыбер тукталмас, Россиягә бәреп керер. Ул чакта безнең белән ни булыр? Коммунист Кальюо Киротарның туганнары дип, атып үтермәсләрме? Хильдиның әтисе Леонард, зур бокалдан сыра эчүеннән тукпап:

— Карл, бер бүгенге көн турында гына уйламыйк әле. Кальюо бит башсыз бала түгел. Ана без ярдәм итик. Яңа властька каршы килү ахмаклык ул. Немецлар Россиягә каршы сугыш башласа да, җиңә алмаслар. Тарихта Россияне оттырганы юк әле, — дия-дия киеренкелекне йомшартты.

...1940 елның август аенда Кальюоны, барлык туганнары да станциягә төшеп, Ленинградка озатып җибәрде. Аның Россиядә беренче булуы. Нарва елгасын кичүгә — Кингиссеп шәһәрчеге, аннан Ленинград өлкәсе башлана. Бирелдәге йортлар да, халык та эстоннардан аерылып тора икән. Революция башкаласы Ленинградның чиста, төзек урамнарын, тарихи биналарын күреп, телсез калды ул. Кибетләрендә дә ни генә юк!

Тимер юл академиясе Смольныйдан ерак түгел бер тарихи бинада урнашкан булып чыкты. Укырга килүчеләрнен күпчелеге 30-40 яшьлек ир-атлар. Араларында латыш, литва, украин телләрендә сөйләшүчеләр дә бар. Ләкин группалар бик нык уйланып төзелгән иде. СССРның төрле якларыннан килгән урыслар арасында Кальюо берләнбер титулсыз милләт вәкиле булып чыкты. Болар арасына тиз арада кереп булмас дип, урыс телен камилләштерү, җырларын, биюләрен өйрәнүне максат итеп куйды ул. Укуларның программасы тимер юлга кагылышлы дәресләрдән кала, СССР, ВКП(б) тарихы, икътисад, немец теле һәм физик әзерлек, корал белән эш итү кебек дисциплиналарга да зур урын бирелгән иде. Болай да сабыр холыклы, оешкан кеше буларак, эстон офицеры беренче яртыеллыкта иң яхшы укучылар сафына басты. Ялга кайту беркемгә дә рөхсәт ителмәде. Яңа, 1941 елны каршылыйсы төндә, аларны полигонга учениегә алып чыктылар...

Хаапсалуга да яңа власть үзгәрешләр кертте. Күп кенә оешмаларга җитәкчеләр итеп урыс, украин, белоруслар китертелде. Эстоннарга янача яшәү өчен урыс телен өйрәнү хаҗәте килеп басты. Бу Кальюо Киротарның өлкән кызы Лайнены да читләтеп узмады. 1 сентябрьгә аларны яңа уку елы белән котларга килгән роно мөдире Иосиф Звездинский моңа аеруча басым ясап әйтте: «Киреләнергә урын юк. Әгәр югары уку йортларына керәсегез килсә, рус телен өйрәнү зарур. Телләрне белгән кеше югалмас».

Лайне, чыгарылыш сыйныф укучысы буларак, моңарчы ишетмәгән-белмәгән урыс язучылары әсәрләрен өйрәнергә керешге. Александр

Пушкин, Михаил Лермонтов, Сергей Есенин шигырьләрен яттан өйрәнде. Бәлки әле әтисе янына Ленинградка укырга да китәр. Әнисе әйткәнчә, аңа якынрак булыр.

Лайне ял көннәрендә бабасы Рудольф белән диңгезгә балыкка йөрергә яратты. Бәләкәй генә моторлы баркаста алар Хаапсалудан бик еракка китә иделәр. Бабасы диңгезгә ятьмә сала да, әкрен генә көймәне кайту юлына куя. Күк зәп-зәңгәр. Аның матурлыгы Лайненың күзләрендә чагыла кебек. Диңгез суы ул, зәп-зәңгәр булмаса да, чиста, яшькелт төсмерле. Дулкыннар әкрен генә, бер-берсен куа-куа, әллә кая офыкка, еракларга омтыла. Уналты яшен тутырган зифа гәүдәле, шалкан кебек сары тәнле, йомры сыйраклы Лайне үзенчә хыяллана. Инде аның үбешеп карыйсы да, берәр егет белән очрашасы да килә. Тик нигәдер егетләр аны читләтеп узалар. Үпкәләгән вакытта каты итеп кычкырасы килә:

— Кайда йөрисең син, минем ярым, кайчан очрашырбыз икән, матурым?!

Ятьмәнең чыгуын көтеп очкан акчарлаклар да бер үк тавыш чыгара: чырык-черек, черек-чырык... Бу ни дигәне була? Лайне аңламый шул әле кошлар телен...

Матур җәйләр узды, салкын көзләр килде. Хәзер диңгез хәрби караблар белән тулды. Саарема утравы белән ике арада йөри торган паром да туктады. Пристань тимерчыбыклар белән әйләндереп алынган режимлы объектка әйләнде. Хәзер балыкчыларга да диңгезгә чыгу чикләнде.

***

Хильди — Хаапсалудан ерак кына түгел авылдан, Калью белән алар университетта укыганда таныштылар. Ике арадагы мөнәсәбәт шуннан узмады. Дүртенче курсны тәмамлагач, студентлар кайсы кая таралышып бетте. Июль башында үткәрелә торган Яаан көнендә бераз кәефләнеп алган яшьләрнең зур учак өстеннән сикерә торган гадәтләре бар иде. Кем биегрәк сикерә, шуңа хөрмәт. Калью да, әлбәттә, беренче булырга омтылды. Ялкыннары күтәрелә барган учак өстеннән ул бөркет сыман очып үтте. Сикерүен сикерде, тик тизлегән киметә алмый тамашачылар арасына кереп китте. Һәм... Хильди алдында тезләнгән килеш туктап калды. Алар бүтән аерылмадылар. Туган җирләренә берсе табиб булып, берсе юл станциясенә эшкә кайтты. Өйләнештеләр. Башта Лайне туды, аннан — Марта. Сөеп сөелер чакта тормышшлар үзгәрде, яна власть Кальюны укырга җибәрде. Ленинград белән Хаапсалу арасында йөри торган хатлар яшь хатынның мәхәббәткә сусавын баса алмады. Ни булса, шул булыр, дип, Яңа ел үткәч, Ленинградка китте. Биредә ул иренен укый торган җирен эзләп тапты, тик курсантлар учениегә киткән булып чыкты.

Хильдины кунакханәгә урнаштырдылар. Курс башлыгы латыш Круминьш Кальюга бер тәүлек ял бирү мәсьәләсен дә хәл итте. Учение дигәннәре, сугыш була калса, Ладога күле аша боз өстеннән тар колеялы тимер юлын салып, олы җирдән Ленинградка кирәк-ярак ташу мөмкинлеген өйрәнү генә икән.

***

1941 елның язы житте, аннан — җәе. Кулына өлгергәнлек аттестаты алган Лайне әнисе белән Ленинградка укырга керергә килде. Институтка документлар тапшыра да алмады, сугыш башланды. Немец фашистлары яшен тизлеге белән Ленинградка, Мәскәүгә ыргылды. Совет офицеры, коммунист гаиләсенә Эстониягә кайту юлы ябылды. Хөкүмәт яңа властька ярдәм иткән кешеләрнең, аларның гаиләләрен ерак тылга күчерү хәстәрен

күрә башлады. Тимер юл академиясе тыңлаучылары да, укуларын өзеп, кайсы кая хәрби хезмәткә билгеләнде. Киротарга хәрби юнәлештә эшләүче дәүләт күләмендәге серле институтны Казанга алып бару бурычы йөкләнде. Таләпләр катгый булса да, ул хатыны белән кызын эвакуацияләнүче институт хезмәткәрләре арасына урнаштыра алды. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән Казан, Татар иле дистәләгән, йөзәрләгән мең яһүд, эстон, латыш, белорус халыкларына сыену урыны бирде. Аларның саны 230 меңнән артып китте. Араларында Хильди белән Лайне да бар иде.

Ленинградка китәр алдыннан Хильди гаҗәеп төш күрде. Имештер, дингез өстен утлы дулкыннар каплаган, балыкчылар аны сүндерергә тели, ләкин көчләр тигез түгел. Ялкын ярдан чыгып, йортларны, агачларны чолгап ала. Алар Лайне белән чаба-чаба ниндидер таныш булмаган елга буена килеп җитәләр, утлы дулкын биредә дә тынгы бирми. Лайне чиста сулы инешне йөзеп, ниндидер матур утрауга чыгып кала, ә Хильди — ялкын эчендә... Моны нигә дип юрарга да белмәде ул. Зәңгәр, матур Балтыйк дингезендә — утлы дулкын. Аның өйләргә күчүе дә аңлашыла. Ә менә фронттан җәһәннәм тишегендә урнашкан Татар иленә аның ни кагылышы бар? Димәк, яңа урында да Хильдины куркыныч көтеп тора түгелме...

Серле институт җиһазлары һәм хезмәткәрләре белән Казанга исән-имин килеп житте. Биредә яңа задание — Калью Киротарга хәрби эшелонны Татарстаннан Волхов фронтына алып бару бурычы йөкләнде. Вакыт бик аз булганлыктан, хатыны белән кызына акча, азык-төлек, тиешле документлар биреп, яу кырына китеп барды ул. Республика эвакуация пунктында эстоннарга Кызыл Йолдыз районының Кыерлы авылы медпунктына эшкә юллама бирделәр.

***

...Кыерлы авылы Чулман елгасыннан әлләни ерак түгел. Биегрәк калкулыкка менгәч, очсыз-кырыйсыз мәйданга җәелгән күлләр, болыннарны күрергә мөмкин. Төбе тавы кырыеннан исә берөзлексез саллар ага, баржалар, пароходлар каядыр ашыга. Тыныч көннәрдә аларның хәтта моңсу гудок тавышлары ишетелә. Язгы чәчү эшләре тәмамлангач, Кыерлы халкы кышкылыкка утын әзерләргә керешә. Хәллерәкләр ат белән кипкән агач ташыса, берничә гаилә «уфалла» арбасы белән корыган куагын алып кайта. Фермада эшләүчеләргә аеруча почет, аларга колхоз идарәсе карары белән күп җылы бирә торган өрәңгесе, имәне, каены кайтарыла. Июнь урталарында, гадәттәгечә, авылларда сабантуйлары башлана. Бәйрәм Кыерлыдан тотына, аннан — Тимерлектә, Ямаш, Күкидә, Байтирәктә. Халык бер-беренә барып, бер атна ял итә. Сабантуйлары татарның күңел ачу урыны гына түгел, ул аның рухи көче, киләчәккә нигез салу юласы да бит. Егетләр бил алыша, атларда узыша, әлбәттә, яшь-кыркын бер-берсе белән таныша, ә инде кичен уеннар гөрли.

Егерменче еллардагы ачлыктан соң татарлар кабат аякка басып килә инде. Яңа гаиләләр төзелә, дистәләгән, меңәрләгән балалар туып, егет-кыз булып өлгерде. Мәктәпләрдә укучылар саны артты. Азмы-күпме булса да, тормышлар яхшырды. Халыкның миенә Сталин җитәкчелегендә СССРның иң көчле держава булуы сеңдерелде: киләчәктә электр белән эшләүче тракторлар җир сөрер, комбайннар иген суктырыр, сугыштан да куркасы юк. Чөнки бездән көчле ил юк!

Уналты яшен тутырган Газизнең дә болытларга басып йөри торган чагы. Тагын бер елдан мәктәпне тәмамлый, Аллаһы боерса, югары уку йортына керү бәхете дә ачыла. Башка егетләр кебек үк, бүген Газиз дә Кыерлы сабантуена әзерләнә. Хәер, бу эшләр инде май азагында ук гөрли башлады.

Яшь-кыркын «Ага сулар», «Күперле», тагын әллә нинди биюләр башкара. Аларның аягында, гадәттәгечә, чабата, кайберләрендә галош, күнитек кунычыннан эшләнгән сандаллар. Тормышның ачысын-төчесен күргән карт-коры да уенга төшә. Баш очларында кәләпүш, сакал-мыек матур итеп кырылган, киндердән тегелгән ап-ак күлмәктән, буйлы ыштаннан булырлар. Сүзләре дөнья хәлләре белән башланып китә дә, үзләренең яшьлегенә барып тоташа. Әле кайчан гына мәйдан тоткан, кызлар кочкан егетләрнең гомере узган да киткән. Сабантуйлары, аулак өй, кичке уеннардагы җырлар-йолалар яшәтә татарларны! Казанны яулаучылар, халыкның җирен, йортларын тартып алсалар да, динен-рухын тартып ала алмаганнар. Укымышлы, акыллы милләткә генә хас сыйфатлар бу!

Газизнең яратып йөргән кызы юк әле. Уен бетүгә, ул өйләре каршында үскән йөзьяшәр өрәңге янына атлый. Гади генә агач түгел ул. Аны моннан күп еллар элек бабасының бабасы Әбелгази утырткан. Аның ботаклары да, яфраклары да үзенчә, өстән аска буын-буын булып урнашкан. Җәйге эссе көннәрдә хәл җыярга менә дигән урын инде. Газиз «нәсел агачын» башка яктан да файдалана. Юан, биек өрәңге — күзәтү урыны да. Ул анда менә дә, ботаклар арасында әзерләнгән урынга утырып, Иделне, андагы матурлыкны күзли, киләчәк турында хыяллана. Шәһәр халкы бик бәхетледер инде. Әнә, Чистай ничек матур күренә. Җүкәтаудагы элеваторыннан алып, пристаньга кадәр, аннан тагын бер чакрым урамнар «ильич» лампаларына күмелгән. Ә Кыерлыда һаман керосин лампасы. Шәһәрдәге утларның күп булуы яшьләргә очрашу өчен комачаулык та ясый торгандыр. Бар җирдә якты булгач, ничек очрашасың, кочаклашасың?! Ә бездә, Кыерлыда, һәр почмак караңгы, ни эшлисең килсә, эшлә, хөррият. «Эх, тизрәк Казанга укырга китәсе иде. Анда кызларның билләре дә нечкәрәк, иреннәре дә баллырак диләр». Газизнең әле тагын да татлы уйлар кочагында кошларның җырын тыңларга иде исәбе. Тынлыкны Ризван бозды: «Эй, Аникин-пограничник, төш әле монда! Житәр сиңа Чистай марҗаларының күлмәк салганын карарга. Кил, әйдә, бер секрет сөйлим үзеңә!»

Газизнең бинокле бик иске-искесен, тик Чистайның кешеләрен күрсәтә, әмма беленер-беленмәс кенә. Тик шулай да сер бирми: «Мин, брат, барын да карамыйм. Әнә, теге Карл Маркс урамының ике катлы йортындагы озын, кара чәчле Зөбәйдәне күзлим. Әле үзе яңа гына кайтты, йокларга да ятты, йокласын, комачауламыйк», — дигән була. Ялганлый, әлбәттә. Белми ул Зояны да, Зөбәйдәне дә. Ризванның авызын ябар өчен генә әйтә ул аны.

Жиде классны ничек алай тәмамлап, ат жигеп йөргән дустын тыңламый мөмкин дә түгел. Ул үзенә күрә Кыерлының абруйлы егете. Беренче булып тәмәке тартырга ул өйрәнде, әче балдан соң исереп, тынкыш Идрисне кыйнады. Газиз, дустының серен тыңлау теләге белән, «дозорный пунктыннан» аска төште.

— Йә, нинди сер тагын? Әллә берәрсенең колагын тешләдеңме?

Ризван, абыйсының армиядән алып кайткан фуражкасын утын әрдәнәсе өстенә куйды да, сары бөдрә чәчләрен сыпырып, яңалыгын сөйли башлады:

— Газиз, безне өлкәннәр алдый-алдый кызларга йөрергә өйрәттеләр. Аларның ялганын тыңлый-тыңлый аякларны күпме кычыткANга чактырдык.

Ризван әтисенең самосадын төреп кабызды да, тәмләп суырганнан соң, сүзен дәвам итте:

— Вәт, җүләр, вәт, аңгыра... «Гайшә, мин сиңа приколка, көзге, хушбуй алып бирәм, только минем белән йөр», дип...

Почти армиягә китәсе егет бүген үзенең аңгыра икәнлеген аңлады. Ялган

икән ул. Ярату өчен бүләк тә кирәк түгел. Ул үзеннән — килә торган халәт икән бит.

Газиз дустының хәлен белергә теләгәндәй, тәмәке төпчеген алып, суырып карый да тончыга-тончыга:

— Мондыйга әле минем тамак көйләнмәгән, — дип, тәмәкене җиргә ыргыта.

— Мин бүген уенда Шаһи Саниясенең кулыннан тоттым да: «Беләсеңме, — дидем, — мин сине мәктәптә укыганда ук күзләп йөрдем, тик сиздермәдем, эчтә ялкын дөрләсә дә түздем. Әйтсәм-әйтим, мин сине яратам икән!» — дидем.

Сания каршы да түгел, риза да түгел:

— Син бит Гайшә артыннан чаптың, ни буе, ни йөзе дигәндәй, миңа яратканыңны әйтсәң, ни була? — ди.

— Әле соң түгел, тормыш башлана гына, дим. Кулын тоттым да, Ат чишмәсенә алып киттем, биленнән кочып, үбеп тә алдым. Мин хәзер синең кебек хыялыйларны кызлар белән йөрергә өйрәтә алам инде!

— Эх, Ризван, беләсеңме, Ризван, кызны ярату ул биленнән кочып, үбеп-ярату гына түгел, ул — изге нәрсә. Яраткан кешеңне син хөрмәт тә итәсең, күз карасыдай да саклыйсың! Әнә, Такташ абыең нәрсә ди:

Мәхәббәт ул иске нәрсә,Һәрбер йөрәк аны янарта...

Ризванның исә үз фикере:

— Такташ та синең кебек хыялый булган. Ярату — ул тормыш кору, балалар үстерү...

Таң атарга санаулы сәгатьләр калса да, авыл йокламый. Әле тегендә, әле монда капка ябылганы ишетелә. Атлар пошкыра, сыерлар мөгери. Газиз белән Ризван сөйләшкән арада гына да тана Исмәгыйле, Кырчын Харисы, Мишка Ибрае, тагын әллә кемнәр узып китте. Аларның кайберләре кызлар озаткандыр, йә армиядән кайткан егетләрнең кыйссасын тыңлагандыр инде.

***

Сабантуйлары Кыерлыда да бик матур узды. Тирә-як авыллардан өлкәннәр дә, алар белән кызлар да, егетләр дә килде. Туганнары, танышлары булганнар атларын туарып, мәйданга төште. Болай гына килүчеләр инеш буенда малларын печәнгә кушып, тамаша карарга булдылар. Өстенә сатин, киндер күлмәк, аягына чабата кигән татар Уракчы, Көл, Гарталовка маржалары алып килгән тозлы кыяр, кәбестә, алма белән сыйланды, салкын куас эчте. Батыр калганнарга матур сөлге, күнитек, камыт, самавыр бирелде. Аннары халык өйләренә кунак төшерде. Авыл урамнарына морҗалардан чыккан бәлеш, коймак исе таралды.

Егерменче июньдә бәйрәмнәр тәмамланды. Биш йөз хуҗалыклы Кыерлы Чулман буендагы болынга печәнгә төште. Йөзәрләгән ат арбасына сигезәр-унар кеше утырып, Төбе тавына юл алды.

Болынга җитүгә өлкәннәр куыш, чыбылдык кора, хатын-кызлар исә зур казанда аш пешерә башлады. Ирләр, егетләр ак ыштаннардан су керә. Нинди рәхәтлек! Яшисе, яратасы килә! Төшке аштан бераз хәлләнеп алганнан соң, бригадир Фатыйх, Газиз, Ризван кебек яшьләрне алга бастырып алып, печән чабуга керештеләр: «Аллага тапшырдык, малларга бәрәкәтле азык булсын».

Яшьләргә уйланырга вакыт юк. Чөнки синең арттан тәҗрибәле чалгычылар килә: «чаж» да «чож» итә чалгы тавышы. Тизрәк кыймылдамасаң, аяксыз калуың да бар. Телисеңме, юкмы, фәкать алга!

Йөзләрендә шатлык, күкрәкләрендә дәрт кайнаган йөзәрләгән ир-ат

кошлардай тезелеп, кичкә кадәр печән чаба. Дөрес, яшьләрнең күнелендә печән түгел, кызлар кайгысы әлбәттә. Тизрәк эшне бетерәсе иде дә, кичке уенда берәр сылуны биленнән эләктерәсе иде. Уяу егетләр тик тормый, якындагы Күки, Тимерлек авыл уеннарына сугыла.

Тәвәккәл таш яра, дигәндәй, чит авылның иң ямьсезе дә әнгер-менгердә матур булып күренә икән. Тик тыңлаучан гына булсын, аяк ару өчен генә булса да кочаклатсын икән. Беренче танышуга анысы да бик җиткән.

Көне буе эшләп арган Мирсат бабай яшьләргә карап көнләшә. Тик ни эшләсен, вакыт узган, ыштан тузган дигәндәй, хәзер Газизләр, Ризваннар, Ибраһимнар заманы.

Төбе тавын яңгыратып, Пермь—Казан пароходы гудок бирә. Димәк, тиздән яңа көн туар, хәере белән генә булсын, Ходаем! Иртәнге чәйдән соң, чык кибүгә халык кабат печән чабуга тотына. Таңны кызлар янында каршылаган егетләргә бик авыр, бераз ял итеп алырга иде дә, тик арттан өлкәннәр килә, чалгылары «чаж» да «чож», «чаж» да «чож»...

Халык төшке ашка да утыра алмады, Иделдәге баржалар гудок биреп, тиз-тиз китеп бардылар. Бу ни бу? Озак та үтмәде, авыл советы рәисе Фатыйх күренде. Атының авызыннан күбекләр ага. «Сугыш башланды, тизрәк-тизрәк авылга», — дип хәсрәтле сүзләрен җиткерде. Сугышның ни икәнен белгән Мирсат бабай чалгысын җиргә кадады да : «Безнең рәхәт яши башлау кемгә ошамады икән?» — диеп, елап та җибәрде. Әле ике көн элек җырлап-көлеп печәнгә төшкән халык тавыш-тынсыз гына Кыерлыга, Күкигә, Тимерлеккә юл алды. Яшь егетләр Кадрәккә хәрби комиссариатка китеп барды. Ата-ана балаларны, хатыннар ирләрен озак кул болгап, озатып калды. Әле кичә генә болында танышып, бер тапкыр да үбешергә өлгермәгән кызларга ничек авыр булганын аңласагыз иде. Каяндыр әчтән, йөрәктән аерылышу җыры таралды:

Идел бит ул, киң бит ул шул,
Караңгы төн, томанлы көн,
Без аерылышкан көн бит ул...

Илгә афәт, кайгы-хәсрәт килде. Ул күкрәп үскән нарат урманнарындагы асыл-асыл агачларны төбе-тамыры белән йолкып алгандай булды.

Кыерлының һәр йортыннан берәр-икешәр әзмәвердәй егет сугышка алынды. Бер селтәнүдә иминлекнең, рәхәтлекнең эзе дә калмады. Газиз, Ризван, Ибраһим, Исмәгыйль кебек үсмерләр ирләр булып, җитдиләнеп уянды. Авыл карт-коры һәм яратканнары куенына кереп, наз тәме татырга да өлгермәгән яшь хатыннар кулына калды.

Алдан төзелгән килешү буенча, СССРга ике-өч елга тыныч тормыш вәгъдә иткән Адольф Гитлер бу алдауны үзенчә Сталинның сизгерлеген киметү өчен эшләде. 1937 елда башланган репрессия илнең талантлы белгечләрен, зыялыларын юкка чыгарды. Армия, завод-фабрикалар оештыру сәләтенә ия булган җитәкчеләрен югалтты. Хәзер вакытны сузу һәм табигатьнең кырыслыгын файдалану нәтиҗәсендә генә илне фашистларга каршы торырлык дәрәҗәгә җиткерү мөмкин иде. Берлин халыкның фанатларча партияне, туган илен яратуын, СССРның очсыз-кырыйсыз мәйданнарын һәм халык ресурсларының бу кадәр үк зур булуын исәпкә алып җиткермәгән булып чыкты. Кыска гына вакыт эчендә совет армиясе резервтан 15 миллионнан артык кешене мылтык астына куйды. Фронтка китүчеләр урынына үсмерләр, хатын-кызлар, хезмәт ветераннары килде. Тылда эшләүчеләрнең саны бик нык кимесә дә, җитештерү күләме сакланып кына калмады, ә тагын да артты. Халык түзде. Матур киләчәк бәрабәренә ач-ялангач килеш көнне төнгә

ялгап эшләде. Ил җитәкчелеге бу фидакарьлек өчен яхшылык белән җавап бирергә тиеш иде дә, ләкин ул моны эшләмәде. Утыз җиденче елларда үзенең явызлыгы белән Кремльнең абруен казанган Татарстан АССРның эчке эшләр министры Алемасов бер гаепсезгә дистәләгән халыкны төрмәләргә япты, лагерьларга озатты, атып үтерүгә хөкем итте. Мәскәү аның бу «хезмәтләрен» истә тотып, ВКП(б)ның Татарстан Өлкә комитеты беренче секретаре итеп билгеләде. Сугыш башлангач та халыкны кимсетү, юкка-барга ээзәрлекләү, бер уч арыш өчен дә хөкемгә тарту дәвам итте. Моны бәләкәй генә Кыерлы халкы да үз җилкәсендә татыды. Фин сугышында катнашып пленга эләккән Зөлмөхәммәтнең ни гаебе булгандыр, аяк бармакларын өшетеп гарип калган егерме өч яшьлек егеткә, ичмасам, инвалидлык кына бирсеннәр иде дә, юк! Күргән-белгәннәрен авыл халкына сөйләгәннән соң күп тә үтмәде, НКВДның Кызыл Йолдыз районы уполномоченные, Алемасовның иярчене — бәләкәй буйлы, пеләш башлы Змеев аны үзенә чакырды.

— Синең өстән шикаять бар. Совет армиясен яманлыйсың икән. Кыш көне сугышчылар салкында катып үлде дигәнсең... Финнарның киемнәре яхшы... Кораллары да шәп дигәнсең... Бу дөресме?

— Әйе, дөрес...

— Финнар яхшы яшиләр икән. Кешегә кешечә карыйлар дисеңме?— Әйе, шулай.

— Димәк, безнең строй начар булып чыга түгелме? Син гарип хәшәрәт бөек Сталинга, иптәш Алемасовка яла ягуыңны таныйсыңмы?

— Юк, танымыйм. Мин иптәш Сталин өчен сугыштым. Кирәк булса, хәзер дә гомеремне бирәм.

— Монысы дөрес. Ләкин яшисең килсә, уйлап сөйлә Зуль... Мухаммед...

Змеев нидер әйтеп сүгенде дә, идәнгә төкереп:

— Откуда берут такие имена? Назвали бы хотя бы колом или бараном...— дип акырды.

— Зөлмөхәммәт алдагы сорау алуларда совет армиясен мактады гына. Сталин өчен гомерен бирергә әзер булуын әйтте. Змеев татар егетен барыбер сындыра алмады. Ел азагында зуррак эшкә күчереләчәгенә өмет итеп, Змеев Зөлмөхәммәтне Кыерлыга кайтарып җибәрде. Зөлмөхәммәт бүтән финнарның яхшылыгы, батырлыгы хакында бер тапкыр да сөйләмәде. Менә кабат сугыш. Монысы инде финнар ише генә түгел, корбаннар, һичшиксез, күп булачак. Фин сугышы ветераны Зөлмөхәммәт Змеев ишеләрдән көн беткәнен аңлап, кабат сугышка китү ягын карады. Пехотага алмаячакларын чамалап, тракторчыга укырга булды. Ризван, Ибраһим, Ильяс, тагын бик күп үсмерләр дә шундый ук курсларга язылды.

Фронтка китәчәк егетләргә исә үз урынына алмаш әзерләү максаты куелды. Кыерлы авылы басуларында урып-җыюда катнашучы комбайнга, тракторларга хатын-кызлар утырды. Техника ватыла калса, МТС каршында берничә ремонт бригадасы оешты. Барлык мәйданнарның күбесе, гадәттәгечә, кулдан урылды. Көннең нормасы элек 25 сутый булса, хәзер ул 30 гектарга җитте. Мәһабәт гәүдәле, районның алдынгы тракторчысы Дәүләтханның да фашистларны тизрәк җиңәсе килде. Инде ничәнче тапкыр броньнан ваз кичеп танкка утырасы итте. МТС директоры Сабирҗанов аны кат-кат үгетләде: «Синең үләсең киләме? Дошманны бит тырыш хезмәт белән дә җиңеп була...» Егет барыбер үзенекен тукыгач, ул да соңыннан ризалык бирде. Тик үз урынына ике алмаш әзерлә, диде. Икенчесен тапканчы, Дәүләтханга Уракчы дигән урыс авылыннан Агалая исемле матур кыз килде. Староверлар гаиләсеннән булганга, ул үзен бик

сәер тотты. Тик татар егетенең кайнарлыгы Агалаяның башын әйләндерде. Техника серләренә өйрәнү мәхәббәт белән үрелеп барды. Ике айда матур кыз тракторчының бөтен осталыгын үзләштереп өлгергән иде инде. Бу өйрәнүнең үзгә нәтиҗәсе дә булды: Агалая егерме өч яшьлек остазын фронтка йөкле килеш озатып калды...

***

Газизне, актив комсомол буларак, җаваплы урынга куйдылар. Ул егерме чакрым ераклыкта урнашкан Балык Бистәсе заготзерносына ашлык илтүдән гыйбарәт иде. Звенога утыз җигүле ат кирә. Һәр обозга ун капчык ашлык салына. Бер баруда звено 2350 центнер арышын, бодаен фронтка озата дигән сүз! Моңа колхоз рәисе Габдрахман шатланса да, икенче яктан бөтен ашлыкны җибәрсәк, киләсе елда ни чәчәрбез, халык ни ашар, дип борчыла. Болай да бит күпләрнең яңа уңыштан ипи салырлык оннары да юк. Уракка баручылар бәләкәй генә ярма яргычлары белән басуда учак ягып ботка пешерә, үзләре дә тамак ялгый, балаларына да өлеш чыгара. Ни хәл итәсең, фронтка да кирәк, авыл халкына да.

Колхоз рәисе Газизнең яшенә күрә кылган гамәлләренә шатлана. Бу егеттән менә дигән җитәкче чыгачак. Иң мөһиме — күңеле яхшы, иманлы егет.

Газиз, комсомол буларак, обозга сәяси төсмер дә бирә. Иң беренче арбага, кызыл флаг тоттырып, ун яшьлек Гамирне утырта. Ул, өстәвенә, тальян гармунда берничә көйне дә маталый. Авылларны узганда җиденче арбадагы ике пионер «Бөек Җиңүгә «Якты Юл» колхозы хезмәтчәннәреннән — бүләк» дигән кызыл комачларны ачып сала. Күрүчеләр аз булса да, бу алым халыкта ышаныч хисләрен арттыра. Ашлыкны үлчәп сушилкаларга бушаткач, обозчылар кире кайтырга чыга. Шомыртлыкта аларны Мәннан бабай көтеп тора. Бер чиләк борчактан бик тәмле шти пешерә. Аңа колхоз исәбеннән бирелгән тозлы ит кисәге дә салгач, моннан да тәмле ризык юк кебек тоела. Кичен эш ындыр табагында дәвам итә. Иртәгәсен тагын ашлык илтү...

Фронттагы хәлләр бик мөшкел булуга карамастан, аңлашылып бетми торган киеренкелек бик еш кабатланып тора. Сугышка дип киткән Кыерлы ир-егетләре нигәдер мари урманнарында агач мылтыклар белән немец танкларын «туктатырга» өйрәнә, ачлыктан интегә...

Фашистларны кырачак Салих, Гайнетдин, Гыйләҗи биредәге авыр хезмәттән үпкәләренә салкын тидереп вафат булдылар. Болай да ач авыл хатыннары инде ничә тапкыр ирләренә сохари илтүне оештырды. Караңгы урманнарда сугыштан качкан дезертирлар күзгә чалынгалый. Казанга Мәскәү, Ленинград, Балтыйк буе республикаларыннан эвакуацияләнгән халык агылды. Татар авылларына моңарчы ишетелмәгән телдә сөйләшүчеләр килде. Кыерлы авылы да өлешсез калмады. Бирегә Ленинны күргән өч партия ветераны, Совет партия әһелләренең җиде туганы, Кыерлы халкы ишетмәгән ниндидер артистларның әти-әниләре килде. ВКП(б)ның өлкә комитеты беренче секретаре Алемасов имзалаган карарларда: «үзең ачтан үлсәң дә, колхоз, җирле власть бәхетсезлеккә тарыган кешеләргә азык-төлек, кием-салым белән булышырга» кушылды. Алар арасында совет армиясе тимер юл гаскәрләре майоры Калью Киротарның тормыш иптәше, балалар табибы Хильди һәм аның унҗиде яшьлек кызы Лайне дә бар иде. Алар бирегә юллама белән — Хильди медпункт мөдире, Лайне санитарка итеп җибәрелде. Икесенә дә дәүләт тарафыннан хезмәт хакы, офицер гаиләсе буларак льгота билгеләнде.

Эстон кунакларын да, гадәттәгечә, Газизнең кызыл обозы алып кайтты.

Бу юлысы да алар Шомыртлыкта бодай ярмасыннан пешерелгән майлы өйрәдән авыз иттеләр. Ике атналап юлда үткәргән хатын-кызлар беренче мәртәбә бугай яулыкларын чишеп, сары чәчләрен тарадылар, чишмә суында битләрен юдылар. Яше елмаеп ук жибәргәч, йөзе салкын көнгә жылылык, яктылык биргәндәй булды.

— Без әни белән эстоннар иленнән килдек. Медпунктта әни врач булачак, мин аның ярдәмчесе. Исемем — Лайне, — дип таныштырды ул үзе белән.

Әнисенең сүз катасы килмәде. Чәй өчен рәхмәт әйтеп, агачлар арасына юл алды. Аның үз кайгысы. Бәләкәче Марта, әти-әниләре ни хәлдә икән? Сугыш озак булырмы?

Авыл советы рәисе Фатих Галәүев эстоннарны фронтовик хатыны Шәмсияләргә кертергә булды, ягъни Газизләр күршесендә генә. Егет аларны өйләренә кадәр илтеп куйды. Бер күрүдә үк ошатырга өлгергән эстон чибәрен кичен очрашырга чакырды. Тегесе эстонча «Палун, палун», дип җавап бирде. Газиз укый торган класста гына түгел, авылда да сылу кызлар бар. Ә Лайне үзенең серле елмаюы, күзләрендәге очкыннар белән үзенә әсир итте. Ул чакта арышлы-бодайлы хәсрәтле август көне ике йөрәкне мәңгелеккә берләштерер дип кем уйлаган?! Эстон кызы белән татар егете Газизнең әле бу хакта хәтта уйларына да килмәде. Очсыз-кырыйсыз мәйданнарда урнашкан дәүләтнең ныклыгы Кыерлы да Приуралье, Корсаков, Хаапсалу, Гури кебек меңәрләгән авыл-шәһәрләрдә формалашты. Илнең иминлеге өчен кан коючы солдатларның сөйгәннәренә карата булган мәхәббәте аларга гына түгел, бөтен илгә ныклык бирде, киләчәккә өмет уятты...

Газизнең ундүрт яшьлек сеңлесе Әлфия бар. Тиздән әнисе тагын бер сугыш баласы алып кайтачак. Әтиләрен дә алып киттеләр, хаты Суслонгердан килә. Зарланмый, тик монда урман кискәнче, фронтка китәсе иде дип уфтана. Бабасы унҗиденче елда патша хезмәтендә сугышта һәлак була, әбисе Гөлфәния район үзәгендә яши. Туганнарыннан — Нәгыймулла абыйсы, күршеләрдән Хәлил, Вилдан, тагын бик күпләре — сугышның беренче көннәреннән фронтта. Сугыш Газизнең дә планнарын үзгәртте. Хәзер инде ул урта мәктәптән соң хәрби училищега керү турында уйлады. Ничек итеп комсомол егет изге бурычын үтәмәсен ди?! Ул сугышын, һичшиксез, Берлинда тәгәлләячәк!

Газиз, ярты литрлы банкага сөт салып, Шәмсия апаларына керде. Кунаклар инде юынып өс киемнәрен алыштырган, чәчләре матур итеп таралган. Өстәлдә яна бәрәңге, арыш ипие. Газиз монарчы күрмәгән матур кәгазьле кәнфитләр.

— Менә безнең күрше егете дә керде. Хәзер чәй эчәбез, — дип Шәмсия апасы Газизне дә өстәлгә чакырды. Үзара сөйләшү урысчалы-татарчалы барды. Кунаклар аңлашмаса, бер-бере белән үзләренчә гәпләшеп алдылар. Аннары әңгәмә дәвам итте. Эстонча исәнмесез «тэрэ» икән, Газиз андый сүз бездә дә бар тәре — крест, тире — кожа, дип көлдереп тә алды. Сау булыгыз — «хэад айга», гафу итегез — «вабандаге».

— Исәнме, минем кадерлем! — ничек? — Лайне бу сорауга да җавап бирде: «Тэрэ мо каллис!» Рәхмәт — «тянан», сау булыгыз — «хеад айга».

— Ә менә исемегез ни аңлата?

— Хильди — горур, зыялы. Лайне — дулкын...

— Мин — Газиз. Кадерле кеше, изге ватан кебек...

— Бер — «юкс», ике — «какс», өч — «колм».

Шәмсия апа белән Газизгә Ленинградта чыга торган матур кәгазьле кәнфит бик тә ошады. Эстон кунаклары кәҗә сөтен мактады. Туган җирләрендә дә алар сакаллы малның сөтен эчәләр икән. Ул организмга

бик тә файдалы, имеш. Хильди белән Лайне моңарчы татар-монгол игасыннан башканы белмәгәнгә, Газиз кыскача гына татарларның да дәүләте булуын, аннан мөстәкыйльлекне югалтулары хакында сөйләп алды.

Чәйдән соң Газиз Лайнены Кыерлы белән таныштырырга дип урамга алып чыкты. Кадермә елгасын үтеп, алар авыл уртасында урнашкан медпунктны, аның каршысындагы манарасы киселгән мәчет-клубны карадылар. Аннары, агач мәктәп... Бирedә зур алма бакчасы. Газиз соң өлгерә торган бер алманы Лайнега да бирде. Кыз, аңа рәхмәт әйтте дә:

— Азиз, син Адәм белән Хәваның җәннәттәге мажараларын беләсеңме? — диде.

— Әйе, беләм.— Әйдә, бу алманы ашамый торыйк. Йә без дә гөнаһ эшләрбез...

— Килештек... — дип Газиз Лайненың кайнар кулларын учына алды.

— Ә бит Адәм анарчы ук гөнаһлы булган, Иблис тәкъдим иткәч, Лилит исемле чүл кызы белән төннәр үткәргән.— Менә ышан егетләргә... Әле мин моны белми идем. Кайдан укыдың?

— Борынгы яһүдиләр тарихыннан.

Лайне өстенә яшел күлмәк, милли бизәкләрдән бәйләнгән ак свитер кигән иде. Соңрак ул Газизнең ике кулын сыйпый-сыйпый:

— «Айтеп күл», ягъни бүгенгә җитәр. Башка вакытта мин сине Хаапсалу белән таныштырырмын... — диде.

Беренче очрашу шулай тәмамланды. Газиз, Ризванның «Ат чишмәсе» янында Санияне үбүен искә төшереп, үзен битәрләде: «Мин хыялый гына түгел, куркак куян да икән әле...»

Лайненың инде күптәннән җылы йомшак мендәрләрдә, юрганнарда йоклаганы юк иде. Шуңа күрә Кыерлыда ул төшләр күреп маташмады, рәхәтләнеп йоклады гына.

Иртәгәсен Газиз Хильдине авыл советы рәисе Фатих абыйсы, колхоз председателе Габдрахман янына алып төште. Утыз белән кырык арасындагы ике ир-ат эстон хатынының матурлыгына бик сокландылар. Тик аларда бүген матурлык кайгысы түгел иде. Ничек итеп халыкка ашлык бирергә дип баш ваталар. Өстәвенә, чит җирләрдән артык кашыклар да килде...

— Врач булгач, күнелебез тыныч, халыкның сәламәтлеген сезгә ышанып тапшырабыз, ярдәм кирәк булса, тартынмагыз, — диде Фатыйх.

Сугышка алынган медпункт мөдире аларның икесе өчен дә үз кеше. Айга бер мәртәбә Фазыл биргән разнарядка белән дарулар алып кайта. Шул ук көнне хәл белергә дип авыл начальниклары килеп чыга. Фазыл белә — алар спирт эчәргә килгән. Гәпләшә-гәпләшә бер литрлы банка төбенә төшү дәрәҗәсенә житәләр. Иртәгәсен медфельдшер эчелгәне урынына аракы яки су өсти. Чөнки әле киләсе кешеләр юк түгел. Аларның иң куркынычы — күпме эчсә дә исерми торган Змеев. Ике рәис, салкын карашлы яңа врачтан өлеш чыкмас дигән фикергә килеп, Хильди белән саубуллашалар.

Кыерлы медпункты клуб янындагы бәләкәй генә йортка урнашкан. Ул ике бүлмәдән тора. Берсендә төрле дарулар, инструментлар, алдагысында авыруларны кабул итү урыны. Фазыл яхшы белгеч кенә түгел, оста хужа да булган, күрәсең. Бүлмәләр чиста, мич акшарланган, утын ярып өелгән, тәрәзә төпләрендә матур гөлләр үсә. Документлар да төгәл тутырылган, кемнең кайчан туганы һәм үлгәненә кадәр исәпкә алынган. Бәлки аны НКВД органнары шулай таләп иткәндер. Анысын әле яна медпункт мөдире белми иде.

Тарих һәр милләткә ниндидер бер аерым сыйфат «бүләк" иткән. Кавказ халыкларын кайнар канлы, татарларны яраклашучан, эстоннарны акрын,

немецларны төгәл, башкортларны астыртын дип саныйлар. Әлбәттә, бу билгеләнү дөрестәдер, ләкин бөтен кешегә дә бер үк калыплар тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Хильдины, мәсәлән, акрын дип әйтеп булмый. Ул башлаган эшен жиренә житкермичә туктый алмый. Тыштан салкын, таләпчән булуга карамастан, нечкә күнелле, кешеләрне кызганучан ул.

Сугышнын тиз арада бетүенә ышанмаса да, күнеле белән ул туган жирендә, вакыты-вакыты белән эстонча жырлап жибәрәсе, балалар кебек үксеп елыйсы да килә анын. Күнел төшенкелегеннән фәкать яраткан эше генә коткарып кала. Моның өчен генә дә түгел, авыр чакта үзләрен сыендырган татарларга рәхмәтен дә житкерәсе килә.

Хильди төшке ашка кадәр авыруларны кабул итсә, аннан авыл халкынын өйләренә барып, яшәү шартлары белән танышуны да максат итеп куйды. «Исәнмесез», «рәхмәт», «баш авыртамы», «эч авыртамы» кебек сүзләрне ятлады. Татарларның бәйсезлекләрен югалтуга карамастан, гореф-гадәтләрен саклап кала алуына гажәпләнде. Бик үк бай тормышта яшәмәсәләр дә, өйләренең чисталыгын күреп таң калды. Медпунктта техничка булып эшләүче Галия тылмач ролен оста башкара. Революциягә кадәр Ревельдә 5 ел солдат хезмәтен үтәгән Зыятдин белән очрашу аеруча кызык булды. Ул эстон телен дә онытмаган булып чыкты. Кирәк булса, мин тәржемәче ролен үтәрмен, диде Зыятдин. Аларның өч уллары, ике кызлары үсә. Хәлемгөл исемлесе авыру туган, гәүдәсе дә камил түгел. Кызганыч, ләкин вакыт узган, табибларның ярдәме инде хәзер кирәк тә булмас. Кызның яшисе дә күп калмагандыр инде...

***

Хильди белән Лайненың Кыерлыга килүенә ике айлап үтте инде. Вакыт кыска булса да, авылга похоронкалар килә башлады. Жирле совет рәисе Фатих Галәүев белән колхоз председателе Габдрахман Бәhманов та ватан алдындагы бурычларын үтәргә фронтка китеп бардылар. Бронь алып тыныч кына эшләргә мөмкинлекләре дә бар иде югыйсә. Сугыш яңа көчләр, азык-төлек, кием-салым, техника таләп итте. Мәскәүдән — Казанга, Казаннан — районга кискен таләпләр явып кына торды: «20 октябрьгә ашлыкны суктырып бетереп, еллык планны үтәргә!» «Данлыклы Кызыл армиягә 50 пар оекбаш, 150 пар перчатка, 225 данә эчке кием, 25 данә шарф, 114 пар киез итек жыеп тапшырырга!» Шул ук вакытта мәктәп директоры Әхәт Фазылов авыл советы сессиясендә, киемнәре булмау сәбәпле, 23 бала дәрескә йөри алмый дип зарланды. Монысы бер бәла, әле килеп лотерея, займ, контрафакция, ит, сөт, йомырка тапшыру планнары, төрле фондларга акча жыюлар... Фронтка киткән житәкчеләрне алыштыручылар бу авырлыкларның гонаhлы да, каргышлы да икәнлекләрен аңламадылармы икән? Аңлаганнардыр, әлбәттә. Фронттагы солдат та, гади колхозчы да бер үк бурычны үтәде — ничек булса да дошманны туктату. Хильди үзенең тәкъдимнәре белән яңа рәис янына төште. Яшькелт-зәңгәр күзле Фәйзри килгән кунакның кыюлыгына бик нык гажәпләнде:

— Тегесенә льгота, монысы корсаклы... Мин кем белән план үтим, утын хәзерлим, окоп казыйм? Бу бит кычытмаган жирне кашу була. Унынчы октябрьгә егерме кешене Киров урманнарына жибәрү заданиесе килде, утыз биш кешене Казан астында окоп казырга, унике баланы ФЗӨгә жибәрергә. Каян алыйм мин аларны?

Хильди түзмәде:

— Үз халкыңны күрә торып юкка чыгару... Сез сакламасагыз, ул мескен хатыннарны, балаларны кем саклар?! Әтиләре кайткач ни дип жавап бирерсез?! — диде.

Фәйзри әллә аңлап, әллә чыгырыннан чыгып, тагын акырды:

— Корсаклы хатыннарны жәлләгәч, нигә кызыңны окоп казырга җибәрмәскә? Менә сине, кызыңны, тагын утызга якын чакырылмаган кунакны ашатып яткырабыз. Эшлим дип торучылар аз. Тегесен давай, монысын давай. Бик грамотный булгач, җибәрәбез кызыңны. Үлмәс, корсаклы хатыннар да үлми бит әле...

Менә шулай итеп, Лайне ике йөз километрга сузылган оборона корылмалары төзергә дип Кайбыч якларына Кыерлының утыз биш хатын-кызы белән китеп барды. Житкерелгән норманы башта үти алмаса да, соңрак ияләште. Урта мәктәпне тәмамлагач медсестра булып эшләү хокукы биргән белешмә дә ярап куйды. Бер ай җир казыгач, хәлсез эстон кызын күчмә медпунктка билгеләделәр. 1942нче елны алар Кайбыч урманнарында землянкада каршыладылар. Татарстанның авыл-шәһәрләреннән җыелган халык Дәүләт Оборона комитетының заданиесен үтәде. Немецларны Мәскәү астында тар-мар итү әлеге корылмаларның кирәкмәвен расласа да, бушка киткән хезмәт өчен халык нык борчылмады, иң мөһиме — дошман туктатылды. Димәк, җиңүгә дә күп калмый.

***

Авыр чаклар кешеләрне сыный, берләштерә, якынайта. Газиз белән Лайне да бер-береннән яши алмаслык дәрәҗәдә иде. Мәхәббәтнең күзе сукыр дигәндәй, алар өчен дине дә, милләте дә юк, тик бергә генә булсыннар. Лайне җир эшләреннән тагын да ныгып, җитдиләнеп кайтты.

Кыз әнисе янында мәш килде. Хәрәкәтләнә алганнар медпунктта дәваланды, хәле авырларның өйләренә бардылар. Апрель аенда «фронтовик балалар» дөньяга аваз салды. Ни кызганыч, күбесенең әтиләре якты дөньяда да юк иде инде. Районда врачы да берән-сәрән генә булгач, Эстониядән килгән шифалы вә шәфкатьле куллы врач турында яхшы сүз авылдан-авылга, өйдән-өйгә таралды. Аңа яше-карты, бала-чагасы килде.

Әйе, Хильди кебекләрнең файдадан башка зыяны юк. Ә менә карт большевиклардан район җитәкчелегенә дә, җирле хакимияткә дә тынгы булмады. Аеруча, Бронислав Светицкий «елан мөгезе» белән «күгәрчен сөте» таләп итте. Үтәлмәсә, жалоба Мәскәүгә адресланды. Хат районнан ары чыкмаса да, ул беренченең контроленә алынды, нәтиҗә ясау өчен аерым кеше билгеләнде. Әлбәттә, сигнал Змеевка да килеп җитте. Светицкийның дәгъвалары медпункт мөдире, буржуаз Эстониядән килгән балалар врачы Хилдега да юнәлде. Юантык гәүдәле, колак яфракларына кадәр йон баскан, кәкре борынлы Светицкий медпунктка көтелмәгәндә килеп керде. Нечкә тавыш белән исәнләшкәч, үзенең 1917 елдан Большевиклар партиясе әһеле булуы, Ленинны күрүе хакында бик тәфсилләп сөйләде. Аннан таньшлар белән мактанды, соңыннан үзенең авырулары турында әйтте:

— Мин Ленинградта махсус поликлиникада дәваландым. Даруларны да чит илләрдән китерә иделәр. Миңа «Е» витамины, балык мае кирәк... Аннан соң махсус массаж... Миндә простата аденомасы.

Хильди үзенең гадилеге белән Светицкийга ярып салды:

— Дарулар безнең Эстониядә дә җитәрлек булды. Сез сораган витаминнар биредә юк. Балык маен да балаларга бирәбез. Массажга килгәндә... сезгә җәяү йөрергә, хәрәкәтләнергә кирәк. Бер дә булмаса, берәрсенә йортка керегез. Сезнең льготаларга өч-дүрт кешене туйдырып кына буладыр, мөгаен.

Әле эшләргә сәләтле Светицкийның нинди дер татарларга ярдәм итәргә теләге юк иде. Ул Ленинградта партия ветераны буларак, төрле эшләргә тылкышып рәхәт яшәргә өйрәнгән кеше иде. Алтмыш өч яшьлек «ветеран» Хильди янына ук килеп елмайгандай итте:

— Әйе, байлыгым бар анысы. Ниндидер татаркага йортка керү минем дәрәҗәне төшерә. Ә менә сина каршы килмәс идем...

— Гафу итегез, мин Совет офицеры хатыны. Гомумән, сезгә берәр шәһәрдә калырга кирәк булгандыр. Анда чирегезне дәвалаучылар табылыр иде.

Әнгәмәнең болай борылыш ясавын көтмәгән Светицкий җавапсыз калмады:

— Менә фронттагы хәлләр яхшырсын әле, китәрбез. Син, асылкош, тәкъдим турында онытма. Үпкән-кочкан, жилгә очкан дигәндәй, Светицкийның күңелен күрергә теләүчеләр пруд пруди, уйла!

Бу яһүд бүлмәдә ниндидер тәмсез ис, шом калдырып китеп барды. Хильди исә үксеп-үксеп елады. Ачлыктан балалар интегә, ә аңа массаж кирәк, витаминнар...

Татар гаиләләре гомер-гомергә әхлак законнары нигезендә яшәгән. Егет белән кыз аулак өйләрдә бергә кунсалар да, ике арадагы мөнәсәбәт үбешүдән ары узмаган. Өйләнешеп яши башлагач исә ир гаилә иминлеге өчен тырышкан. Хатын балалар үстергән, йорт җылысын саклаган. Тормышлары авыр булса да, алар төнне сагынышып көткәннәр. Кыска гына вакыт эчендәге мәхәббәт аларга көч-дәрт биргән. Ирләр — ирлек, хатыннар — хатынлык серләре хакында фикер алышмый калмаган анысы. Иренә, яки хатынына салкынлык күрсәтүчеләр дә булган билгеле. Мондыйлар озак яши алмаган. Мулла аларны фикерләре яки мәхәббәтләре туры килмәде дигән сылтау белән аерган. Тегеләр яңа парлар табып матур гына тормыш иткән.

***

Газиз белән Лайненың танышуларына көз, кыш, яз узды. Беренче көннәрдән үк аларның акыл белән генә аңлашу түгел, ниндидер башка хисләр, мәхәббәт хисләре дә берләштерде. Бу чакларда алар ниндидер сихри дөньяга кучкәндәй була иделәр. Алга таба тормыш нинди генә сынаулар әзерләмәсен, ике яшь йөрәк бер-берсе өчен көрәшергә әзер иделәр. Тик алда ни көтә, Лайне туган җирләренә кайтып китәрме? Ә Газизнең язмышы сугыш белән бәйле. Аны исән-сау чыгып булырмы? Егет имтиханнарын биргәч, алар ике арадагы дуслыкны ант белән ныгыттылар. Лайне аны көтәргә вәгъдә бирде. ...Районнан Газиз белән тагын Егерме җиде егетне Ульяновскидагы хәрби артиллерия училищесына җибәрделәр. Уку программасында каралганча алар ике елдан соң лейтенант званиесе алып фронтка китәргә тиеш иделәр. Кылыч борынлы, соры күзле, житез хәрәкәтле Газиз тагын да ныгып китте. Хәрби киеме дә матур гәүдәсенә килешеп тора. Эх, Лайне күрсен иде хәзер сөйгәнен! Шатланыр иде үзе, ә?! Кыерлы белән Ульяновск арасында хатлар өзелмәде. Алар ике якка да ышаныч, өмет бирә торган хәбәрләр иде. Яңа 1943 елны каршылаган көннәрдә Газиз сөйгәненнән шомлы хат алды. «Газиз, сөеклем. Мин бик авыр хәлдә калдым. Әтидән күптән хәбәр юк. Әни үлде. Ни эшләргә дә белгән юк. Кая барыйм? Синең ярдәм кирәк. Мөмкин булса, кайта алмассыңмы? Лайне»,— диелгән иде анда.

Ни эшләргә? — Курсант Газиз Әбләзиев шул хакта уйлады. «Сөйгән кызым авыр хәлдә» дип әйтсәң, кем отпуск бирер? Бәлки: «Әни авыр хәлдә, яки әтигә фронтта нидер булган» дип рапорт язсам, ышанырлар? Курслар начальнигы — сугыш инвалиды капитан Брагин уку алдынгысы Әбләзиевка ярдәм итәргә алынды.

— Фронттагы киеренкелекне истә тотып, Совет гаскәрләре хәлиткеч һөҗүмгә әзерләнә. Шуна күрә сезнең укуларны ун айга калдыру хакында

приказ килде. Июнь айларында сезне инде шунда җибәрәчәкләр. Алдагын Алла белә. Кайтып саубуллашу бик урынлы булыр, — диде ул.

Газизгә Кыерлыга кайту өчен биш көн вакыт отпуск бирелде. Казан. Аннан соң Арча яки Шәмәрдән станциясе. Кыерлыга тагын сиксән чакрым кала. Бу араны ничек үтәргә? Казаннан Кукмарага кайтучы Гафур бабай: «Сезнең яклар Шәмәрдәнгә йөри кебек. Нырсы. Аннан Яңарышка. Бу якларга үзем дә итек басарга йөргәләдем» — диде дә, Газизнең аягындагы күн итекләрен күреп: «Улым, аягыңны өшетәсең килмәсә, әйдә, итекләрне алмашыйк», — дип бик акыллы фикер әйтте.

Аяк исән булса, күн итеге табылыр дип, ул бабайның киез итеген киде. Тик бирелгән вакытка кайтып өлгерәсе генә иде. Кайда ат чанасына утырып, кайда җәяү атлап, Газиз Кыерлыга таң алдыннан гына кайтып житте. Менә аның туган нигезе. Әле кайчан гына бик зур булып күренгән «нәсел агачы». Шәһәр йортлары белән чагыштырганда өйләре дә бәләкәй икән. Боз белән капланган тәрәзәләрдән берни күренми. Газиз әкренләп кенә өйалды ишеген шакыды. Эчтән әнисенең тавышы ишетелде:

— Кем анда?

— Әни, әни. Бу мин, улың Газиз!— Газиз? Син бит укуда. Ничек кайтасы иттең?

— Яхшы укыган өчен биш көнгә отпуск бирделәр, әни. Юлда менә икесе үтте инде.

Тавышка сеңлесе Әлфия дә уянды, бишектәге Хөсәен дә елап алды. Әнисе тагын да ябыккан, бәләкәйләнеп калган. Газиз юл капчыгыннан шакраеп каткан ипи, шикәр, тушенка чыгарды. Сеңлесенә матур косынка, әнисенә яулык бирде.

— Хильдины үзебезчә, мөселманча җирләдек. Бик әйбәт кеше иде. Халыкка күп ярдәм итте. Чит диндә булуына карамастан, зиратның иң түрендә җир куенына тапшырдык. Змеев дигән кабахәт, халык дошманы дип куркыткан, төрмәгә ябабыз дигән. Чыдый алмый үз-үзенә кул салган, бичара. Лайне хәзер берүзе. Нишләр инде... Бәлки, үз иленә киткәнче бездә торыр.

Газизнең көн яктырганын көтәргә түземлеге житмәде, Шәмсия апаларына керергә булды. Нииндидер карарга килергә бары бер тәүлек вакыт калган иде. Ә алдагысын капитан Брагин әйткәндәй, бары бер Алла үзе генә белә. Менә ул таныш тавыш, менә ул кадерле мизгелләр. Тэрэ, Тэрэ Ыхтуст мо каллис! Сәлам, сәлам, хәерле иртә, минем кадерлем! Лайне бераз тынычлана төшкәч, әнисенең саубуллашу хатын укыды. Кыскасы, Змеев Хильдига җинаять эше ачкан. Аңа партия карарларын үтәүдә саботажлык итү, буржуаз Эстониядәге тормышны мактау турында Светицкийның шикаятьләре теркәлгән була. Змеев: «Хәлеңне йомшартырга мөмкин, моның өчен минем сөяркәм булуың кирәк», — дигән. Медпунктта эчеп алгач, Лайнены пистолет белән куркытып, чишенергә мәҗбүр иткән. Ә тегесе, котылу өчен, шешә белән Змеевның башына суккан. «Мине гафу итегез. Халык дошманы булып әтиенә һәм сиңа кара тамга ясыйсы килми. Газизне ташлама. Ул сине ярата. Мин сезнең бергә булуыгызны телим.» Хильдиның үз-үзенә кул салыр алдыннан язган хаты бу... Алемасов Татарстанның җилегенә төшкәч, халыктан бик күп жалобалар Мәскәүгә яуган. Кремль, ахыр чиктә аннан котылу ягын карап, кырык алты яшендә сәламәтлеге «начарлану» сәбәпле, моны пенсиягә чыгарган. Шуңа күрә, Змеев эшен дә зурга җибәрмәгәннәр, аны тавышсыз-тынсыз гына фронтка озатканнар. Алемасов — татарларны кыру буенча бик күп начарлыклар эшләгән кеше. Никадәр милләттәшебезнең башына житкән. Аның урынына СССР тимер

юлы министрлыгы хезмәткәре Зиннәт Үмәр улы Моратов билгеләнгән. Монысы исә татарның динен, денен, телен бетерү буенча зур этлекләр эшләгән кеше буларак тарихка кереп калды. Змеев урынына халыкны күп кан елаткан, хәтта хатынын да төрмәгә утырткан Нәсих Тәфкилдиев җибәрелде. Лайнены Кыерлыда калдыру, аны коткару юлы бер генә иде. Язылышып, аңа Әбләзиева фамилиясе бирү һәм совет офицеры хатыны буларак, барлык льготалар белән тәэмин итү. Газиз менә шушы карарга килде. Моны тормышка ашырырга бары бер тәүлек вакыты бар иде. Әнисе Газизнең бу адымын хуплап, яшьләргә бәхет кенә теләде. Әле алар Газизнең тагын дүрт айдан Курск дугасында үлем белән күзгә-күз очрашачагын белмиләр иде. Газиз белән Лайнега никахны Мәннан бабай укыды. Авыл советында да язылырга каршы килүче табылмады. Ир белән хатын буларак, Әбләзиевлар фәкать бер тәүлек яшәп калдылар. Язмыш аларны «мәхәббәт алмасын» шулай иртә татырга насыйп итте.

***

Тора-бара кайгы-хәсрәтләр урынына бәләкәй генә булса да шатлыклар өстәлә торды. Әтисе Калью да табылды. Алар кырык икенче елда, хәрби техника белән шыгрым тулы эшелонны фронтка илткәндә, немец самолетлары атакасына тарыйлар. Нәтиҗәдә, эшелон начальнигы каты яралана. Күп тапкырлар операцияләр ясап аякка басканнан соң, подполковник Киротарны Котлос-Воркута тимер юл төзелешенә хәрби күзәтче итеп җибәрәләр. Капитан Газиз Әбләзиевнын да теләге чынга аша. Ул тугызынчы майны Берлинда каршылый. Кальо Киротар кызы Лайне, оныгы Муса һәм кияве Газиз белән 1945 нең арышлы-бодайлы — алмалы августында Кыерлыда очраштылар. Тик алар арасында сугышның утлы дулкыны йоткан, ачлыктан шешенеп үлгән Бәдрисафа белән Лиүзә, танк эчендә янып һәлак булган Зөлмөхәммәт, бертуган Зыятдин, Фәрзетдин, Фатыйх Фәлаховлар, Кыерлы халкы өчен бик күп яхшылыклар эшләгән эстон хатыны — Хильди һәм тагын бик күп, бик күп изге җаннар гына юк иде... Эстониянең Хаапсалу шәһәрендә башланган Киротарлар тарихы Татарстанның бәләкәй генә Кыерлы авылында Әбләзиевлар белән тагын да тулыланды, яңа үсеш алды. Иң мөһиме — зур сынауда алар кешеләрнең каргышын алмады, намусларына хилафлык итмәделәр.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге документлар булу мәҗбүри:

1. Паспорт күчерелмәсе (титул, прописка бите).
2. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы күчерелмәсе.
3. ИНН күчерелмәсе.
4. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
5. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп).



Ленар
Шәех

# БЕЗ САЙЛАГАН ЮЛЛАР ХАТА ТҮГЕЛ

* * *

*Безнең эрага кадәр 480 ел. Фарсы патшасы Ксерксның 200 меңлек гаскәре Грециягә һөҗүм итә. Аларны Фермопила тарлавыгында 6 мең сугышчы (шунда ук 300 спартан) белән Спарта патшасы Леонид каршы ала. Фарсылар ике көн дәвамында тарлавыкны штурмлый, ләкин нәтиҗәсе булмый. Эфиальт исемле хыянәтче дошман гаскәрен тау сукмагы буйлап Спарта патшасының тылына алып китә. Грек гаскәренең күп өлеше китеп котыла, ләкин Леонид җитәкчелегендәге 300 спартан туган илләрен саклап вафат була.*
*1944 елның 25 августы. Плетцензее төрмәсе. Дошман тылында туган ил азатлыгы өчен көрәш алып барган Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең башлары киселә.*

**Спартанларның батырлыгын**
**Чагыштырыйм ни белән?**
**Көйләп биримме соң әллә**
**Ирексөяр көй белән?..**

**Күп тә түгел, бөтенесе**
**Нибары өч йөз генә.**
**Дистә меңләгән гаскәргә**
**Бу — уен, көчсез генә...**

**Күзләрендә ярсу ялкын,**
**Шыксыз үлем тынлыгы.**
**Һәрберсенең йөрәгендә**
**Мең кеше батырлыгы.**

**Туган җирне яратуда**
**Аларга бер тиңнәр юк!**
**Спартанлар гел алга бара —**
**Чигендерер имнәр юк!**

Ленар ШӘЕХ (1982) – *шагыйрь; «Дүртенче кат... Бишенче кат...», «Җылытасы килә дөньяны!..», «Безнең ишегалдында» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Республикасының М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Аларны кире борырлык
Көчләр әле тумаган.
Җаннарына сөю тулган,
Ә хыянәт тулмаган.

Хатыннары, балалары,
Хөр илләре хакына
Кылдан үткен кылычлары
Һава буйлап атына.

Күп тә түгел, бөтенесе
Нибары өч йөз генә.
Дошманнары җиргә ята
Тын гына, сүзсез генә.

Меңәрләгән гаскәринең
Йөзләреннән кан кача.
Спартанлар бар да көрәшә
Актык тамчы кангача.

Җаннары сөңге, кылычтай
Оча тау-ташка таба.
Калкан булып атылалар
Нурга, кояшка таба.

Васыятьләре — ике сүз,
Яңгырый еллар аша.
«Хәтерләгез безне!» диләр... —
Күк белән җир тоташа.

Күп тә түгел, бөтенесе
Нибары өч йөз генә.
Башлары да иелмәгән,
Чүгелмәгән тез генә...

Җәлилчеләр батырлыгын
Тиңлим икән ни белән?
Көйләп биримме соң әллә
Милләтсөяр көй белән?..

Күп тә түгел, бөтенесе
Унике генә бары.
Ирендә сүзсез елмаю
Һәм җиңү авазлары!..

Баш киселә, уй киселми,
Өзелми хәтер җебе.
Мәңгелек исемнәр белән
Үрелгән тарих төбе.

«Хәтерләгез безне!» диләр
Җәлилчеләр үткәннән...
Алар без азат булсынга
Үлем аша үткәннәр.

Юк, яшьләре таммагандыр,
Кайнар тир аккандыр ул!..

Җәлилчеләр соң минутта
Кояшка баккандыр ул!

Күп тә түгел, бөтенесе
Уникe генә бары...
Сибәли тора яңгыры,
Яуғалый тора кары.

Спартанлар һәм җәлилчеләр
Яшиләр күңелләрдә.
Искән җилдә, сайрар кошта,
Ташны тишкән гөлләрдә!

Алар кылган батырлыкны
Чагыштырыйм ни белән?
Авазлары ишетелә
Иртән искән җил белән.

«Хәтерләгез безне!» диләр,
Дәвамчыларын белеп... —
Ватансөяр, ирексөяр
Каһарманнар мәңгелек!

* * *

*Улыма*

Син зур үскәч,
Чәчеңә чал кергәч,
Син ак чәчле бабай булганда,
Сәгать теле, каударланып кына,
Вакыт машинасын куганда...
Мин булмамын инде бу дөньяда —
Тәнем — җирдә, җаным иректә...
Элеккечә күрешүләр... юк-юк...
Бер минут та, ярты... чирек тә...
Оныгыңны кулга алырсың да
Елмаерсың шунда аңа син...
Мин елмайган кебек сиңа карап,
Мин сөенгән кебек... кара син!.. —
Гел әтиең инде карашларың,
Елмаюың әнкәң төслерәк.
Өлкәнәйгән саен хәтерләрдә
Хатирәләр, хисләр көчлерәк.
Искә төшәр шулчак сабый чагың,
Үткән гомер узар каршыңнан.
Без сайлаган юллар хата түгел,
Дөрес алар төптән, башыннан.
Сайланган юл ялгыш була алмый,
Күңел яткан, җаның тартылган.
Безгә кадәр күпме сулар аккан,
Җилләр искән, йолдыз атылган...
Бу туктаусыз шулай дәвам итәр,
Ә Җир шары торыр әйләнеп.
Таң атамы? Офык тирәсендә
Ап-ак нурлар килә шәйләнеп...
Син зур үскәч,
Чәчеңә чал кергәч,
Син ак чәчле бабай булганда,

**Күзгә җилләр, каударланып кына,**
**Күктән болытларны куганда...**
**Укып җибәр шушы шигыремне**
**(Безнең өчен дөнья тар иде!..),**
**Исеңә ал, әле кайчан гына**
**Синең яңда әти бар иде!**

## Ике Салих

*Бөек татар композиторы Салих Сәйдәшев*
*һәм аның рухи шәкерте Салих Шамов истәлегенә*

**Татар моңы яшәешнең**
**Үзәгеннән тора тамып.**
**Күңелемдә ике Салих:**
**Берсе — Сәйдәш, берсе — Шамов.**

**Берсе бөек көй остасы,**
**Милләтемнең газиз улы.**
**Аның көе уйнаганда**
**Йөрәк ярсу, күңел тулы.**

**Сәйдәш моңы агылганда**
**Беркем йөрмәс күнәр–күнмәс...**
**Үткәннәрдән килә аваз:**
**«Без кабызган утлар сүнмәс!..»**

**«Әдрән диңгез», «Хуш, авылым!»**
**Җанны айкый астын–өскә.**
**Кабатланмас Сәйдәш маршы**
**Кояш кебек якты төстә!..**

**Җанатары икенчесе**
**Якты Сәйдәш көйләренең.**
**Серен белә чал тарихның,**
**Яңа бистә өйләренең.**

**Күпне күргән, күпне белгән**
**Туксан яшьлек Салих ага**
**Якты Сәйдәш турындагы**
**Китап булып җанга кага.**

**Сәйдәш моңы киләчәккә**
**Язгы җилдәй очып барсын!**
**Чуар дөнья уртасында**
**Татар «Без!» дип оран салсын!**

**«Без Тукайлы!» «Без Сәйдәшле!»**
**«Без Җәлилле бөек халык!» –**
**Дисен татар,**
**тыңласыннар**
**Шаклар катып, таңнар калып.**

**Ә китаплар чыгып торсын,**
**Истәлекләр саклансыннар.**
**Шамов кебек фидакарьләр**
**Узган юллар аклансыннар!**

Чорлар аша татар моңы
Ургый-ургый тора агып.
Күңелемдә ике Салих:
Берсе — Сәйдәш, берсе — Шамов.

* * *

Күңелемнең тулган чагы, ташкан чагы,
Акылымның ычкынган һәм шашкан чагы.
Гөрләвектәй агып ятам җир буйлатып,
Бар дөньяны уйландырып та уятып!..

Уянсыннар һәм күрсеннәр минем хәлне,
Көлкеме мин, әллә инде мескен, җәлме?
Җил булып исәр мәл түгел, коштай очар.
Кемдер әйтте: «Түзалмасаң, әнә, оч, бар!..»

Юк, гөрләвек халәтеннән чыга алмам,
Шуңа микән бертуктаусыз агам-агам.
Киртә түгел таш диварлар, мәрмәр юллар,
Аларны да үтеп чыга агым сулар.

Күңелемнең тулган чагын «көш!» диялмыйм,
Терсәгемне берничек тә тешли алмыйм.
Акыллымы, акылсызмы — җавабы юк,
Тораташтай яшәүнең бер сәбабы юк.

Гөрләвектәй агып китәм кая таба?.. -
Уйлар йөри җан ишеген кага-кага...

* * *

Күңелемнән ургып чыга
Бар хисләрем ташып.
Мин бит сиңа йөз мәртәбә,
Мең мәртәбә гашыйк!

Аның саен мәхәббәтем
Арта гына бара.
Кулларыңны куй кулыма,
Күзләремә кара.

Кочыйм әле синең җанны,
Җаным белән кочыйм.
Кайнар хисләр ташкынына
Тагын сөю кушыйм.

Бер тын икәүләп утырыйк,
Җанны җанга куеп.
Иңебездә мәхәббәтнең
Пар канатын тоеп.



Фәрит
Имамов

# КҮЛӘГӘ

ДЕТЕКТИВ РОМАН

Типсә тимер өзәрдәй таза егет, тормышының тәмен генә белеп яшәр чагында, гомерен үз теләге белән өзәр дип кем уйлаган... Соңгы вакытларда тормышында булган кайбер сынаулар аны тез чүктерерлек түгел сыман иде. «Чечен сугышы» дип аталган мәхшәрдән исән-сау калган егет андый гына кыенлыкларга бирешмәскә тиеш иде... Тик, октябрьнең салкынча бер көнендә, үз дачасындагы өйнең чоланында, Маратның асылынган гәүдәсен табып алдылар. Аны бу хәлдә беренче күрүче кеше әнисе Зәйтүнә иде.

Җәй көннәрендә аны бакчага үз машинасында Марат озаткалады. Ә менә соңгы арада әллә нәрсә булды улына. Берничә атна күзгә-башка чалынганы юк. Ана күңеле баласының нindидер күңелсезлеккә тарыганын сизенде сизенүен. Тик аның эшләренә тыкшынып, ачуын китерәсе килмәде.

Пошынырга сәбәпләр дә бар анысы. Атна-ун көн элек, без милициядән дип, нindидер адәмнәр улының соңгы көннәрдә нәрсәләр белән шөгыльләнүен, кайларда йөрүен сораштырганнар иде. Алар киткәч, Зәйтүнә ашыгып киенде дә улы яшәгән фатирга китте. Ләкин ана ишек ачучы булмады. Маратның хатыны Люба да соңгы вакытта гел читләшеп йөри. Бу хатын улының өйдәше генә. Хәзерге яшьләр «гражданский брак» дип атаган мондый мөнәсәбәтләрне Зәйтүнә бик хупламады. Шуңа күрә Люба белән алар элек тә сирәк аралаштылар. Маратның, командировкаларга еш йөрим, дип сөйләгәне булгач, бу юлы да шунда киткәндер дип күңелен тынычландырырга тырышты ул. Әмма ана йөрәге ана йөрәге шул...

... «Кайнар нокта»ларда хезмәт итеп кайткан егетләргә кайберәүләр бераз көнләшеп тә карыйлар. Шул ук вакытта, шикләнүчеләр дә юк түгел. Ни әйтсәң дә, үлем белән янәшә йөргән, кан күргән ир-атның холкын аңлап бетермәле түгел. Юкка-барга кызып та киткәлиләр.

Авыррак холыклы булса да Марат күңелле компанияләрдән бер дә читләшмәде. Бигрәк тә үзе кебек дары исе иснәгән егетләр белән очрашып бәйрәм итүләре «югары дәрәҗәдә» уза иде. Дуслар төрле сугышчан бәрелешләрне искә төшереп утыра торгач, көн төн белән алышына, вакыт исәбе югала. Акрынлап, шешә артыннан шешә бушый торгач, егетләр

---

Фәрит ИМАМОВ (1960) – *журналист, язучы; әсәрләре Республикабыз газета-журналларында даими басылып килә. Түбән Кама шәһәрендә яши.*

«төтенгә» әйләнә. Еш кына «сугышчан дуслык» мәҗлесләре Маратның өендә, әнисе күз алдында үтә. Ана мондый мәҗлесләргә теше-тырнагы белән каршы булса да, авыр сүз әйтеп, егетләрнең күнелен төшерәсе килми. Анда — ут эчендә җинел булмагандыр, әйдә, тыныч тормышның рәхәтен күрсеннәр... Кайчак, малайлар янына кабымлыгын, тегесен-монысын әзерләп чыгарганда да: «Артыгы китмәсен. Нигә шулкадәр эчәсез инде?» — диюдән ары узмый. Ә Марат күп эчүдән калайлана барган карашын әнисенә текәп: «Не беспокойся, все под контролем», — дип куя. Мондый «мальчишник»ларның хәерлегә илтмәсен күнеле белән сизенгән ана эш таба алмыйча йөргән улын тизрәк эшкә урнаштыру кирәклеген аңлый иде...

Ул берданбер улын ялгызы тәрбияләп үстерде. Ире, малай әле бик кечкенә чагында ук, яшьрәк бичәгә күзе төшеп, гаиләсен ташлап чыгып киткән иде. Зәйтүнә, баштарак, бераз җилләнеп алыр да кайтыр, бала хакына гафу итәрмен, дип ирен көтте. Ләкин яшь хатын күнеленә хуш килгән булса кирәк, ире берничә айдан кайтып законлы аерылышырга теләде.

Зәйтүнә башкага кияүгә чыгу турында уйламады да. Улы ким-хур булып үсмәсен дип, икешәр эштә эшләде. Маратның тамагы тук, өсте дә бөтен иде. Ә менә тәрбия ягы житенкерәмәде бугай. Малай, үз сүзен сүз итәргә өйрәнеп, иркәрәк үсте. Анысын таный Зәйтүнә. Үсмер чагында кыңгыр юлга кереп китмәгәе дип бик нык кайгыра иде. Югыйсә, таныш-белешләреннән, әле тегендә, әле монда, кемнендер малае «группировка»га эләккән, кайсыныкыдыр шикле адәмнәр белән аралаша икән дип сөйләгәннәрен еш ишеткәләде. Ә малае бу яшьтәге күчеш чорын күз төбен кара яндырып кайту, күрше малаеннан «акча кысу», шуның аркасында зыян күрүче малайның әти-әнисе белән әйткәләшү кебек вак-төяк күнелсезлекләр белән генә уза алды.

Армиядән кайтып сыйланулар башлангач та, ананың күнелен «тайгак юлга» кереп китмәгәе дигән уй тырнады. Ул, сиздермәскә тырышып кына, үзе дә улына эш урыны эзләргә кереште. Таныш-белешләрдән сорашкалады, газеталардагы белдерүләр буенча шалтыраткалады. Кайберләрен Маратка әйтеп караса да улы, ошатмыйча кул гына селтәде. Бервакыт урамда «чыбык очы» туганын очраткач та улын эшкә урнаштыру турында сүз кузгатты. «Ник Наил Хәкимовичка мөрәҗәгать итмисең соң? Хәлгә керә торган ярдәмчел кеше бит. Өстәвенә, мина чыбык очы туган тиешле. Ул мина чыбык очы, мин сина чыбык очы, димәк ерак булса да туганнар бит әле», — дип сөйләнде шунда теге хатын. Наил Хәкимович Нәгыймуллин, чыннан да олы урында эшли. Аның шәһәрдә бик дәрәҗәле адәм икәнлеген Зәйтүнә дә ишетеп белә, тик ул кеше белән бер дә аралашканы юк, болай гына, тик торганда аның янына барып керә алмыйм бит инде. Бәлки үзең ярдәм итәрсең дигәч, теге танышы: «Ярар, фәләннең фәләне аша үтенеченне житкерермен. Наил Хәкимович аның ишеләрне игътибарсыз калдыра торганнардан түгел. Барыбыз да аңа барып егылдык. Беребезне дә бормады. Хәзерге көндә балаларыбыз Аллага шөкер» — дип өметләндереп юата алды.

Әлеге сөйләшүдән соң Зәйтүнә өенә канатланып кайтты. Һәм чыннан да, атна-ун көн үткәч, теге хатын гозере буенча түрәнең кабул итәргә риза булуы турында хәбәр иттеләр.

Наил Хәкимович Зәйтүнәне көтелмәгәнчә жылы каршылады. Ул хәтта, кабинет түрендәге урыныннан торып, ишектән керүче хатынның каршысына килеп: «Нишләп элегрәк мөрәҗәгать итмәдегез? Андый кыенлыклар булганда, оялып тормаска кирәк. Ни әйтсән дә, туган тиешле дә икән», — дип сөйләнә-сөйләнә, кул биреп күреште. Мондый жылы мөнәсәбәттән эреп киткән Зәйтүнә, бөтенләй чит булган әлеге кеше каршында, ин якын

туганы белән сөйләшкәндәй чишелеп, энҗе-мәрҗәннәрдәй сүзләрне тезде дә тезде. Бары тик үтенечен генә аяк астына салмасын, бары улын гына эшкә урнаштырсын...

Наил Хәкимович: «Мәсьәләне тиз көндә хәл итәрбез», — дип озатты Зәйтүнәне. Чыннан да, бер атна узды микән, һаман шул «чыбык очы» туганы аша, ул Маратны үзенә чакыртты. Бәхеткә каршы, әллә түрәнен сүзләре үтемле булды, әллә башка сәбәпләр белән, егет аның тәкъдименә ризалашып кайтты. Дөрес, Наил Хәкимовичның үз кул астында эшләмәячәк икән. Бөтенләй икенче оешмада, ди.

Шулай итеп, Зәйтүнә «чыбык очы»н «чыбык очы»на ялгап, максатына иреште.

Улы эшли башлагач, «мальчишник»лар, эчемлекле табыннар сизелеп кимеде. Зәйтүнә моны да Наил Хәкимович йогынтысы дип аңлады. Бигрәк игътибарлы, кайгыртучан кеше шул. Беркөнне, шәхсән үзе, Зәйтүнәләр өенә килеп, аларның яшәеш-көнкүрешләре белән кызыксынды. Үзләренең фәкыйрь генә җиһазландырылган фатирлары өчен Зәйтүнә аның каршында оялып та куйды хәтта. Бары белән табын әзерләп йөргән булды. Чәй янына мәен дә чыгарды. Кунак анысын да кире какмады. Ашау-эчү барышында үзе күп сөйләшмәсә дә сораулар бирде, Маратның ничек эшләве белән кызыксынды.

«Улыгыз миңа беренче караштан ук ошады. Кайнар ноктада хезмәт иткән егетләргә, гомумән, ихтирамым зур. Ышанычлы кешеләр алар. Үзем дә кайчандыр Әфган шулпасын эчкән кеше мин», — дип Зәйтүнәнең күңелен күтәрде.

Йорт каршында торган кара «Волга»сына дәрәҗәсен белеп кенә кереп утырган олы кунакны Зәйтүнә тәрәзәдән шыкаеп карап озатып калды.

Марат акчаны әйбәт алып эшләде. Башта үзенә яхшы өс-баш киемнәре юнәтте. Соңрак, әнисе бик нык үтенеп сорагач, инде ничә дистә ел ремонт күрмәгән фатирларын ремонтлату җаен да тапты. Зәйтүнә моңа сөенеп бетә алмады. Шундый төшемле эшкә урнаштырганы өчен Наил Хәкимовичны ничек итеп бәхилләп бетерермен, дип кайчак кайгырып та куя иде. Тора-бара Марат ял көннәрендә өйдә тормый башлады. Ял көннәрендә дә эшлисезмени, балакаем, дип сораштырырга керешсән, Наил Хәкимович шәһәр читендә дача төзи, шунда булышырга йөрим, дип кенә җавап бирә. Ана монысына куанды гына, әйдә, кылган яхшылыклары өчен бәхилләве булыр диде.

Ел ярым узды дигәндә, Марат өр-яңа «девятка» машинасына утырып кайтты. Рульдә үзе иде. Әнисенең шикләнүенә каршы, бу юлысы да Наил Хәкимович булышкан икән. Ана артыгын төпченмәде. Нишлисең, яшьләр үзләренчә яшәргә тели. Марат бурычлы булып калучылардан түгел, әҗәтен түләр. Тагын берәр айдан Маратның аерым квартирга күчеп яшәргә теләве турында сүз чыкты. Булачак хатынының бер бүлмәле фатиры бар диме шунда... Әле егерме дүрте тулмаган егетне, аерып чыгарып җибәрергә бик теләмәсә дә, анысына да ризалашырга туры килде. Ни генә димә, бала анага биш яшьтә дә бала, егерме биштә дә. Ярар, үз янында җылы ашы да, юып үтүкләнгән киемнәре булыр, өйдән чыгып китсә, кем шулай тәрбияләр баланы... Туй уздырмадылар, Люба исемле хатын белән «гражданский брак»та гына яши башладылар...

* * *

Кайбер кешегә язмыш гел елмая. Нинди генә эшкә тотынса да, уңышлы чыга, теләгәннәренә җиңел ирешә. Ә Наил Хәкимович андыйлар рәтенә керми. Язмыш аңа, үзе әйтмешли, алдын да, артын да күрсәтте, хәзерге дәрәҗәсенә ирешсен өчен бик күп «тоз ашатты». Алты балалы гаиләдән

чыккан гади бер авыл малаена шәһәрдә кем җинел тормыш әзерләп куйсын соң?! Кая инде ул! Түрә балаларының гына барысы да җитеш: үзләре туганчы әтиләре әллә кайчан «алтын таулар» өеп куйган була.

Наил мәктәптә әллә ни яхшы укымады. Гаиләдә укуны алга сөрүче, аны максат итеп куючы да юк иде. Әтисенең: «Миччедән — мичче, чабатачыдан чабатачы туа, безнеке дә әллә кем булмас, үзебез шикелле ферма тирәсендә йөрер, әйдә, эшкә өйрәнеп үссен», — дип сөйләшкәнен Наил хәтерли әле. Өлкән бала буларак, кечкенә эне-сенелләрен карау да аңа йөкләнгән иде. Тик ул ыбыр-чыбыр балаларның өйдә чыр-чу килеп сугышуларын карап торырга бик яратмады. Шуңа күрә, әлеге «вазифаны» тулысы белән үзеннән яшь ярым кечерәк сенлесенә йөкләп, мәктәптән кайтуга, әти-әнисенә булышуны сылтау итеп, фермага йөгерә иде. Эштән вакыты калса да, дәресләрен карарга ашыкмый, малайлар белән «шар сугарга» чаба. Әнә шуна да укуының рәте булмады. Ата-аналар җыелышында: улыгызның башы бар, тырышмый гына. Бераз күз-колак булыгыз әле шуна, дигән сүзләрне еш ишетергә туры килде. «Миччедән — мичче...» дип әнә шул вакытларда әйтә иде инде әтисе.

Урта мәктәпне тәмамлагач, Наил шәһәргә китеп, ГПТУда төзүче һөнәре бирә торган курсларга укырга керде. Әти-әнисе моңа да куандылар. Менә бит уллары шәһәрдә укып йөри. Өстәвенә ашау-эчү, киенү дә дәүләттән. Әйдә, бер тамак кимрәк булыр...

Шәһәрдәге төзелеш оешмаларының берсендә ике-өч ай монтажчы булып эшләгәч, егетне армиягә алдылар. Ата-ана монысына да көенмәде. Армиядә хезмәт итмәгән кеше сирәк, дөнья күреп кайтыр, холкы нығыр, диделәр.

Һәркемнең дә язмышында кискен борылышлар була. Армиягә алыну, әле анда да Әфганстанда хезмәт итү, Наилне тормышка икенче төрле карарга өйрәтте. Совет солдатларын интернационалист итеп сугыш хәрәкәтләрендә катнаштыру халык теленә «Әфган сугышы» дигән исем белән кереп калды. Үзебездә тыныч тормыш барганда, нindидер икенче бер илнең эчке эшләренә тыкшынып кан коеп йөрү тарихның бер ялгышы гына, дип бәяләнде. Кичәле-бүгенле мәктәп партасы артыннан чыккан, әле ныклап дөнья күреп тә өлгермәгән яшь кенә малайларны ут эченә кертеп, аларның рухына күпме зыян салынгандыр. Кайберләре дары исе иснәп, шул сугыш афәтеннән исән-имин кайтсалар да, мондагы мохиткә яраклаша алмыйча, җәмгыятьтән читкә кагылды, кайберләре эчкечелеккә салынды, икенчеләре йомылып яши башлады...

Бөтен кешенең дә язмышы бертөрле түгел: Наил дә, «интернациональ бурыч»ын үтәп, Әфганстаннан исән-имин кайтты. Егет «дары исен иснәп» кенә калмады, әлеге мәгънәсез сугышның бөтен авырлыгын үз иңендә татыды. Юк, кемнеңдер киң җилкәсе артына качып йөргәнгә генә исән калмады ул. Башкалар шикелле, «дух»ларның һөҗүмнәрен кире кайтарырга да туры килде, сугышчан заданиеләргә дә барды. Әйе, ут эчендә беркемгә дә ташлама юк, «Сугышчан батырлык өчен» медален дә юкка гына бирмиләр.

Армиядән соң озаклап ял итеп ятарга туры килмәде, Казандагы төзелеш техникумына юл тотты. Имтиханнарга әзерләнү өчен вакыт кына калмаган иде. Шуңа күрә, имтихан сорауларына җавабы да әлле-мәлле генә булды. Белеме белән артык ялтырамаса да, күкрәгенә медаль таккан бу егетнең әфганчы булуы ярдәм итте: имтихан алучы укытучы билгене җәлләмәде. Әнә шулай итеп, бер михнәтнең — бер рәхәте, дигәндәй, укырга да керде, энеләрен-сенелләрен аякка бастыру өчен тырышкан ата-анасына җинелгәрәк туры килер дип, төнге каравылчы булып эшкә дә урнашты. Буш вакытларында вагон бушатып та акча эшләштергәләде.

Техникумда үткән елларында ул тагын да җитдиләнде, ныклап, тырышып

укырга кирәклегенә төшенә башлады. Белемен булмаса, син дөньяда беркем дә түгел икән — әнә шуны анлады егет. Тырышлыгы юкка булмады, уку буенча алдынгылар рәтендә барды. Хәтта берчакны техникум дирекциясе исеменнән авылга әти-әнисенә рәхмәт хаты да юлладылар. Соныннан әтисе: «Малай прафисыр булырга жыена ахры, укыган жиреннән мактап хат язганнар», — дип, шул рәхмәт хаты белән күрше-күләнгә мактанып та йөргән бугай. Авыл укытучыларына да шәп кенә эләккән, улыгыз кәчкә өчкә укый, дип гел зарландыгыз, әнә, Казаннан мактау хатлары ява гына. Үзегезнен укыта белмәгәнегезне балалардан күрмәгез, дигән Хәким абзый. Сонгы сүзләре Наилнен әле һаман да авыл мәктәбендә укучы энекәш-сенелкәшләре өчен әйтелгән иде, әлбәттә. Алар да абыйларыннан әллә ни ерак китмәгән. Укулары куанырлык түгел. Ата-аналар жыелышына барган саен әниләре өчен мәктәптән һаман шул зар булып ияреп кайта. Дөрес, әлеге рәхмәт хаты балаларына кайчак үрнәк итеп тә кулланыла. Әнә, абыегызны күрегез, янәсе, сезнен кебек икелегә-өчлегә укып, ата-анасынын йөзенә кызыллык китерми.

Үлем белән йөзгә-йөз очрашкан кеше генә тормыш кадерен чын-чынлап белә башлый диләр. Шулай микән? Югыйсә, сугыш мәхшәреннән исән-имин кайтып та, илдә үзләренә таяныч таба алмыйча, тормыш төпкеленә төшкән егетләр аз түгел. Ә Наил төпкә төшмәде, киресенчә, күтәрелә генә барды.

Ул производствога килгәч жәмәгать эшләреннән читләшмәде. Аеруча, Әфганстанда сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан егетләрнең яшәешен, көнкүрешен яхшырту буенча тырыша башлады. Эреле-ваклы түрәләрнең ишекләрен еш шакырга туры килде ана бу мәсьәләдә. Уңышсызлыкка очраган чакларында егет ярты юлда туктамый, жилкәннәрен тиз генә төшерергә жыенмый, кем әйтмешли, ишектән куып чыгаралар икән, тәрәзәдән килеп кереп, түрәнең каршысына баса. Һәм бу тырышлыклары юкка гына булмады. Тиздән аны шәһәр түрәләре таный, ә гади кешеләр хөрмәт итә башлады. Шулай итеп, студент чактагы «Шустряк» кушаматы онытылып, ул әкрен генә Наил Хәкимовичка әверелде.

Прораб итеп куйгач Наил Хәкимович, югары белем кирәклеген анлап, Казан төзүче инженерлар институтына читтән торып укырга керде. Кул астында эшләүчеләр белән дә, житәкчеләре белән дә уртак тел таба белә. Үзенен «служебный» машинасы булмаса да, трест инженеры Афанасьевнын иске генә «ГАЗ–69» машинасы белән берничә мәртәбә авылына кайтып килде. Гаилә башлыгы Хәким абзыйның авылда дәрәжәсе күзгә күренеп үсте. Ул хәзер чынлап торып улы белән горурлана — менә бит нинди егет үстерде...

* * *

Көзге көннен матур иртәсендә Зәйтүнә бакчага барырга уйламаган да иде. Иртән кер юарга әзерләнгәндә, өйдә сабын юклыгы беленде. Кибеттән тиз генә сабын алып кайтыйм дип урамга чыккан иде, күрше подъезд янында танышларын — ирле-хатынлы Хатип белән Минсылуны очратты. Бакчага барырга жыенып йөрүләре икән. Шунда, көзен автобуслар сирәк йөргәч, юл унае бит, әйдә утыртып алып барабыз дип үзләре тәкъдим иттеләр. Бераз икеләнеп торгач, Зәйтүнә ризалашты. Керләрне сонрак та юарга була бит. Дүрт стена артында бикләнеп ятканчы, бераз саф һава да сулармын, дип уйлады ул үзенчә.

Сонгы көннәрдә улы күзгә-башка чалынмагач, болай да ике ут арасында яна. Дөрес, килене Люба, Марат озак вакытлы командировкага китте, ярты елсыз да кайтмас дигән иде. Шул сүзләрдән бераз тынычлангандай булды

булуын, тик ниндидер яман шик һаман күңелен тырнап тора. Милиция формасындагы кешеләрнең килеп, сораштырып йөрүләре дә бу шиген көчәйтте. Шуларны уйлап монда акылдан шашарга мөмкин, бераз кеше белән дә аралашырмын дип күңелен юатты...

Машина Зәйтүнәнең бакчасы янына житеп туктагач, Миңсылу, кабинадан төшеп койма аша гына жиләк-жимеш агачларын караштыргалап торды. Урам капкасын ачып, өйгә таба баручы хатынга: «Теге алмагачыгыз нинди сортлы, монысы нинди?» —– дигәнрәк сораулар бирде.

Зәйтүнә, өйгә якынлашып, кесәсендәге ачкычларын да барлый башлаган иде инде. Шулчак күзе ишек бигенә төште. Ул ачылган. Соңгы вакытларда, бакча өйләренең йозакларын ватып, әйберләр урлап чыгу очраклары гадәти күренешкә әверелде. Анысына шаккатасы түгел. Ләкин монда йозак та ватылмаган, күгән дә каерылмаган. Ә запас ачкыч бары тик Маратта гына. Зәйтүнә, ничектер, күңеле белән, улы өй эчендәдер дип уйлап алды. Тик ни өчен ул анда булырга тиеш? Менә анысы аңлашылмый. Шуңа күрә, әле һаман да китәргә ашыкмаган, сораулар биреп йөдәтүче теге хатынга игътибар итмичә, ишек янына килеп, сак кына аны үзенә тартты. Ишек эчке яктан бикле түгел иде. Хатын ачты да куркудан катып калды. Нәкъ анын каршында бауда кеше гәүдәсе асылынып тора...

Анын ачыргаланып кычкырганын инде машинага кереп утырып, ишекне ябарга жыенган Миңсылу да, ире Хатип та яхшы ишеттеләр. Йөгереп килеп житкән юлдашларына берни дә әйтә алырлык хәлдә түгел иде шул Зәйтүнә. Ул бары тик бармагы белән ишеккә ишарәләп алды да үксеп жиргә чүгәләде. Хатип ишекне ачып карады һәм каршындагы күренештән өнсез калды...

Калганнары бик тиз эшләнде кебек. Хатип, машинасына утырып, милиция чакырырга шәһәргә кайтып китте. Зәйтүнә аңа килене Любаның адресын әйтте. Мондый вакытта аннан да яхшы киңәш бирүче булмас, шалтыратып кара дип, Наил Хәкимовичның телефон номерын бирде. Хәер, ул бу хакта Хатип китәргә жыенгач кына исенә төшерде. Чыннан да, мондый кайгылы вакытта ялгыз хатынга төпле киңәш бирердәй, кайгысын уртаклашырдай һәм кирәк чакта тиешле ярдәм күрсәтә алырдай бер якын кешесе дә юк иде...

Бер сәгать үтте микән, милиция һәм «Ашыгыч ярдәм» машиналары да күренде. Алардан тыш, каяндыр ишетеп өлгергән берничә кеше килеп басты. Наил Хәкимович та биредә. Ул килгәндә, милиция хезмәткәрләре Маратның гәүдәсен баудан төшергән, ишек алдына чыгарып салган иде инде. Аны караштыргач, янәшәсендәге егеткә нидер әйтте. Аннан милиция төркеме белән килгән капитанга ниндидер күрсәтмәләр бирде. Соңыннан гына шушы көтелмәгән фажигадан нишләргә белмичә гажизләнеп калган ана янына килеп, анын кайгысын уртаклашты. Нык булуын, кайгыга бирешмәвен теләде. Бөтен эшен ташлап монда килеп житкән һәм чын күңелдән кайгысын уртаклашып торучы бу кешедән дә якынрак беркеме дә юк иде ялгыз хатынның...

Өй тирәсенә беркемне дә якын китермәделәр. Вакыйга урынын фотога төшереп алдылар. Өй эчен һәм ишегалдын да бик жентекләп тикшереп чыктылар. Тирә-якны карарга да онытмадылар. Урамның икенче ягына китеп барган милиционер тиз генә кире борылып та килде. Оператив төркем житәкчесенең колагына иелеп, нидер әйтте. Кыяфәтенә караганда, ул тагын нәрсәгәдер тап булган. Маратның гәүдәсе янында милиционер калдырып, барысы да шул якка ашыктылар. Ә бераздан аларның берсе жыелып торучылар янына килде дә, пүнәтәй итеп өч кешене чакырды.

Өйдән нибары илле-алтмыш метр ераклыкта, тыкрыкка борылган жирдә, тагын бер мәет ята иде. Аны чәнчеп үтергәннәр. Күкрәгендәге канлы ярасы

шул хакта сөйли. Оперативникларның: «Танучылар юкмы?» — дигән соравы җавапсыз калды...

Ике урам чатында калган «Ока» машинасы тикшерүчеләрне үзенә җәлеп итте. Кычкырып эзләсәләр дә бирегә килүчеләр арасында аның хуҗасы табылмады. Якын-тирәдәге йортларда да бер җан иясе юк.

Машинага беркетмә төзеделәр.

Корбаннарның гәүдәсен моргка алып киткәч, Наил Хәкимович Зәйтүнәне өенә кадәр озатып куйды. Әле аның фатирында ярты сәгатьләп утырырга да вакыт тапты.

— Әше дә яхшы, якын-тирәсендә йөрүчеләр дә мин белгән ышанычлы кешеләр иде. Күрәсең, читтән йогынты ясаучылар да булгандыр. Кызганыч, бик кызганыч, билгеле...

Зәйтүнә аның сүзләренә каршы җавап табарлык хәлдә түгел иде. Ул бары тик ыңгырашкандай аваз чыгарды да:

— Белмим... Башыма сыйдыра алмыйм... Ничек болай килеп чыкты соң? — дип сөйләнгәндәй итте.

Шактый гына сөйләшмичә утыргач, Наил Хәкимович, урыныннан кузгалып Зәйтүнәнең иңнәреннән тотты да нык булырга кушып, ишеккә юнәлде...

Маратны җирләүне дә Марат Хәкимович шәхсән үзе оештырып йөрде. «Сез — житәкче кешенең мәшәкатьләре болай да баштан ашкандыр. Моңа кадәр күрсәткән ярдәмегез өчен дә рәхмәт. Үзебез җаен табар идек әле», — дигән сүзләргә ул кул гына селтәде.

— Үз энем шикелле якын күрдем. Соңгы ярдәмем булыр, — диде.

* * *

Наил Хәкимович Маратны эшкә урнаштыру мәсьәләсендә үзенә чакыргач: «Менә нәрсә, энем, махсус белемең булмагач, мин сиңа житәкче урыннар вәгъдә итә алмыйм. Ә акчалы эш табарга мөмкин. Минем бер якын танышым бар. Аның предприятиесе зур түгел. Шулай да акчаны шәп сугалар кебек. Кайвакыт үзем дә, их шунда гына эшләсәм, мондагы тиеннәргә карап ятмас идем, дип көнләшеп куям. Ә киләчәктә кем булуың синнән тора. Үзеңне күрсәтә аласың икән... Беркем дә министр булып тумаган. Барыбыз да түбәннән күтәрелдек. Мин үзем әле бөтенләй авылдан чыккан малай. Хезмәт юлымны төзүче-монтажчы булып кына башладым. Ә хәзер шактый гына йогынтылы адәмнәр дә минем белән исәпләшә. Барысына да үз көчем белән ирештем...» — дигән иде. Аның, үзе әйткәнчә, тиеннәргә генә эшләп йөрмәгәнен Марат бик яхшы чамалый. Кая инде җылы урынны ташлап китү. Аркан белән сөйрәсәләр дә тырышып-тырмашып урынында калачак ул.

Алай да түрә сүзендә торды. Берәр атнадан Марат эшкә урнашты. Шәһәрнең зур гына гаражлар кооперативында мастерскойга слесарь итеп алдылар аны. Баштарак шөреп боргалап йөрде, нәрсә кушсалар шуны җиренә житкереп үтәргә тырышты.

Бу мастерской янәшә урнашкан җиде-сигез боксны берләштерә. Һәммәсе уртадан ишек белән тоташкан. Кайберләренә генә тыштан керешле. Боксларда эшләүчеләр саны өч-дүрттән артмаса да, алар аерым бер цех дип аталалар.

Мастерской гараж кооперативының бер бүлекчәсе булып исәпләнсә дә рәсми яктан аңа бернинди катнашы юк. Марат моның шулай икәненә эшли-эшли төшенде. Кооператив директоры бу тирәләргә бер мәртәбә дә килеп чыкмый. Ә мастерской житәкчесе, ниндидер Анисимов Юрий Николаевич дигән йомыкый гына адәм, эшчеләр белән аралашырга бик яратмый, кайчак

көннәр буе күзгә-башка чалынмый. Монда тагын нindидер кирәкмәгән «пом»нар, цех житәкчеләре, мастерлар бар. Кемнең нинди урында һәм нәрсә белән шөгыльләнүен Марат үзе дә тәгаен генә анлап бетерми иде. Хәер, анын өчен алары вак мәсьәлә. Иң мөһиме: эш бара, замана авыр дип тормыйлар, акчасын түлиләр.

Юрий Николаевичның монда төп роль үтәмәгәнлеген Марат тиз чамалады. Бер көнне ул йомышы төшеп, автомастерской житәкчесе кабинетына кергән иде. Вакытсызрак туры килде бугай. Кабинетта Анисимов үзе һәм машиналарны ремонтка кабул итү цехы житәкчесе Василий Кулагин нәрсә хакындадыр сөйләшәләр. Маратны иң гажәпләндергәне шул булды: Кулагин өстәл каршындагы урындыкка җәелеп утырган да тавышын күтәребрәк нindидер күрсәтмәләр бирә. Әллә әрли иде шунда. Анисимов исә, акланырга тырышкан гаепле бала кебек, кәнәфиеннән торып анын каршысына баскан. Василий Кулагин, әнгәмә белән мавыгып, Маратның кергәнен тоймады. Марат Анисимовның үз урынында бер «пешка» гына икәнлеген анлады.

Наил Хәкимович биредә берничә мәртәбә күргәләде. Кыяфәтенә, үз-үзен тотышына караганда, ул монда кунак түгел, ә үз кеше иде сыман. Анисимов та анын янында йомышка йөгерергә әзер торган малайны хәтерләтә. Ул килгәч, Кулагин да гел шул тирәдә кайнаша. Кайчак алар өчәүләп: Анисимов, Кулагин һәм Наил Хәкимович житәкче кабинетына кереп китәләр дә сәгатьләр буе чыкмыйлар.

Дөрес, Марат боларына әллә ни игътибар итмәскә тырышты. Түрәләрнең кайда нәрсә кыланып йөрүләрендә эше юк ла анын. Тик Вася Кулагинның гына гел житәкчеләр тирәсендә бөтерелүен өнәп житкерми. «Кулак» кайчак монда эшләүчеләргә күрсәтмәләр бирүдән дә тарсынмый. Ә эшчеләр берсүзсез буйсыналар тагын үзенә...

Дүрт-биш айлап, шулай, шөреп борып йөргәч, Маратны да Вася Кулагин эшли торган хәзерлек цехына күчерделәр. Николай исемле слесарь егет бу көннәрдә аварияга очрап үлгән дә. Марат анын урынына килде.

Бу бокс башкаларына караганда бераз зуррак. Һәм, алардан аермалы буларак, биредә арткы якта ике бүлмә бар: берсендә Анисимов үзе утыра, икенчесендә — Кулагин Вася. Эш булмаган чакларда Женя белән Марат та шунда кереп ял итә. Артык зур булмаса да, ул уңайлы итеп җиһазландырылган: өстәл, диван, кресло кебек әйберләр куелган. Музыка тынлыйм дисәң транзистрлы радиоалгыч, аклы-каралы телевизор да бар хәтта. Ике жылыткыч, чәй кайнатып эчү өчен электр чәйнеге дә тора. Түрдә — зур гына сейф, ачкычы Василий Кулагинда. Ул анда нәрсәләр саклыйдыр, Марат монысын тәгаен генә белми. Чөнки Марат барында, Вася сейфны бары тик бер мәртәбә генә ачты. Анда да гәүдәсе белән каплап торды, жилкәсе аша берни дә күренмәде. Сейф янындагы өстәл түрендә агачтан бизәкләп эшләнгән урындык та Кулакныкы. Үзе монда чакта анын «тәхет»енә беркем дә утырмый. Бары тик ул каядыр юкка чыгып торганда гына Женя менеп кунаклаштыргалый, һәм биредә Васядан кала икенче кеше икәнлеген күрсәтү өчен киерелеп утыра. Ә Женя монда эшләүчеләрнең өченчесе. Артык күп сөйләшми. Васяның сүзеннән чыкмый торган егет. Эше төшеп, кереп чыгучыларны исәпләмәгәндә әнә шулар гына.

Биредә эш тә әллә ни авыр түгел икән. Машиналарны ремонтка әзерләү өчен бер кат тикшереп чыгасы гына. Аннан соң машина хуҗасына ремонт өчен базардан нинди запчастьлар алырга кирәклеген ачыклап, кайсы цехка кертергә икәнлеген әйтәсең. Күпчелек очракта, килгән машиналарны бокс эченә кертеп тә тормыйлар, урам якта гына карап, янәшәдәге бокска куалар иде. Бу эшкә нибары егерме-утыз минут житә. Ә калган вакытта Женя белән Марат, эчке бүлмәгә кереп, карта суга, телевизор карый. Диванга ятып,

алмашлап «черем» итеп алган вакытлары да булгалый. Кайчак Василий да алар белән карта суккалый. Дөрес, Вася белән Женяның «девятка»га утырып чыгып китеп, ятрышар көн кайтмаган чаклары да була. Киткәндә алар Маратка цех эченә тәртип ясарга кушып калдыралар иде.

Монда күчкәннән соң көннәр әнә шулай үтә торды. Эше аз булгач түләве дә кимрәктер дип Марат башта икеләнеп тә йөргән иде. Әллә соң хуҗалардан сорап, элекке цехка кайтыргамы, дип уйланган чаклары еш булды. Тик акча алгач, алай ашыгып уйланганы өчен үзе дә оялып куйды. Хезмәт хакы элеккегә караганда бермә-бер күбрәк иде. Марат нинди хезмәтләре өчен мондый суммаларга лаек булуын төшенмәде.

Дөрес, тора-бара, ул мондагы хәлләрнең гадәти түгеллеген аңлый башлады. Аның үткен күзеннән кыңгыр эшләр читтә калмады. Кулагин белән Женяның сакланыбрак сөйләшүеннән, монда закон кысаларына бик үк сыймаган гамәлләр эшләнүен дә шәйләп өлгерде. Марат, әлегә турыдан-туры аларда катнашмаса да, үзен шуңа әзерләгәннәрен сизенде.

* * *

Бер мәлне Женя Маратка ачыктан-ачык: «Мондый заманда гел туры юлдан гына йөреп булмый, братан, әгәр кешечә яшәргә телисең икән, бөтерелергә туры килә», — диде. Ул көнне алар боксына юеш асфальт төсендәге бер «десятка» машинасы кертеп куйганнар иде. Дөресрәге, Марат аны кайчан, кемнәр керткәнен күрмәде дә. Төнлә булгандыр. Чөнки, егет иртән эшкә килгәндә машина анда иде инде. Вася, Женя һәм тагын берничә таныш түгел егет шунда кайнашалар. Күренеп тора — бу гадәти ремонтка кертелгән машина түгел. Аның тирәсендә кайнашучы егетләр дә машинаның хуҗалары булырга охшамаган. Женя аларның берсенә — Косой, икенчесенә Зебра, дип дәште. Димәк, алар күптәнге танышлар. Машина урланган булырга тиеш. Аның шулай икәнен Марат сизә. Бу ике егет машинаны алып кайтканнар да, эзләрен югалту өчен монда яшереп торганнардыр. Озакламый алып китәрләр дип фикер йөртте үзенчә. Тик машина бокста тагын атнадан артык торды әле. Марат, аның двигатель номерын үзгәртүләрен, башка төскә буяуларын һәм яңа документлар рәсмиләштерүләрен күреп, белеп торды. Шул көннәр эчендә ни Зебра, ни Косой бөтән күзгә-башка чалынмады. Янарган машинаны сатып җибәрүче дә Вася үзе булды. «Бәхетле» сатып алучы ГАИда законлы рәсмиләштерелгән машинасына утырып киткәч, Маратка боксны чистартып чыгарырга куштылар. Ә үзләре, арткы бүлмәгә бикләнеп акча санадылар, дөресрәге, бүлештеләр. Әлбәттә, Женя белән Вася үзләрен рәнҗетмәгәннәрдер. Кемнең — кулында, шуның — авызында... Ә менә Маратка өлеш чыгар микән, анысы билгесез. Бу эшкә әллә ни катнашмады бит. Хәер, кыңгыр эшне күреп тору үзе үк шул эштә катнашу кебегрәк инде. Өлешсез калдырмаслар анысы... Әйе, юраган — юш килде. Әнә шул өлешне кесәсенә шудырганда әйтте дә инде Женя, «гел туры юлдан гына йөреп булмый», дип.

Әле монысы баласы гына, алда тора анасы, дигәндәй, Маратка да гел бокста кәрт сугып кына ятарга туры килмәде. Бер кичтә Вася белән Женя, үзләре белән Маратны да алып, «савым»га чыгып киттеләр. Гел бокс саклап ятмас бит инде, эшкә өйрәнергә вакыттыр, диде шунда Женя. Ул көнне аларны үзәк урам чатында Косой белән бәдән ныгыткан тагын ниндидер егет көтеп тора иде. Аларны да үзләре белән алдылар.

Атап барган җирләре студентлар тулай торагының подвалына урнашкан «Мебель» кооперативы икән. Монда абыйлы-энеле ике бәндә кечерәк кенә цех ачып, агачтан җиһаз ясау белән шөгыльләнә башлаган. Гади генә эш кораллары, тегеннән-моннан җыеп ремонтланган иске станоклар.

Мондыйлар белән әллә нәрсә майтарып та булмас иде. Тик егетләр, күренеп тора, үзләре тырыш. Кулларыннан да килә икән. Яңарак кына ясалган ике тумбалы өстәл шул хакта сөйли.

Вася егетләре үзләрен хуҗаларча тоттылар. Мондый урыннарда еш булырга туры килә күрәсең. Косой, килеп керүгә ишек янәшәсендәге электр рубильнигының тоткычын үзенә тартып куйгач, түрдә эшләгән «циркулярка» тынып калды. Анда иске халат кигән бер ир агач борыслары телә иде. Ул, эшеннән туктап, кереп килүчеләргә төбәлде. Арырак, диван кебегрәк әйбер җыеп маташучы өч кеше дә күтәрелеп, бу тарафка карады. Вася, казиен кләе белән ябыштырылып, стена кырыендагы җылылык батареялары янәшәсенә киптерергә куелган урындыкларның берсен үзенә тартыбрак, җәелеп утырды.

— Закир, нәрсә кунакларны каршыламыйсың?..

Аның соравына каршы, түрдә диван җыеп торучыларның берсе, билен турайтып күтәрелде дә Кулак каршысына атлады. Кооперативның җитәкчесе Закир шул икән инде. Икенче төрле әйтсәк — эшмәкәр. Ул килеп күрешергә кулын сузса да Вася аның сәламен алырга ашыкмады. Шуңа күрә теге мужикның кулы һавада асылынып калды.

— Закир, син нишләп миңа һаман буш кулыңны сузасың. Андыйлар үзебездә дә бар. Инде буш куллар белән сөйләшә торган вакытлар күптән узды?..

— Соң, егетләр, мине дә аңлагыз. Мантып җитә алмыйбыз бит. Әле тегесе, әле монысы акча даулый...

— Тукта, егеткәем, син моннан өч ай элек тә нәкъ шул сүзләрне әйткән идең түгелме? Күпме көтәргә була тагын?.. Син бәлки беркайчан да мантый алмассың...

— Арендага, материалы-чималы өчен түләргә, налогы... Эшләүчеләргә хезмәт хакы бирергә дә калмый бит... Өстәвенә «крыша»га акча сорап җаңга тиясез...

Бу сүзләргә Вася күркә кебек кабарынды. Ул Закирның якасыннан умырып тотып үзенә тартты.

— Син нәрсә, үләксә. Мине һәрчак шулай алдап котылмакчы буласыңмы? Моннан бер атна элек билгеләнгән сумманы әзерләп куярга кушылган иде. Ә син һаман күзгә төтен җибәрәсең. Болай булса, мин синең бу хәчтрүш мастерскоеңа ут төртеп, ун минутта көлгә әйләндерәм бит...

Шулчак, әле яңа гына «циркулярка» янында торган икенче мужик килеп, араларына кермәкче булды.

— Барыгыз да акча даулап килә башладыгыз. Әрәмтамаклар! Акчаны алу өчен башта эшләргә ки...

Ләкин ул сүзен әйтеп бетерә алмады, янәшәдә генә торган Косой аңа саллы гына селтәнгән иде, мужик, артка мәтәлеп, киптерергә өеп куелган урындыкларга ауды. «Пирамида» җимерелеп, ап-ак агач урындыклар, шалтор-шолтыр килеп, тегенең өстенә ишелде. Закир аңа ярдәмгә ташланды, кабаладан тартып чыгарып, аягына басарга ярдәм итте. Бу Закирның энесе икән. «Кызу» егетнең авыз-борыныннан кан киткән. Закир аны тынычландырып азапланды. Ә Вася исә урыныннан да кузгалмыйча, моны тыныч кына күзәтеп утырды да тагын сүз башлады:

— Нәрсә, Закир, егетләреңне безгә каршы күтәрелергә өйрәтеп куйган идеңме әллә? Үзеңне үзең якламакчы буласыңмы? Ха! Барып чыкмас. Түбәдән башка син беркем түгел. Мөлкәтеңне яклый да, саклый да алмаячаксың, ахмак. Хәзергә безнең хезмәткә мохтаҗ син. Ә хезмәт өчен түләргә кирәк! Аңладыңмы, адәм актыгы?..

Вася, йодрыгын йомарлап, Закирның эченә төртте. Мужик авыртуга түзә

алмыйча корсагын тотып бөгелде. Аннан, чыраен сытып, авырлык белән генә күтәрелде. Күренеп тора, хезмәт белән тәрбияләнгән бу авыл егетләре хәзерге зил-зиләле, тынгысыз тормышка ияләнмәгәннәр. Кулларыннан эш килсә дә, мондый «разборка»ларга әзер түгел шул алар. Шуна күрә Закир тиз йомшарды. Гаепле кыяфәткә кереп:

— Егетләр, без крыша дип акча кысып китүчеләр дә күбәйде бит хәзер. Кемнен кем икәнен белмәссен. Килеп керәләр дә, пистолет терәп, акча даулыйлар. Әле узган атнада сезнең белән очрашкач та, өч «текә егет» кереп, без сезнең крыша, дип, пистолет белән куркытып, акча каерып чыгып китте. Инде тагын сез килеп кердегез. Бездә Әндри казнасы юк бит. Эшләүче егетләр инде ничә ай рәтле акча алганнары юк. Мин монда үзем житәкче, үзем бухгалтер, үзем үк эшче дә, ничек итеп очын-очка ялгарга белмим...

— Ха! Авыр дисен инде алайса?..

— Инде болай да үләргә житешеп, азапланып кына яшисен, шулай яшәргә дә ирек бирмиләр. Нишләргә кала сон безгә?

— Син нәрсә, көчәнмичә генә ты...га жыенган иденме әллә? Алай бармый ул дөнья, братуха...

Вася, урыныннан торып, ясалган өстәл янына килде. Аны бер әйләнеп чыкты. Агач өслеген сыйпаштыргалады, тумба ишекләрен ачкалап карады.

— Моны күпмедән жибәрәсез сон?

Закир уйланып торды да:

— Күпмедән, дип... Алай төгәл куйган бәясе юк... Барыбер без куйган бәяне бирмиләр. Без кайчак әйберләтә дә алабыз. Ит, бәрәнге, мәсәлән...

— Ит әйбәт инде ул... Әле шушы көннәрдә генә кооперативыгызга машина алып куйгансыз икән дип ишеттем... — Бездән берни дә яшереп калдыра алмассын дигәндәй, масаеп, егетләр ягына карап куйды.

Закир аклангандай сөйләнә башлады:

— Әй, аны машина дисән, хәтере калыр... Төбе череп беткән, кырык ямаулы иске «Каблук» инде. Складтан материалларны йөртергә транспорт кирәк. Читләргә ялынырга туры килә. Ә аларга тагын акча түләргә. Ә болай үзебезнеке...

— Иске, дисен инде?..

— Әйтәм бит, срогын күптән тутырган машина дип...

— Шулай булса да, машина әле ул... Акчам юк, дисен, ә үзен машина алгансын. Бушка гына бирмәгәннәрдер, югыйсә?..

— Әле анын ярты бәясе дә түләнмәгән. Калганына мебель ясап бирергә сөйләштек... Менә бу өстәл дә шуна...

Вася өстәлне тагын бер мәртәбә әйләнеп чыкты.

— Мин синен машинанны гына конфисковать итәр идем. Тик без кешенен сонгы әйберсен тартып алырга жыенмыйбыз. Бу юлы менә шушы өстәл дә ярап куяр...

Закир, нәрсәдер анлатырга тырышып, сон, егетләр, дип мыгырдана башлаган иде, Вася аны шунда ук бүлде.

— Станокларын бар, кабат ясарсыз. Ә монысын иртәгә, минем егетләр машина белән килгәч, салып жибәрерсен. Закир, ан бул, мина тере акча кирәк. Икенче килгәндә, агач белән генә котыла алмассын. Монысында гафу итәм...

Аннан сон, Закирнын энесе ягына борылып:

— Ә син, үләксә, кулынны кемгә күтәргәненне белеп күтәр. Юкса...

Вася, юкса нишләтәсен әйтеп бетермәде, лачкылдатып идәнгә төкерде дә ишеккә борылды. Яраннары, бер командага буйсынгандай, анын артыннан

атладылар. Косой абыйлы-энеле эшмәкәрләрнең каршысыннан узганда, уң кулының биш бармагын да тырпайтып, Закирның йөзенә якын китереп боргалады, кыяфәтен чалшайтып, ырылдаган аваз чыгарды...

* * *

Вася соңгы вакытларда Наил Хәкимовичтан шикләнә башлады. Шулай булмый соң, тегесе гел тырнак астыннан кер эзләп кенә йөри. Ник тегеләй эшлисең, ник болай эшләмисең. Тирәнә шикле адәмнәр җыйгансың дип тә бәйләнеп алгалады. Димәк, аны юлыннан алып ташламакчы була. Инде үзләре янына мастерскойга Маратны урнаштыргач, бу шик көчәйде генә. Чыннан да, Вася урынына алмаш әзерли булса кирәк. Берчакны Хәкимыч автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү предприятиесенең элекке данын кире кайтарырга кирәк диген сүзләр дә ычкындырды. Әйе, Васяның эшеннән канәгать түгел. Өстәвенә, хәзерге вакытта предприятие җитәкчесе булып исәпләнүче Анисимов инициативасыз кеше. Маратны әнә шул урынга әзерләмиме икән, дигән уй бораулый иде аның миен.

Шикләнергә урын да бар кебек: Әфганстан һәм башка локаль сугышларның ветераннары оешмасы да таркала башлады. Очрашулар әллә нигә бер генә була. Анда да егетләр бармак белән санарлык кына килә. Һәрберсенең тормыш мәшәкатьләре, гаиләләрен тартып барырга кирәк. Аннан соң, Наил Хәкимовичның оештыру эшләренә үзенең дә вакыт ягы тарайды. Шәһәр күләмендә башкарыласы җәмәгать эшләре башыннан ашкан. Аның өчен оешма хәзер икенче планга күчте. Бервакыт Наил Хәкимович, оешмага яңа рәис сайлап, җыелышларны җанландырып җибәрергә кирәк дип тә сөйләнгән иде. Ул урынга да Маратны куюны күз унында тоткандыр бәлки. Бер атуда ике куян — ветераннар оешмасы җитәкчесе һәм, шул ук вакытта, шәхси предприятие директоры да. Тик Вася моңа риза түгел... Алай гынамы, теше-тырнагы белән каршы...

Вася, әлеге хәлләрдән соң Наил Хәкимович турында: «Үсте, симерә башлады», — дигән нәтиҗә чыгарды. Югыйсә, аны кеше итү өчен алны-ялны белмичә йөгереп йөргәннәренә кайчан гына әле. Әйе, власть кешене боза шул... Бер югарыга күтәрелгәч түбәндәгеләрне таптап узу җиңел. Күтәрелү өчен үзе дә гел чиста юлдан бармады бит. Трест начальнигы Нур Гаяновичны юлыннан алып ташлаганда Вася ярдәменә мохтаж иде ул. Депутатлыкка күрсәткәндә, халык арасында өндәү эшләре алып барганда да Васядан башка гына әллә нәрсә майтара алмас иде. Ә хәзер әнә, ул кирәк түгел. Ярар, әгәр алайга китсә, Вася үткәндәге гөнаһларынны тиз исенә төшерер...

Анисимов дигән бәндәне рәсми рәвештә шәхси предприятие директоры итеп кую Кулагинны чын мәгънәсендә чыгырыннан чыгарды. Әлеге урынны үзе өмет иткән иде ул. Бу нәрсә? Элеккеге дуслыкларын инкарь итүме, ышанмаумы, әллә башка сәбәпләре дә бармы?.. Тик боларны ул Наил Хәкимовичның йөзенә туры бәреп әйтә алмады. Сез алай эшләсәгез, без болай да эшли беләбез, дигәндәй «әфганлылар» җыелышына йөрми башлады. Читтән әшнәләр тапты. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың дигәндәй, Вася, әкренләп кыңгыр эшләргә чумды. Яңа дусларны өйрәтеп торасы юк, караклык, юлбасарлык, шантаж — аларның төп кәсебе. Төрмәдә утырып чыкканнары күп, берничә мәртәбә утырганнары да бар. Аларга тиешле юнәлеш биреп, бер йодрыкка тупласаң, мондый болганчык елларда акчаны күрәргә була. Вася әнә шул аерым кисәкләрне аз гына вакыт эчендә йодрыкка туплый алды да инде. Ни әйтсәң дә, Наил Хәкимович мәктәбен үткән кеше бит. Шуның ярдәме тиде. Дөрес, Вася бу очракта да хәйләгә керешә. Ул егетләр алдында үзен төркем лидеры итеп түгел, ә

андагы икенче кеше итеп күрсәтте. Төркемдәгеләр барысы да Кулагиннан өстә босс барлыкка ышаналар иде һәм алар Васяның күрсәтмәләрен түгел, ә анықын үтәүләренә шикләнмиләр иде. Чөнки югарыда ниндидер йогынтылы кеше булганда гына, төркем әгъзалары үзләренең тыллары ныклыгына ышаналар. Югары постларда утыручы җилкәләр артында закон да куркыныч түгел. Андый төркемнәр озак яши. Әнә шуңа да Вася күп «указ»ларын уйлап чыгарылган босс исеменнән бирә иде. Ул Наил Хәкимычмы, Иван Иванычмы, Гали Галиечме яисә башка берәүме, барыбер... Төркемдәгеләр өчен ул — босс!

Төркем җинаятьчел сферада танылсын өчен, әлбәттә, аның исеме булу шарт. Монысына Кулак икеләнеп тә тормыйча «әфганлылар» дип кушты. Дөрес, Васяның үзеннән башка алар арасында Әфганстанда яки «кайнар нокта»ларда хезмәт иткән берәү дә юк. Гомумән, шикле төркемнең әфганлыларга бернинди катнашы да юк. Тик бу исем Кулакның үзенә бик ошый. Яңгырашы да әйбәт. Башка төркемнәрдәгеләрне бераз гына шүрләтә дә кебек.

Шәһәр җинаятьчел төркемнәр тарафыннан, шартлы рәвештә, йогынты сфераларына бүленгән. Үз «хуҗалыгыңны» чит төркемнәр йогынтысыннан саклау өчен күп көч куярга кирәк. Корал тотып аңлашуларда «Канга—кан, үлемгә—үлем» дигән бәрелешләрдә ике яктан да үлүчеләр еш була.

Инде төркем әгъзалары кайчандыр әфганлылар өчен оештырылган машиналар ремонтлау предприятиесендә очраша башладылар. Бирелән эштән киткән әфганчылар урынына Вася үз төркемендәге берничә «шома егет»не предприятиегә эшкә алуга да ирешге. Янында «әтүтән» кебек йөрүче Женя да аның үз кешесе. Хокук саклау органнарында шик уятмас өчен алар бирелә йә слесарь, йә каравылчы кебек штатларда торалар. Тик берсе дә үз вазифасына кагылышлы эшләр башкармый. Көндезләрен кәеф-сафа корып уздырсалар, кичләрен төнге «ауга» китәләр. Ә кайчак, машинага төяләп, көндезләрен дә шәхси эшмәкәрләргә «хәл белешергә» йөриләр.

Көннәрнең берендә Наил Хәкимович Васяга шалтыратып, «чыбык очы туган» тиешле бер егетне үзләренә эшкә алуны үтенде. Чечняда хезмәт иткән, утны-суны кичкән егет дип, мактап та алды.

— Алай бик яхшы егет булгач, ник үзегезгә генә алмыйсыз соң? — дигән сорауга:

— Соңгы вакытта төзелеш эшләре кимеде. Әле штатта торучыларны да кыскарту турында сүз алып барабыз. Сездә ичмаса акчасы яхшы булыр. Машиналар ватыла тора, китерә торалар, эше барның ашы да бар, — дип җавап кайтарды.

Вася белә, кирәк чакта юк урынны да бар итеп табалар, эшләп торган кешеләрен кыскартып булса да эш урыны ясыйлар. Хәзер инде төзелештә дә хәл ул кадәр үк начар түгел. Хәкимыч үзе, җае чыккан саен: «Мин трестны күтәрдем, эшләрне җайга салдым», — дип шапырынырга ярата. Шуларны уйлап, Вася җавап бирергә ашыкмады. Наил Хәкимовичның үтенечен кире кагарга да батырчылык итмәде. Ләкин, ахырдан булса да, аңа булган үпкәсен белдерергә җай тапты.

— Ни өчен аны миннән сорап торасыз соң? Юрий Николаевичка гына әйтергә иде...

Наил Хәкимович тамагын кыргалады.

— Сүз дә юк, Анисимовка да җиткердем. Ул каршы түгел. Тик эшчене нинди урынга билгеләргә кирәклеген барыбер син хәл итәсең. Юрий Николаевичның аның эше эшләргә бик тыгылырга яратмавын беләм, — дип куйды...

Маратны бер цехка слесарь итеп билгеләделәр. Вася баштарак сынап,

караштырып йөрде. Болай үзе ышанычлы егет кебек күренә. Бик осталардан булмаса да, акчасын эшләп алырга тырыша кебек. Тик менә Хәкимыч аны ни өчен урнаштыра? Анысы караңгы. Әллә соң эшчеләр арасында Васяга каршы астыртын гына коткы таратамы? Аннан җае чыгуга, «хап» артыңа тибәргә дә күп сорамаслар.

Марат бераз слесарь булып йөргәч, Вася аны үз янына — автомобильләрне хәзерләүләр цехына күчерде. Нәрсә эшләсә дә күз алдында булыр дип уйлады. Марат монда да үзен тыныч тотты. Биредәге кыңгыр эшләрне дә күрмәмешкә салыша иде. Бу сыйфаты ошады Васяга. Урланган машиналарны яңа төскә буяп, двигатель һәм кузов номерларын үзгәрткәннән соң, сатып җибәрүләрен күреп-белеп торса да, артык сәерсенмәде. Әлеге машиналар акчасыннан аңа да өлеш чыгардылар, әлбәттә. Аларын да берсүзсез кесәсенә шудырды. Вася егетнең җиңел кергән акча ятатуын аңлады.

Шулай итеп, Марат җинаятьчел төркемгә кереп киткәнен үзе дә сизми калды. Хәзер аның кушаматы да бар: үзара сөйләшкәндә «Марка» гына диләр. «Түбә» булып эшмәкәрләрдән акча җыюга да катнаша башлады, егетләр машина урлаганда корал тотып «шухер»да да торды, «разборка»ларның да нәрсә икәнлеген татып карады. Барысы да тәртиптә иде кебек. Васяның егеткә ышанычы көннән-көн арта барды.

* * *

Эштән соң Вася белән Женя сыраханәгә кереп утырдылар. Сыра бокаллары артында сөйләшү организмдагы киеренкелекне алып ташлый, имеш. Мондый шартларда кайчак күңелгә яхшы гына фикерләр дә килә. Алар гел шулай, үзләре «крыша» булып торткан «Хрустальный бокал» сыра барына кереп, гәп куертырга яраталар.

Бу юлы да, гадәттәгечә, анда кеше аз иде. Нибары бер өстәл артында әле борын аслары кибеп тә житмәгән биш яшүсмер утыра. Шактый гына кәефләнгән малайлар, тирә-якта кемнәр булуына игътибар да итмичә, ике сүзнең берендә, зәһәр генә сүгенеп сыра чөмерәләр. Сүз сөрешләре дә үз яшьләренә караганда шактый кыю: һәрберсе хатын-кыз затының итәк асты мәсьәләсендә үзен иң белдекле һәм тәҗрибәле икәнлеген күрсәтергә тырыша. Булдырганы ике мәртәбә арттырып сөйли, булдырмаганы кемнәндер ишеткән хәлләрне үз «батырлыгы» итеп бәянлый. Өстәвенә, һәр ике җөмлә саен барны яңгыратып, ихахайлап көлешәләр...

Вася баштарак аларга игътибар итмәде, бармен янынннан узышлый үзләренә ике бокал сыра һәм кипкән балык китерүен сорады да, аулаграк почмактагы өстәл артына барып утырды. Женя да аның каршындагы буш урындыкка чүмәште. Бүген ул теге көнне Закир кооперативыннан алган өстәлне әйбәт кенә бәягә сатып җибәргән иде. Көндәлек мәшәкатьләр турында берән-сәрән сүз алышудан башланып киткән әңгәмә бераздан шуна күчте. Күренеп тора, алыш-бирештән икесе дә канәгать.

– Закир егетләрен әйтәм, куллары эш белә. Мебельләре койган да куйган, фабриканыкы инде менә, шәп ясыйлар. Күргәзмәләрдә генә тотарлык, — дип, Женя осталарны мактап алды.

– Женя, аларның эшләре шул. Кемдер өстәлләрне ясый, ә кемдер алар артына утырып, дөнья рәхәтен татый, белдеңме? Дөнья шулай яратылган, братан. Ул безгә кадәр дә шулай булган, хәзер дә, алга таба да шулай барачак...

Вася, башлаган фәлсәфәсеннән канәгать калып, иренеп кенә киерелде. Авызын зур ачып иснәнеп алды.

– Купшы мебельләр ятатучы акчалы түрәләр өчен күктән төшкән бәхет булды ул өстәл. Бәясен дә әллә ни кыйммәт куймадым, — дип, сүзен дәвам итте Женя, зур батырлык кылгандай.

– Нишләп тагын да кыйммәткәрәк җибәрмәден соң?

– Ярар, Вася, монысына канәгать булыйк. Үзебез көч түгеп ясаган нәрсә түгел лә.

– Әллә соң беразын үз кесәңә шудырдыңмы?

– Син нәрсә, Вася, Алла сакласын! Күпме бирделәр, барысын да сиңа тапшырдым. Барчасы да уртак казанга.

– Кара аны, Женя, кынгыр эшенне сизсәмме?..

Шул арада бармен өстәлгә күбекләнеп торган саргылт сыеклык тутырылган ике бокал һәм тәлинкә белән кипкән балык китереп куйды. Вася сыра өстендәге күбекләрне өргәли-өргәли:

– Күбекле сыра әйбәт, дигән булалар. Аның күбеге нәрсәгәдер, белмим. Барыбер өреп кенә очырасы, югыйсә, — дип сөйләнде.

Ә Женяны өстәл сатудан кергән акчаның күпмесе үзенә булачагы кызыксындыра иде бугай. Ул, тәвәккәлләп, Васядан шуны сорарга җөрьәт итте. Чөнки гомуми акчадан кемгә күпме чыгарырга икәнне ул хәл итә.

– Вася, калымның күпме өлеше миңа булыр икән? Юкса, соңгы вакытта кесә ягы такыраеп китте...

Соравын сорады да, тик җавап көтеп Васяның йөзенә текәлмәде, өстәлдәге тоз савытына куелган кечкенә калакның очына тоз алып, сырага салды да болгаткан булып маташты. Аның бу гадәтен өнәмәгән Вася кашларын җыерды, тик сорауга җавап бирергә ашыкмады. Күренеп тора: ул нәрсәдәндер канәгать түгел һәм әнә шул ризасызлыгын ничек белдерергә җай таба алмый интегә иде кебек. Менә ул як-ягына каранып алды һәм ачу алуны, шаркылдап көлеп утыручы малайлардан башлады бу юлы. Башкаларга ирек бирмичә, әрсезләнеп, җыен юк-барны сөйләшеп утыручы «яшь әтәчләр»нең кикрикләрен шиндерү нияте белән, өстәл янынннан торып, ашыкмыйча гына шулар янына килде.

– Бераз гына тынычрак булмыйммы, пацаннар?! — диде ул, тавышында тынычлык сакларга тырышып.

«Пацан» дип кечерәйтү үсмерләргә ошамады, әлбәттә. Яңарак кына хатын-кызлар белән «батырлык»ларын сөйләп утырган егетләр ничек «пацан» булсын соң? Араларыннан калкурак, төеремрәк бер малай шунда ук торып басты. Каяндыр килеп чыккан әлеге кешенең үзләренең ләззәтле әңгәмәләрен бүлүе ошамаганлыгы салкын сыра чөмерүдән авыз читләре кызарган шактый гына кәефле бу малайның йөзенә чыкты. Ул бөтен барны яңгыратып кикереп куйды да, шул кызган шәпкә, үзләренең инде күптән пацан түгел икәнлеген аңлатмакчы булды бугай. Көтүдә барысы да батыр, дигәндәй, бишесе бергә тотынсалар бу адәмне генә җиңәчәкләренә шиге юк иде үсмернең.

– Ты че, мужик?..

Аның бу сүзләре хәтта Женяны да сагаерга мәҗбүр итте. Васяның холкын бик яхшы белгәнгә сагайды ул. Кулакны чыгырдан чыгару өчен шушы өч сүз дә бик җиткән. Хәзер хәлләр булачак! Чебеннәрне пыран-заран китереп кугандай, өстәлдән себереп очырачак ул боларны.

Юк, бу юлы Вася ачуын капылт кына чыгармады. Аның бары тик кыяфәте генә күзгә күренеп үзгәрде. Кашлары җыерылды, күзләрендә ниндидер кыргый ачу чалымнары ялтырап китте. Гадәттәгечә, яңак мускулларын уйнаткалады. Менә ул ашыкмыйча гына куенына тыгылды һәм аннан... пистолет тартып чыгарды. Моны күреп торган Женя урыныннан сикереп торды да, нишләргә белмичә, тораташтай катып калды... Вася юләрләнгәнме әллә?!

Ә Вася пистолетының көпшәсе башлаган сүзен дә тәмамлый алмыйча, авызын ачып калган малайның ияк астына терәлде.

– Син, манка малай, моның нәрсә икәнен беләсеңме?

Малайның авызыннан ниндидер мекердәгәнгә охшаш авазлар чыкты. Аның: «Э—э.. Әйе, әйе,» — дигән сүзләре генә ишетелде. Ә Васяның кыяфәте тагын да куркынычрак төс алды. Хәзер инде берниндиди пистолет күрсәтмәгән көе дә, аның шушы кыяфәтеннән генә дә кот алынырлык.

– Менә нәрсә, вонючка, монда кергәнче, иң беренче өлкән абыеннар белән сөйләшергә өйрән яме. Ә хәзергә, менә шушы уенчык белән маңгаеңа тишек ясаганчы, табаныңны ялтырату ягын кара.

Күренеп тора, кызым, сиңа әйтәм, киленем син тыңла, дигәндәй, бу сүзләр өстәл артында утыручыларның барысына да адресланган иде. Малайлар моны шунда ук аңлап, һичсүзсез үтәлергә тиешле әмергә буйсынгандай, бердән торып ишеккә юнәлделәр. Теге калкурак малай да аларга ияpде. Ул әле һаман, арттан атмаса гына ярый дигәндәй каерылып карый-карый атлады. Бераз китеп өлгергән малайны Вася кабат үз янына дәште. Инде котылдым дигәндә генә янә чакыргач, малайның йөзенә кадәр агарды. Тик Васяның боеручан тавышына карышып буламы соң, шикләнеп кенә кабат элекке урынына килеп басты. Вася, артык төчеләнеп тормыйча, өстәлдән яртылаш бушаган бокалны алды.

– Сыраңны калдырма, мә, эчеп бетер. Акча түләп алгансыңдыр, югыйсә. Өстәвенә, акчаңны да йә атаң, йә анаң кесәсеннән чиерткәнсеңдер әле, — дигән сүзләр белән сыраны малайның йөзенә сипте. Сыра тегенең бите буйлап агып изүенә керде. Малай теле белән авыз кырыйларын ялманды, тик берни әйтмәде, гаепле кешедәй түбән карады. Аның моннан бишалты минут элек кенә булган батырлыгы юып алгандай юкка чыккан иде. Малай, кырт борылып, ишеккә атлады, аннан соң иптәшләре артыннан йөгереп үк китте.

Әлеге тамашаны карап торган бармен башын селки-селки урынына утырды.

Женя да:

— «Ну, Вася, килештерәсең дә инде үзең. Малайны шыр җибәрттерден бугай, — дип куйды.

– Әй, мондый манкаларны да акылга өйрәтмәгәч...— дип, кулын гына селтәде дә Вася кабат үз урынына утырды. Бокалын күтәреп берничә йотым сыра уртлады. Кысладан чемченде.

– Карале, бу тамерланлылар көннән-көн әрсезләнәләр бит?! Закирның мебель ясау кооперативын да саумакчылар. Ә ул остаханә безнең биләмәдә урнашкан... Тулай торак безнең территориядә бит...

Гомуми казаннан үзенә күпме өлеш чыгачагы турындагы соравына җавап бирмичә, Васяның бөтенләй икенче нәрсә турында сөйли башлавы Женяның кәефен кырса да, ул моны сиздермәскә тырышты. Әле генә булып алган хәлләрдән соң, йоннарын уңайга сыпырсаң да, таманга туры килер, дип уйлады. Юкса, Васяга пистолет көпшәсен кем иягенә терәсә дә барыбер...

– Ул общага һөнәр училищесыныкы бит. Ә училище алар кул астында. Тамерлар шуны аргумент итеп куя...

Вася әле яңа гына күргәндәй текәлеп Женяга күзе белән тишәрдәй итеп карады. Малайлар белән булган хәлдән соң әле усаллык чаткылары сүнеп житмәгән, менә хәзер очкыннар чәчрәр кебек иде.

– Минем аларның училищеларына дәгъва белдергәнем юк бит. Анысы бөтен директорлары, ректорлары, училкалары, тагын әллә нинди шайтаннары белән үзләренә булсын. Ә общаганың ул сасы подвалындагы остаханәгә кагылмасыннар. Әгәр шуңа юл куйсак, алар әкренләп безнең бөтен биләмәләргә хуҗа булачак.

– Эшләр шуңа таба бара да инде, Вася. Ә беләсеңме нәрсә ишеттем

әле мин? Ул мебель кооперативын гына түгел, Тынычлык урамындагы келәмнәр сату кибетен дә, аннан соң менә без синен белән хуҗаларча сыра чөмереп утыра торган шушы барны да үз «түбә»ләре астына алмакчылар икән тамерланлылар.

Васянын моңа карата «җавабы» кыска булды: ул баш бармагын янәшәдәге ике бармагы арасына кыстырып кәҗә тоягы күрсәтте дә: «Менә аларга», — диде.

Ә Женя анын саен учакка бензин сибә торды:

— Ә беләсеңме, безнең биләмәләрне шулай әкренләп үзләренә күчерү идеясен кем таккан ана?

— Кем?

— Хәтерлисеңме, моннан ике еллап элек, Порх кушаматлы берәү безнен тирәдә ышкынгалап йөрде. Чын исеме Вадим анын. Прохоров Вадим. Ул, үз шайкасын оештырып, элек үк безнең кайбер «янчыклар»ны үзенеке итмәкче булып йөргән иде. Тик ул вакытта, анышып калып, без аларны тиз акылга утырттык. Егетләр белән җыелышып барып, яхшылап төйгәч, Порх үзе, сындырылган янак сөяген дәвалап, шактый вакыт больницада ятып чыкты. Шуннан сон, яхшатланып безнен тирәдә дә чуалгалады. Тик без аны арага кертмәдек. Ул хәзер тамерланлыларга кушылган. Тимур аларга берничә комокны, шул исәптән, без сава торган точкаларны да контрольдә тотарга рөхсәт биргән. Һәм, әлбәттә, шундый мәрхәмәтлелеге өчен Порх егетләренә ясак салган. Табышнын яртысы Тимур кесәсенә керә икән.

— Ха-ха, Тимур безнең комокларны контрольдә тотарга хокук биргән, имеш. Алай Порхка яхшылык эшлисе килгәч, үз биләмәләреннән өлеш чыгарсын. Андый юл белән мин Порхка Тимурдан да юмартрак ярдәм күрсәтә алам. Әнә, тамерланлылар биләмәсендәге бөтен нокталарга контрольлек итсен. Ясакны да Тимурга караганда азрак сораячакмын...

Артык кызып киткәнлеген чамалап, Вася кинәт кенә тынып калды. Бокалын күтәрде, сырасынын беткәнлеген күргәч, тагын алып килергә кушып, барменга ишарәләде. Тегесе, йөгереп кенә, анын бушаган бокалына сыра тутырып китерде. Гомумән, Вася үзен биредә хуҗаларча тота. «Түбә» булгач, ана монда рестораннардагыча хезмәт күрсәтәләр.

Янадаан сыра йотып куйгач, ул, инде шактый тынычланып, әңгәмәне дәвам итте:

— Янак сөяген сындырып та анламаган кешене нишләтәсен инде?.. Юлдан алып ташларга кирәк ул Порхны. Юкса, ашка төшкән таракан шикелле, һаман килеп чыгып тора. Закир егетләренә пистолет күрсәтеп, акча даулаучылар да анын этләре булгандыр, мөгаен.

— Әйе, әйе, Вася, йомдырырга кирәк аны. Юкса... Аннан сон Тимур да кемлегебезне белсен, безнен белән шаярырга ярамаганлыкны анласын.

Вася күзләрен кыскалады, унъяк кашын сикерткәләп алды. Нәрсәнедер үлчәп, чамалап караганда, анын кыяфәте нәкъ менә шулай үзгәрүчән.

— Порхны йомдырабыз икән, бу — тамерланлыларны үзебезгә каршы күтәрү булачак.

— Анын гамәлләрен күрмәмешкә салыну да әйбәт түгел...

Инде әңгәмә үзенен иң югары ноктасына күчә бара иде. «Йомдыру» дип сөйләп утыру гына җинел, аны үтәү икенче мәсьәлә. «Стрелка»ларда коралга ябышып, үзара атышу һәм шунда кемнен дә булса башына житү бер нәрсә, ә менә корбанынның кем булачагын белеп, аны сагалап торып үтерү — анысы бөтенләй икенче. Беркемнен дә «мокрый»га барасы килеп тормый. Шул исәптән, Женянын да. Анын башыннан да үтте андый хәл. Үзләреннән үк Тимур шайкасына күчкән бер «лазутчик»ны Вася әмере

белән дөмектергән иде ул. Төркемнәр арасындагы бәрелешләрдә утлы корал белән эш итүдә чирканчык алган Женя ул чакны җебеп төшә язды. Шуңа күрә, Вася сүз башлаганчы, ул үз тәкъдимен әйтергә ашыкты. Югыйсә, Вася алдан әйтеп куйса, барыбер сүзен сүз итәчәк.

– Бу эшне Чегәнгә... Артемкага йөкләсәк ничек булыр?..

Вася җавап бирергә ашыкмады. Чөнки ул егетне бик үк өнәп бетерми иде.

– Ышанмыйм мин синең ул Чегәнеңә. Җил кайсы яктан иссә, шул якка авыша ул. Эзенә төшсәләр, шунда ук сатачак.

– Сон, әйдә алайса Маркага йөклик... Корал белән эш итә белә... Кан күргәне бар... Әле хәзергә кушылган эшләрне җиренә җиткереп үтәп тора. Ин мөһиме: акча ярата. Уртак казаннан өлешне дә юмарт чыгарсак, тәтегә басарга икеләнеп тормас. Йомшак сыйраклы егеткә охшамаган.

Васяның күзләре тагын да ныграк кысылды. «Марка... Марат...» дип кабатлады ул үзалдына. Аннан соң:

– Әйе, аңа йөкләргә кирәк. Егетне тагын бер мәртәбә сынау да булыр. Үзем дә шуның кандидатурасын әйтергә теләгән идем, — дип, сүзен йомгаклады...

* * *

Шимбә көнне Женя, ни өчендер, Маратны ресторанга чакырды. Сәбәбен алдан ук әйтеп тормады. Барда бергәләп сыра эчкәләсәләр дә, аның белән ресторанда булганнары юк иде әле. Йә туган көнедер инде, сәбәбе бардыр, дип уйлады Марат. Хәер, Женя шикелле егетләр сәбәбе булмаса да, эчәргә сәбәп табарлар, анысы. Хәзер календарьның кайсы битен ачып җибәрмә, шул — бәйрәм. Һөнәри бәйрәмнәрне билгеләп үтү модага кереп китте. Нindиләре генә юк?! Бер көнгә икешәр һөнәри бәйрәм туры килгән көннәр дә бар. Хәтта, бушаган шешәләр тапшыручыларның да үз көне бар имеш. Бәйрәмнәре күп булгач, хәзер көн саен шешә тапшыручылар көнедер инде, анысы... Кем белә, бәлки Женяның туган көнедер? Вася да килер әле. Женя аннан башка Маратның үзен генә ресторанга чакырмас...

Нәкъ ул уйлаганча булып чыкты: ресторан янында аны Вася белән Женя икесе көтеп торалар иде. Бу ике әшнәне кем аерсын соң? Әллә бүтән көтәр кешеләре юк, әллә эчтә көтәргә булдылар, Марат килеп хәл-әхвәл сорашкач, ресторанга керделәр. Юл уңаенда Маратның: «Нинди бәйрәм соң бүген?» — дигән соравы җавапсыз калды. Өстәл арасына кереп урнашып, шактый мул табынга заказ бирелгәч кенә, Марат өчәвеннән башка бүтән беркемнең дә булмаячагына төшенде.

Әнә, Вася, йөзенә ясалма елмаю чыгарып: «Узкий круг», — дип, тешләрен ыржайтты. Женя исә, аның сүзләренә ачыклык кертергә ашыккандай: «Гел эш тә эш, иркенләп ял да иткән юк. Эш атларымы әллә, конца да концов. Дөнья мәшәкатьләрен онытып, иркенләп утырыйк ичмаса. Нервыларыбыз тимердән түгел лә! Авыр эш атнасыннан соң разгрузочный көннәр дә кирәк», — дип сөйләнде.

Чыннан да, салмак кына агылган көй, люстрадагы лампаларның сүрән яктысы күнелгә ниндидер тынычлык бирә. Монда вакыт агышы акрынаеп калган шикелле. Әйтерсең, залның соры диварлары артында шаулап торучы дөнья бөтенләй юк. Монда барысы да — вакыт та, дөнья үзе дә дүрт стена белән чикләнгән. Бирегә килеп эләккәннәрне тормыш мәшәкатьләре борчырлык булмасын өчен шулай эшләнгән кебек...

Официант, өстәлгә ризыклар китереп куеп, бокалларга кыйммәтле коньяк салгач, Вася, тамак кыргалап, тост әйткән булып маташты:

– Егетләр, менә хәзер күпме вакыт бергә эшлибез, шушындый шартларда

иркенләп базарить итеп утырганыбыз да юк. Женя белән без күптән корешлар инде. Менә син дә, Марат, чыннан да, үзеннен тугрылыклы кеше, ышанычлы дус икәненне эш-гамәлләрен белән аклап киләсен. Бөтен кеше үзенә дә шикләнеп карый торган заманда янәшәндә шундый кореш булу —олы бәхет бит ул. Әйдәгез, бу рюмкаларны киләчәктә дә бер-беребезне анлап эшләү, тугрылыклы дуслар булу өчен күтәрик!..

Вася сүзен тәмамлады, тик эчәргә ашыкмады, өстәлдәшләре ягына карап баш игәндәй итте. Женя исә, авызын купме булдыра ала шунын кадәр җәеп, Маратка күз кысты, рюмкасын төбенә кадәр бушатып куйды. Марат та үз рюмкасын бушатты. Вася исә алар эчеп бетергәч кенә иреннәрен эчемлеккә тидерде, анда да бетереп эчмәде.

Ниһаять кашык-чәнечкеләр «телгә килде». Салатлардан авыз иткәч, бокалларны кабат «түбәләмә» тутырдылар. Инде Женя сүз алды.

— Марка, мин үз гомеремдә кайларда гына, кемнәр белән генә эшләмәдем, тик синен кебек ышанычлы дусларым булмады, — дип төчеләнде ул. — Менә шуна да, бүген, башка беркемне дә чакырмыйча, үзебез генә, ин якыннар, узкий кругта утырабыз. Әйдәгез, иркенләп күнел ачыйк әле бер.

Женянын монын ише урында телгә бик үк осталыгы юк икән. Шулай да, ырып-ерып чыга алды тагын үзе. Бусында рюмкалардагы коньякны һәр өчесе дә төбенә кадәр эчеп куйды. Затлы эчемлек, тиешле урынга барып житеп, үзенекен эшли башлады. Егетләрнен күнелләре бермә-бер күтәрелде, тормыштагы вак мәшәкатьләр әкренләп арткы планга күчә барды. Күнелләрне алгысытып, әрле-бирле йөрүче официант кызнын йомры арт саны күзгә чалынды. Күрше өстәл артында, ярыйсы гына төшереп алган хатын-кызларнын чытлыкланып көлүе дә колак читеннән узмады. Өстәвенә, Женя да бераздан әнгәмәне шул якка борып җибәрде. Иһаһай-миһаһай килеп утыручы шук хатыннар һәм алар янәшәсендә тук айгырлар кебек кешнәүче ыспай ирләр ягына ишарәләде:

— Әнә, андыйлар ял итә белә ичмаса. Без түгел инде. Алар көн саен шушында. Кайчан килмә, күнел ачалар. Шу-у-улай, акча сикертә ул. Ә безнен сон?.. Тегеннән бер тиен, моннан ике тиен, дигәндәй...

Шунда Вася да анын сүзләрен элеп алды:

— Әле анысын да тартып алмакчылар. Инде кул астыннан биләмәләребезне талый башладылар. Безгә — кукиш. Болай булса, тиздән ресторан түгел, кара икмәккә дә акча житмәячәк...

Васянын тавышы калтыранып куйгандай булды. Маратнын аны мондый мескен халәттә әлегә кадәр күргәне юк иде. Әллә юри-мыри гына кылана, әллә, чыннан да хәлләр мөшкел инде? Беркөнне Закирнын мастерскоенда үзен ничек иркен һәм батыр тоткан иде. Маратнын уенча, андый «комок»лардан гомуми казнага акча әз керми бит. Ә кергән акчанын барысы да Васянын үз кулында. Тели икән, бөтенесен үз кесәсенә шудыра ала. Һәм шудыра да... Ә монда мескенләнеп утырган була...

— Ул тамерланлыларны акылга утыртмыйбыз икән, Вася, алар безне басып алачаклар. Аннан сон беребезгә дә көн булмаячак Безне чебеннәр урынына сытачаклар. Мона юл куярга ярамый, братаннар! — диде Женя, әшнәсенен сүзләрен хуплап.

Ә Марат жилнен кайсы якка искәнен һаман анламый. Хәер, анларга да теләми иде кебек. Эчелгән коньяк тәэсиреннән тәненен һәр күзәнәге нидидер рәхәтлек кичерә иде бу минутларда. Нәкъ шундый чакта баш миенен һич кенә дә дөнья мәшәкатьләре хакында уйлыйсы килми бит ул.

Менә ресторан диварларына беркетеп куелган динамиклардан бию көе агыла башлады. Күрше өстәлдәге бер ханымнын: «Ох-хо-хо! Белый танец! Дамы приглашают кавалеров», — дигәне ишетелде. Шул сүзләрне генә

көткәндәй, өстәл артында ыгы-зыгы купты. Әнә, берсе янәшәсендәге ирне урындык арасыннан алып чыкты, очлы күкрәге белән аңа «кадалып» бии дә башлады. Бүтәннәр дә берәм-берәм урыннарыннан кузгалдылар. Өстәл артында калган икәүдән, бер йомры гәүдәле хатын, үз өлешенә тигән чал чәчле өлкән ир-атны кыстап-кыстап та биергә алып чыга алмагач, Маратлар өстәле янына килде һәм, бик килешле генә итеп, Васяны чакырды. Биергә исәп тотмаган Вася мондый чакыруга әзер түгел иде, әлбәттә. Ләкин кире кагу да бу чибәркәй алдында дәрәҗәсен генә төшерәчәк. Ул, ирексездән, хатынның беләнә кулын салды һәм алар музыканың дәртле тавышы астында биючеләр арасына кереп киттеләр.

Женя бокалларга тагын коньяк салды. Тик рюмкасын күтәрергә ашыкмады. Бераз биючеләр ягына карап торды да, бик яшерен сер әйтергә җыенгандай, урындыгын күчереп, Маратның янәшәсенә үк килеп утырды.

– Беләсеңме, Марка, проблема килеп чыгып тора бит әле. Безнең гомуми эш җимерелү куркынычы астында, братан. Аяк чалучылар бар. Порх кушаматлы бер бәндә, әнә, комокларыбызга хуҗа булмакчы. Тамерланлылар канаты астына ышыкланып, безнең авыздан икмәгебезне тартып алмакчы, гнида. Без менә Кулак белән уйлаштык-уйлаштык та, Порхны юлдан алып ташларга кирәк, дигән нәтиҗәгә килдек. Йомдырырга кирәк ул адәм актыгын, аңлыйсыңмы?..

Шул сүзләрне әйтте дә, Маратның җавабын да, фикерен дә сорап тормады, өстәлдәге тулы рюмкаларның берсен Марат ягына шудырды:

– Әйдә, моны да күтәреп куйыйк әле, юкса, Вася да биергә киткәч, гел күңелсезләнеп калдың, — диде. Ә үзе Мараттан күзләрен алмаган килеш кенә рюмкасын бушатып куйды.

Марат та, башын артка чөеп, бер селтәнүдә рюмкасын авызына каплады.

– Шә-ә-әп китте, — дип кулларын угалады Женя, чәнечке белән кыяр телеме алып капты да кетердәтеп чәйни-чәйни кабат Маратка текәлде. Сүзләренең әйтелгән кадәресенә Марканың мөнәсәбәтен беләсе килә иде аның.

– Шуннан, миннән нәрсә сорала? — дип, үзе сорау бирде Марат.

– Менә без Вася белән уйлаштык та, бу эшне башкарып чыгуны сиңа йөкләргә булдык...

Марат чәйни башлаган ризыгын йотып җибәргәнен үзе дә сизми калды. Бүген ресторанга ни өчен чакырылуын ул шунда гына аңышты. Женяның туган көнедер, дип уйлаган иде тагын. Туган көненә чакырган ди әнә, тот капчыгыңны! Женя өчен Марат кем инде?! Беренче тостны күтәргәндә генә «якын дус» дип төчеләнгән булып маташты. Менә ни өчен кирәк булган икән аның юхалануы. Вася белән уйлаштык, имеш. Ә Марат белән киңәшләшүне кирәк тә санамаганнар. Уйлашканнар да, аны эшкәртү өчен монда ресторанга чакырганнар, бетте китте...

Эчтән шулай уйласа да, теле гел киресен әйтте. Женя алдында йомшаклык күрсәтеп торасы килмәде аның.

– Миннән башка кеше юкмы?

– Юк, иң ышанычлысы син. Баштан Чегән кандидатурасын уйлаган идек. Тик ул бик ышанычлы түгел... Бөтен өмет синдә. Манчы син Порхны. Гомуми эш өчен бит, братан. Босс аның ише эшләргә гонорарны да җәлләми. Әйдә, тәвәккәллә, Марка. Ул Порх дигән бәндә җәлләүгә лаек түгел. Аның ише гнидаларның баш чүмеченә тишек ясадың ни дә, иске чиләк калаен тиштең ни, барыбер...

Бу юлы шешәдәге коньякны рюмкаларга Марат үзе агызды. Женяны кыстап та тормыйча, рюмкасын күтәреп, шунда ук эчеп тә куйды.

Авызына бер чеметем ямь-яшел салат яфрагы капты да, шуны чәйни-чәйни:

— Кайчан? — диде.

Маратның соңгы сүзләре ризалык билгесе иде. Женя аны тиз генә күндерә алуына башта ышанып та житмәде кебек. Аек чакта һәр адымын уйлап эшләүче егетнең шундый житди эшкә тиз генә ризалашуы — эчелгән коньяк тәэсиреннән дип бәяләде ул. Тик бер нәрсәгә шиге юк Женяның, «әйткән сүз — аткан ук» принцибы белән яшәүче Марат хәзер сүзендә торачак та торачак инде.

— Иртәгә, аек баштан, өчебез бергә яхшылап кабат уйлашырбыз да шушы көннәрдә тәвәккәлләрбез...

Марат рестораннан чыгып китәргә җыена башлады. Ул арада бию көе дә тәмамланып, теге хатынны күрше өстәл янына озатып куйгач, Вася үз урынына килеп утырды. Шунда, ботинкасының чишелеп киткән бавын бәйләргә иелгәндә, Марат, күз чите белән генә, Женяның баш бармагын тырпайтып, Васяга ишарә ясаганын күреп калды. «Булды, эшләр пеште!» — дигән бу ишарәне аңлау өчен артык зирәк булу кирәк тә түгел.

Марат, ашыгыч эшем бар иде дип, Вася белән саубуллашты да авызына сигаретын кабып, ишеккә юнәлде...

* * *

Марат белән Артем-Чегән инде мәнә ничәнче көннәрен Порхны сагалыйлар. Теге сөйләшүдән соң, Вася кушкач, Артем Маратка ярдәм итәргә алынды. Алар бер атнага якын Порх яши торган йорт подъезды тирәсен өйрәнделәр. Баштарак эшләрен шунда гына башкарып чыкмакчылар иде. Күзәтә торгач, уңайсыз урын булып чыкты. Монда, каршыда ук, нәкъ Порх яшәгән йорт шикелле күп подъездлы икенче йорт бар. Алар бик якын — араларында нибары машина юлы да тротуар гына. Ишегалдында ниләр эшләнгәне һәр ике йортның тәрәзәләреннән дә уч төбендәгечә күренә. Подъезддан кергән-чыккан кешеләрне тәрәзә аша күзәтеп торучы һич югы бер пенсионер карчык табылмыйча калмас. Өстәвенә, подъезд төбендә утыручыларны да исәпкә алмыйча булмый бит әле. Якты көндә эскәмияләрдә пенсионерлар, инвалидлар утырса, эңгер төшә башлагач, аларны яшьләр алмаштыра. Ә операция барышында көтелмәгән хәлләр килеп чыгып, тикшерү-сораштырулар башланса, кемнәрнеңдер «хәтерләре яңарырга» мөмкин. Әнә шуна да, Артемка-Чегән белән бер атна подъездны сагалагач, Порхны монда атмаска, дигән фикергә килделәр.

Кичен, Порх машинасын стоянкага куйгач, турыдан гына, сукмак буйлап, өенә кайта. Ә сукмак әнә шул ташландык төзелеш яныннан уза. Сукмак үтә торган жирдә койма урынына тезеп куелган панельләрнең берсен алып эчке якка сөяп куйганнар. Порхны шунда саклап торудан да яхшысы булмас дип уйлашты егетләр. Анда аулак, кешеләр сирәк йөри, аннан соң мәетне качырып калдыру өчен дә уңайлы.

Порхның төгәл йөри торган гадәте юк. Моннан өч көн элек ул кайтканда әле якты була иде. Өстәвенә, күпләр нәкъ мәнә шушы вакытта стоянкага машина куя. Сукмактан үткәләп-сүткәләп йөрүчеләр дә байтак. Ә кичә Порх өенә бөтенләй кайтмады булса кирәк. Һәрхәлдә, ул төнге унга кадәр күренмәде, машинасын подъезд ишеге төбендә калдырган булса гына инде. Бүген дә мәнә кичке тугыз тулып, унынчы китеп бара. Ә Порх һаман күренми дә күренми.

Стоянка капкасын Артем сагалый. Ул бераз гына читтәрәк үзенең «Ока» машинасында «шухер»да тора. Порхның 362 номерлы «Жигули»е стоянкага

кереп китүгә, Артем, панел астындагы куышта яшеренеп торучы Марат янына йөгереп килеп, аны кисәтәчәк...

Көткән чакта вакыт бик акрын үтә. Артем, сулышына кабып, панел астындагы куышка килеп кергәндә сәгать ун туларга унөч минутны күрсәтә иде.

– Марка, әзерлән, Порх биш минуттан моннан узачак, — диде ул мышный-мышный.

Марат ашыкмыйча гына урыныннан кузгалды, пистолетын куеныннан алып, артка — чалбар каешы астына кыстырып әзерләп куйды да сукмакка чыгып басты. Ул Порх килгәндә тәмәкесен кабызган булып маташырга тиеш иде. Шушы очрак өчен газы бетеп кабынмый торган иске зажигалка да алды хәтта.

Менә сукмакта аяк тавышлары ишетелә башлады. Ул да булмады, борылыштан бер шәүлә чыгып сызгырына–сызгырына Маратка якынлашты. Марат зажигалка төймәсенә баскалады. Чакматаштан очкыннар сибелде, тик ут кабынмады. Шунда, үзенә якынлашкан теге шәүләгә мөрәҗәгать итеп, Марат:

– Тәмәке көйрәтергә иде, зажигалкаң юкмы? Минеке нишләптер янмый, — диде.

– Зажигалкам юк, ә менә шырпы табарга була, — дип, Порх «ветровка» кесәсенә тыгылды, шырпы алып, егеткә сузды. Марат тәмәкесен кабызды да шырпыны кире иясенә тапшырды. Тегесе, бернидән шикләнмичә, шырпы кабын кесәсенә сала-сала алга атлады. Ә Марат, куеныннан пистолетын алып, предохранителеннән аерды да аңа иярде, ике-өч адым атлагач, кабат алда баручыга эндәште:

– Тагын бер нәрсә сорарга мөмкинме?..

Порх бөтен гәүдәсе белән артка каерылды. Ә бу арада Марат пистолетын аның күкрәгенә терәп өлгергән иде инде. Көпшәсенә тавыш киметкеч куелган коралдан тонык кына тавыш чыкты...

Үлем белән тартышып ятучы Порх өстенә сыный карап иелгән иде генә, нәкъ шундый чакта кирәк бит, сукмакта аяк тавышлары ишетелде. Югыйсә, биш-алты сәгать саклап ятып, нибары ике-өч кеше генә узган иде, ә монда менә сиңа мә!

Марат җирдә ятучы исерекне торгызырга маташкан булып кыланды.

– Дуңгыз урынына эчмәскә иде... Әйттем бит мин сиңа, күп эчмә дип. Тор, әйдә, өенә илтәм, –дип сөйләнде.

Узып баручы, караңгыда күренмәгәч, җирдә мәет ятадыр дип уйлап та карамагандыр, киресенчә: «Булышырга кирәк түгелме?» — дип, ярдәм итмәкче иде әле.

– Кирәкмәс, мин аны хәзер үзем дә... — дип сөйләнде Марат.

Комачаулаучы күздән югалгач, Порхның җансыз гәүдәсен Артем белән панель астына сөйрәделәр. Җиргә сузып салгач йөзенә төбәп Чегән фонарь кабызды. Ничә көннәр буе ерактан күзәтеп йөрсәләр дә, Маратның корбанны болай якыннан күргәне юк иде әле. Бер мизгелгә генә ул аның йөзенә текәлде. Теге көнне ресторанда Женя: «Ул бәндәне җәллисе юк. Аның эше гнидаларның баш чүмеченә тишек ясадың ни дә, иске чиләк калаен тиштең ни, барыбер», — дигәч, Марат уенда Порх барып чыккан түбән җанлы кеше булып гәүдәләнгән иде. Чынлыкта исә ул борын астына сирәк кенә «бала йоннары» үсеп килүче бер малай булып чыкты. Чечняда үлем белән йөзгә-йөз очрашкан, утны-суны кичкән ир-егет монда менә нинди малайлар белән сугышып йөри икән ләбаса. Нинди түбәнлек! Ләкин инде бернишләп тә булмый, уен башланган. Хәзер артка чигенү юк. Марат пистолет көпшәсен Порхның маңгаена терәде. Тагын тонык кына тавыш ишетелеп куйды...

Ул төнне Марат озак кына йокыга китә алмыйча азапланды. Әле тегеләй, әле болай боргаланды ул урын өстендә. Бүген гел юктан гына Порхнын мангаена «тишек ясау» күнеленә тынгылык бирми иде. Нигә үтерде соң әле ул аны? Вася Кулагин белән Женяга биргән вәгъдәсен үтәү өченме? Әйткән сүзеннән чыкмас өчен генә япь-яшь егетнең канын койды. Сугышта ярар инде, кемгә дә булса атарга, кемне дә булса үтерергә туры килә. Анда шунсыз чара юк. Син атмыйсың икән, сиңа атачаклар. Ә бу малай үзенә корал күтәрдеме? Юк бит, хаиннарча саклап ятып, куркакларча артыннан килеп, атып ектың...

Әнә шундый уйларга бирелеп ул йоклый алмыйча ятты. Аптырагач, урыныннан торып, суыткычтагы шешәдән кырлы стаканны тутырыр-тутырмас аракы салып эчте һәм үзе дә сизмәстән тирән йокыга талды.

* * *

Ә көннәрдән бер көнне...

Маратка ул көн төш кебек кенә тоелды. Иртән бар да яхшы башланган иде. Марат, гадәттәгечә, йокысыннан торып, чәй эчте дә эшкә китте. Сәгать тугызлар тирәсендә Женя белән аны ни өчендер Кулак чакырып алды. Ашыгыч кына сөйләшәсе сүз бар дип, «Хрустальный бокал» сыраханәсенә алып китте. Шунда алар, аз-маз сыра йоткалап, тозлы балык чемченеп утырдылар. Нинди дә булса җитди эшкә җыенганда, ныклап план кору өчен, Кулак шушы сыраханәне сайлый иде. Монда кешеләр сирәк керә. Аулакта тынычлап сөйләшергә була. Васяның үз-үзен тотышына, кыяфәтенә караганда, нindидер гадәттән тыш хәл килеп чыкканга охшый.

Вак-төяк дөнья мәшәкатьләре хакында берара сүз алышкач, Кулак җитди темага күчте:

— Порхны дөмектергәч, тамерланлылар тәмам азынды. Ныклап торып, безнең «җимлек»кә үрелә башладылар. «Заман» предприятиесен дә үз йогынтылары астына алырга маташалар. Югыйсә, без ул кооперативка оешкан вакытларыннан башлап «түбә» булдык. Әле чак-чак аякларында басып торганда күтәрдек тә, хәзер акча керә башлагач, табышлары арткач кына, Тимур саумакчы була. Босс миңа шуны тәртипкә салырга чакырды.

Шунда Женя кабынып торып басты.

— Ха, тапканнар җүләрләрне. Шундый олы калҗаны ычкындырырлар дип уйлыйлар микәнни? Тотсыннар учлап...

Тагын Кулак сүз алды:

— Алар белән очрашып, сүз беләнме, көч кулланыпмы — ничек кенә булса да бу кооперативның безнеке икәнлегенә ышандырырга тиешбез. Кичә Зебра белән Жук батыраеп китеп, аларны идарә янында саклап торганнар. Ахмаклар, салган баштан икәүләшеп кенә акылга утыртмакчы булганнар. Атыш башланган. Безнең Жукны шунда ук манчыганнар. Зебра да яраланган. Дәваланып ята. Аякка басар басуын. Хәзер тамерланлылар безне «стрелка»га чакыралар. Бүген сәгать дүрттә, Ялантау янындагы урман полосасында очрашырга тиешбез. Сөйләшү кискен булыр шикелле. Безне чынлап торып куркытырга бугай исәпләре. Ләкин без дә кемлегебезне күрсәтергә тиешбез. Без Босс белән киңәшеп карадык. Аерым-аерым йөреп кенә берни дә кыра алмаячакбыз. Хәйлә белән алдырырга кирәк. Бер төркем, машинага төялеп хәзер үк шунда китә, урман полосасының алгы башындагы чокырга засадага урнаша. Тамерланлыларга ышаныч юк, алар да берәр җирдә засада куярга мөмкиннәр. Шулай була калса, алдан килгән төркем кемнең кайдалыгын күзәтеп, икенче машинада килгәннәрне кисәтергә тиеш. Засаданы юк итү дә шул беренче төркем өстендә. Әгәр инде засада

юк икән, без ул үләксәләрне ике сөйләшеп тормыйча дөмектерәчәкбез. Житте, алар белән мәми авызланырга. Бу дөньяга кемнәр хуҗа икәнлеген таныта башларга вакыттыр. Пушкаларыгызны әзер тотыгыз. Беренче төркемгә инструктаж бирелде. Алар хәзер үк шунда китә. Ә сәгать дүрттә мин, Борзой, Марка һәм Женя шунда барачакбыз. Безне беренче төркемнән Косой каршыларга тиеш, засада булу-булмавын да ул әйтә. Борзой белән мин сөйләшергә чыгачакбыз. Машинадагыларга пушкаларын әзер тотарга! Алдан ук кисәтеп әйтәм, сөйләшүләрдә берниндн ташлама ясамаячакбыз. «Заман» — безнеке, бетте китте. Аларның бу җавапка риза булмаячаклары көн кебек ачык. Куркытырга маташачаклар. Ләкин безнең алдан җибәрелгән егетләрдә гранатомет бар. Тамерланлыларның машиналарына төбәп атуга, тегеләр югалып калачак. Сөйләшергә чыкканнарын кырып салабыз да табан ялтыратабыз. Калганы «легавый»лар эше. Алар куаначаклар гына. Мафиозларның үз куллары белән кырылуы аларга файда гына бит.

Кулак әнә шулай барысын да жентекләп аңлаткан кебек иде. Тик корылган планнар белән чынбарлык гел туры килсә икән ул. Нәкъ кирәкмәгән чакта план дигәнең үзгәрә дә куя...

Алар билгеләнгән урынга аз гына алдан килделәр. Егетләрне Косой каршылады. Аның әйтүенчә, тамерланлылар засада куймаганнар ди.

Агачлар ышыгына туктап, ярты сәгатьләп көткәннәрдер, тузан туздырып машина килгәне күренде. Тәрәзәләре караңгы «БМВ» машинасы Маратларның иске «Ауди»ына йөз-йөз илле метр ара калдырып туктады. Минут чамасы ике якта да берниндн хәрәкәт сизелмәде. Һәркем каршы яктагыларны өйрәнде булса кирәк. Тик тәрәзәләре аша машина эчендә кемнәр һәм ничә кеше барлыгы күренми. Бераздан, БМВның арткы ишеге ачылып, аннан кара күзлек кигән шкафтай бер егет чыкты, каршыдагы машинага игътибар да итмәгән кебек, авызындагы сагызын чәйни-чәйни алгы ишекне ачты. Аннан Тимурның такыр башы күренде. Шулчак БМВның икенче як ишеге дә ачылып китте, аннан да беренчесеннән ким булмаган икенче «шкаф» чыкты. Алар, Тимурны уртага алып, ашыкмыйча гына Маратлар машинасы ягына атладылар. Шунда Кулакның иртәнге күрсәтмәләре үзгәрде дә куйды. Ул: «Менә нәрсә, егетләр, болар каршына Косой, Марка һәм Женя, сез чыгарсыз. Борзой белән мин монда калам», — дип яна команда бирде. Егетләр моны көтмәгәннәр иде. Ләкин хәзер: «Ни өчен, нишләп?» — дип тикшереп торудан файда юк иде. Кулакның ачулы карашын тотып алган егетләр, әмерне берсүзсез үтәргә кирәклеген аңлап, машинадан чыктылар.

Сөйләшергә килүчеләр бер-берләренә якынлашырга инде аз гына калган иде, шулчак көтелмәгән хәл булды: тамерланлылар бара торган җирләреннән кинәт туктап калдылар, аларның йөзләрендә ниндидер аптырау галәмәте чагылып узды. Аннан соң өчесе дә табан ялтыратырга җыенгандай, кырт борылып, ни өчендер машиналарына таба йөгерә башладылар. Шул ыгы-зыгыдан файдаланып, Женя куенындагы пистолетын тартып алды да төзәмичә-нитмичә генә качып баручыларга атты. «Шкаф»ларның берсе «ух»ылдап куйды һәм ике кулы белән сул ботын тотып, аягын сөйрәп атлый башлады. Ни өчен тамерланлылар табан ялтыратырга булды? Кемнән шүрләделәр? Боларын Марат әлегә анык кына төшенеп җитмәде. Кесәсеннән пистолетен алырга өлгергән Косой да качучылар артыннан бер-бер артлы ике мәртәбә гөрселдәтте. Икенче «шкаф» тынсыз калып җиргә ауды. Бу вакытта БМВдагылар, двигательне кабызып, юлга унайлы итеп борылганнар иде. Тимур һәм аягы яраланган әзмәвер машинага кереп чумдылар. Алар артыннан ачык ишектә берничә автомат очереды яңгырады. Кайда соң, кайда засададагы егетләр, нишләп гранатометтан ут ачмыйлар?

Шулчак, урман полосасын янгыратып, сирена уларга тотынды. Марат унга каерылып караган иде, елга кырыендагы куаклык арасыннан берегә таба йөгерүче биш-алты милиционерны шәйләп алды. Алар артыннан, сиреналарын кычкыртып, зәңгәр путалы ике «шестерка» чыгып килә иде. Машина динамикасыннан: «Коралларыгызны ташлагыз! Кулларыгызны күтәрегез!» — дигән катгый әмер яңгырады.

Маратның баш миен «Засада!» дигән уй телеп узды. Димәк, легавыйлар аларны көтеп, сагалап торганнар. Ә засададагы егетләр кайда соң? Кемдер саткан булып чыга түгелме?! Бәлки, тамерланлылар шулай итеп үч алмакчы булганнардыр? Алай дисәң, үзләре үк зыян күрде. Белсәләр, паникага бирелмәсләр иде. Алдан күреп алулары да легавыйларның аларга каршы Маратлар ягыннанрак килеп чыгуларында булгандыр бәлки.

Димәк, безнең гранатомет белән утыручы егетләрне каптырганнар болар.

Ул арада Женя белән Косой да куаклыктан чыгып килүче оператив төркемне күреп алдылар. Берничә мәртәбә тәтегә басып, утлы корал тавышын ишеткән егетләрдә азарт уйный башлады булса кирәк, Женя, ике дә уйламыйча пистолетын күтәреп, алдан килүче «мент»ка төбәде. Ара якынайганнан-якыная бара. Шуңа күрә Марат килүчеләрнең йөзләрен аермачык күрде. Алдан йөгерүче милиционер ана таныш кебек тоелды. Әйе, әйе, бу Чечняда солдат шулпасын бергә чөмергән, кем әйтмешли, шинельне бергә бөркәнгән дусты, якташы Саттаров иде. Чечняда хезмәт иткәндә, әле күптән түгел генә хәрби училище тәмамлаган булса да, инде дары исен иснәп өлгергән яшь лейтенант, якташы буларак, Маратны якын итеп, «земляк» дип эндәшә иде. Бервакыт алар взводы тау юлыннан барганда, боевиклар засадасына юлыкты. Азрак атышканнан соң, тегеләр «рукапашный»га күчте. Ул чакта әле бер бәрелештә дә катнашырга өлгермәгән, тере боевикны ишетеп кенә белүче Марат, кулына ялангач пычак тотып өстенә ерткыч җанвардай ташланган әзмәверне күргәч каушабрак калды. Тагын бер адым һәм бандит хәнҗәре белән егетнең бугазына сызып та җибәрәчәк. Әйе, ут эчендә салкын канлылык та кирәк. Аз гына кабаландың исә, бетүең хәзер. Марат әнә шундый хәлдә калды. Кинәт янәшәдә автомат чиратты яңгырады. Бандитның кулыннан хәнҗәре төшеп китте һәм ул яман үкереп, бөгәрләнеп җиргә ауды да тынсыз калды. Коткаручы — Татарстан егете Саттаров Гомәр иде. Марат сугыш чирканчыгы алган шул беренче бәрелештә лейтенант Саттаров аны үлемнән йолып алды. Бандитларны тау елгасы ярына кысрыклый башлагач, тегеләр ягыннан ыргытылган граната шартлап, Гомәр үзе дә яраланды. Аны авыр хәлдә госпитальгә озаттылар. Соңыннан лейтенантны үзебезнең илгә җибәрүләре хакында ишетелде. Үзен үлем тырнагыннан йолып калган бу кешегә Марат гомере белән бурычлы иде. Аны беркайчан да онытмаска, армиядән исән-сау кайтса эзләп табып рәхмәт әйтергә сүз бирде. Тик язмыш кеше уйлаганча гына бармый шул. Марат армиядән исән-имин кайтса да Саттаровны таба алмады. Дөресрәге, ул аны эзләмәде дә. Әгәр ни булды дип сорасалар, кырык сәбәп табар иде. Тик болар берсе дә аны акламый. Егет кеше сүзендә тора белергә тиеш. Һәм менә нинди шартларда очраштырды аларны язмыш. Ул чакта да засада иде. Бандитлар засадасы... Менә хәзер дә засада. Тик аны кайчандыр үлемнән коткарган Саттаров хәзер үзе пистолет «мушкасында утыра». Аның гомерен өзү өчен, Женяның бармак селкетүе дә җитә.

Марат кинәт пистолетын күтәрде дә Женяга атып җибәрде. Егет моны көтмәгән иде, әлбәттә. Ул гаҗәпләнгән күзләрен Маратка текәде. Ядрә аның уң кул башына тигән күрәсең, пистолет тоткан кулы асылынып төште. Ул, «ах»ылдап, сул кулы белән ярасын тотты. Янәшәдә торган Косой, яман

сүгенеп, Маратка борылды. Аның күзләрендә нәфрәт һәм шул ук вакытта гаҗәпләнү дә бар иде.

– Ух син, адәм актыгы... Сука! Ананны фәлән итим... Мин сине...

Тик Марат өлгеррәк булып чыкты: Косой пистолетын төбәгәнче, аның «пушка»сыннан ут бөркелде. Тегесе, күкрәген тотып, җайсыз гына селкенеп куйды, аның авызы бер ачылды, бер ябылды. Шулчак, аскы ирене читеннән ал тасма күренде. Косой башта акрын гына тезләренә чүкте, аннан соң җиргә йөзтүбән капланып, тынсыз калды.

Женя һушына килеп өлгергәнче, Маратка тиз генә табан ялтыратырга кирәк иде. Урман якында, егерме-утыз адымда гына. Кем әйтмешли, ике атлап бер сикерсә, анда барып та җитәчәк. Шуны уйлап, ул агачлык ягына омтылды. Артта Женяның: «Марка, тукта! Качма! Атам юкса», — дип кычкырганы ишетелде. Һәм чыннан да, ике мәртәбә «шарт-шорт» аткан тавыш яңгырады. Ядрәләр Маратның колак яныннан сызгырып узды. Женя бу кадәр генә ераклыктан тидергән дә булыр иде. Ул төз ата. Тик уң кулы яралы шул, сулы белән генә атты. Марат та артка борылып, пистолетын төзәп тормыйча гына, бер-ике мәртәбә курокка басты. Тик ядрәләр Женяга тимәде бугай. Шунда Марат, күз чите белән генә, зур тизлектә юлдан ераклаша барган БМВны күреп алды. Бер милиция машинасы аның артыннан куа китте. Тик «шестерка»га кая инде ул БМВны куып җитү?! Монысы юләргә дә аңлашыла... Ә Кулагин белән Борзой утырган «Ауди» икенче якка, урман читендәге борылышка кереп күздән югалды. «Опер»ларның икенче машинасы аның артыннан кузгалып та тормады. Ул Маратлар артыннан йөгергән «мент»ларны көтә калды...

Агачлар арасына кергәч, Женя тагын бер мәртәбә атты. Бу ядрә дә агач ботакларын сындырып читтән узды. Хәзер инде эзәрлекләүчедән качу җитезлеккә бәйле. Женяның кулы гына яралы булса да ул хәлсез. Ә Маратның сыдырылган җире дә юк. Бу яхшы, әлбәттә. Ара ерагая бара бугай, моны куа килүченең аяк тавышыннан һәм ботак-сатаклар сынганнан яхшы чамаларга була...

Кәүсәләре куе булып үскән агачларны әйләнеп үтим дип уңгарак борылган иде, саргайган куе үләннәр арасында шактый зур чокыр капланган булган икән, Марат, шәйләмичә шуңа егылып төшкәнен сизми дә калды. Чокыр кырыенда яндырырга дип җыеп куелган куак өеме ишелеп Маратны каплады. Шунда егет борын төбеннән генә кап-кара елан шуышып үткәнен күреп калды. Аның дулкынсыман хәрәкәте дә аермачык күренде хәтта. Кинәт өстенә кеше егылгач, курыкты күрәсең, хәшәрәт. Башка вакыт булса, Марат, кычкырып читкә сикерәсе иде. Тик бу юлы ул аз гына да шүрләмәде. Арттан килүче дошман куркынычрак, мәкерлерәк тә. Килеп төшкән урыныннан кузгалырга маташу мәгънәсезлек булыр иде. Бу очракта, «ятып калганчы, атып кал» дигән гыйбарә бигүк үзен акламас. Һәм егетне шул коткарды да. Женя аны күздән югалтты булса кирәк, авыр гына мышный-мышный, куакның бөтенләй икенче ягыннан үтеп китте. Хәер, үз кайгысы кайгы булгандыр. Артыннан легавыйлар куа килә бит.

Женяның аяк тавышлары тынып бераз торгач, ике-өч милиционер йөгереп узды. Тик ун-унбиш минуттан алар кире киләләр иде инде. Куак өеме яныннан узганда Марат аларның өзек-өзек сөйләшкәннәрен дә ишетте хәтта.

– Җир йотты диярсең, әллә кая олактылар....

– Икәү иделәр бугай?..

– Нишләп үзара атышканнарын гына аңлый алмадым...

Димәк, Женя да качып котылган. Алар киткәч Марат тагын берәр сәгатьләп чокырда ятты әле. Чокырдан чыккач Марат бу тирәдән ераккарак

китү жаен карады. Урманга да бик эчкә керергә ярамый, Женяга тап булуы ихтимал. Урманнан читкә чыксаң легавыйларга эләгүе бар. Шуңа ул, куркынычсызрак жиргә житкәнче, урман читенә чыкмыйча, агачлар арасыннан гына атлады...

* * *

Ялантау янында тамерланлылар белән булган «стрелка»дан соң, Васяның уйлары бөтенләй чуалды. Маратның ул көнге кыланышларын берничек тә аңлатырлык түгел иде шул. Косойны атып екты, Женяны яралады. Һәм болар барысы да «легавый»лар засададан күтәрелгәч булды. Димәк, ул ментлар шымчысы булып чыга түгелме? Ә бу очракта, Наил Хәкимович кем? Ул да ментлар ялчысымы? Маратны алар арасына ул тыкты бит. Менә монысын Вася һич кенә башына сыйдыра алмый иде. Кайсы яктан гына чыгып уйласа да Вася башында кайнаган бу сорауларга җавап таба алмады...

Косойны жирләп, берәр көн узгач, автомобильләр ремонтлау мастерскоена тикшерүчеләр килеп, «иснәнеп» йөрделәр. Сораулар бирделәр. Анисимов, гадәттәгечә ык-мык итте, үзенең аңгыра башына барып житмәгән сорауларга жавабы да керделе-чыктылы гына булды. Аны күзәтеп торган Вася: «Натуральный бозау!»— дип уйлап куйды. Әллә юри генә тилегә сабышамы, әллә чыннан да?.. Кулагиннан да сорау алдылар. Марат белән кызыксындылар. Ялантау янындагы «стрелкага» үзенең дә катнашы бармы-юкмы икәнлеген белештеләр. Гомумән, бу мастерской тирәсендә шикле эшләр ешайды, дип кисәттеләр. Вася барлык сорауларга да «Белмим..., ишеткәнем юк...» кебегрәк жавап бирде. Мастерской турында исә: «Монда һәрберсе үз эшен белә. Кыңгыр эшләргә вакытлары юк. Ә эштән тыш егетләрнең нишләп йөрүләрен каян белик. Һәрберсенең артына каравылчы тага алмыйбыз бит», — диюдән узмады. Марат турында сораштыргач: «Белмим, кайда йөридер, эшкә килгәне юк. Хәбәр итмәде. Каядыр юкка чыкты. Үзебез дә аптырашта», — диде. Аннан соң, үз өстеннән бурыч төшергәндәй: «Андый сәер яклары элегрәк тә булгалый иде», — дип тә өстәде. Женя Кривошеев турында сорашмадылар. Ул бу вакытта өендә, качып-посып, кулындагы ярасын ялап ята иде. Егеткә больницага барырга ярамый — утлы коралдан яралангannар турында шунда ук эчке эшләр идарәсенә тапшырачаклар. Ә анда инде төпченеп, төбенә төшмичә туктамаячаклар: кайда, ничек, ни өчен? Шуңа күрә Вася тикшерүчеләрнең Женя хакында кызыксынмауларына сөенеп тә куйды. Теге көнне кемнең кем икәнлеген танымый калганнар, күрәсең. Маратны таныганнар менә. Вася өчен анысы тагын да гажәбрәк. Бу үзе үк Маратның ментлар кешесе булуын раслый кебек. Ә Наил Хәкимыч бу хәлләргә кайсы яктан бәйле икән? Марат «чыбык очы туганым» дип, Васяның күзенә төтен жибәргән булды...

Шуңа күрә ул, бер очрашканда, Наил Хәкимовичка үзенең бөтен ачуын чыгарды. Нур Гаянович турында да шул чакта искәртте. «Үзеңнең артың пычрак икән, башкаларның күтен тикшермә», — диде, бик мәгънәле генә итеп.

— Чыбык очы туганыңны безнең арага нинди максат белән тыккан булгансың, белмим. Ләкин ул иң кыен чакта тәртәгә типте. Бөтен эшне бозып ташлый язды, — дип, Марат турында да исенә төшерде.

Тик артыграк сөйләп ташлаганын аңлап, бу хакта сүзне озынга сузарга теләмәде. Соңыннан, хәер, Хәкимыч инде күптән хәбәрдардыр, дип уйлап үзен юатты да, бүтән сөйләшергә теләгем юк дигәндәй, кулын селтәп китеп барды.

* * *

Оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәш бүлегенең оператив төркем җитәкчесе Саттаров Гомәр, Ялантау янында «тамерланлылар» һәм «әфганлылар» төркемнәре арасында булган вакыйгадан соң, бүлек җитәкчесе Шәрифуллин Әнис янына керде. Ул анда «стрелка»да катнашкан әлеге ике төркем турында мәгълүматлар тупланганын белә иде. Тамерланлыларның шәһәрдә нык йогынтылы төркем икәнлеге дә Гомәргә күптән мәгълүм.

Әле сиксәненче еллар азагында ук сәяси үзгәрешләргә, җәмгыятьнең эчтән какшый башлавына бәйле рәвештә, шәһәр яшьләре арасында шикле төркемнәр оеша башлады. Менә күп еллар дәвамында яшьләрне тәрбияләп торган пионер, комсомол оешмаларының таркалуы сәбәп булгандыр мөгаен. Аларга нинди дә алмаш кирәк иде бит. Изге урын буш тормый, дигәндәй. Төркемнәр әнә шундый җирлектә оештылар. Шәһәрдә теге яки бу төркемгә кермәгән яшьләр юк иде диярлек. Булсалар да бармак белән генә санарлык һәм, гадәттә, андыйлар кимсетелүләргә дучар иделәр. Шуннан соң дистә еллап вакыт узды. Җинаятьчел төркемнәрнең күпчелеге таркалды, алар урынына яналары барлыкка килде. Ә менә «Тамерлан» шул еллардан ук, ничектер, башкалар белән булган кискен көрәшләрдә бирешмичә, тотрыклы яшәвен дәвам итте. Үзләренә каршы төшкәннәргә аеруча кансызлык күрсәткәннәре өчен җинаятьчел төркемнәр алардан бераз шүрлиләр дә иде хәтта....

Ә менә әфганлылар төркеме тамерланлыларга һич кенә дә буйсынырга теләмәде. «Әфганлылар» дип аталсалар да, төрмәдән чыккан, җыен әтрәк-әләмнәр җыелган бу төркемнең Әфганстан һәм башка локаль сугыш ветераннары оешмасына, бигрәк тә интернационалистларны эш белән тәэмин итү максатында төзелгән автомобильләр ремонтлау станциясенә бөтенләй кагылышы юклыгын Гомәр бик яхшы аңлый. Мондагы егетләрнең Вася Кулагин тирәсендә нинди дер кыңгыр эшләр майтарып йөргәнлеген ул күптән түгел генә белде. Сирәк булса да әле тегендә, әле монда бу исем калкып чыга башлады. Эчке эшләр идарәсенең оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәш бүлегендә алар өстеннән аерым «эш» ачылган. Әледән-әле хокук бозулар кабатланып тора. Әлбәттә, хокук сакчылары тарафыннан «әфганлылар» төркеменең һәр адымы контрольдә. Һәрхәлдә, рәсми документларда бу шулай.

Сентябрь ахырында «тамерланлылар» белән «әфганлылар» арасында «стрелка» булачагы турында аноним хәбәр алынуга, милициядә баштан аның чынлыгына шикләнебрәк караса да, шайтан теле ни юрамас, дигәндәй, Саттаров җитәкчелегендәге оперативчылар юлга ашыкты. Алдан җибәрелгән төркемне алар шунда ук күреп өлгерделәр дә инде. Дөрес, берсеннән алынган Макаров пистолетыннан кала, егетләрдән шикләнерлек берни табылмады. Сораштыруга каршы: «Менә пистолет таптык та, сынап карар өчен ауга чыккан идек», — дип, алдаларга маташтылар. Пистолет белән ауга йөрмәгәннәрен сабый бала да белә, югыйсә. Андагы ике егетне, кулларына богау салып, тоткарларга туры килде. Шулар белән мәш килгән арада, урман поласасы янына «Ауди» килеп туктады. Ләкин аннан чыгучы булмады. Болар кемнәрнедер көтәләр. Оператив төркем дә агачлар ышыгыннан әлеге машинаны күзәтә башлады. Һәм, озак та үтмәде, икенче яктан тәрәзәләре карангылатылган «БМВ» машинасы күренде. Саттаров, егетләргә әзер булырга кушып, пистолетын кулына алды. Коралны һавага атып кисәтү өчен генә кулланырга дип команда бирде ул. Гадәттә, мондый «стрелка»лар атышусыз узмый. Төркемнәр нәрсә дә булса бүлешә алмаганда гел «стрелка»га чакырышалар. Сүз дә юк, болар да корал кулланачак. Ләкин

эшне мона кадәр житкерергә ярамый, коралсызландырып, кулга алырга кирәк үзләрен.

Чыннан да, машиналарда утыручылар чыгып, бер-берсенә каршы атлагач, Саттаров аларның Ялантау янына юкка гына килмәүләрен, ике якның да бары тик корал телендә генә сөйләшергә теләвен сизеп алды. Атыш башланганчы өлгерергә кирәк иде. Шунда ул егетләренә: «Әйдәгез, якынрак киләбез!» — дип команда бирде. Тик «тамерланлылар» бер үк юнәлештә иде — алар милиционерларны күреп алдылар. Араларында ыгы-зыгы башланды. Кирегә борылып, табан ялтыратучы «паникерлар»га «әфганлылар» пистолетлардан ут ачты. Тәртипсез рәвештә атыш башланды. «Тамерланлылар»дан берәү егылды, калган икесе машинага йөгерде. Аларның да берсе яраланды булса кирәк. «БМВ» ишегеннән милиционерлар ягына автомат очереды булып алды. Тик ул беркемгә дә зарар китермәде. Ядрәләр колак төбеннән генә сызгырып узды. Инде бу хәлләрдән соң «әфганлылар» да борылып, милиционерларны күреп өлгерде. Шунда Саттаров егетләрнең берсен танып алды. Ул кайчандыр Чечняда аның взводында хезмәт иткән иде. Исемен дә хәтерли әле — Марат бугай.

Ә аннан соң вакыйгалар шулкадәр тиз алышынды... Каршыдагы егетләрнең берсе, пистолетын күтәреп, Саттаровка төбәде. Шунда көтелмәгән хәл булды: Марат тегенә атып жибәрмәсенме! Анысы, яралы кулын тотып, аптырап торганда, янәшәдәгесен дә атып екты ул һәм урманга таба йөгерде. Беренче аткан яралы егет Марат артыннан ташланды. Ул арада «БМВ» белән «Ауди» машиналары икесе ике якка китеп югалды. Урман эченә кереп качкан егетләр артыннан өч милиционер куа китте. Жирдә бары тик ике жансыз гәүдә генә ятып калды. Егетләр икесе дә шунда ук жан биргәннәр. Саттаров аларның кесәләрен капшады. Бернинди документлары да юк иде әлбәттә...

Маратның дусларга каршы корал күтәрүенең сәбәбе, үз алдында бурычын үтәү өчен булганына Саттаров шикләнмәде. Димәк, ул аңа карата яхшылык эшләгән булып чыга инде. Гомәрнең элекке яхшылыгына, ягъни аны үлемнән йолып калуы өчен рәхмәте. Тик бер үк гамәл төрле күзлектән караганда төрлечә бәяләнә. Кешелеклелек ягыннан Гомәрне үлемнән коткарып калуы изгелек булса, «тамерланлылар» ягыннан — теләктәшлек, «әфганлылар» ягыннан караганда — хыянәт! Хокук сакчылары өчен — жинаять булып исәпләнә. Әйе, әйе, жинаять! Беренчедән, ул жинаятьчел төркем әгъзасы, икенчедән, кеше үтерүче. Дөрес, үтерелгән егет тә жинаятьчел төркемнән. Ләкин ул барыбер кеше бит...

Бу хәлләрдән соң Маратның «әфганлылар» төркеменә сыймаячагын Саттаров аңлый. Хыянәтчеләрне беркайчан да, беркайда да гафу итмәгәннәр. Шулай ук, хокук сакчылары кулына килеп эләксә дә аны жәза көтә. Чөнки анда жинаятьчеләрнең башыннан сыйпамыйлар. Гомәр уенча, Ялантау янында булган вакыйгалардан соң, Марат качып яшәргә мәжбүр.

Саттаров тикшерүчеләрдән алган «Дело»ларны яхшылап өйрәнде. Аларның Тамерлан төркеменә кагылганы берничә том тәшкил итсә, чагыштырмача соңрак оешкан «әфганлылар»ныкы юкарак иде. Аларда фамилияләр дә бармак белән генә санарлык. Лидерлары ниндидер Вася Кулагин исемле егет икән. Гомәр күпме генә эзләсә дә, ул «Дело»дан Марат турында бернинди дә мәгълүмат тапмады.

«Стрелка» урынында ятып калган ике мәетнең кемнәр булуын тикшерүчеләр тиз ачыкладылар. Аларның берсе «тамерланлылар» шайкасының иң актив әгъзасы — инде берничә мәртәбә төрмәдә утырып чыккан «Кабан» кушаматлы Сизов Геннадий Николаевич иде. Икенчесе — «әфганлылар» ягыннан, Расих Нигъмәтуллин. Хулиганлык өчен хөкем

ителеп, бер мәртәбә утырып чыккан адәм. Соңгы вакытта беркайда да эшләмәгән. Ничек көн күргәндер, анысы мәгълүм түгел.

Оператив төркемгә үзләрен «пистолет белән ауга чыктык» дип алдашкан ике егетнен дә кем булуларын тикшерүчеләр бик тиз ачыклады. Алар, шулай ук, бер җирдә дә эшләмәүче Сарматов Николай белән Шәфыйков Айтуган иделәр. Ләкин «әфганлылар» эше буенча кузгатылган элекке «Дело»ларда аларнын да исемнәре чыкмады. Бу егетләрнең моңа кадәр җинаять җаваплылыгына тартылганнары булмаса да, аларны тоткарлап, вакытлыча сак изоляторына ябып куйдылар.

Тикшерүче, тамерланлылар төркемендә йөриләр, дип шикләнелгән берничә егетне чакыртып сөйләште. Төркемнең лидеры Тимур чакыруга килмәде.

Әфганлылар ягыннан ачыклыйсы сорауларга җавап табу өчен тикшерүчеләр гараж кооперативында да булдылар. «Ялантау вакыйгасы» турындагы эш тикшерүчеләргә тапшырылды. Үзенә бернинди кагылышы булмаса да Гомәр аларга ияреп барды. Исәбе Марат турында җентекләбрәк белү иде. Тик Вася Кулагин авызыннан: «Белмим, кайда йөридер, эшкә килгәне юк. Хәбәр итмәде. Каядыр юкка чыкты. Үзебез дә аптырашта. Андый сәер яклары элегрәк тә булгалый иде», — дигән сүзләрдән башка нәрсә ишетмәде.

* * *

Наил Хәкимович белән Василий Кулагинның дуслыгы сизелми генә башланган иде. Ул вакытта Наил, хәрби комиссариат аша, төрле елларда Әфганстанда интернациональ бурычларын үтәгән егетләрне эзләп табып, җыелышларга чакыра башлаган иде. Бергә җыелып, хәл итәсе проблемалар да шактый: армиядә һәлак булып, цинк табут белән кайткан солдатларга кабер ташлары ясату, зыярат кылу, аларның гаиләләренә ярдәм итү, мәктәпләрдә музейлар оештыру, укучылар белән очрашулар үткәрү — менә шундый тавык чүпләп бетермәслек эшләр. Боларның барысын да җәмәгать тәртибендә, эштән соң яки ял көннәрендә башкардылар. Әнә шул чакларда ук Василий Кулагин Наилгә теләктәшлек белдереп йөрүче иң ышанычлы егетләрнең берсенә әверелде.

Наил совет солдатлары Әфганстанга кертелгән беренче елларда хезмәт иткән, Василий исә унъеллык бу сугышның ахырына эләккән. Еллар аермасы күп булса да бер үк юлда йөргәннәр, бер үк авырлыкны үз җилкәләрендә күтәргәннәр, хәзер дә максатлары бер. Бәлки егетләрне әнә шул берләштергәндер, Наилнең үз-үзен аямыйча, «әфганлылар» өчен янып-көеп йөрүе Василийда ихтирам уяткандыр. Очрашулары бик җанлы уза иде. Кайнар әңгәмәләр тынып торган арада, Василий кулына гитарасын тотып, берәр әфган җырын җырлый башлый. Аның бераз гына гырылдабрак чыккан тавышына башкалар кушыла. Кайчак патриотик җырлар «блатной» җырлар белән аралашып китә. Василий аларын аеруча осталык белән башкара. Шуңа күрә, җырларның мондые да егетләр күңелендә бердәй хуплау таба иде...

Ул елларда әфган сугышы ветераннарын эш белән тәэмин итү буенча Наилгә күп көч түгәргә туры килде. Әлбәттә, үзе максат итеп куйганнарның күбесенә ирешә дә.

Туксанынчы еллар, башыннан ук, халыкка көтелмәгән сынаулар куйды. Илдә кризис. Кибет киштәләре буш. Хәер, гади халыкның әйбер сатып алырга акчасы да юк. Чөнки икътисади кыенлыкларга каршы тора алмыйча, илдә күп кенә предприятиеләр бөлгенлеккә төште яки бөтенләй ябылды. Күпләп эштән кыскартулар... Хезмәт хакын яртышар елга, кайчак аннан

да озакка кичектереп түләүләр. Эшчеләргә эшләгәннәре өчен әйберләтә түләү модага керде. Көнкүрешкә мона кадәр колак ишетмәгән «бартер» дигән сүз таралды. Әнә шул «болганчык еллар» шаукымында, хөкүмәт хәерфатихасы белән, кече бизнесны үстерү программасы нигезендә, яңгырдан соң тишелеп чыккан гөмбәләр шикелле, күпсанлы кооперативлар оешты. Социализм системасы таркалып, черек капитализм исе килә башлады. Совет заманындагы кыйммәтләр икенче планга күчте. Ләкин бер чиктән икенчесенә сикерү сәясәте алып барган Россия — капитализмда да Россия булып кала бирде. Үстерәбез, дип лаф орып кына бизнес үсми бит әле ул. Башта аңа нигез әзерләү, эшмәкәрләрне яклау өчен житди законнар кабул итү зарур. Ә болар берсе дә башкарылмады. Шунлыктан, безгә ирек, хөррият, дип үзләренең эшләрен башлаган адәмнәр икенче зур каршылыкка очрадылар. Илдәге олы-олы дәүләт предприятиеләре башында утыручы өлкән абзыйлар, алны-артны карамыйча, дәүләт милкен талаганда, халыкның маңгай тире бәрабәренә житмеш елдан артык тупланган байлыкны бүлешкәндә, завод-фабрикаларны хосусыйлаштырып, үзләренеке итү белән мәшгуль булганда, оешкан жинаятьчел төркемнәр, зурдан кубып, эшмәкәрләр дилбегәсен үз кулларына алу хәстәрен күрә башладылар. Хөкүмәт булдыра алмаганны, жинаятьчел клан үзенчә хәл итеп тә өлгерде. Әнә шулай итеп, эшмәкәрләр ике яклап кабалага эләкте. Бер яктан, сүз боткасы куертудан башка бернинди ярдәм күрсәтмәгән хөкүмәт аларны салымнар, аренда түләүләре белән кысса, икенче яктан, без сезне саклыйбыз, дигән сылтау белән «крышалар», шикле төркемнәр, оятсыз адәмнәр, рэкетирлар йодрык терәп акча даулый башладылар. Ныклап аягында басып тора алмаган шәхси эшмәкәр, мондый кабалага түзә алмыйча, эшен ябарга мәжбүр була, әлбәттә. Шуңа күрә ул елларда яңарак кына ачылган дистәләрчә, йөзләрчә кооперативлар бер-ике ай, күп дигәндә ярты ел эшләгәч ябылырга мәжбүр булдылар. Әлеге әкәмәт күренеш кечкенә балаларның сабын күбегеннән куык ясап уйнавын хәтерләтә иде: бераз кабартасың да «пылт» итеп сүнә, бераз кабартасың да...

Шул чорда Василий машиналар ремонтлау өчен шәхси мастерской оештыру турында тәкъдим белән чыкты. Кооперативларга, шәхси оешмаларга теше-тырнагы белән каршы булса да эш таба алмыйча йөргән әфганчыларны кайгырту йөзеннән, Наил аның бу тәкъдименә ризалашты. Васяның киңәш соравы да, аны олылаудан бигрәк, эшне башлап жибәрү өчен ярдәм өмет итү, ә бәлки финанс ягын кайгыртудан булгандыр. Ни әйтсән дә, Наил гади эшче генә түгел, йогынтылы адәмнәр белән элемтәсе зур. Төзелеш тресты житәкчелегендә эшләгәнлектән, матди база туплауда да ярдәме тияргә мөмкин.

Тиздән Наил әлеге мәсьәләне шәһәр хакимияте алдында күтәрде. Аны хәл итүгә депутатларның да ярдәме тиде. Гаражлар кооперативында кайчандыр төзелә башлап, финанс житмәү аркасында туктап калган бер-ике боксны төзеп бетереп, шул корылмаларны киләчәктә шәхси эшмәкәрлек белән шөгыльләнү өчен файдаланырга була дигән карарга килделәр. Ә төзеп бетерү өчен жирле бюджеттан бер тиен дә бүлеп бирелмәде. Шулай булса да жирле газеталар «әфганлы»ларга ярдәм итүнең шәһәр хакимияте керткән өлешен шактый күпертеп язды. Республика газеталары хәтта әлеге хәлне «Матур башлангыч» дип атап, «әфганлы»ларның хәлен жиңеләйтү өчен башка төбәкләрдә дә шундый ук эшләр башкарырга була дигән тәкъдим белән чыктылар.

Төзелеш материаллары, техника белән Наил Хәкимович үзе ярдәм итте. Әле тегендә, әле монда кадерсезләнеп ятучы тактасындыр, кирпечен, ташын

җыйгаладылар, искеләрен дә «ходка» җибәрделәр. Бөтен эшне «әфганлылар» үз көчләре белән бушлай эшләделәр. Бер-ике ай дигәндә, мастерской өчен биналар әзер иде инде. Төп капканың өстенә эре хәрефләр белән: «Автомобильләр ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү мастерское» дип язылган такта эленде. Наил Хәкимович ишек янәшәсенә «Биредә сезгә әфган сугышында катнашып, утны-суны кичкән егетләр хезмәт күрсәтә» дигән язу да кадаклатты.

Әлбәттә кооператив законлы рәвештә Наил Хәкимович исеменә рәсмиләштерелде. Бу шулай булырга тиеш тә иде сыман. Үзенең төп хезмәт урынында кыенлыклар баштан ашкан булуга карамастан, Наил кооперативны оештыру мәшәкатьләренә һәм финанс мәсьәләләрен көйләүгә шактый көч сарыф итте. Шуңа күрә, эшләр җайга салынып, табыш ала башлагач та Наил Хәкимовичны онытмадылар, аңа шактый гына өлеш чыга торган булды. Наил үзе дә моңа каршы түгел иде, шулай булырга тиеш дип кабул итте. Ә иң яхшысы, аларның кооперативына «крышалар» да, рэкетирлар да борын тыга алмады. Андыйлар күренә башласа, егетләр бердәм җыелып, шунда ук тиешенчә каршылык күрсәтәләр иде. Бизнес үзен аклый башлады, янәшәдән тагын бер-ике боксны сатып алдылар, киңәйделәр. Яхшы эшләгәч, кооперативның даны тиз таралды. Күпчелек клиентлар туры аларга килә иде...

Наил Хәкимович үзен җирле Советларга депутатлыкка кандидат итеп күрсәткәч, аның исемендә торучы бу кече предприятие комачаулык тудыра башлады. Үзең безнесмен һәм шул ук вакытта «халык хезмәтчесе» дә булу бигүк макталмый. Кризистан башлары әйләнгән гади халык болай да эшмәкәрләрне куралмас дәрәҗәгә җиткән иде инде. Совет тәрбиясе алган кешеләр өчен бизнес белән шөгыльләнүчеләр, барыбер «спекулянт» булып кала инде. Киләчәктә депутатлык карьерасына комачаулык тудырмасын өченгә, Наил Хәкимович, әлеге кооперативны икенче кешегә саткан кебек итеп рәсмиләштерергә карар кылды. Вася Кулагин кооперативны үз исеменә күчерерләр дип өметләнеп йөрде. Баштарак Наил үзе дә шулайрак сөйләнгәндәй иде, ләкин, һич көтмәгәндә, фикере үзгәреп куйды. Документларны һәм бар мөлкәтне ниндидер Анисимов Юрий Николаевич исеменә яздырды. Әйтүләренә караганда, бу йомыкый кеше белән кайчандыр ГПТУда бергә укып, «студент шулпасы»н бергә чөмергән булганнар бугай. Кооператив яңа исем белән аталып, аның җитәкчесе алышынса да Васяның вазифалары үзгәрмәде. Элек нәрсә башкарган булса, хәзер дә шуны ук башкара. Тик алар арасыннан барыбер кара мәче узды инде.

Тора-бара Вася үз тирәсенә шикле адәмнәрне, төрмәдән чыкканнарны туплый башлады. Күңеле белән кыңгыр эшләргә әвәс Вася моңа бик җиңел иреште. «Әфганлылар» кайсы кайдан эш табып, әкренләп мастерскойдан китә башладылар. Наил Хәкимович, үзенең ышанычлы «гвардия»сен югалту куркынычы яный башлагач, Вася белән утырып сөйләште. Тик тегесе төпле бер сүз дә әйтмәде...

* * *

Маратның асылынган гәүдәсен табып, җир куенына салгач, Женя Кривошеевның күңеле бераз тынычланды. Шулай булмый ни, Ялантау янында Маратны кулдан ычкындырган өчен Вася әнә ничек кабарынган иде. Әйтәсе дә юк, кызу канлы. Бәргәләп ташларга да күп сорамас. Юкка гына кушаматы Кулак түгел. Хәер, кушаматы аның Кулагин фамилиясеннән алынган үзе...

Тамерланлылар белән «стрелка» вакытында Марат Косойны атып еккач,

Женя аның артыннан йөгергән иде йөгерүен. Күздән яздырды шул. Куаклык эченә кереп чумды да жир йоткандай каядыр юкка да чыкты. Шуннан кайткач, Кулак ана Маратны жир тишегеннән булса да табарга әмер бирде. Ә берничә көннән, Женя яралы кулын бераз дәвалап эшкә чыккач, кабат исенә төшерде. Босс та Маратны кичекмәстән табып, юк итәргә кушкан. «Ул исән йөргәндә, босстан сиңа да, миңа да көн булмаячак. Кара аны, шул гниданы үтереп, тугрылыгыңны миңа дәлилли алмыйсың икән, үзеңнең жаныңны кыячакмын», — дип куркытып та маташты хәтта.

Женя Босснын кем икәнен әлегәчә тәгаен генә белми. Ичмасам, бер мәртәбә дә күргәне дә юк. Аларның шайкасы Кулакка берсүзсез буйсына. Ә югарыдарак торганнарны алар командасында беркем дә белми булыр. Шуңа күрә, Кулак алар төркеменең житәкчесе дә, шул ук вакытта Босс белән бәйләп торучы арадашчы да. Төркемдәгеләр аннан шыр жибәреп шүрли. Аның кулы дүрт нәрсәгә оста: акча санарга, машина йөртергә, сугышканда дошманының борын төбенә ямарга һәм хатын-кыз капшарга. Хәйләкәр, тиз кызучан, тешләк бу егетне Босс нәкъ менә шул сыйфатлары өчен яратадыр, мөгаен. Әйе, хәйләкәрлек хәттин ашкан анда.

Женя Марат хакында Кулак куйган ультиматумны онытмаган иде. Шуңа егетнең асылынган үле гәүдәсе табылгач, күңеле тынычланып калды. Монда дәлилләп тә торасы юк, бар да аңлашыла: үлгән, беткән. Ә инде Марканы жир куенына да салып куйгач бөтенләй йомшарды.

Шул кичне ул ресторанга килде. Анда Кулак белән Зебраны очратты. (Әти-әнисе кушкан исемен сакларга тырышып дус-ишләре Зәбирне Зебра дип кенә йөртәләр). Женя өстәл янында Маратның үлеменә карата аларның фикерен ишетергә теләде. Хәтта үз чутыннан «сыйларга» да риза иде егет. Тик ресторанга килгәндә үк шактый кызмача булган Зебра кәефен кырды. Әңгәмә тиешле юнәлеш ала дигәндә генә ул һаман үзенең кичә күңел ачкан хатыннары турында сүз башлый. Әйтерсең лә Маратның үлеме дә, башка тормыш мәшәкатьләре дә аның өчен вак-төяк кенә. Гомумән, Зебра бүгенге көн белән генә яшәүче бәндә. Салырга да ярата. Хатын-кыз — аның бөтенләй йомшак ягы. Инде берничә мәртәбә «мәхәббәт чире» йоктырып, дәваланып та алды бугай. Шулай да, аз гына буш вакыты булдымы, һаман чәчбикәләр ягына каера. Жилбәзәк кызлары да гел сагыз шикелле ябышырга гына торалар үзенә. Иш—ишен ерактан таный, дигәндәй...

Вакыт әрәм итеп утырганчы дип, такылдык Зебраны Кулак белән икәүләшеп озата чыктылар. Аннан соң «донжуан», айкала-чайкала өенә юл тотты. Дөресрәге, аның күңелендә һаман төнге мажаралар эзләү иде әле. Шуңа күрәдер егетләргә үзен озаттыртмады да.

— Озатыйк. Бу тирәдә Тамерлан шайкасы егетләре күренгәли, — дип үгетләүгә каршы Зебра кулын гына селтәде һәм парктагы агачлар арасына юл тотты.

Егетләр аллея янындагы эскәмиягә утырып тәмәке кабыздылар. Женя Маратның үлеменә карата Кулакның фикерен беләргә тели, тик тегесе генә, тәмәкесен суыра-суыра, үткәләп-сүткәләп йөрүче хатын-кызларны күзәткәләп, Женяның кайбер сүзләрен бөтенләй искә алмыйча үткәреп жибәрә тора.

Женя, бераз утыргач, туп-турысын әйтеп сөйләшергә булды:

— Маратны әйтәм, башта Косойны, аннан Артемканы дөмектергәч, үзе дә муенын элмәккә тыккан, яшәргә рәт калмады, дип уйлады микән? Вөжданы газаплагандыр... Үз корефейларына пушка төбәгәч, — дип куйды.

Кулак егеткә сәерсенгән сыман караш ташлады. Аннан соң тәмәке төпчеген чүп савыты ягына чиртеп жибәрде дә авызыннан төтен алкалары өрә-өрә:

— Вөждан дисең инде алайса?.. Ә нәрсә икәнен беләсеңме соң син аны

— вөжданны?.. Әллә Маратны шулай тиз генә бирелә торганнардан дип уйлыйсыңмы? — дип куйды.

— Юк, ул турыда базар булуы мөмкин түгел. Мин аның тиз генә бирешмәслеген беләм... Ну, барыбер үлгән бит инде. Безнең өчен ничек үлсә дә... юк инде ул.

Тик Кулак аның сүзләрен бүлдереп, соравын янә кабатлады:

— Маратны үзе үлгәндер, дисенме?

Женя, гаҗәпләнеп, Кулакка текәлде. Ул аннан мондый сорауны көтмәгән иде. Шаяра гына дисәң, йөзе җитди күренә.

— Нәрсә, син үлмәгән дип уйлыйсыңмы әллә? Аны соңгы юлга озатканда бар идең бит. Каберенә балчык атканыңны оныттыңдамы?..

— Соңгы юлга озатканда гына түгел, муеныннан элмәкне алганда да шунда идем. Дөресрәге, мин килгәндә яңарак кына элмәктән төшергәннәр иде.

— Соң, шулай булгач?..

Кулак нәрсәнедер әйтеп бетерми. Монысын Женя шундук аңлап алды.

— Тик мин ышанмадым һәм ышанмыйм да...

Женяның күзләре мангаена менде. Ул бер тын сүзен дә әйтә алмыйча торды хәтта.

— Ничек инде?.. Нәрсәгә ышанмыйсың?..

Кулак «черт»ләтеп җиргә төкерде, аннан, озак кына көттереп:

— Мәетнең Маратныкы булуына, — дип куйды.

Женя монысын ук көтмәгән иде, әлбәттә.

— Нәрсә, акылдан шаштыңмы әллә? Әнисе булып әнисе, ничек өзгәләнеп, шашып елады... Барысы да хушлашты... Шикләнерлек нәрсә бар соң?.. Әллә шаяртасың гынамы? Монда икеләнерлек урын юк, минемчә...

Кулак авыз читен мәзәк кенә чалшайтып елмаеп куйды:

— Ә син аның чыннан да Марат икәнлегенә раслап күрсәт.

— Соң, нәрсәсен раслыйсы... Менә, мәсәлән, каршымда син торганга мин расламасалар да ышанам.

— Ә мин ышанмыйм! Каршымда син торганга мин кайчак ышанмыйм да! Бәлки каршымда кыяфәте белән генә сиңа охшаган икенче берәүдер. Ә менә кулыңдагы татуировканы күргәч, ышанам...

Кулак Женяның кулыннан кысып тотты да егетне үзенә якынрак тартты, җиңен терсәк турысыннанрак сыдыра төшеп, кул буынтыгының эчке ягына ясалган рәсемгә күрсәтте:

— Менә шушы татуировка синең Женя икәнеңне әйтеп тора...

— Соң татуировкалы адәмнәр күптер ул, — дип сүзен сүз итәргә маташкан иде, Кулакның чынлап ачулана башлавыннан куркып, тынып калды.

— Татуировкаң гына түгел, аны ясау рәвеше үк син икәнне кычкырып тора. Тагын кайсы идиоты үзенең кулына хатын-кызның бала таба торган нәмәстәсен ясап куяр икән?!.

Женя кыенсынмады. Ул мондый төртмәле сөйләшүләргә ияләнеп беткән инде. Чөнки әлеге татуировканы күргәннәр һәрчак тыела алмыйча көләләр генә. Кулы буыныннан бөгелгәндә ул кыймылдап тора.

Женя Кулакның тел төбе кая таба барганын аңлый башлады.

— Нәрсә Марканың татуировкасы юк иде, димәкче буласыңмы?

— Әгәр хәтерләсәң, аның күкрәгендә бөркет төшерелгән иде.

— Әйе, беләм. «Орлы гнездятся на скале» дип язып та куелган иде бугай. Күлмәк изүен ачып йөргәндә, ул күренеп тора иде.

— Мин аны элмәктән алгач ук килеп җиттем бит. Гәүдәсен ишегалдына

чыгарып салганнар иде. Шунда, жил чыгып, күлмәге ачылып китте. Аның корсак астында шактый зур гына җөе бар иде. Мин аны бер мәртәбә мунчада күргәч, сораштырып та маташкан идем. Чечняда алган ярадан калган икән ул. Мәетнең исә әнә шул җөй урынында тиресе сыдырылган кебек ачык яра гына. Мин, аптырагач, күлмәген тартып кую сылтавы белән, иелеп капшап та карадым.

— Ә татуировканың нинди катнашы бар соң монда?..

— Шунда күзем күкрәк турысына төште, татуировка булырга тиеш урында да шундый ук сыдырылган чи яра. Менә шуннан күңелгә шик керде.

— Соң, Марат ул көннәрдә качып йөрде. Бакчаларда дисеңме, урманнарда... Сыдырылган, җәрәхәтләнгән урыннары булгандыр инде...

Кулак Женяга ачулы күз ташлады.

—Булгандыр... Булгандыр, — дип үчекләде ул аны. — Мин үзем дә баштан икеләнеп йөрдем, бәлки дөрес күрмәгәнмендер, дип уйладым. Икенче көнне, шикләремне тарату өчен, моргка барып, гәүдәсен җентекләп карап чыктым. Ләкин...

— Соң әйтеп торам бит, ул көннәрдә Марка качып-посып йөрде. Бакчаларда кунып-төнеп йөргән кешедә сынган, сыдырылган урыннар була инде ул.

— Анысы белән дә килешер идем. Тик Маратның тәнендә тагын бер татуировка бар иде. Җүләрлек белән ясатканмын, хәзер ничек бетерергә белмим дип сөйләнгәнен үзем ишеттем. Чөнки анда бик әшәке сүзләр язылган иде. Шул татуировка урынында да тиресе сыдырылган иде.

— Соң, бетергәндер...

Кулакның бу юлы чынлап ачуы килде. Ул Женяның якасыннан йомарлап тотты да үзенә тартты. Һәм, тешләрен кысып, ысылдап чыккан ачулы тавыш белән:

— Берьюлы өч урында һәм татуировкалар булган җирдә генә тән сыдырылмый бит инде, идиот. Аңладыңмы? — диде.

Женя аннан куркыпмы, әллә чыннан да ул әйткәннәрне күз алдына китерергә тырышыпмы, туктап калды. Кулак кулларын йомшартты, аннан соң бөтенләй ычкындырды. Тәмәкесен кабызгач, якындагы эскәмиягә утырып, уйга калды. Чыннан да, шикләнсән шикләнерлек урын бар монда...

* * *

Ялантау янындагы урман ышыгында тамерланлылар белән «стрелка»дан соң Марат берничә көн урманда яшеренеп ятты. Ул анда утын әзерләүчеләрдән калган шалаш сыман нәрсә дә тапты хәтта. Агач ботаклары белән тишек-тошык урыннарын каплаштыргач, астына калын итеп кипкән яфраклар түшәгәч, ярыйсы гына куыш барлыкка килде. Берәр көн яфрак өстендә аунагач, Марат башкача монда калырга ярамаганлыгын аңлады: беренчедән, аның эзенә төшү өчен ментлар урманнарны «тарап» чыгарга мөмкин; икенчедән, биредә ризык табу бик авыр. Кулда корал-мазар булмагач, киек җәнлек тә атып булмый. Аулаган очракта да, аны чи килеш ашамас бит. Шырпысы юк, зажигалкасы каядыр төшеп калган. Әнә шуларны уйлагач кешеләргә якынрак урнашырга дигән карарга килде ул. Тик шәһәргә кайтырга ярамый. Шунда ук эләктереп алачаклар. Өстәвенә, теге көннән соң ул ике ут арасында калды: бер яктан ментлар, икенче яктан элеккеге дуслары. Марат берсеннән дә шәфкать көтми: беренчеләре, кулыңны боргычлап, каталашкага тыгып куячак; ә икенчеләре бугазыңа хәнҗәр кадаячак — иң яхшы дигәндә, маңгаеңа ядрә җибәреп, үлемеңне җиңеләйтәчәк. Әнә шуңа күрә, дус-

ишкә яки таныш-белешкә сыенып, яшеренеп яту варианты үзеннән-үзе төшеп кала. Документ-фәлән булмаганда, әллә кая еракка чыгып китү мөмкинлеге дә икеле. Ярдәм итәргә, озатып куярга бик якын дустың булса ярар иде. Ә монда...

Озак уйлый торгач, шәһәрдән җиде-сигез чакрым ераклыкта урнашкан бакчачылык ширкәтенә барып яшеренер урын табарга дигән карарга килде егет. Аларның үз «фазенда»лары да шунда. Гомумән, Марат өчен таныш урын. Якын-тирә урманнарны да яхшы белә. Кирәк вакытта качу мөмкинлеге дә зур. Әле күз, бакчаларда уңышны яңарак кына җыеп алдылар. Анда бәрәңге дисеңме, кишер-чөгендере табылыр. Янгырларга китсә баш өстендә түбә булыр. Соңыннан күз күрер әле.

Марат үзләренең бакча йортларында яшәргә уйламады да. Ана күзәтү куйган булулары мөмкин. Анысына «легавый»ларны өйрәтеп торасы юк. Инде күптән башлары җиткәндер. Дөрес, элекке дуслары, братаннарының да куллары озын, кайлардан эзләргә кирәклеген тиз чамалаячаклар. Шулай булгач, үз өенә барып тору — үзеңне үзең илтеп ябу белән бер булыр иде.

Шуларны уйлагач, Марат үзләреннән ерактарак бер бакча өенә урнашты. Анда инде күптән хуҗалары килгәне юк. Ул бер карт белән карчыкныкы булган. Ләкин тегеләр кинәт кенә икесе дә бер вакытта диярлек үлеп киткәннәр дә, инде бакчага килердәй туганнары юк ахрысы. Тирә-күршесе дә бакчага әллә ни килми. Кунып-төнеп ятучылар бөтенләй юк. Көзнең соңында гомумән кешеләр бакчага сирәк йөри. Димәк, беразга качып яшәү мөмкин булачак.

Башта ул аеруча сак булды, көн яктысында куышыннан чыкмады да диярлек. Кич, караңгы төшә башлагач кына, тирә-якны күзәтеп кайткалады. Эзләнә торгач, бер онытылган бакчадан күпләп бәрәңге җыйды. Хуҗалары алмыйча калдырган, күрәсең. Икенче бакчадагы түтәлдә вак булса да бераз кишер бар иде. Ачык калган бер алачыкта помидорлар тапты. Дөрес, аларның яртысы черегән. Ләкин, караштыргалый торгач, ашарга яраклылары да шактый җыелды. Кичен үзләренең бакча өйләреннән газ плитәсен алып килде. Әнисе борчылыр борчылуын. Тик бакча йортыннан әйбер урлау бу ширкәттә генә түгел, бөтен җирдә гадәти күренеш. Кайвакыт «бомж»лар «рейд» ясап, бакча йортларын рәттән чистартып чыга. Әнисе газ плитәсен кем алып чыкканны сизмәячәк.

Ә бер көнне Марат әнисен күрде. Шактый ерак булса да, ул урнашкан өйнең тәрәзәсеннән үзләренең бакчасы күренеп тора. Әнисе вак-төяк эшләр табып, әле тегесен, әле монысын кузгаткалап, чыбык-чабык җыйгалап, бер-ике сәгать шул тирәдә йөргәләгән булды да кайтып китте. Эче пошканнан йөридер инде мескен. Эш белән борчуларым онытылыр дип уйлый күрәсең. Тик ялгызы гына әллә нәрсә майтара алмый шул. Бүтән вакыт булса, агачларны бәйләшергә дип Маратка дәшкән булыр иде... Элегрәк эш күп, вакытым тар, тормыш мәшәкатьләре дип, Марат аңа әллә ни булыша да алмады. Ә монда... Хәзер әнә бер эше дә юк. Вакыты да җитәрлек... Тик барыбер булыша алмый... Ярамый... Әнә шундый уйларга бирелеп, әнисен читтән генә күзәтүдән уза алмады.

Ә бер көнне әнисе бакчага Люба белән килде. Агачларны бәйләшергә ярдәмгә чакыргандыр инде. Кайгы кешеләрне берләштерә шул, хәзер ничектер якынаеп та киткәннәр. Шунда Марат, әнисенә сиздермичә генә, Любаны күреп сөйләшергә дигән карарга килде. Тик җаен ничек туры китерергә? Тегеләр гел икесе бергә. Марат, коймага ышыкланып, куе булып үскән кура җиләге артына кача-поса, үз бакчалары янына якын ук килде. Әнисе белән Люба аермачык күренә, сөйләшкән сүзләре дә аермачык

ишетелеп китә. Тик күпме генә теләмәсен, Люба ул посып торган урынга якын килмәде, хәтта ул якка борылмады да. Ә Марат хатынның игътибарын ничек җәлеп итәргә белмичә гаҗизләнде.

Ярты сәгатьләп шулай үткәндер, ниһаять Люба чиләкләргә чүп-чар, иске-москы, тирескә ярамаган полиэтилен пакетлар һәм шешәләр тутыра башлады. Ул хәзер аларны урам чатындагы чүп контейнерына илтеп бушатачак. Моны Марат тиз чамалады. Люба белән очрашып сөйләшү өчен шуннан да кулай вакыт булмаячак. Егет әнисенең читкәрәк карап торганын көтте дә, мәче житезлеге белән тыкрык башыннан икенче бакча янына йөгереп, чүп савытлары артына качты. Чыннан да, биш-ун минут үтте микән, кулына ике чүп чиләге асып, Люба контейнерлар тарафына юнәлде. Килеп житкәч, бер чиләген жиргә куеп икенчесен түгәргә жыенганда гына Марат контейнер артыннан башын калкытты. Аны күргәч, хатынның йөзендә курку чалымнары пәйда булды. Ул хәтта «ах» дип кычкырып жибәрде һәм берәр адым артка чигенде. Контейнер читенә тотынмаган булса, бәлки артына да утырган булыр иде.

Ярый әле әни ерактарак, югыйсә ишетер иде, дип уйлады Марат. Ә үзе, бармакларын ирен читенә тидереп, «тс-с-с» дип ысылдады. Шунда, куллары кырынмаган йөзенә ышкылып узгач, Любаның ни өчен шулай нык курыкканын төшенде ул. Бөтенләй көтелмәгән урыннан, сакал-мыек баскан пычрак «бомж» килеп чыксын да, хатын-кыз ничек курыкмасын инде! Марат үзенең кыяфәте нинди булуын бөтенләй истән чыгарган иде шул. Монда инде ничә атна йөзенә бритва тигәне юк, юыну яклары да ташка үлчим, су булганда әллә нигә бер генә... Куркырсың да... Бәлки әле күрүгә үк танып та өлгермәгәндер. Дөрес, яшь хатын үз-үзен кулга алырга тырышты.

— Марат?.. Син?.. Каян килеп чыктың болай? — диде ул, куркудан һаман күзләрен түгәрәкләндереп.

Марат тагын бер мәртәбә: «Тс—с—с, шаулама», — диде дә, үзенә якынрак килергә ишарәләде.

— Сораштырма... Вакыт бик тар. Соныннан барысын да сөйләрмен.

Шунда ук Любаны битәрләп алды:

— Нәрсә мина карап каттың, чүбенне түгүеңне бел. Югыйсә, хәзер әни шикләнәчәк...

Люба чүп түккән кыяфәт ясады. Ике чиләкне озаклап бушатты ул. Ә шул арада Марат хатынына үзенең үтенечләрен тезде.

— Безгә очрашырга кирәк. Вакыт табып, бүген кичкәме, йә якын көннәрдә монда килеп чык. Кара аны, артыннан күзәтмәсеннәр! Әгәр килгәнеңне күрмичә калсам, әнә теге ташландык йортта булырмын. Берәз ашарга-эчәргә, кырыну-юыну әйберләрен дә онытма. Кыскасы, нәрсә кирәклеген үзең уйла. Никадәр тизрәк килсән, шулкадәр яхшырак... Әнигә сиздерә күрмә. Берни дә белмәсен...

Ике контейнер арасындагы бушлык аша Марат анасына да күз төшергәләде. Ул, Любаның контейнерлар янында озаграк торганын сизеп булса кирәк, берничә мәртәбә алар ягына караштырып алды. Артык торуда мәгънә юк иде. Люба, буш чиләкләрен селкеп, бакчалары ягына атлады...

Люба шул ук кичне килеп житте. Бер сумка тутырып азык-төлек, бер-ике шешә минераль су алган иде ул. Кырыну кирәк-яракларын да онытмаган. Өч-дүрт кап сигарет тыккан. Боларны күргәч, Марат чын күңелдән сөенде.

— У—у, бер айлык провизия алып килгәнсең син монда. Ничек күтәрдең? — диде ул, шатлыгын яшермичә.

Люба «попутный»га утырып килгән икән. Олы юлдан монда кадәр җәяүләп атлаган.

Марат шунда ук сигарет кабызып тирән итеп суырды. Аның күптән инде тәмәке капканы юк. Кайвакыт, сулышынаияләнелгән никотин кермәсә, юкка гына ачуы кабара торган иде. Тартасы килгән чакларда кипкән үлән төреп тартырлык хәлгә килгәләгәне дә булды. Төтен белән агуланган организм барыбер үзенекен сорый шул.

Бераз тынычлангач, Люба:

— Йә, хәзер сөйлә инде, син ничек мондый хәлгә төштең? Исән-имин үзен. Ни өчен качып йөрисең?.. — дип, сорау артыннан сорау яудыра башлады.

Тик, хатыны булса да, Маратның Люба каршында бик чишелеп китәсе килмәде.

— Хәзергә берни дә сорама, Любаша. Барысы да үз урынына баскач, аңлатырмын. Мондый вакытлар озакка бармас, тагын әйбәтләп яши башларбыз. Бераз буталыш кына килеп чыкты.

* * *

Көн төш вакытына якынлашып килә иде. Эчке эшләр идарәсенең дежур бүлегенә бакчачылык ширкәтендә асылынган ир-егет мәете табылу турында килеп әйттеләр дә, Саттаров Гомәр җитәкчелегендәге оператив төркем ашыгыч рәвештә шунда чыгып китте. Мондый вакыйгалар еш булганлыктан, «опер»лар өчен бу көтелмәгән хәл түгел. Хәтта көнгә бер-ике мәртәбә җинаять булган урыннарга барырга туры килгәли. Һәм, кайвакыт, ашыгыч рәвештә кузгалгач, урынга килеп җиткәнче кая һәм ни өчен барганнарын да төшенми калалар.

Оператив төркемгә хәбәр китерүче кешенең «Москвич»ы артыннан бакча кишәрлекләре арасындагы тар урамнардан боргалана-сыргалана шактый баргач, дүрт-биш кеше җыелып торган бакча өе янына килеп туктадылар. Капка янында җыелып торучы кешеләр төркеме читкә тайпылып милиционерларга юл бирде. Алдан баруы белән Гомәр, ачык чолан ишегеннән асылынып торучы кешенең аякларын ерактан ук күреп алды. Баудан төшермәгәннәр. Һәм дөрес тә эшләгәннәр. Гомәр мондый вакыйгаларны элегрәк тә хәтерле. Яңарак кына асылынмаган яисә кешене коткарып калу мөмкин түгел икән, милиция һәм суд-медицина экспертлары килмәгән килеш гәүдәне элмәктән алу киңәш ителми. Асылынган кеше, гадәттә башын үз теләге белән элмәккә тыга дип уйланылса да, бу һәрчак алай булмый, кешегә читтән «ярдәм иткән» очраклар да юк түгел. Гомәр андый хәлләрне дә белә.

Саттаров ишектән керешкә асылынган кешенең йөзен күреп имәнеп китте. Бу — әле моннан берничә атна элек Ялантау янындагы вакыйгалар вакытында Гомәрне үлемнән йолып калган, ә соңыннан милициядән дә, үзенекеләрдән дә качып киткән Марат иде. Димәк, бу көннәрдә ул шушы бакча өендә яшеренеп яткан булып чыга инде.

Гадәттә, мондый аулак урыннарда табылган мәетләрне тануы авыр була. Тик бу очракта кыенга туры килмәде — мәрхүмнең кем икәнлеген Саттаров кына түгел, бирегә җыелган һәркем белә булып чыкты. Монда килгән кешеләр аның туганнары һәм якыннары икән. Ә бакча егетнең әнисенеке ди.

Кызык, тикшерүчеләр менә инде ничә атна Маратның эзенә төшә алмадылар. Бакчаларын тикшермәделәр микәнни? Иң беренче шушында сак куярга кирәк иде югыйсә. Инде күптән эләктергән булырлар иде. Монда әнисе ашарына китереп йөргәндер әле...

Шунда Гомәр төркем янынннан аз гына читтәрәк басып торучы Вася Кулагинны күреп алды. Каяндыр ишетеп килеп житкән. Дөрес, Марат белән бер оешмада, хәтта үз кулы астында эшләгәч, монда килүе гаеп түгел анысы. Тик теге көнне, Ялантау янында булган вакыйгалардан соң, тикшерүчеләрнең Марат турында сораштыруларына каршы: «Белмим, күрмәдем, ишетмәдем, мина мәгълүм түгел» кебек сүзләр белән җавап биреп утырган иде. Ә бүген, сәгате-минуты белән ишетеп белгән дә, килеп тә җиткән әнә.

Гомәрнең үзенә игътибар иткәнен Вася да шәйләп алды, аның ягына борылып, башын иәде, исәнләшкән кыяфәттә иреннәрен селкетте. Тик аның һәр хәрәкәтеннән, үз-үзен тотышыннан Саттаровның монда булуына ризасызлык чагыла иде.

Суд-медицина экспертлары эшләрен бетергәч, хокук сакчылары Маратның гәүдәсен элмәктән алып, ишегалдына чыгарып салдылар, беркетмә төзеделәр, җыелган кешеләргә якынрак килү мөмкинлеге туды. Маратның әнисе Зәйтүнә апа инде еламый, ара-тирә бөтен гәүдәсе белән калтыранып, сулкылдап кына ала. Әлеге фаҗигадән гаҗиз калган ананың күзләрендә ниндидер чарасызлык галәмәте чагыла.

Шунда Вася Кулагин да якынрак килде, бераз карап торгач, иелеп Маратның корсак турында ачылып калган күлмәген каплаштырды. Юк, каплап кына калмады, ул аның корсагын капшады да кебек. Һәрхәлдә Гомәргә шулай тоелды. Әле аның белән дә бетмәгән икән. Вася торып басты да кабат иелеп, күкрәк тирәсендәге төймәсен чишеп, тагын нидер карады. Юк, Гомәр ялгышмады, Васяны чыннан да нәрсәдер кызыксындыра иде. Нәрсә икән?.. Шуннан соң Вася озак тормады, машинасына утырып китеп барды. Ул киткәч Гомәр Маратның мәетен җентекләп карарга исәпләгән иде. Тик кая ул? Читтән янә бер җансыз гәүдә табылгач, аның белән мәш килгән арада медиклар Маратны моргка алып китәргә әзерләп куйганнар иде инде...

Гомәрнең ул көне чамасыз мәшәкатьләр белән узды. Бары тик икенче көнне иртән, бераз эшләре кимегәч кенә ашыгып моргка китте.

Моргта эшләүче поталогоанатомны ул яхшы белә. Шамил Фатыйхович аны ачык чырай белән каршылады. Маратның гәүдәсен озакламый килеп алып китәчәкләр икән.

— Сез оперлар исәннәргә дә, үлгәннәргә дә тынгылык бирмисез инде, — диде ул шаярып.

Гомәр үтенечен җиткергәч, янәшәдә торучы өлкән абзыйга: «Яким дәдәй, менә бу иптәшне камерага озат әле. Милициядән ул. Кичә китерелгән егет гәүдәсен карарга тели», — дип үтенде.

Яким дәдәй дигәне Саттаровның милиция формасыннан икәнлеген үзе дә чамалаган иде. Карышып маташмады. Шулай да:

— Зурдан кубып тотындыгыз ахрысы. Инде иртән, тан тишегеннән, берәвегез аның янына мин милициядән дип килгән иде, — дип үз сүзен әйтергә ашыкты.

Гомәр сагая калды.

— Ә нишләде соң ул анда?

— Белмим, гәүдәсенең артын-алдын дигәндәй, җентекләп карап чыккач миңа бер иллелек төрткән булды. Алмадым. Үлеләр белән сәүдә итеп, акча эшләү минем кәсеп түгел.

— Ниндирәк егет иде соң?

— Нинди дип, егет шикелле егет инде. Карарак кына, уртача гәүдәле таза егет. Милициядә шундыйлар эшли бит...

— Документларын карамадыңмы?

— Ниндидер кызыл тышлы катыргысын күрсәтте. Минем сукыр-бакыр

күзләр белән анда ни язылганын аерып буламыни?! Төпченеп тормадым. Милициядән тек милициядән...

Вася Кулагин булуы ихтимал, дип уйлады Гомәр күнеленнән генә...

Чыннан да, мәетнең корсак өлешендә һәм күкрәгендә нindидер сыдырылганга охшаш яралар бар. Гомәр, әйләндергәләп карый торгач, сыртында да шундый ук ярага тап булды. Әйтерсең лә махсус ясалган. Әгәр үзе асылынмыйча, кем дә булса «ярдәм итеп», тәнендәге үзенчәлекле тамгаларын яшерергә маташса?.. Әйтик, нинди дә булса җөй, миң яисә татуировка булырга мөмкин. Алай дисәң, ни өчен ул аны монда — тиз генә табып алырлык җирдә калдырган? Югыйсә башын, йөзен танымаслык итеп, еragrак яшерергә дә була бит. Җинаятьчеләр эз яшерү өчен күп очракта шулай эшлиләр дә. Ә монда?.. Бәлки Марат үзе?.. Башын элмәккә тыгар алдыннан, үзен танытырдай билгеләрне юкка чыгарырга теләп... Тик болай эшләү ни өчен кирәк булыр икән? Юк, монысы нигәдер ягылмый. Тагын болай да булырга мөмкин, әйтик, үзенә охшаган кешене үтергән дә... Саттаров әлеге уйларыннан елмаеп куйды. Монысы бигрәк фантастикага якын шул. Андый нәрсә әкиятләрдә булган очракта да, тормышта була алмас кебек. Шулай да, тикшереп карарга кирәк...

Маратны җирләп, өч-дүрт көн узгач, вакыт табып, ул аның әнисе яши торган өйгә китте. Шундый кайгылы вакытта борчып йөрисе килмәсә дә барырга булды. Әле яңарак кына улын җирләгән ана кара кайгыда иде, билгеле. Өстәвенә, соңгы вакытларда милициядән килеп сораштыручылар күбәйгән. Гомәр ананың кайгысын уртаклашты. Кайчандыр Марат белән Чечняда бергә хезмәт итүләрен, батыр йөрәкле егет булуын әйтергә дә онытмады. Зәйтүнә, боларын ишеткәч, чишелеп китте, елый-сыктый күнелендәгесен сөйләргә тотынды. Кайгысын уртаклашырдай кеше булгач, күнеле йомшаган ананың моң-зарларын Гомәр бүлдермичә тынлады. Бераз әнә шулай хәл-әхвәлләр белешеп утыргач, мөмкин булганча авырткан урынына кагылмаска тырышып, үзен кызыксындырган сорауларны бирде.

— Зәйтүнә апа, сезгә бер кечкенә генә соравым бар. Улыгызның тәнендә нинди дә булса үзенчәлекле тамгаларын хәтерләмисезме? — дип башлады ул.

Ана берара Гомәргә сынаулы карап торды.

— Нинди билгеләр соң алар?..

— Миң, ярадан калган җөй, татуировка яки башка шундыйрак?..

Ана кабат уйга калды.

— Алай күзгә ташланырдай миңнәре юк иде кебек. Корсагында җөе бар иде. Чечняда хезмәт иткәндә алган ярасыннан калган җөй. Армиядән кайткач, күрсәткән иде. Шундый җәлләгән идем шул чакта. Ә татуировка дигәне нәрсә соң?

— Бетми торган итеп тәнгә ясалган рәсем...

— Күкрәгендә нindидер рәсеме бар иде кебек. Кайчан ясаткан булгандыр, белмим...

— Кайчан ясаткан булуы әһәмиятле түгел... Бар идеме генә дип сорыйм?

— Бар иде, бар...

Зәйтүнә апа Маратның соңгы елда үзеннән аерым бер хатын белән яшәвен әйтте. Гомәр аның белән дә сөйләшеп карарга булды. Ни әйтсәң дә, хатын-кыз иренең тәнен яхшырак белә. Адресын алып, Любаның өенә китте. Тик соңгы көннәрдә Любаны сораулар белән бик нык тинтерәтеп бетергәннәр иде булса кирәк. Ул җавап бирүдән баш тартты.

— Туйдырдыгыз! Нәрсә барыгыз да миңа бәйләнәсез? Әллә мин үтердемме

аны? Әйе, без аның белән бер еллап яшәдек. Ә калганын мин белмим дә, белергә дә теләмим, — дип, үксеп елый ук башлады.

Мондый хәлдә ярсыган хатыннан берни дә ала алмасын аңлаган Гомәргә чыгып китәргә генә калды. Тик шулай да Зәйтүнәдән ишетелгән фикердә мәгълүмат шикләнерлек нигез бирә иде...

* * *

Васяның: «Үзен дә юеш җирдә утырасың...» дип, аяк терәп сөйләшүеннән нәрсәгә ишарә ясавын Наил Хәкимович бик яхшы аңлый. Ачыктан-ачык шантаж булып әйтелгән әлеге сүзләр аны уйланырга мәҗбүр итә. Җиде ел элек трест начальнигы Нур Гаяновичның урынын дәгъвалагандагы хәлләрне күздә тотып әйтүе аның. Ул чакта, комарланып власть өчен көрәшкәндә, бу «шантрапа» малайга кирәгеннән артык чишелеп китте шул. Кызу канлы Вася да артыгын бөгеп ташлады...

Наил Хәкимович уйлары белән үткәннәргә кайтты. Ул вакытта трестагы кыңгыр эшләрне үз күзләре белән күреп, кирәк чакта саллы дәлил булыр дип, кайбер документларның күчермәләрен җыя барган иде. Җитешсезлекләрне теркәп бару өчен «кара блокнот» та башлады хәтта. Вакыты җиткәч, аларның трест начальнигын стенага терәргә менә дигән дәлил булачагына Наил шикләнми. Ул, закон кысаларына сыймый торган эшләр турында, ачыктан-ачык булмаса да Нур Гаяновичка әйткәли торды. Тик тегесе тиз генә бирергә теләмәде.

— Ә син шушындый кризис шартларында, зур бер трестны бернинди хаталарсыз гына җитәкли алыр идеңме? — дип акланды Нур Гаянович. — Ай-һай! Хәзер, әнә, ил җитәкчеләре дә кайсы юл дөрес, ә кайсысы ялгыш икәнлеген чамалый алмый. Бер яктан икенче якка ташланалар. Мондый хаос шартларында башлары бөтенләй әйләнеп беткән. Ә без, күреп торасың, тырышып-тырмашып булса да әлегә яшәргә омтылабыз. Баштан бәяләр бәйдән ычкынды. Аннан җәмгыять үзе дә түбән тәгәрәде. Документлар, имеш. Ә менә син, алай бик акыллы баш булгач, дөрес юлны әйт. Әйдә, закон кысаларында гына эшләп, трестны күтәрик... Үз кул астымда шушылай эшемнән кер эзләүче табылыр дип уйлап та карамаган идем. Беләсеңме син кем? Предатель син! Мондый ук әшәке булырсың дип кем уйлаган?! Синең бу аргументларыңа утырып та тычмыйм, — дип тәмамлады ул сүзен.

Наил Хәкимовичка, өстәл өстенә җәелгән кәгазьләрен җыйнап, җитәкче кабинетыннан чыгып китәргә генә калды.

Дөрес, мондый кискен сөйләшүләр Нур Гаяновичның күңелендә эзсез генә үтмәгәндер. Әкренләп ул Наил Хәкимович белән бөтенләй аралашмас булды. Элек трест эшенә кагылышлы мөһим мәсьәләләрне урынбасары белән киңәшләшеп хәл итәргә яраткан начальник, хәзер инде турыдан-туры Наил Хәкимович вазифаларына кагылган сорауларга да аннан башка гына җавап табарга күнекте. Һәм Наил моны турыдан-туры үзен читкә этәрү дип кабул итте. Соңгы вакытта Нур Гаянович Наил өчен тагын бер яктан ачылды: эшкә салгалап килә башлады. Күз төбендәге «капчыклар»ы кабарды. Контора хезмәткәрләре аны күкрәгенең сул ягын тоткан килеш тә күргәләгәннәр.

Җитәкчесе белән исәпләшмәгәннәрне кем яратсын соң?! Мондый мөнәсәбәтләр кайчак Наил Хәкимовичны чыгырыннан чыгара иде.

Җанын кая куярга белми йөргән көннәрнең берсендә ул Вася Кулагин белән очрашты. Сүз уңаеннан гына дигәндәй, ана үз «кайгысын» җиткерде. Әле ул вакытта һәрдаим эшендә ярдәм итәргә әзер торган Вася, үзе әйтмешли, «босс»ын ярты сүздән аңлады.

— Өркетергәме, куркытыргамы, әллә бөтенләй сөйләшми торган итәргәме? — диде ул.

— Булдыра алсагыз, өркетеп карагыз. Юкса, андый кеше белән янәшә эшләү тәмуг газабына әйләнде.

Аннан соң, Васяның дуамал холкын искә төшереп:

— Артыгын бөгеп ташламагыз тагын, — дип тә өстәде.

— Ноу проблем, Наил Хәкимович. Барысы да о кей булыр. Ул баш бирмәс начальнигыңны тиз сындырырбыз, — диде.

Шул сөйләшүдән соң ике атна үтте микән, Нур Гаянович эшкә килмәде. Иртән, сәгать тугызлар булгандыр, Наил Хәкимовичның эш кабинетында телефон шылтырады.

— Алле, тыңлыйм...

— Исәнмесез?!

Наил Хәкимович шылтыратучыны тавышыннан таныды. Бу — Нур Гаяновичның хатыны Җәмилә иде.

— Исәнмесез, Җәмилә ханым?

— Мин исән. Тик Нур Гаянович кына...

Хатынның тавышы калтыранып куйды, ул сулкылдап елый башлады.

— Нәрсә, авырып киттеме әллә?..

— Китте... Бөтенләй китте Нур Гаянович...

Трубкада өзек-өзек гудок тавышы ишетелде.

Наил Хәкимович, тиз генә җыенды да машинасына утырып Нур Гаянович өенә китте.

Ул Җәмилә ханымның сөйләвеннән шуны аңлады. Нур Гаянович соңгы атналарда үзен бик авыр хис иткән. Җәмгате белән дә аз сөйләшкән. Берәр кайгың бармы әллә? — дигәч, эштә киеренке, дип кенә җавап биргән. Еш кына эштән кызмача кайткалаган. Тора-бара бу көнсаенга күчкән. Бераз разгрузка да кирәк бит, шуның өчен эчәм дип акланган.

Эштән кайтканда, янәшә кварталда машинасыннан төшеп калып, «Бокал счастья» кафе-барында, йөз-йөз илле грамм эчеп чыгу гадәткә әверелгән. Соңгы көнендә дә аны ике егет шуннан култыклап кайтарып куйганнар. Бик нык исергән, урамда калдыра алмадык дигәннәр. Ә Нур Гаянович үзе тел әйләндереп сүз әйтерлек хәлдә булмаган...

Ул төнлә үлгән. Врачлар, суррогат аракы эчеп агуланган, дип нәтиҗә чыгарганнар. Ул елларда урам чатларында итәк астыннан сатып алган аракы эчеп, шактый ирләр якты дөнья белән бәхилләште. Кем белә, соңгы вакытларда алкогольгә тартылган Нур Гаянович та аракыны шулардан алып эчкәндер, бәлки. Әнә шуңа да үлеменә карата җинаять эше кузгатып тормадылар. Барысы да тыныч кына хәл ителде...

Нур Гаяновичны җирләгәннән соң озак та үтмәде, Наил Хәкимовичны аның урынына начальник итеп билгеләделәр. Моны бөтенесе шулай тиеш дип кабул итте. Чөнки ул урынга лаек кандидатура бүтән юк иде.

Бу хәлләрдән соң атна-ун көн үткәч, «яңа» начальник кабинетына Вася Кулагин килеп керде. Ул шунда Нур Гаянович белән булган хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Алар, Наил Хәкимович белән сөйләшүдән соң, Нур Гаяновичның эштән кайтканын сагалап торганнар. Башта планнары да икенчерәк булган. Ә күзәткәли торгач, көн саен эштән кайтышлый «Бокал счастья» кафесына туктаганын белгәннәр. Берара шуның янәшәсенә кереп, сыра эчкән булып күзәтеп йөргәч карарлары үзгәргән. Көннәрдән бер көнне егетләр, барга кереп, аның янына килеп утырганнар. Нур Гаянович каршы килмәгән. Бер кайгысыз, ачык күңелле егетләр күңеленә ошап киткән

күрәсең, үзенең гадәттәге йөз граммын эчеп бетергәч егетләр янында теле ачылган. Өстәлдәшләре юмарт кыланып, бокалына тагын өстәгәннәр. Сүз артыннан сүз ияреп стаканнарын бушата торгач, шактый гына йомшаган Нур Гаяновичка техник спирт кушып җибәргәннәр. Һәм калганы, нәкъ алар планлаштырганча килеп чыккан...

Васяны тыңлап бетергәч, Наил Хәкимович, бик мәгънәле итеп:

— М-да—а, таякны артык бөгеп ташлагансың. Мин монысын ук көтмәгән идем,— дип сузды.

Вася, артык исе китмәгән кыяфәттә:

— Җайлап-майлап, иркәләп-назлап маташырга балалар бакчасы түгел лә! Сезнең белән уртак эш өчен без барысын да эшләргә әзер, — диде.

Наил Хәкимович аның мондый хәтәр эшләргә сәләтле икәнен күптән сизенә иде. Каршында утырган егеткә каш астыннан сөзеп карап: «Палач», — дип уйлап куйды ул. Аннан, кинәт кенә урыныннан торды да, сейфыннан бер төргәк акча алып өстәлгә шудырды.

— Ал, — диде ул, — кирәге чыгар.

«Рәхмәт»тән башкага өметләнмәгән Вася эшләгән гамәлләрен акчалата хуплауны сөенеп кабул итте. Бераз икеләнеп торган булды да тизрәк төргәкне куенына яшерде.

— О—о, Наил Хәкимович, сез бик юмарт. Мондый «бабка»лар килеп торса, без көн саен...

— Шикләнмим, — дип, аның сүзен бүлде Наил Хәкимович...

Васяга акча бирәсе калмаган да бит... Тик хәзер эш узган шул инде, терсәк якын булса да, тешләп булмый.

Менә Вася хәзер шуны «козырь» итеп тота да инде. Имеш, Нур Гаяновичны аның хәер-фатихасы белән йомдырган.

Ярар, чебен дулап тәрәзә ватканы юк. Әллә нәрсә эшли алмас. Наил Хәкимович заказчы икән, Вася үзе киллер була түгелме? Хокук саклау органнарына барып сөйләсә, аның үзен үк «каталашка»га тыгачаклар. Бу сөйләшүләрдән соң Наил Хәкимович үзен әнә шулай тынычландырды.

* * *

Чолан ишеген кемдер сак кына өзлексез шакылдата. Марат уянып кинәт сикереп торды да тәрәзәгә ташланды. Ләкин, әлегә йокыдан айнып җитмәгән акылы белән дә, кискен адымнар ясарга ярамавын төшенеп алды егет. Ул стенага сыенып, пәрдә урынына эленгән чүпрәкнең читен генә күтәреп тышка карады. Тик аннан ишек ягы күренми иде. Марат ерак та түгел бакчачылык ширкәтенең ике урамы тоташкан урындагы мәйданчыкка күз салды. Соңгы ике-өч атнада шушы тирәлеккә күзе ияләшкән егет бүген анда нинди дә артык әйбер барлыгын шундук шәйләп алды. Мәйданчыкта яшькелт «Ока» машинасы тора иде. Әле сызылып кына килгән таң яктысында да аның төсе аермачык күренә. Мондый машина танышларыннан Артемда гына бар. Чегән кушаматлы бу кара егет кыйммәтле машиналарда йөрергә яратмый. Күзгә артык ташланмасаң җаның тыныч ди ул. «Мент»лар андыйларга артык игътибар итми. Димәк, бүген Маратны эләктерү өчен Чегән машинасына төялеп килгәннәр.

Эзгә төшкәннәр, дигән уй йөгереп узды аның башыннан. Тик ничек таба алганнардыр? Югыйсә, бик сак эш итте кебек. Любаның килеп йөргәнен сизгәннәрдер, күрәсең, артыннан күзәткәннәрдер, дип нәтиҗә ясады Марат. Тик озаклап анализлап торырга аның вакыты юк.

Люба, чолан ишеген тышкы яктан бикләү өчен «ялган йозак» элгән иде. Аны ачкычсыз да ачарга була. Ышанычлырак булсын өчен, Марат ишекне эчке яктан шудыргыч кełә белән бикләп куя. Ә кирәк чакта, үзе почмак

яктагы тәрәзәдән чыгып йөри иде. Димәк, тыштагы йозакны ачканнар да эчтән бикле булгач кеше барлыгын аңлаганнар. Хәзер шуңа шакылдатып маташкан булалар.

Марат ачылмалы тәрәзәдән җиңел генә чыгып та китәсе иде. Тик бу уеннан тиз кире кайтты. Тәрәзә тирәсендә засада булуы бар. Тегеләр дә җүләр түгел, Маратның кайдан чыгып качу мөмкинлеген инде күптән исәпкә алганнардыр. Ишекне дә хәйлә өчен генә тыкырдатып торуларыдыр. Хәзер монда бер генә юл — тыныч кына көтәргә кала. Әгәр ишекне ватып керергә маташсалар, күз күрер...

Марат мәче кебек сак кына атлап, чоланга чыга торган ишеккә якынайды. Кулындагы пычак — аның бердәнбер коралы. Теге көнне урман полосасында, Женядан качып соңгы ядрәләрен атып бетергәч, пушкасын кайдадыр ташлап калдырган иде ул.

Марат чолан ишеген акрын гына этқән иде, ул тавышсыз-тынсыз ачылып китте. Гадәттә, мондый өйләрдә ишекләр чиелдап ачыла. Баштарак бу ишек тә шулай җанга тиеп, ямьсез шыгырдый торган иде. Маратның шуңа эче пошып йөрде дә, беркөнне ике кулга бер эш булыр ичмаса дип маргарин мае белән күгәннәрен яхшылап майлап куйды. Менә хәзер Марат тавыштын чыгармыйча чоланга үтә ала. Тик, гөнаһ шомлыгына каршы, бер адым атладымы икән, идән сайгагы яман шыгырдап куйды. Моны тышкы яктагы адәм дә бик яхшы ишетте. Шунда ук:

— Марка, ач әле, бу мин — Артем. Үзем генә, курыкма, ач! — дигән тавыш ишетелде.

Бу чыннан да Чегән тавышы иде. Юмалап алдырмакчы була. Үзем генә имеш. Ишекне ачып җибәрсәң, хәзер өстеңә ташланып, кулыңны боргычлап алырлар.

Марат сак кына басып ишек янына килде дә ике такта арасына үзе алдан ясап куйган ярыктан ишегалдын күзәтте. Кайчак, Люба ишекне ача башласа, ул икәнлегенә ышану өчен, әлеге ярыктан карый иде егет.

Ишек янында торучы чыннан да Чегән икән. Марат аның сулышын да тойды хәтта. Ярыктан күрә алырдай тирәлеккә дә күз салды егет. Тик башка беркемне дә күрмәде.

— Марат, синең анда икәнлегеңне беләм... Ач ишекне, курыкма... Сөйләшәсем бар...

Ха, курыкма, имеш. Синең ишеләрдән курка торган туннар инде күптән тузган. Маратның әллә нинди киеренке вакытларда да шыр җибәргәне булмады. Тик монда, нindидер бер чиругә үтертеп ташлату өчен, ишекне ачып, ахмаклык эшлисе килми. Ничек булса да бу хәлдән чыгу ягын карарга, бәлки качып котылып булыр. Ә инде үләргә туры килә икән, сугышып үләргә. Марат әнә шуларны уйлады. Тик инде эндәшмичә ятудан да мәгънә юк.

— Нәрсә, эземә төштегезме? Ничәү килдегез соң?.. Ә—ә, дүртәүдер, шулаймы?.. Анысын дурак та белә, синең «Ока»на дүрт кешедән артык сыймый ла...

Ишекнен теге ягында торучы «чертләтеп» җиргә төкерде.

— Марка, ач, юкка шикләнәсең, миннән башка беркем дә юк монда...

Марат хәйләгә керешергә булды. Ярыктан тагын бер мәртәбә тирә—якны яхшылап күзәтте ул. Янә шикләнерлек нәрсә күренмәде. Димәк, алгы якта беркем дә юк. Әгәр засада оештырганнар икән, ул йә өйнең почмагында, йә тагын да арырак, коймалар янындагы ботак-сатак, чүп-чар өеме артында. Әгәр Артемга ишекне ачса, засададагылар килеп җиткәнче, аның белән «алыш-биреш ясап» өлгерерме? Чегән белән беркайчан да көч сынашып караганы булмады Маратның. Өстәвенә, кухня пычагы гына дисәң дә

«салкын корал»ы бар. Артем да буш кул белән түгелдер анысы. Чегәннең «задание»ләргә пушкасыз йөрмәгәнен Марат бик яхшы белә. Сүз белән юмалап, уяулыгын киметергә дә ишекне ачарга, аны-моны уйлап өлгергәнче бөтереп алырга, һөҗүм итә калса, пычакны корсагына батырырга... Житез генә эш итә белгәндә, пычак пушкага караганда яхшырак та әле. Чегәнне тиз генә түндерә алса, гәүдәсен эчке якка аударып, засададагылар килеп житкәнче, ишекне эчке яктан кабат бикләп алырга өлгерер. Аннан, Артемның пушкасы белән коралланганч, калганнары белән алыш-биреш ясау озакка бармас.

— Йә, ярый, Артем, мин ишекне ачам. Тик шуны онытма, нинди дә булса кискен хәрәкәт ясыйсың икән, шунда ук атып егачакмын...

Монысын ул, әлбәттә, Артем аны буш кул белән түгел икән дип уйласын өчен әйтте.

Тик Марат үз көченә күбрәк ышанган булып чыкты. Ул селкенергә өлгергәнче, Чегән аның кулын каерып, бөтереп, идәнгә егып та салды. Егәрле икән, шайтан. Күрәсең, ул да Маратның хәйләле адым ясарга маташуын чамалап, әзерлектә торгандыр. Идәндә йөзтүбән яткан Марат авыртудан ыңгырашып куйды. Чегән аның кулын шулкадәр каерып тоткан иде ки, аз гына кымшанса да, түзеп булмаслык авырту тойды егет.

— А—а—а... Артем, каерма шулкадәр... Йә, йә, теләгегезгә ирештегез... Жиңелдем...

— Ахмак син, Марка. Монда миннән башка беркем дә юк дип әйтеп торам лабаса!

Чыннан да, засададан чыгып, Чегәнгә ярдәмгә ташланучылар күренмәде. Болай булгач, үзе генә инде...

— Йә, ышандыңмы?...

Марат, «әйе» дигәнне белдереп башын селкеде. Хәер, бүтән чарасы да юк иде...

Өйгә кереп, өстәл янына утырышкач, Чегән ана бәйнә-бәйнә тезде.

Маратның теге көнге «стрелка» вакытында башта Женяны атып яралавы, ә соныннан Косойны үтерүе тамерланлылар арасында да, Кулагин егетләрендә дә низаг китереп чыгарган. Тамерланлылар аны үзләренә теләктәшлек күрсәткән, шуңа күрә дусларына каршы корал күтәргән дип уйласалар, элекке дуслары Маратны «легавый»лар куйган кеше, дип фикер йөрткән. Засадада ятучы егетләр хакында да оперларга ул житкергәндер дигәннәр. Ул көннәрдә аны сатлыкжан дип уйлап Кулак тиресенә сыеша алмыйча бәргәләнеп йөргән. Кичекмәстән Маратны эзләп табарга кушкан. Ялантау янындагы урманда, мәми авызланып Маратны ычкындырганы өчен, Женяга да шактый «эләккән». Тегесе: «Жир йотты диярсең, әллә кая юкка чыкты», — дип акланган, имеш. Билгеле, Вася үзе дә әллә ни майтара алмаган булыр иде. «Мин! Мин!» — дип шапырына гына. Әнә бит, атыш башланып, өсләренә «мент»лар ябырылгач, «Ауди»га утырып, Борзой белән качып котылды.

Шуннан соң Вася белән Женя арасында бик житди сөйләшү булып алган, имеш. Мина шул стукачны тере, йә үле килеш табып китермәсәң, игелек көтмә, дигән Кулак. Адәм актыгын үз кулларым белән буып үтерәсем килә дип тә ычкындырган.

Женя шул ук көнне Маратның әнине яши торган йортка күзәтү куйган. Ә Любаның квартирын күзәтергә Артемны билгеләгән. Анысы Маратның Люба белән ирле-хатынлы булып яшәп ятуын белмәгән әлбәттә. Женя аны шул квартирда яшәүче шлюха янына барып кунгалап йөри, дип кенә уйлаган. Һәрхәлдә, Артемның сөйләгәннәреннән Марат шулай аңлады.

— Күзәткән беренче көннәрдә шикләнерлек нәрсә тоймадым. Люба,

гадәттәгечә, эшкә китә, эштән кайта. Өенә кергән-чыккан кешеләр күренми, — дип дәвам итте сүзен Чегән. — Тик, берәр атна узгач, хатын үзен сәер тота башлады: артыннан күзәтмиләр микән, дигәндәй, кирәксә дә-кирәкмәсә дә сискәнеп, як-ягына карана. Шуннан соң, хатын эшкә киткәч, фатир ишегенә ачкыч яратып кердем, сине шунда качып ятадыр дип уйлаган идем, юк. Ә беркөнне артыннан ияреп бакчаңа барып чыктым. Ул чакта янымда коралым юк иде. Керергә шикләндем. Шул кичне Любаның якасыннан алдым да: сөйлә минәйтәм. Марат кайда, дим. Яшерә сука. Командировкага китте, дигән була. Тәнен бирсә — бирә, сүзен бирми, диләр андыйлар турында. Тәки серне ачмады. Ләкин куенына кертте. Елан. Шәп нәмәстә икән...

Марат калтыранып куйды. Артемның шулай сөйләшүенә җен ачуы чыкты аның. Чегән алдашып кына маташадыр, дип тынычландырырга тырышты үзен. Ул хатын-кыз ягыннан арттырырга ярата. Люба кочагын ачмагандыр. Алай дисәң, хатынның читләргә күз-каш сикертә торган гадәте бар, Юха елан белән бер. Ә шәп нәрсә булуын Артемнан сорап торасы түгел. Ирләргә яраттыра белә ул. Шулай ук Артем белән ятты микәнни?

Шунда Марат хатынының чит ир белән назлануын, аның ымсындыргыч шәрә тәненең калтыранып куюларына кадәр күз алдына китерде. Колагына Любаның ләззәтләнүдән ыңгырашуы да ишетелгәндәй булды хәтта. Шушы минутта егетне Чегәннән көнләшү хисе биләп алды. Юк, көнләшүдән бигрәк ачу иде бу. Бүтән вакыт булса, өзгәләп ташлар иде дә... Тик хәзер ярамый... юк, хәзергә ярамый.

— Менә шулай итеп эзеңә төштем мин синең, — дип тәмамлады сүзен Артем.

Өй эчендә авыр тынлык урнашты. Әлеге «тарих»ны тыңлап бетергәч тә Марат һаман башын иеп утыра бирде. Ә Чегән сынаулы карашын аңа төбәп тора. Ләкин әйтәсе сүзләре бетмәгән икән.

— Марка, сер булмаса әйт әле, стрелка вакытында нишләп үзебезнекеләргә корал күтәрдең, ник Косойны атып ектың, ә?

Марат, башын күтәреп, Артемга текәлде. Аның ирен читләреннән мыскыллы елмаю чагылып үткәндәй булды. Ха, менә нәрсәне беләсе килгән икән, дип уйлады ул. Акылын котмы?.. Милиция капитаны Саттаров Гомәрне үлемнән коткардым, шулай итеп, аңа булган бурычымны түләдем, дип әйтеп утырмас бит инде бу хөрәсәнгә. Гомумән, ни өчен соң әле ул отчет биреп торырга тиеш?! Милиция бүлекчәсендә допрос алучы түгел лә. Бөтен отделениеләре белән өстендә торсалар да, Марат аларга да берни дә әйтмәс иде. Тотсыннар учлап!.. Шуңа ул Артемның соравын җавапсыз калдырды да үзе сорау бирде:

— Минем кайда качып ятканымны белгәч, нишләп Женяга әйтмәдең соң? — дип сорап куйды. — Женяга да, Васяга да җиткерергә иде. «Задание»не яхшы үтәгән өчен буш калдырмаслар иде әле үзеңне...

— Дөресен генә әйткәндә, туйдым мин алардан, — диде Артем. Аның ашыкмыйча, озаклап сөйләргә җыенганы сизелеп тора. — Кулак та, аның һәр сүзенә биергә әзер торган Женя да туйдырдылар. Без алар өчен беркем дә түгел. Вася соңгы вакытта бөтенләй борзит итә башлады. Кеше кулы белән ут тотарга ярата. Егетләрне иткә симертүче сарыклар урынына да күрми. Кирәксә дә, кирәкмәсә дә төркемнәр арасындагы «разборка»ларга, бәрелешләргә иң беренче безне җибәрә. Төлке шикелле хәйләкәр ул, каян сизенә диген, үзе беркайчан да ядрә астына башын тыкмас. Янәшәсендә «айт» дигәнгә «тайт» дип торучылар булганда, нишләп тормышын куркыныч астына куйсын?! Шуның аркасында дөнья бәясе егетләр башларын сала. Тамерланлылар белән «стрелка»га баргач та сөйләшергә үзе чыкмаган бит,

әнә. Мин — әфганчы, дип күкрәк сугарга ярата да... Ә монда шүрләгән. Югыйсә, беренче ул чыгарга тиеш иде. Шуның аркасында, Косой күкрәгенә ядрә алган. Ә ул, егетләрен язмыш кочагында калдырып, машинасына утырып табан ялтыраткан... Элегрәк, төрле «разборка»ларда үлгән Фиргәвен, Морза, Клоун, Серыйның гомерләре дә аның намусында... Әлегә, исән чакта, бу бүреләр арасыннан китәргә кирәк, брат... Качарга кирәк...

Чегән сигарет алып кабызды да бер-ике мәртәбә тирән итеп суырды. Маратның да тартырына беткән иде. Аның, тамак төерләрен уйнатып, үзенә карап торганын күргәч, сигаретны ана сузды. Марат, авыз-борыныннан төтен алкалары өреп:

— Ә нишләп китмисең соң? Кем тота?.. — дип сорап куйды.

— Барысыннан да качып, ераккарак берәр җиргә олагасы килгән чаклар күп инде анысы. Тик, арт ягың пычрак булгач, тиз генә китеп булмый шул. Барыбер эзенә төшәчәкләр... Кирәк булса, җәһәннәмнән эзләп табарлар... Араларында таянырдай бер рәтле бәндә юк...

Артем туктап тамагын кыргалады. Бу юлы Марат ана инде янып бетә язган сигаретын сузды. Чегән аны бер-ике мәртәбә суырды да, бармагы пешә башлагач, өстәлдәге тәмәке төпчекләре тутырылган консерв калаена ташлады.

— Димәк, син миннән теләктәш эзлисең инде? — диде Марат, «допрос»ын дәвам итеп.

— Әлбәттә! Хәзер үзебезнең братва сине дошман күрә. Син бүтән алар арасына сыймаячаксың... Дөресен генә әйткәндә, сине аларга сатудан миңа бернинди файда да юк. Шуларны уйладым да, сиңа ярдәм итәргә булдым. Дөрес, теләктәшлек күрсәтүче дә кирәк, анысы...

Аңлашылды. Димәк, Чегән үзенә корефей әзерләмәкче була. Киләчәктә бер таянычым булыр, дип өметләнә, күрәсең. Тик бу «төссез» адәм белән Маратның бик якынаясы килми. Бергәләшеп Порхны сагалап ятканда да алар бер-берсенә йогышып китә алмаганнар иде. Ә монда, үзе ярдәм итәргә килгән икән, нишләп файдаланмаска? Сукыр тычкан шикелле гел посып кына ятмассың бит. Хәрәкәттә — бәрәкәт дигәндәй, урын алмаштырырга да туры килер. Ә Артемның нәкъ шул чакта файдасы тиюе бар. Дөрес, соңгы вакытта сирәкләсә дә, азык-төлек белән Люба ярдәм итә... Люба дигәннән... Ә менә Люба өчен Чегәнне беркайчан да гафу итмәячәк ул... Шәп нәрсә, имеш... Марат ачуыннан шартларлык булды. Авызыннан «шлюха» дигән сүз сытылып чыкты... Тик үз уйларына бирелгән Артем аны ишетмәде дә булса кирәк. Хәер, ишетсә дә аңламагандыр.

* * *

Алга таба нәрсә эшләргә кирәклеген Марат әлегә үзе дә тәгаен генә белми. Планнар корып торырга мөмкинлек юк. Язмыш әнә ничек бөтереп алды. Маратның тормышы бер селтәнүдә йөз сиксән градуска борылыр дип кем уйлаган?! Тик, ничек кенә булмасын, бу авыр хәлдән чыгу җаен эзләргә кирәк иде. Һәм моны озакка сузарга да ярамый. Беренчедән, «легавый»лар кайчан да булса барыбер аның эзенә төшәчәк һәм аңа кылган гөнаһлары өчен закон каршында каты җавап тотарга туры киләчәк. Срокны җәлләп бирмәсләр. Кеше үтергән өчен баштан сыйпамыйлар. Инде үзенең «братан»нары ягына да юл ябык. Теге көнне Саттаров белән күзгә-күз очрашкач, пушкасын үзләре ягына борган өчен беркайчан да гафу итмәячәк алар. Ашыктырырдай тагын бер сәбәп бар, озакламый салкын кышлар житәчәк. Җәй өчен генә салынган мондый дача өйләрендә кыш чыгу мөмкин түгел. Миче юк, электр линиясен кышка өзәләр. Гомумән, ашау-эчү өчен генә булса да шәһәр

белән элемтәдә торырга туры киләчәк. Кемдер сина ризыклар ташырга тиештер бит. Ә кышын монда эзләрне яшереп калдыру һич мөмкин түгел. Инде шәһәргә кайтсаң да барыбер эзгә төшәчәкләр. Рәсемнәрен бөтен подъездларга таратып чыкканнардыр. Газеталарга да бастырырга өлгергәннәр бит әнә. Артем шулай диде.

Бүгенге көндә анын монда яшеренеп ятуын бары тик ике генә кеше — Люба һәм Чегән генә белә. Хәер, анысы бер караганда яхшы да әле. Никадәр азрак белсәләр — шулкадәр ышанычлырак.

Алга таба кая барып яшәргә, кем канаты астына сыеныргa икәнен Марат белми әле. Бәлки бөтенләй читкә — ераккарак китеп, берәр яна шәһәргә урнашып, эзне югалтыргадыр? Тик моның өчен икенче кеше исеменә язылган документлар кирәк. Хокук сакчылары ялгыш кына тикшерә башласалар, барыбыр очына чыкмыйча калмаслар. Беренче чиратта яна документ кирәк, документ...

Марат бу хакта Артемга да әйтте. Тизрәк бу яклардан табан ялтыратырга кирәклеген ул да белә. Тик менә ялган документлар табу авыргарак туры киләчәк диде.

— Минем бер канал бар-барын... Заманында, югары даирәләрдә шактый гына билгеле бер дама белән мәхәббәт маҗарабыз булып алган иде. Аның ире кайсы ягыннан тотып селкесәң дә акчасы коелырга торган бай кеше. Тик бер житешсез ягы бар — карт инде. Комы коелган. Әй, картлык кемгә шатлык булсын соң. Ә хатыны яшьрәкләр белән кети-мети уйнап алырга һич каршы түгел...

Чегән хатын-кыз ягына бик дәмә. Анысы Маратка инде әллә кайчан мәгълүм. Әллә нинди һавалы хатыннар йөрәгенә дә ачкыч таба ала торган егет ул. Берәр сихере бармы шунда...

— Ул тутырган тавыкның мамык-йоннарын шактый йолкыдым. Үзем тапкан мал түгел, иремнеке җәл түгел, дигәндәй, акчаны күңел ачуларга жәлләмичә чәчте бичә.

Шуның аркасында ярты ел Артем иркә-назда яшәгән, балда-майда йөзгән. Ашау-эчүе дә иң кыйммәт рестораннарда гына булган. Арка терәшеп ятудан узмаган иреннән соң, каны кайнап торган яшь егетнең кайнар гыйшкы бу даманы әнә шулай юмартландырган инде.

Соңгы вакытларда финанс ягыннан Артемның үз хәле дә әйбәт түгел икән. Запасы бар, ләкин документ ясатырга житмәячәк. Шулай да:

— Нәрсә дә булса уйлап табарбыз! — дип тынычландырды ул Маратны...

Шуннан соң атна-ун көн Артем күзгә-башка чалынмады. Люба гына бер-ике мәртәбә килеп китте. Марат бу урында кабат калырга курка да башлаган иде хәтта. Чегәннең теләктәшлек күрсәтеп йөрүе болай гына түгел микән, мәче-тычканлы уены гына булып, көннәрдән бер көнне килерләр дә Марат белән эшне бетерерләр кебек тоела башлады. Шуңа, көндез күзәткәләп, төннәрен тирә-якны тикшергәләп, хуҗалары килми торган икенче бакча йортын да караштыргалады ул.

Чынлап та көннәрдән бер көнне, дөресрәге, кич — караңгылык төшеп килгәндә, Артемның «Ока»сы тагын урам чатындагы мәйданчыкка килеп туктады. Кеше күзенә күренмәс өчен, моннан да кулайрак вакыт юк иде. Чегән машинасының багажнигыннан бер сумка алды да, як-ягына караштырып, беркем дә күренмәгәч Марат качып яши торган өйгә юнәлде...

Сумкасын идәнгә лапылдатып куйгач, ул өстәлгә сыра шешәләре тезә башлады. Марат шунда ук, капкачын өстәл читенә бәреп, бер шешәне ачты. Сусаган кеше кебек, «голт-голт» итеп, сыра эчә башлады. Артем, ул

арада, барсеткасында актарынды да аннан бер-ике документ алып өстәл өстенә ташлады.

— Мә, сиңа яңа документлар. Үзеннән Марат икәнлегеңне оныт. Хәзер син Гатин Альберт Робертович буласың. Паспортта күрсәтелергә тиешле мәгълүматлар барысы да чын, тәртиптә.

Марат, паспортны алып әйләндергәләп карады, битләрен актаргалады. Үзалдына: «Альберт... Альберт Гатин... әллә ничегрәк... сәер...», — дип сөйләнде.

— Сәер булса да моннан соң бу исемгә ияләнергә туры килер, братан, — диде Чегән, икенче бер сыра шешәсенең бөкесен ача-ача. Аннан соң Марат кулындагы шешәгә чәкештереп алды да:

— Әйдә соң, яңа туган кеше исәнлегенә берне күтәрик. Киләчәктә Альбертның бөтенесе дә яхшы булсын өчен. Вакытлыча гына килгән күңелсезлекләр артта калсын. Ә кем белә, бәлки сиңа калган гомереңне шушы исем астында кичерергә язгандыр...

Чегән тагын шешәдән сыра койды. Сумкасыннан тозлы балык, помидор, кыяр, бер-ике буханка кара ипи, сыр, колбаса кисәге, тагын нәрсәләрдер алып өстәлгә тезде. Марат шунда ук бер кызыл помидорның яртысын тешләде дә, авызын чәпелдәтеп чәйни башлады. Азык запасы бетеп, кичтән тамагы ачыккан иде шул. Ә Артем тозлы балыкны чистарта-чистарта сөйләнүен дәвам итте.

— Ә беләсеңме, бүген мин нинди кызык хәлгә тап булдым. Сиңа килү өчен менә шушы ашамлыкларны алырга дип юл уңаендагы кибеткә — автовокзал кырыендагы азык-төлек кибетенә кергән идем. Шунда чиратта торучылар арасында сине күреп шаккаттым.

Аның бу сүзләрен ишеткәч Маратның авызына капкан икмәге тамагына тыгыла язды. Ул, чәйнәүдән туктап, бермәл авызын ачкан килеш туктап калды. Бераз торгач кына, телен көчкә әйләндереп:

— Ми-и-ине?.. Ничек инде мине? — дип әйтә алды.

— Ха, менә шулай, сине инде, сине... Кибеткә килеп кердем. Бишалты кеше прилавка янынында чиратта тора. Мин дә артка барып бастым. Сатучы алда торган егеткә бер шешә кефир һәм батон сатты. Теге егет чыгарга борылган иде, яхшылап карасам, шаккаттым, бу — син. Ана: «Марка, нишләп йөрисең монда?» — дип кычкырган идем, борылып карады да, танымаганга салышып, чыгып китте. Мин артыннан чыктым да иңеннән эләктереп алдым, үземә таба борам, Марка дим, мин синең өчен ашамлыклар алып йөрим монда, ә син үзең килгәнсең...

Марат әлегә кадәр аны шаяра гына дип уйласа да, Чегәннең житди йөзен күргәч, игътибар белән тыңлый башлады.

— Йә, шуннан, шуннан, — диде ул, ашыктырып.

— Ә ул, гафу итегез, мин сезне белмим ди. Күзләремә текәлеп, чынлап әйтә менә. Яхшылабрак карагач кына бераз үзенчәлекләр күрдем. Яшьрәк кебек. Тавышы да, сөйләме дә икенче. Ә болай тач син инде менә... Гафу ит, минәйтәм, сиңа бик нык охшаган дустым бар, шул дип торам, дим...

— Шулай нык охшаганмыни?

— Әйтәм ич, суйган да каплаган — син! Ә чынлыкта бөтенләй икенче адәм булып чыкты. Исеме Таһир икән. Үзбәкстаннан, Татарстанда яшәүче туганнарыма кайтам, ди. Әти-әниләре үлгән, анда яшәр чамасы калмагач Татарстанга кайтырга уйлаган. Казанга кадәр самолетта очкан. Безнең район үзәгенә автобуста килгән. Хәзер моннан сиксән километрераклыктагы Күкташ авылына кайтырга кирәк икән. Соңгы рейска җибәрелергә тиешле

автобуслары ватылган да пассажирларны иртәнгә кадәр тоткарлаганнар. Бу шәһәрдә беркеме дә булмагач, Таһир автовокзалда гына кунып калган. Тамак ялгарга дип, кефир белән күмәч алырга керүе икән кибеткә. Мин әйтәм, автовокзалда кичен милиция рейд үткәрә, монда кунып-төнеп ятканнарны «мент»лар бик өнәп бетерми дим. Әгәр чыннан да тикшерә калсалар, сина охшаганлыктан, шунда ук отделениегә озатачакларын беләм бит. Бу турыда анын үзенә әйтмәдем әйтүен. Тикшерсәләр минем документларым тәртиптә дигән була. Минәйтәм, бер эләктергәч, синен кемлегенне сорап тормыйлар. Отделениедә төн кундыралар да документларынны иртән генә караячаклар. Ә ул вакытта инде автобусын да тү-тү, китеп барган була, дим. Ә нишләргә кинәш итәсез сон, ди бу. Просто, үзем дә аптырап калдым... Кунакханәгә баруда да файда юк. Кыяфәте сина охшагач анда теркәү узуга ук милициягә хәбәр итәчәкләр.

Маратны эшнен ахыры кызыксындыра иде булса кирәк.

— Шуннан, шуннан нишләттен сон? — дип ашыктырды ул Артемны.

— Кешене күрәләтә торып легавыйлар кулына тапшырмам бит?! Үземә дә алып кайта алмыйм. Минем өйгә күзәтү куйган булулары мөмкин. Сине качырып тота икән дип уйлаулары бар. Бер кичкә — кер мичкә, дигәндәй... Әйдә, минем белән, бер кичлек урын табармын, мин әйтәм, иртән автовокзалга үзем озатып куярмын дип машинама утыртып алып киттем...

Маратнын үз «игезәген» тизрәк күрәсе килә иде. Шуна күрә: «Ә хәзер кайда сон ул егет?» — дип сорады, түземсезләнеп.

— Минем машинада утыра, — дип җавап бирде Артем. — Сине әзерләмичә аны монда алып кереп тормадым инде. Әгәр күрергә телисен икән, хәзер чакырып кертәм.

— Үзенен «двойнигын» кемнен күрәсе килмәсен. Килә, билгеле!

Артем чыгып китте дә, жиде-сигез минут узды микән, ишектән Таһирны ияртеп керде. Егет чыннан да Маратка бик нык охшаган булып чыкты. Бераз яшьрәк кенә. Өй эченә кереп, каршысында басып торучы Маратны күргәч, Таһир, гаҗәпләнүдән, үзе дә берара сүзен әйтә алмады. Ә Марат, тел шартлатып:

— Карале, чыннан да бик нык охшаганбыз икән. Мин шулай уктыр димәгән идем...

Танышып, әлеге шаккатырлык вакыйга тәэсиреннән бераз айный төшкәч, өстәл артына утырыштылар. Марат белән Артем, хәл-әхвәл белешкән булып, вак-төяк дөнья яңалыклары турында сөйләшеп алдылар. Таһир артык чишелеп китмәде. Ул өй эчен күзәтте. «Игезәк сынары»нын җәһәннәм почмагында, шушындый фәкыйрь шартларда яшәп ятуы сагайткандыр әлбәттә. Шуна күрә булса кирәк:

— Сез нишләп монда яшисез сон? — дип сорамыйча булдыра алмады.

Кинәт бирелгән әлеге сораудан Марат та, Артем да каушап, бер-берсенә карашып куйдылар.

— Хәзер бит, брат, шәһәргә пропискага керүләр, ай-һай авыр! Ә дустым Марат читтән килгән кеше. Җайләрен минем дачада яши. Ә кышларын, тыгызрак булса да, шәһәрдәге квартирыма сыябыз, — дип тезде Артем, шулай тиз генә кыен хәлдән чыгу җаен тапканына үзе дә сөенеп.

Марат, колбаса телеме чәйнәгән булып, башын селкеп, анын сүзләрен хуплап утырды. Таһир өй эчен тагын бер кат күздән кичерде. Тик анын күнелендә барыбер шик калды булса кирәк. «Бигрәк шикчел адәм булды әле бу», — дигән уй йөгереп узды Маратнын башыннан. Югыйсә, бүген өй эчен бераз тәртипкә дә китергән иде бит.

Артем, киеренкелекне йомшартырга теләгәндәй:

— Әйдәгез, танышу хөрмәтенә, — диде. Аннан сон кинәт исенә төшкәндәй. — Ә нәрсә эчәбез сон, сырамы?..

— Юк, мин эчмим, — дип, Таһир ана каршы төште.

— Нәрсә, бөтенләйме? Бер дә эчкәнен юкмы әллә? — дип гаҗәпләнде Артем.

— Юк, эчмим. Сыраны бөтенләй эчмим. Минем үз гомеремдә бер тапкыр шәраб кенә эчкәнем бар, — дип сөйләнде кунак.

Ә Артемга шул гына кирәк тә инде:

— Аны башта ук шулай диләр. Шәраб тек — шәраб, — дип сөйләнә-сөйләнә, шешәне ачып, өстәлдәге пластик стаканнарга шәраб койды. Таһир янә:

— Юк, мин эчмим, — дип кабатлады.

— Ничек инде, әле шәраб кенә эчәм, дигән идең, инде эчмим, дисең. Ә мин монда синең үтенечең белән шешәне ачтым.

Үз гаебе белән шешә ачарга мәҗбүр иткәне өчен егет унайсызланды. Каршында торган стаканны кулына бер алды, бер куйды.

— Мин бит, үз гомеремдә бер генә мәртәбә, шәраб кенә эчкәнем бар, димәкче идем...

Аны уңайсыз хәлдән чыгарырга теләгәндәй Марат:

— Сон әйдә, дускай, бер-ике тамчы йотканнан гына әллә нәрсә булмас. Ерак юлдан кайтып аргансың. Өстәвенә, эчү өчен сәбәп тә бар, — дип башлаган иде, аны Артем бүлдерде:

— Егетләр, мәзәк искә төште, тыңлагыз мена. Бер сарык озак кына ашамый-эчми йөргәннән соң, тирән сулы елга ярына килеп чыга. Инде эчәргә дип суга үрелгәндә генә, ул күз чите белән якында ямь-яшел хәтфә үлән каплаган болынны күреп ала. Һәм нәрсә эшли, дисез?..

— Тамагын суда чылатып алгач печәнне ура башлыйдыр, — дип, Марат сүзгә катнашты.

— Ә, юк... Теге аңгыра сарыкның башына, башта эчәргәме, әллә ашаргамы, дигән уй төшә. Әнә шулай уйлый, уйлый, уйлый да, барыбер очына чыга алмыйча, тамагы кибегүдән һәм ачлыктан егылып үлә.

Бу мәзәктән өчесе дә шаркылдашып алды. Ә Артем:

— Егетләр, әйдәгез, сарыклар булмыйк сон, башта шушы шәрабне эчеп куйыйк, аннан сон капкалап алырбыз, — дип стакандагы эчемлекне авызына койды.

Тост барысына да ошады. Таһирның да сарык буласы килмәде, үзенә тигән өлешне эчеп җибәрде. Стаканын куйгач, йөзен яман чытып, авызын күлмәк җиңе белән каплап, закускага нәрсә кабарга белми торгач, Артем аңа помидор кисәге сузды.

Алга таба кысташып маташмадылар. Бераз сөйләшеп утыргач Марат стаканнарга кабат шәраб салып чыкты. Бусында Таһир да шома гына эчеп куйды. Помидорны да үз кулы белән алып капты.

Егетләрнең телләре бердән ачылып китте. Дөрес, Марат сөйләшмәде, күбрәк кунакларның сөйләгәннәрен тыңлап утырды. Кешеләр белән аз аралашкангамы, ул соңгы вакытта гомумән аз сүзле. Ә менә Таһирның, эчми эчкәнлектән булса кирәк, шәраб башына тиз китте. Ул Үзбәкстанда яшәүләре, тормышындагы кызыклы вакыйгалар турында сөйләргә тотынды. Артемның да теле телгә йокмый: булган хәлләрне дә, булмаганнарын да тезә дә тезә генә. Ә үзе әңгәмә арасында стаканнарга шәраб агызырга да өлгерә. Тиздән вино шешәләре бушап калды. Егет стаканнарга сыра койды да, аны аз-азлап йоткаларга тотынды. Инде шактый кызган Таһир да аңа кушылды...

Берәр сәгатьләп шулай утыргач, Марат тартып керергә исәпләп, сигаретын

барлый башлаган иде. «Тукта, мин дә чыгам», — дип, Артем аңа иярде. «Минем дә чаптырып керәсем бар», — дип, Таһир да урыныннан кузгалды...

Салкынча һава егетләрне куырып алды. Йомышын үтәгәч, Таһир, монда салкын дип кереп китте. Артем белән Марат тәмәке кабызып калдылар. Шунда, сигаретларын бер-ике мәртәбә суыргач, Артем сер итеп әйткәндәй:

— Нәрсә, Таһирның кыяфәте сиңа охшаганмы? — дип никтер кабат сорады.

— Бик нык! Әйтәм ич. Мин алай ук дип уйламаган идем дә.

— Менә, әйттем бит мин сиңа. Бу дөньяда һәркемнең бер генә булса да үзенә бик охшаган двойнигы була.

— Әйе, мондый фикернең минем дә кайчандыр колагыма кергәне бар...

— Кызык инде, шулай бит. Дөньяның кайсыдыр почмагында нәкъ миңа охшаган кеше йөри. Кызы—ы—ык.

Артем нәкъ балалар шикеллле «ы—гы—гы» дип, үзалдына көлеп куйды. Аннан соң, сүзен дәвам итте.

— Син монда кайгырасың. Кайчан килеп эләктереп алырлар икән, дип куркып яшисең. Ә янәшәңдә генә икенче берәү, кыяфәте белән сиңа ике су тамчысы кебек охшаса да, бернидән дә курыкмыйча рәхәтләнеп йөри бирә. Кызык бит, ә? Көнләшмәслекмени?..

— Аның арты коры, Артемка... Шуңа күңеле тыныч... Аның урынында булсам, мин дә...

Артем тәмәке төпчеген оста гына бакча ягына чиртеп җибәрде. Аннан соң шактый көттереп:

— Ә аның урынында булырга кем комачаулый соң сиңа?.. Бу хәчтрүшне йомдырырга да... Аннан юлыңны дәвам ит... Күкташкамы анда... Үзбәкстанга укмы...

Марат әңгәмәдәшенең тел төбен аңлап житкермәде. Тирән итеп тәмәкесен суырды. Тәмәке очында җемелдәгән ут яктысында берара Артемның хәйләкәр елмайган йөзе чагылып узды.

— Әйдә керик, юкса туңдыра башлады, — дип, сүзне икенчегә борды Чегән.

Марат, тәмәке төпчеген җиргә ташлап, аны аягы белән таптап изде. Ул бүген салган баштан гына шулай эшли. Аек чакта андый саксызлык күрсәтми, тәмәке төпчекләрен җыеп барып, җиргә күмә иде...

Өйгә кергәч Марат бүтән эчмәде. Ни өчендер эчкән кадәресе дә косасын китереп, кәефен җибәреп тора. Ә тегеләр, тагын берәр бокал сыра бушаттылар. Артем Таһирга сораулар биргәләде, тегесе сөйләде. Кайвакыт икәүләшеп шаркылдашып көлешеп тә алалар. Марат аларның әңгәмәсенә колак салып утырды...

Төн икенче яртысына авыша башлагач, яхшы ук кәефләнгән Артем шушында гына кунып калырга булды. Салган баштан «гаишник»лар кулына эләгеп, кирәкмәгән мәшәкатьләр аласы килмәде. Иртәгә иртәдән кузгалырбыз, диде ул Таһирга. Марат, егетләргә йокларга урын әзерләшкәч, биләмәләремне бер карап керим әле дип ишегалдына чыкты. Гомумән, кичен йоклар алдыннан тарта торган гадәте бар аның...

Төн салкынча. Күк йөзендә йолдызлар чекрәя. Суыта башлар мөгаен дип уйлады Марат. Анысына гаҗәпләнәсе түгел. Салкыннар башлангач, монда яшәп булмаячагын да аңлый ул. Шуңа күрә, башы ни уйларга белми иде әле.

Егет тәмәкесен озаклап тартты. Инде, тәненә салкын үтеп керә башлагач,

куртка якасын кулы белән йомарлап муенын каплаштыргалады. Тәмәке төпчеген Артем шикелле оста гына чиртеп җибәрмәкче иде, барып чыкмады. Төпчек, бармакларыннан ычкынып, аяк астына гына килеп төште. Марат, шуна да ачуы чыгып, зәһәр сүгенеп алды. «Черт»ләтеп җиргә төкерде дә төпчекне ботинка үкчәсе белән таптап сүндерде. Шуннан соң өйгә юнәлде. Ишекне сак кына ачып эчкә үтте... Үтте... Ә аннан соңгы хәлләр күз ачып йомганчы һәм ин кәттә детектив кинолардагыча булды. Егет әле моннан бер-ике минут элек кенә вакыйгалар шушындый борылыш алыр дип башына да китереп карамаган иде.

Ул кергәндә Артем агач караватта чалкан яткан Таһирның баш очына иелеп нидер эшли иде. Ә тегесе яман гына гырылдый. Марат бары тик береаздан гына Артемның бау белән Таһирны буып маташканлыгын аңлап алды. Исенә килеп, аңа ташланган арада, Таһирның чытырдатып бауга тотынган куллары бушап салынып төшкән иде инде. Марат ике атлап бер сикерде дә Артемны якасыннан йолкып җан фәрманга почмак якка селтәде. Артем баш чүмече белән шундагы комот почмагына килеп бәрелде һәм беразга гына хушын да җуйды булса кирәк. Гәүдәсе акрын гына шуып җиргә чүкте. Берничә секундтан ул күзләрен ачты. Нәфрәтләнеп Маратка карады.

— Син нәрсә?! Сука... Мин монда синең өчен... Ә син, гнида, миңа кул күтәрмәкче буласың?!. Мин сине бл...д...

Артем кинәт эчке күкрәк кесәсенә тыгылды. Аннан пистолет чыгарып, төбәп тә тормыйча, Марат ягына атып җибәрде. Ярый әле Марат читкә сикерергә өлгерде. Ядрә өстәл читендәге стаканда янып торган шәмнәрнең берсенә тиде. Тирә-якка парафин кисәкләре чәчелде. Шәмнәрнең икенчесе дә авышты, ләкин уты сүнмәде. Артемның кыяфәтенә караганда анда бернинди рәхим-шәфкать күренми иде. Ул икенче мәртәбә атарга җыенганда, Марат инде өстәлдәге ипи буханкасына кадалган пычакны алып Артем өстенә ыргылды. Пычакны сабына кадәр егетнең күкрәгенә батырды. Тагын бер мәртәбә ату тавышы яңгырады. Ләкин Маратка бернинди зыяны тимәде. Ул Артемның пистолетлы кулын каерып түшәмгә юнәлткән иде инде. Бусында ядрә түшәм такталары арасындагы ярыкка эләкте. Идәнгә шыбырдап балчык коелды. Артем бүтән «ык» та итмичә идәнгә ауды.

Кинәт кенә дөнья тынып калгандай булды. Мизгелләр эчендә булып алган әлеге хәлләрдән тәмам аңы томаланган Марат нишләргә белмичә бүлмә уртасында басып тора бирде. Аны кинәт кенә укшыта башлады. Ул авызын томалап ава-түнә ишегалдына йөгерде, шунда яңгыр суы җыяр өчен куелган кисмәккә башын тыкты. Муенына кадәр чатнама салкын суга кереп чумды. Су салкынлыгы сөякләренә кадәр үтеп, тундыра башлагач, пошкырап башын күтәрде. «Бр-р-р» дип башын селеккәләп алды. Әллә салкыннан, әллә яңа гына булып узган куркыныч хәлләрдән, ул тәмам айныган иде. Тик башы гына берни аңларлык хәлдә түгел.

Марат айкала-чайкала кабат өйгә керде. Анда ике мәет. Хәтта ышанасы да килми, моннан ярты сәгать элек шаркылдашып көлеп утырган егетләрнең җансыз гәүдәләре генә ауный.

Марат кинәт үз-үзен белештермичә идәндә яткан Артемга ташланды, аны якасыннан алып селкергә тотынды.

— Син, дурак, нәрсә эшләдең?.. Нәрсә, сыра белән вино катнашып, миенне сыегайттымы?.. Твою мать, нәрсә ясап ташладың син?.. Болай ук кирәк түгел иде... Ишетәсеңме?..

Марат Чечняда булган кеше. Аңа үлемне күп күрергә туры килде. Үзенә каршы корал күтәреп килүче дошманга атканда беркайчан да кулы

калтыраганы булмады. Ләкин тыныч тормышта, менә мондый мәгънәсез үлемгә ул каршы иде.

Егет өстәл артына килеп утырды, куллары белән башын тотты һәм кинәт ике йодрыклап өстәлгә китереп бәрде дә: «Юк, мин болай булуын теләмәгән идем», — дип, акырып ук җибәрде. Шәм утыртылган стакан өстәл читеннән идәнгә төшеп чәлпәрәмә килде. Ут сүнде. Дөнья сүнде... Марат, өстәлгә башын салып, тынып калды. Ул йоклый иде. Тик бу йокы булдымы, әллә баш миенең шундый нык ярсытуларга реакциясеме, ягъни хуш китүме. Билгесез ...

Марат таң сызыла башлаганда уянды... Ул чыннан да йоклаган иде булса кирәк. Чөнки уяныр алдыннан гына төш күрде. Ниндидер аллы-гөлле матур болында йөри имеш. Шулчак каршысына ак күлмәкле кыз йөгергәнен шәйләп алды. Нинди кыз? Кем ул? Марат аның йөзен аермачык күрмәде дә хәтта. Тик кыз йөгерә һәм аңа кулларын болгап кычкыра, нидер әйтергә тели иде сыман. Сәер төш... Маратның беркайчан да мондый төш күргәне юк иде ләбаса. Гомумән, аның төшенә беркайчан да кызлар кергәне булмады...

Уянуга, моннан тизрәк качарга кирәк, дигән уй башына килде. «Ышанмаслар. Беркем дә ышанмас...» дигән сүзләр миен телгәли иде аның. Инде бер кат пычранган кеше өчен монысы муеннан шакшыга кереп бату белән бер иде. Әле кайчан гына, Вася әмере белән Порхны манчыгач, кеше тормышына кул сузмаска дип бер мәртәбә тәүбә иткән иде югыйсә. Теге көнне Косойны атып егуы да язмышында кара тап булып калды. Кеше гомере шаяра торган нәрсә түгел шул. Хәтта барып чыккан җинаятьчеләр дә «мокруха»га барырга бик атлыгып тормый. Бер килсә килә бит... Ә монда тагын ике мәет ята. Ә бары тик аны гына гаепләячәкләр. Шаһитлар юк... Чын дөресенә беркем дә ышанмаячак. Марат, шуларны уйлап, моннан тизрәк качарга кирәк дигән нәтиҗә ясады. Эзне яшереп торудан мәгънә юк. Тегеләй дә, болай да барыбер аннан шикләнәчәкләр. Бар булган «шмотка»ларны җыеп, шунда ук чыгып сыпыртмакчы иде, тик туктап калды... Артемның тартырга чыккач әйткән сүзләре исенә төште. Таһир урынында булырга кем комачаулый соң сина дигән иде түгелме? Чыннан да кем комачаулый соң? Хәзер инде беркем дә комачауламый. Әйе, Артем аның өчен «тырышкан». Марат үзе моны теләмәсә дә... Әйе, Таһир белән алар бик охшашканнар. Бүген мәетләрне шушылай калдырып китсә, тапкан кешеләр һичшиксез аны ул дип уйлаячаклар. Маратка Таһир булып яшәү мөмкинлеге бар... Кеше үлеме аша үзеннең гомеренне озайту, бәлки, кешелеклелек ягыннан хуплауга лаек та түгелдер. Тик үз-үзеңне саклау инстинкты барысын да җиңде. Ул барсыннан да көчлерәк иде...

Ул Таһирның мәетенә үзенең киемнәрен кидерде дә, үзләренең бакча өйләрендәге чоланга илтеп, бау белән асып куйды. Моннан тизрәк табарлар. Дөрес, беренче булып әнисе күрәчәк. Марат аңа җиңел булмасын да төшенә. Ул исән калып та, монда ике мәет яткач әнисенә җиңел булмаячак. Тирә-ягындагылар барыбер улың үтерүче дип төртеп күрсәтәчәкләр. Ике кешене үтерү уен-муен эш түгел. Ә болай бер Артем гына кебек... Яшьләр арасында ни чыкмас?!..

Марат, икенче эш итеп, Артемның гәүдәсен урам чатына алып чыгып ташлады. Моннан тизрәк табып алырлар. Аның версиясе буенча, әлеге хәлне араларында низаг чыгып Марат башта Артемны чәнчеп үтергән дә, соңыннан намусына көч килеп, үзе башын элмәккә тыккан, дип аңлаталар. Теләсә кемнең башына иң әүвәл шундый уй киләчәк. Ә асылынган Таһирның Марат икәнлегенә шик булмаячак. Таһир аңа бик нык охшаган.

Тукта... Охшавын охшаган, ә аерым билгеләре... Шунда Марат үзенең корсагында ярадан калган җөе барлыгын исенә төшерде. Аны белүчеләр дә юк түгел бит. Ә күкрәгендәге «Орлы гнездятся на скале» дип язылган бөркет татуировкасы?.. Шунда ук беләчәкләр...

Марат кабат үзләренең бакча өйләренә ашыкты. Ул ишегалдыннан кытыршы койма тактасы табып, мәетнең татуировка һәм ярадан калган җөй урынын тиресе сыдырылганчы ышкыды. Әлеге бик шыксыз эштән соң Маратның тагын косасы килә башлады...

Марат Таһирның киемнәрен киеп чемоданын алды да юлга кузгалды. Башта ул шәһәргә кадәр Артемның «Ока»сында кайтырга исәпләгән иде. Ләкин кире уйлады. Соңыннан, машинаны шәһәр читеннән табып алсалар, монда өченче кеше дә булганына төшенәчәкләр. Җәяүләп кенә барса да, автобуска өлгерәчәк. Таһир астобусны иртәнге сәгать сигездә булачак дигән иде.

* * *

Марат автобуска кереп утырды да якасын күтәргәләп куйды. Шикләнеп каш астыннан гына тирә-якка күз салды. Автобуска алданрак кереп арткы урынгарак барып поссаң чит-ят күзләрдән аулаграк булырга тиеш. Җирле рейсларга билетлар сатканда, гадәттә, урыннарны күрсәтмиләр, кем беренче керсә — урын шуңа.

Урнашып, сумкаларын аяк астына җайлап куйдым дигәндә, янәшәсенә бер карт кереп утырды. Ул башта Маратны, таныш түгелме дигән кебек, баштанаяк күздән кичерде. Кулындагы таягына кушучлап тотынды. Кабат, арт санын күтәрә төшеп, як-якка этенгәләп, йомырка өстенә утырырга җыенган каз шикелле селкенгәләп алды. «Озакка урнашырга чамалый бу», — дип уйлады Марат. Карт ун-унбиш минутлап берни сөйләшмичә, алга карап барды. Хәер, Маратның да әңгәмә башларга бик теләге юк иде. Өстәвенә, кичәге вакыйгалардан соң никадәр аз сөйләшсәң, шулкадәр яхшы. Тик әлеге авыл карты эндәшмичә артык түзеп утыручылардан булмады. Бераздан, егетне янә баштанаяк карап чыкты да сүз катты:

— Син дә Күкташка кайтасынмы, әллә юл уңаендагы башка берәр авылгамы?

Марат үз уйларына бирелеп барган җирдән кинәт сискәнеп куйган кыяфәт алды.

— Син... Сез мина дәштегезме?..

Карт соравын кабатлады:

— Күкташка кайтасынмы, дим?

— Юк... Ә, әйе, шунда... Күкташка...

— Күзгә-башка күренгән кеше түгел, шуңа соравым. Хәзерге яшьләрне белеп тә бетермим анысы. Кай арада үсеп житәләр дә, кай арада кеше булалар... Кем малае буласын соң, наный?..

Маратның сөйләшергә бик теләге юк иде, сүзне кыска тотарга уйлады.

— Бабай, мин сезнең авылныкы түгел шул. Туганнарыма кайтып килешем. Үзбәкстаннан мин, — диде ул, бар белгән татарчасын эшкә җигеп. Аннан, йокысы килгән кеше кебек, авызын ачып иснәнгән булды. Комачаулама, йоклап алырга исәбем бар, янәсе.

Карт биш-ун минут дәшмичә барды да янә сүз катты:

— Үзбәкстанда җиләк-җимеш бик күптер инде? Анда алмалар-әфлисуннар бездәге бәрәңге кебек җирдә ауный ди.

Марат иренеп кенә күзләрен ачкандай итте:

— Әйе, җиләк-җимеш күп бездә, — диде дә, шуның белән сүзе беткәнлеген

белдереп, янә башын бер якка кыйшайтып «йокыга китте». Карт тагын бераз эндәшмичә барды. Аннан соң кинәт кенә:

— Алай да, кемнәргә кайтасың соң? — дип сорады.

Марат автобуста ук үзеннән мондый «допрос» алырлар дип көтмәгән иде. Аның бераз гына ачуы да килде хәтта. Тик, бар сабырлыгын җыеп, кичтән Таһир сөйләгәннәрне искә төшерде.

— Хафизларга кайтам, бабай. Хафиз абый белән Нурия апаларга! Шундый кешеләрне беләсенме? Минем әнинең туганнары алар...

Карт, нәрсәдер исенә төшерергә теләгәндәй, берара эндәшмичә утырды. Үзалдына: «Хафиз... Хафиз... Нурия», — дип кабатлады. Аннан соң, онытканын исенә төшергәндәй, «чәпелдәтеп» маңгаена сугып алды.

— Ә—ә, син түбәноч Хафизны әйтәсеңдер әле. Хафиз мулланы. Сәлмән Хафизы була инде. Апасы үзбәк якларында яши дип ишеткән идем шул...

Марат, авылга кайтып җитсәм ничек табармын дип кайгырган иде. Түбән очта икәнен әйтеп куйды менә. Юкса, авылга кергәч урамда очраган кешеләрдән сорашу яхшы түгел. Таһир җәйләрен авылга кайткалаганым бар, дип сөйләнгән иде бит. Авылга кайтып йөргән кеше, ничек туганнарының өе кайдалыгын белмәсен соң?!

Карт тагын беразга туктады. Унбиш минутлап узгач, машина асфальт юлдан борылып грунт юлга керде. Таһир, авылга кадәр бер сәгатьлек юл, яртысын кайткач грунт юл дигән иде. Димәк ярты юл узылган. Иске «ПАЗ» автобусы яман гына чайкала башлады. Әле бер якка, әле икенче якка авышкан саен, аның әллә кайсы төшләре чыкылдап ала, яман шыгырдый. Мондый тавышка йоклап булмый, әлбәттә. Йоклаганга салышып ятудан мәгънә юк. Марат, күзләрен ачып башын күтәрә төште, сәгатенә караган булды. Чыннан да, автовокзалдан кузгалганга нәкъ ярты сәгать узган. Димәк, тагын кайткан кадәр кайтасы бар дип уйлады егет. Аның «уянганын» күреп картның кабат теле чишелде.

— Ата-анаңнар исәннәрме соң, наный? — дип сорады ул.

— Юк, исән түгелләр. Үлделәр шул, — диде, Таһир роленә керә барган Марат.

Карт, Маратны җәлләгәндәй башын селкеп торды.

— Ай-яй, бик яшьли мәрхүм булганнар, бәгырькәйләр... Хәзер яшьли китәләр шул. Заманасы бик тынгысыз бит.

— Авырып түгел, фаҗигага очрап үлделәр алар, бабай.

— Шулайдыр, наный, шулайдыр... Андый хәлләрне дә ишеткәләп торабыз...

Карт авылга кайтып житкәнче башка сүз катмады. Әллә Маратны җәлләде, әллә башка сәбәп белән, таягына таянып, үз уйларына бирелеп утырды. Вакыт-вакыт нык кына тамагын кыргалап көрсенде...

Авыл башындагы шомартылмаган такталардан әмәлләп куелган тукталыш будкасы янәшәсенә килеп туктагач, автобус эчендә чын мәгънәсендә мәхшәр купты. Авыл хатыннары урыннарыннан торып сумкаларын, төенчекләрен барлый башладылар, Кемнендер пакеты авып алмалары коелган, кайсысыдыр юл өстендә ятучы әйберләр астыннан үзенең биштәрен эзли. Шунда кемдер, абайламыйча, каяндыр килеп кергән бер көчекнең аягына баскан булса кирәк, ул чиный башлады. Ә Марат янәшәсендә утырган карт автобуста еш йөри күрәсең — ул тирә-юньдәге мондый тамашага игътибар да итмәде, нәкъ килеп утыргандагыча, ашыкмый гына сумкасын күтәрде. Шулай ук кабаланмыйча гына, аның эчендәге әйберләрен бер кат тикшереп чыкты Кесәләрен капшап күзлеген алып киде. Тышкы кесәсеннән автобус билетын алып караштыра башлады. Нәрсә карагандыр, аңлашылмый.

Аннан соң ул аны ашыкмыйча гына түрдә дә түш кесәсенә куйды. Күзлеген кабат кесәсенә салды. Таягын сөрткәләгәндәй итте. Югыйсә, әле ана тузан куңырлык вакыт узмады да. Анын шулай озаклап маташуына Маратның ачуы да килде, хәтта. Тик, карт ишек ягына кузгалгач:

— Кая, бабай, сумканны күтәрешим. Авырдыр, — дигән булып, сумкасын алды.

— Ай рәхмәт, балакаем. Безнең кебек карт кешегә төенчек тә авыр, — дип, анысына сөенде тагын.

Авылга кереп бераз баргач, карт бер тыкрыкка борылды. Марат кая барасын үзе дә белми бит. Сорарга да унайсыз. Анын белән тыкрыкка борыла башлаган иде, карт сумка бавына үрелеп:

— Ярар, наный, монысы өчен дә рәхмәт. Син үз юлын белән бар. Моннан гына үзем дә кайтып житәм инде, — диде.

Марат та, аклангандай:

— Өенә кадәр озатып куясы идем, — дигән булды.

— Син Хафиз абыеннарга кайтып житкәнче, мин инде әллә кайчан табын артында чәйләп утырган булырмын. Кайтасы жирен ерак бит, авыл башында ук, ү-үнә теге шифер түбәле йорт, — дип, карт авылның түбән очында күренеп торучы бер йортка күрсәтте.

Шулай итеп, Марат кая кайтачагын анлаган иде инде. Хәзер ана елгага төшеп, шундагы күпер аша чыгасы икән әле. Аннан унга борылып, түбән оч башына кадәр төшә дә кырыйдагы сонгы йорт — Хафиз абыйныкы.

Күпер янындарак чишмә бар икән. Бер яшь хатынның су алып торганын күргәч Марат тамагы кипкәнен тойды. Кичтән күпләп эчкәч үзенекен итә. Иртән чәйләп тә алмады шул. Хәер, ана мөмкинлеге дә юк иде.

Егет, чишмә янына килеп, хатынга сүз кушты.

— Кая, апасы, су эчертеп жибәрмәссенме?

Эндәшкән тавышка хатын башын күтәрде. Кап-кара чәч, кыйгач каш... Авылда да шундый гүзәлләр булыр икән. Бераз гына Любага да охшаган.

— Нәрсә, егеткәй, жәй челләсендәге кебек сусадың? Кичтән күбрәк жибәргән иденме әллә? — дип чытлыкланды яшь бичә.

Кара син аны, кыек атып туры тидердеме, әллә чыннан да кыяфәтенә чыкканмы?

— Юк, эчмәдем. Ерактан кайтып килешем. Юлда бик йончыдым. Сезнең Татарстанда автобуслар бигрәк начар йөри икән. Юлларыгыз да мактанырлык түгел, — дип сөйләнде Марат, үзенең читтән кайтып килүен һәм бөтенләй Татарстаннан да түгеллегенә ишарәләп.

Хатын иелеп чиләгенә су агызды, аны чайкаштыргандай итте дә читкә түкте. Иелгәндә анын куртка түшеннән мул күкрәкләре күренде. Алар халат изүенә сыешмыйча тулып торалар иде. Хатын кинәт кенә башын күтәрде. Маратның ымсынып карап торганын күреп куртка якасын тарткалап рәтләштерде. Анын тарафына наян гына караш ташлап, кабат башын иде. Чиләгенә бераз су агызып, егеткә сузды.

— Кайсы яклардан кайтасың сон?

— Үзбәкстаннан, — аннары Марат теге карт әйткән сүзләрне исенә төшереп, — алмалы, әфлисунлы жирләрдән, — дип тә өстәде.

— Күргәнем дә бар шикелле. Кемнәргә кайтасың сон син?

— Түбәноч Хафиз абыйларга. Теге, мулла Хафиз... Сәлмән Хафизын беләсездер?.. — диде егет, карттан ишеткән «Сәлмән» сүзен катнаштырып.

— Нишләп белмәскә, бик яхшы беләм. Без бер урамныкылар. Алар теге баштарак кына яши. Мин сине дә беләм әле. Исемен ничек сон, онытгым.

– Мар... То есть, Таһир исемле мин...

Тьфу, шайтан! Таһир дигән исемгә берничек ияләнә алмый. Тагын Марат дип ычкындыра язды бит. Әйе, бу исемгә ияләнгәнче шактый вакыт кирәк булыр әле.

– Таһир, Таһир, Таһирҗан, – дип такмаклады тәти ханым. – Матур исем...

Үзенең ялгышына артык игътибар иттермәс өчен Марат:

– Әгәр сер булмаса, үзегезнең исемегез ничек? – дип куйды. Дөрес, юлга чыкканда артыгын сөйләшмәскә, чит-ятлар үзләре сүз катмаса, алар белән теленә салынмаска дип үз-үзенә вәгъдә биргән иде. Тик мондый тутәйләр очраганда тел тик торамыни ул?!

– Нәфисә апаң булырмын мин, энекәем, – дип хатын кулына икенче чиләген алды. Маратка мутланып кына күз кыскандай итте дә чиләгенә су тутырырга чишмә ягына борылды.

Марат та бүтән сүз озайтып маташмады. Су өчен рәхмәт әйтеп, юлын дәвам итте. Ә үзе эчтән генә әрепләшеп барды: «Апаң, имеш! Мараттан дүрт-биш яшькә өлкәндер инде, апаң дип тора. Мин синең шикелле апаларны дистәләп фәлән иткән кеше!»

Бераз киткәч кабат артына борылып карады. Нәфисә көянтәсенә чиләк элеп маташа иде. Аның чамасыз күтәрелгән итәгеннән ап-ак юан ботлары күренеп китә. Хатын, егетнең карашын тойгандай, кинәт башын күтәреп артка карады да нәрсә күзлисең дигән шикелле бармак янады.

Бу Маратның әз генә булса да сөйләшеп алган беренче, дөресрәге, автобуста «допрос» алып кайткан бабайны исәпкә алсаң, икенче Күкташ кешесе иде. Беренче сынаулар дип әйтергә мөмкин. Һәм аларны уңышлы уздым дип исәпләде Марат. Ә алдагысын кем белгән...

* * *

Артык зур булмаган авыл йорты. Коймалары зәңгәргә буялган. Өч каен күләгәсендә утыра. Капка янына килеп җиткәч Марат икеләнеп туктап калды. Монда кемнәр яши, аны ничек каршыларлар, бөтенләй чит-ят итмәсләрме – болар барысы да әлегә табышмак. Тик уен башланды инде. Алдагысы – билгесез, ә артка юл юк. Ишегалды ягында «һау-һау»лап эт өрә башлады. Монда эт булыр дип уена да кертеп карамаган егет каушавыннан кинәт артка тайпылды. Ләкин үзен бик тиз кулга алды. Эт чылбырга бәйләнгән, ә чылбыр озынлыгы аңа җитешле түгел иде.

Марат этне тынычландырырга тырышып «фиют-фиют» дип сызгыргалап та карады. Ләкин теге аның саен ярсыбрак өрүен дәвам итте. Шул тавышка булса кирәк, өй ишеге ачылып, аннан түбәтәйле бер абзый күренде. Ул чыгачыгышлый, эткә: «Тарзан, тик кенә тор! Өрмә! Тукта, ишетәсеңме?! – дип кычкырды һәм капкадан керүче Маратны күргәч: «Чү, ник шулчаклы дөнья куптарасың? Лән-лән тавышың белән ишегалдын күтәрәсең бит. Таһир абыеңны да танымыйсыңмы әллә?» – дип сөйләнә-сөйләнә, кулларын алга сузып, егеткә таба атлады.

– Әйдүк, әйдүк, туганым. Кайтам дип телеграммаң килгәч көтә идек инде. Ничек соң, юллар бик авыр булмадымы? Исән-сау кайттыңмы? – дип кочаклап ук алды. Ә үзе һаман туктамыйча өргән Тарзанга кисәтү ясарга да онытмады.

– Пшол, хәерсез нәрсә! Бу Таһир абыең бит... Үзебезнеке!.. Оныттыңдамыни?

«Пеләмәш»ен кочагыннан ычкындыргач, Хафиз арткарак чигенде. Шунда Марат аның, ничектер, үзенә сәерсенебрәк, ятсынып караганын

тойды. Аерма шулай ук бик зур микәнни? Әллә шуны сизенде инде? Аның башыннан яшен тизлеге белән әнә шундый уйлар йөгереп узды.

Тик Хафизның ул халәте озакка бармады.

— Нык үзгәргәнсең, энекәем, бик нык. Хәер, көрәшмәгәнгә дә байтак, — диде ул, авыр сулап.

Һәм шунда ук, Маратның җавабын да көтмичә:

— Кинәт кенә әти-әниең үлеп киткәч, җинел булмагандыр анда. Нинди олы кайгы бит... Озатышырга да бара алмадык... СССР таркалгач аралар ераклашты шул. Рәнҗеп, безгә үпкәләп ятмасыннар өчен, монда рухларына дога кылдым. Бәгырькәйләрнең урыннары җәннәттә булсын!...

Аның хәтта күзләре дә дымланды кебек. Әнә шул йомшаклыгын күрсәтергә теләмәгәндәй читкә карап көрсенгәч:

— Авыр туфраклары җинел булсын, бәгырькәйләрнең, — дип тә өстәде.

Аны тынлап торган Марат та «кайгыга сабышты»:

— Әйе шул, соңгы вакытта кайгы бер-бер артлы килеп кенә торды, абый, — диде ул башын иеп...

Аның бу сүзләрен дә Хафиз, ничектер, сәерсенебрәк кабул итте.

Шулчак өйдән, май кояшы кебек балкып, аяк йөзенә кадәр озын күлмәк кигән, башына урап ак яулык бәйләгән унбиш-уналты яшьләрдәге бер кыз килеп чыкты. Коңгырт чәчле, түгәрәк йөзле, елмайганда бит очларында уймак кадәр генә «мәхәббәт чокырлары» беленеп тора. Бу кыздан нindидер самимилек бөркелә. Ул елмаеп чыгып басты да Марат янына килеп, аны кочаклап ук алды. Егет колак янында кызның кайнар сулышын тойды. «Туган абыем, кайттыңмы? Белсәң иде ничек сагынганымны», — дип сөйләнә иде кыз. Маратка, ничектер, уңайсыз булып китте. Юк-бардан гына җебеп төшә торган егет түгел дә... Тик менә бу үсмер кыз каршында әллә ничегрәк булды... Бөтенләй таныш түгел кыз «туган абыем» дип, кочагына сарылсын да... Аның өчен гади бер кыз гына бит ул. Юк, гади түгел икән лә. Әнә бит, йомшак куллары белән ничек яратып кочаклый. Тыгыз йомры күкрәкләре төртелеп, нindидер рәхәт тәэсир калдыра, Маратның үзенә әллә кайчан таныш булган азгын хис күңелен кытыклый башлады. Тик егетнең бу халәте озакка бармады. «Ярамый» дигән уй калкып чыкты.

— Гөлназ, буй җиткән кызларга шулай кочакка ташлану килешми, бераз тыйнаграк бул, кызым!

Бу өйалды ишегеннән янарак килеп чыккан хатын-кыз тавышы иде. Димәк, монысы Хафиз абыйның хатыны Нурия апа инде.

— Әй, булса соң. Ул минем туганым бит, — дип чытлыкланды кыз.

— Туганың булса да, килешми, — дип каршы төште әнисе.

Маратның кочагындагы бу сылу кыз Гөлназ исемле икән димәк. Таһир андый исемне телгә алган иде кебек шул. Барысын да каян истә калдырмак кирәк...

— Исәнме, Гөлназ?! Мин дә сине сагындым...

Марат кызны үзеннән читкәрәк тибәрде. Дөрес, бу хәрәкәтенең җайсызрак килеп чыкканын үзе дә аңлады. Киеренкелекне йомшарту өчен, кулларын сузып торган Нурия апа белән кушучлап күрешкәндәй итте. Тегесе егетнең аркасыннан сөеп, үзалдына нидер сөйләнә-сөйләнә, балавыз сыга башлады. Хатын-кызның күңеле тиз тулучан була шул.

Аннан соң алар дүртәүләшеп өйгә керергә кузгалдылар. Әле һаман ярсуыннан туктамаган Тарзан яныннан узганда, Нурия апа чылбырында ыргылып өргән этне тынычландырырга тырышты.

– Чү инде, Тарзан. Үзебезнең Таһир абыйны да танымыйсың. Гупчим... Шулай булмыйлар инде. — Аннан соң Маратка борылып: — Таһир, хәтерлисенме әле, наным, бер җәйне бездә чакта син урамнан табып кайткан иден бит үзен. Кечкенә көчек чагында. Инде алты-җиде ел узган да киткән. Хәзер, әнә, хуҗасын танырга да теләми. Картая, ахры, мәхлүк...

Ә Маратның үз уйлары иде. Юк, алты-җиде елда гына эт картаймый. Үтә сизгер эт булырга тиеш бу Тарзан. Кеше генә ул, йөзенә карый да таный. Эт өчен синең йөзең әллә ни әһәмиятле түгел. Ул кешене дә, башка җан ияләрен дә исеннән генә аера ала. Марат аның өчен бөтенләй ят кеше. Эткә аның исе таныш түгел. Әнә шуңа өрә дә инде ул.

– Ничего, таныр. Бүген китәргә җыенмыйм ич. Әле дуслашып бетәрбез. Шулаймы, Тарзан, — диде Марат, бусагадан үтеп.

Хәл-әхвәлләр белешкәч, «туган-тумачалар» күңелле генә гәпләшеп өстәл артына ашарга утырды. Марат артык сөйләшмәде. Ул сорауларга җавап бирде, ләкин күбрәк башкаларны тыңлады. Хәер, нәрсә сөйләшсен?! Белгәненә караганда белмәгәне күбрәк. Әнә Хафиз абый дигәне, болай да вакыт-вакыт каш астыннан сөзеп кенә карый. Кирәксә-кирәкмәсә дә бик мәгънәле итеп тамак кыргалап куя. Сизенәдер. Сизенмичә... Тышкы кыяфәт охшашлыгы бер нәрсә, ә эчке дөнья бөтенләй икенче шул. Алар озак яшәп дөнья күргән кешеләр... Ялган никадәр генә матур булмасын, ясалма ул. Фальш... Өлкән кеше ясалмалылыкны эчкерсезлектән тиз аерадыр...

Ашагач, һәрберсе, «амин» әйтеп дога кылды. Ашап туйгач дөньяны җимерерлек итеп кикерүдән башканы белмәгән Марат аларга кушылмады. Табын артыннан кузгалырга җыенган «туганнар»ының үзенә, ничектер, сәер караш ташлап алганын гына тойды. Башка вакытта, табыннан кузгалганда моны исәпкә алырга туры килер, дип уйлап куйды.

Яңа «туганнар» белән танышу әнә шулай башланды. Марат кыяфәте белән Таһирга ничек кенә охшамасын, барыбер аермалы яклары беленә булса кирәк. Йорт хуҗаларының үз-үзен тотышыннан, әйткән сүзләреннән тойды ул моны. Бигрәк тә Хафиз абый шикләнебрәк карый кебек. Егетнең кыяфәтендәге үзгәрешкә гаҗәпләнүе беренче күрешүдә үк йөзенә бәреп чыкты аның. Тик кешеләр шикләрен бик тирәнгә яшерә белә. Ә менә Тарзан яшереп тормады. Ятсынып һаман да «һау-һау»лап өрүен белде. Әгәр теле булса, кычкырып әйтеп тә бирер иде. Теле генә юк. Хәер, телсезлеге Марат өчен яхшы да әле.

Әлегә борчылырлык бернәрсә дә юк. Барысы да уйланганча яхшы бара. Бүгенгесе әйбәт, иртәгесе өчен ишәк кайгырган ди егет.

* * *

Куктәшкә кайтып, Хафиз абыйларда яши башлагач, Маратның башыннан нәрсәләр генә узмады. Кайвакыт ул соңгы көннәрдә булган вакыйгаларны төш кебек кенә кабул итте. Егерме дүрт ел үзе теләгәнчә яшәгән кешегә әлеге яңа шартларга ияләнү җиңел булмас, әлбәттә. Тагын шунысы да бар, хәзерге мохит элеккегесеннән бик нык аерыла, хәтта, аның капма-каршысы, дияргә була.

Марат муллыкта үсмәсә дә иркенлектә үсте. Син тегеләй эшләмә, болай эшлә, дип артыннан эзәрлекләп торучы да булмады. Шуңа күрә, үзе ни теләсә шуны эшләү, кая барырга теләсә шунда бару, гомумән, нәрсә кыланырга теләсә шуны кылану аның канына сеңгән. Ә монда үзенә күрә җитди әхлакый калыпта яшисе, шулардан читкәрәк тайпылсаң: ник болай эшләден дип, искәртеп торырдай кешеләре дә бар...

Мин-минлекне яратучы, үзе дигәнчә генә яшәргә өйрәнгән Марат әнә шул мохиткә килеп эләкте. Ул бу дөньяны төш кебек кенә кабул итте. Озакка бармас, кинәт кенә уянып китәр дә кабат элекке тормыш белән яши башлар кебек иде аңа. Тик...

Тик уянып та китә алмый, шулай ук кабат элекке тормыш белән яшәргә хакы да юк. Элеккечә яши башласа, бар ялганы тотылачак, гөнаһлары берәм-берәм калкып чыгачак. Ә бу үзенә үзен кабер казу дигән сүз. Шулай булгач, бер генә нәрсә кала: мондагы тормышка яраклашу, гадәтләрен үзеннеке итү.

Ул күбрәк Гөлназ белән аралашырга тырышты. Кайчак икәүләшеп бакчага чыгып утыралар да, озаклап сөйләшәләр, «үткәннәрне искә төшерәләр». Дөресрәге Гөлназ искә төшерә, ә Марат аларны колагына киртләп, хәтеренә сеңдерә бара. Шундый сөйләшүләрнең берсендә Гөлназ:

— Туган абыем, син хәзер рәсемнәр ясамыйсыңмы әллә? — дип сорап куйды.

Марат аңа каршы: «Ник, элек ясый идеммени?» — дип әйтеп ычкындырганын сизми дә калды. Алдын-артын уйламыйча сөйләшә торган кешеләр турында, «агач тел» диләр кайчак. Сүзен уйламыйчарак әйтте шул. Элек ясый идеммени, имеш! Ул бит хәзер Марат түгел, Таһир. Ә Таһирның элегрәк рәсемнәр ясаган булуы мөмкин. Шуңа күрә ул ялгышын төзәтергә ашыкты:

— Ә, әйе... Юк... Әлегә ясамыйм, — дип мыгырдангандай итте. Аннан соң, сүзләре үтемлерәк булсынга: — Сәбәпләре бар, — дип тә өстәде.

Нинди сәбәпләр?.. Нәрсә турында сүз булырга мөмкин — ул боларын үзе дә анык кына уйлап бетермәде.

— Син җәйләрен кунакка кайтканда, без су буйларына, урман-кырларга рәсемнәр ясарга йөри идек. Этюдникыңа иелеп, акварель буяулар белән рәсем ясаганда, мин, кәҗә бәрәне кебек сикергәләп, сиңа комачаулап йөри идем. Син мине кайчак шаярып кына ачуланып та ала идең... Исеңдәме?

— Әйе, исемдә, — дип, Марат аның сүзләрен җөпләгәндәй итте. Ә үзе, эченнән генә, димәк, Таһир рәссам да булган икән әле, дип уйлап куйды.

Бу күңелсез теманы тизрәк тәмамлыйсы килеп, сүзне икенчегә бормакчы иде, тик Гөлназ һаман үткән хатирәләрен искә төшерүен дәвам итте:

— Абыем, син мине дә рәсем ясарга өйрәтә башлаган идең бит. Соңгы киткәнеңдә, син кайтканчы күп итеп рәсемнәр ясап куярга кушкан идең. Сүзеңне тыңладым тыңлавын. Тик барыбер синең шикелле матур итеп ясый алмыйм. Ясаган рәсемнәремне күрәсең киләме? — диде ул.

Марат моңа шатлануын белдергән кыяфәт белән:

— Килә. Нишләп инде аны элегрәк күрсәтмәдең? — дигән булды.

Гөлназ, йөгереп кенә өйгә кереп китте. Ә Марат үз уйларына чумды. Аның гомерендә бер мәртәбә дә рәсем ясап караганы юк. Мәктәптә укыган елларда рәсем укытучысы, тартып-сузыптыр инде, дүртле куйгалый иде. Кая инде аннан рәссам! Тик ничек булса да хәлдән чыгарга кирәк.

Шул арада Гөлназ, житез күбәләктәй бөтерелеп, кулына шактый калын папка тотып, килеп тә чыкты. Папканы беседка өстәленә куйгач, ашыкмыйча гына ачып, альбом битләрен ала башлады. Төсле акварель белән ясалган рәсемнәрнең берничәсен карауга ук Марат аларның матурлыгына шаккатты. Аның күзлегеннән караганда, алар искиткеч оста ясалганнар. Ул үзе ничек кенә тырышса да мондый рәсемнәрне ясый алмас иде.

— Йә, әйдә, ялгышларымны эзли башла инде, — диде кыз, оялган сыман, читкә карап.

Марат башта берни дә әйтмәде. Дөресрәге, бу кызга ни әйтергә икән дип уйланды. Фикереңне туплап, уйлап сөйләшмәсәң...

— Ялгыш, дип... Монда ялгышлар да шактый кимегән инде... Молодец, әкренләп остарасың бит... Рәсемнәреңне күргәч, үзем дә таң калдым, — дип сөйләнде...

Ләкин кыз бу сүзләрдән генә канәгать түгел иде шул. Ул иренәрен турсайткан булды.

— Әй лә, син минем күңелне күрер өчен, юри-мыри гына мактаган буласың. Элек, ни өчен төсләр тоныкь, нигә янәшәдәге әйберләр белән офык яны бер үк тонда, перспективаны оныткансың, дип, гел бетереп ташлар идең...

Ул сүзен тәмамлый алмады, Марат бүлдерде.

— Соң, сеңелкәш, кешенең эшеннән гел гаеп кенә эзләп булмый бит инде. Ялгышларың бар анысы... Тик...

Марат бер рәсемне кулына алды да игътибар белән карарга тотынды. Әнә, алгы планда агачлар сурәтләнгән, бераз арырак инеш, аның аша салынган күпер, еракта иген кырлары саргаеп күренеп тора, аннан да арырак — зәңгәрсу урман, офык... Бар да урынында, тәртиптә кебек... Ниндидер ялгышлары булса да, Маратның аларны аңлардай гыйлеме юк.

— Тик, унай якка үзгәрешләр дә шактый бит. Анысын да күрергә кирәк, — дип, рәсем сәнгатендә булган бар гыйлемен туплап, сүзләрен тәмамлады ул.

Элегрәк телевизордан ил җитәкчеләренең шәһәрләр буйлап йөрүләрен, төрле завод-фабрикаларда «халык массалары» белән очрашып сөйләшүләрен күрсәткәндә Марат аларның производствода һәр тармак белән нык хәбәрдар булуларына шакката иде. Тегеләрнең, үзләрен белдеклегә санап, бернича гомуми сүз белән «кешеләр колагына токмач элеп» йөрүләре турында уйлап та караганы булмады ул чакта. Гомуми сүзләрне дөрес кулланганда, әнә бит, кешене алдавы җиңел икән. Аның өчен әллә ни тирән белем дә кирәк түгел ләбаса.

Маратның соңгы сүзләреннән Гөлназ бераз тынычланса да ул барыбер канәгать түгел иде әле.

— Син, Таһир абый, бу кайтканыңда бик нык үзгәргәнсең. Кайчак, син — гел син түгелсеңдер кебек миңа...

Нәрсәне-нәрсәне, Марат мондый сүзләрне көтмәгән иде. Менә хәзер, инде ничәнче мәртәбә: тагын ялгыштыммы, Таһирдан шулай нык аерыламмы дигән уйлар йөгереп узды аның башыннан. Әгәр алга таба да шулай дәвам итсә, бу йортта озак яши алмас. Тик менә хәзер үз-үзен тизрәк кулга алырга кирәк иде.

— Гөлназ, минем дә бит соңгы вакытларда башымнанниләр генә узмады... Әти-әнине югалту.

— Әти дә, Таһир бик нык үзгәргән, ди. Әти-әнисен югалтуны авыр кичергән, күрәсең, ди...

— Әйе, Хафиз абыйның миңа ничектер ятсынып караганын тоям...

— Хәтерлисеңме, син бит элек әтигә, Тәти абый, дип эндәшә идең... Хәзер абый гына дисең...

Марат беренче күрешкәндә, абый, дигәч, Хафизның сәерсенебрәк калганын тойган иде шул. Менә ни өчен гаҗәпләнгән икән. Таһир аңа Тәти абый дип эндәшкән икән. Бер уйлап карасаң, әллә ни әһәмиятле нәрсә дә түгел кебек. Тик шикләнгән кешегә шик өстәү өчен шул җитә кала.

— Әти-әнине югалту җиңел булмады... Анысы бер нәрсә... Кайгы өстенә кайгы, дигәндәй, мин тагын бер фаҗига кичердем әле...

— Нәрсә булды?

— Үзем дә юл һәлакәтенә эләктем. Озак кына больницада ятарга туры килде миңа, сеңелкәш...

Моны ишеткәч, Гөлназның күзләре мангаена менде.

— Таһир абый, нәрсә, син аварияга эләктеңме? Нишләп без белмибез? Ник яшердең?..

— Борчыйсым килмәде. Хәбәр итеп тормадым... Хәзер барысы да үтте инде... Тәртип... Әнә шул чакта миңа амнезия булды...

— Абый, ә амнезия нәрсә соң ул?

Амнезия, медицинада өлешчә яки тулысынча хәтерне югалту, дигән мәгънәне аңлата. Чечняда хезмәт иткәндә бер хезмәттәше снаряд шартлаудан контузия алып, амнезия булган иде. Аның үткән тормышын бик авырлык белән генә хәтерләве Маратның исендә әле. Менә хәзер шул ярап куйды. Дөрес, «амнезия театры» уйнау турындагы уй әле Күкташка автобуста кайтканда ук башына килде аның. Бу очракта аннан башка хәлдән чыгып булмас иде.

— Алган травмалар нәтиҗәсендә хәтерне югалту дигән сүз ул, сеңлем. Менә минем белән дә шундыйрак хәл булды. Өлешчә хәтерне югалттым. Кайбер вакыйгаларны бөтенләй хәтерләмим, ә кайберләре өлешчә генә истә. Менә син, хәзер рәсем ясамыйсыңмы дип сорадың. Дөресен генә әйткәндә, Гөлназ, мин рәсем ясау сәләтен дә югалтканмын. Киләчәктә бәлки, әкренләп, кабат өйрәнермен....

Марат, сүзләрен раслау өчен, чалбарына кыстырылган күлмәк итәген тартып чыгарды да, кызга ярадан калган җөйне күрсәтте. Чечня сугышында снаряд кыйпылчыгы телеп алган ярадан калган бу җөйне күргәч, Гөлназ бөтенләй әсәрләнде, «аһ» итте.

— Ай, үләм! Бик авырткандыр инде, абый, — диде ул, яраны учы белән сыйпап. Аның хәтта күзләренә яшь тә килде сыман.

Марат зарлануны кирәк санамады. Бу чынлыкка якын булмас иде. Шуңа күрә, тыныч кына:

— Авыр инде анысы... Тик түзәрлек... Ә менә якыннарыңны югалту?! Гөлназ, кайчак йөрәк авыртуы тән авыртуга караганда авыррак була, анысына түзүләр читен, — диде ул, артистларча Таһир роленә керергә тырышып. Һәм, Гөлназның кыяфәтенә караганда, бу искиткеч уңышлы чыкты. Бераздан Марат берни булмагандай:

— Ә «тәти» дигән сүз нәрсәне аңлата соң ул? — дип сорады.

— Матур, яхшы дигәнне аңлата... Кечкенә балалар сөйләшкәндә, гадәттә, тәти диләр. Синең минем әтине «тәти абый» диюең, яхшы абый дигәнне аңлата инде. Бәләкәй чакта шулай эндәшергә өйрәткәннәр дә, соңыннан ияләнгәнсең инде...

— Тәти... Тәти абый... — дип кабатлады Марат, урыныннан кузгалып.

Бүгенге «дәрес» шуның белән тәмам иде. Гомумән, башына берьюлы күп мәгълүмат керү соңгы вакытларда Маратны тиз ялыктыра башлады...

*Ахыры киләсе санда*

*Ахыры киләсе санда*



Гөлнур
Корбанова

# ЮШКЫННАРНЫ ВАКЫТ ЮА

***

**Сабый хыялларым**
**искә төшә кабат:**
**«Алыгызчы миңа**
**сатып ике канат!**

**Мин дә очар идем**
**кошлар белән бергә.**
**Минем бик тә, бик тә**
**кош буласым килә!»**

**...И, зарыккан чагым**
**кочарга дип күкне...**
**Канатсыз да күккә**
**җитүчеләр күпме...**

**Канатларын кеше**
**күңелендә йөртә.**
**Кошлар булу өчен**
**КЕШЕ булу җитә.**

* * *

**Юктыр синең**
**хәрәмнәргә**
**ымсынганың,**
**намазлы һәм**
**уразалы**
**мөселманым.**

**Җирдәгеләр**
**кычкырганда:**
**«Таптык алмаз!»,**
**синең өчен**
**чын алмазлар**
**булыр — намаз.**

---

Гөлнур КОРБАНОВА — *шагыйрә; «Уемның куены», «Утлы яшеннәргә кагылсаң», «Аю булу кыенмы?» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Мал урының
кесә булыр,
йөрәк түгел.
Акча өчен
янчык булмас
синең күңел.

Йөрәгеңдә
һәрвакытта:
«Аллаһ! Аллаһ!»
Адашканнар
бәхетеңне
аңлый алмас.

***

Хыялдагы бер хатирә булып
кал син –
китмә хыялдан!..
... Кар сулары ярсып аккан чакта,
тау өзелгән чакта кыядан,
Син калкырсың минем хәтеремдә.
Тетрәнерләр хәтта болытлар.
Юк, югалма!
Китмә хыялымнан –
буй җитмәслек кояш булып кал!
Ишегенә йозак эленмәгән
күңелемне кемнәр шакымас...
Ләкин
Сиңа охшаш берәү –
Син булмас шул,
Синең адаш сиңа тиң булмас.
Үткәннәргә
кабат–кабат кайтам,
хәтеремнең тегәм тапларын.
Юшкыннарны вакыт юа–юа,
бер караңгы җиргә атканын
мин аңлармын әле,
танырмын.
Югалсаң да,
яктылыгың аша
Сине кабат табып алырмын.
...Ә хәзергә
шундый моңсу салкын чакларда
миңа кала киләчәкне бары,
бүгенгемә төреп сакларга.

* * *

Җанда никтер борчу
язлар килгән мәлдә.
Син дөньяга карап
баскан өчен әллә.

Бу дөньядан азга
күзләреңне ал да
тик бер генә тапкыр
язга таба кара:

кайта җиргә тормыш,
шыта җирдә үлән,
ә син әйткән идең:
«Юк, терелмәс үлгән».

Язга гына кара:
язлар килгән мәлдә
җир терелә кабат
күз алдыңда әнә.

Бу язларда сиңа
бер теләгем минем:
кайбер эшләреңне
ташла. «Тәүбә», диген.

Бу дөнья ул сиңа
бер хыянәт итәр.

Артык сөймә аны.
Тукта. Булды. Җитәр.

Бәлки мине аңламассың...
Бу — саваплы хатам...
Йөрәгеңне саклар өчен
(мин — кабырга)
аркылыга ятам...

***

Офык читләрендә ышык таулар
яктылыкка таба үрелгән.
Таулар йөрәгеннән сафлык алып
кардәшемә таба йөгерәм.

Әзербайҗан, кыргыз, башкорт, төрек,
төрекмәнем, казах, балкарым...
Күңелемә исемеңне яздым,
тарихыңны синең ятладым.

Төркиләрем, газиз төркиләрем!
Йөрәгемдә саклыйм мин сезне.
Офыкларда — таулар. Җитәкләшкән
кардәш төрки халык шикелле.

* * *

Күк катында берәү сайрый,
әллә инде тургай...
Шул тургайга кара әле,
турай, Татар, турай!

Тураям, дип, туйдыргандыр
уклау йоту гел, гел.
Намазлыгың кайда, Татар...
бөгел, Татар, бөгел!

Дәшми тора. Уйга баткан
чал тарихлы Идел.
Таугa менү — авыр. Төшү
җиңел,
    җиңел,
        җиңел...

***

Ябып куйдың үткәннәрнең
ишекләрен,
үткәннәрдә моңым калды –
ишетмәдең.

Үткәннәрдә нурым калды,
күләгәдә...
Кайтам шуңа бик еш кына
үткәннәргә.

Үткәннәрдә — айлар, еллар,
безнең гомер.

**Гомерләрне кисеп ташлау**
**мөмкин түгел...**

***

**Кара болыт, кара болыт,**
**кара болытлар кара.**
**Кара каргалар уртәлә**
**кара болытлар барга.**

**Кара болыт, кара болыт,**
**карашлар күккә бага.**
**Кояшны каплап, һавада**
**буш ак болытлар ага.**

**Кара болыт, кара болыт,**
**йөрми ул болай гына,**
**бер кочак файда төягән**
**юлының уңаена.**

**Кара болыт, кара болыт,**
**кара болытлар кара.**
**Тормышта кара болыттан**
**кайчак җаннар агара.**

***

**Язларым...**
**Язларым...**
**Язларым...**
**Укыйм мин күкләрнең язганын:**
**гомерләр — бер генә. Язы да,**
**җәе дә, көзе дә аз аның.**

**Җәйләрем...**
**Җәйләрем...**
**Җәйләрем...**
**Җәйләрдә — җиләкле чәйләрем.**
**Вакытка буйсынып, тын гына**
**җәйләрне көзләргә бәйләрмен.**

**Көзләрем...**
**Көзләрем...**
**Көзләрем...**
**Ни белән тиңлим соң үзләрен?**
**Көзләрем сагышлы килсәләр,**
**сагыштан өзелер үзәгем.**

**Кышларым...**
**Кышларым...**
**Кышларым...**
**Зәмһәрир суыклы тышларым.**
**Аңлармын, ни өчен кышларны**
**калдырып киткәнен кошларның.**



Рүзәл
Мөхәммәтша

# ХИКӘЯЛӘР

### Төшләр

...Рауза карчык кат-кат Аллаһыдан минем гөнаһларымны кичерүен үтенде. Авылыбызның зиратында булган барча әрвахларның рухы шәрифләренә дога кылды, бабамнарны, әбиләремне, ир һәм кыз туганнарымны исемләп атап, барчасына-барчасына теге дөньяда оҗмахта урын сорады. Аннары аңа күчте:

— Йа Раббым! Рамил улы Раил Фаиз улы Рүзәлне җәдәтеп җөрмәсен, төшләренә кермәсен! Тынычлыкта калдырсын аны, әлхәмдүлилләһи, әлхәмдүлилләһи...

Менә, Ройка, нинди көн килеп житте бит, ә: безне Аллаһ белән исем-отчестволап таныштыралар...

**1**

Үлеменнән соң берничә көн үткәч, Ройка тәүге кат төшемә керде минем. Төше дә әллә нәрсә түгел иде, үзем дә хорафатларга артык ышанмыйм — төнлә күргәннәр миңа берничек тә тәэсир итмәде.

Шулай да...

Имеш, мәктәп еллары...

Без — Ройка, Рафил, мин — ни сәбәпледер Кәркәвеч клубына төшкәнбез. Нәкъ менә Кәркәвеч клубы! Минем анда гомердә булганым юк югыйсә... Нишләптер, һәммәбез дә авылча киемнәрдән: Ройка бейсболка, совет заманындагы мәктәп формасын кигән. Шулай йөри иде ул... Мәйдан шаулый, гөр килә! Рафил белән мин дә и сикерешәбез, и бии Рафил! Хәер, нәрсә ул Рафил — гомер бии белмәгән мин дә шатыр-шотыр җилдерәм генә. Аяклар очып кына йөри диярсең. Тик... Ройка монсу иде. Йә тавыш-тынсыз басып тора, йә дивар буйлап тезелгән урындыкларның берсенә барып утыра. Ә тирә-юньдә музыка хакимлек итә... Биюләр! Мин түзмәдем, ахыр, якасыннан тоттым да, җилтерәттем тегене:

— Ач күзенне! Нәрсә монсуланасың, шәп бит! Киттек, биибез, — дим.

Рүзәл МӨХӘММӘТША (1989) – *шагыйрь, прозаик; «Каралама» китабы авторы. Татарстан Республикасының М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

— Юк, — дип ымлады ул, башын иеп, һәм дәшми генә чыгып та китте... Бөтен көчкә акырган музыка аша да ишекнен шап итеп ябылганын аермачык ишеттем мин. Музыка көчәйде (менә сина вәйт, ниндидер трагедия диярсен: музыка көчәя. Ут сүнә. Пәрдә.) Ройканың китүен башлары түшәмгә тигәнче котыра-котыра биегән яшьләр сизмәде дә...

Рафил белән без дә биеп калдык.

Ройка китте, ә без биеп калдык.

Без һаман биибез әле...

## 2

Ул вакытта мин Казанда идем.

Милли музейда лекцияләр тынлыйбыз.

Кызу. Чәч арасында берәр-берәр тир бөртеге шытып, әледән-әле маңгайдан, ияктән ага тора иде...

Кесәдә тавыш чыгарган телефоным мине сискәндереп куйды... Кайсы хәерсезе икән? Телефонны кулга алам. Укыйм: «Раил үлгән». Мин, дөрес аңламадым, ахры, дип күзләремне тагын берничә мәртәбә электрон хәрефләр буенча йөгерттем. Нәрсә бу?

Калтырый-калтырый, смс жибәргән номерны — сеңелемне — кире җыям:

— Ни булды?

— Абый, Раил үлгән.

Мин тораташтай каттым. Сүгенеп җибәрдем.

— Ничек? Кайда?

— Казансуда баткан...

Сеңелем шул сүзләрне әйтеп бетерергә өлгерде генә, элемтә өзелде. Акчасы беткән булса кирәк... Озын-озак гудоклар гына ишетелеп калды.

Бетте. Минем өчен лекция, алай гына да түгел — бу көн тәмам иде. Дәфтәр-ручканы тиз генә пакетка салып, тышка чыктым. Биредә тагын да тынчу иде. Мин Кремль урамы буйлап университетка таба атладым, ләкин озак бара алмадым — аяклар чуала башлады, баш чатный — туктап, аркам белән йорт диварына терәлдем, дивар буенча шуышып төшеп, чирәмгә утырдым. Янәшәмнән генә мина, һәм гомумән, бөтен дөньяга битараф булган адәмнәр ашыга иде. Кайберләре мина шикләнеп, кайберләре миннән көлеп уза бирде. Аларга ни ул таныш түгел бер үсмернең башын иеп утыруы? Мин күземне күккә төбәдем, зәңгәр-зәңгәр болытлар да каядыр ашыгалар иде... Тамак кипте, кармакка эләгеп яр кырыена ыргытылган балык төсле, авызымны ачтым, һаваны йоттым, гүя бу һава сусавымны басарга мөмкин иде...

Ройка үлгән. Ройка үлгән... Ройка — үлгән!.

Сеңелем тарафыннан әйтелгән бу сүзләр минем башымны ярды, контузияләнгән хәрби кебек, колагымда бары тик шушы хәбәр генә яңгырады:

— Ройка — үлгән!

Ничек инде алай, ничек инде... Ничек инде?!! Әле генә, Сабан туенда гына бергә йөргән идек бит...

## 3

Ройка безнең өйдә утыра икән...

Мин аның үле икәнен хәтерлим, имеш, ләкин ул ничектер кире кайткан. Иң кызыгы: ул бернинди хисләр, тәм-ис тоярга сәләтсез. Безнең кече якта утырабыз. Табын тулы сый-нигъмәт, чәй эчәбез... Ә Ройка бернинди тәм тоймый, һәм мина бу шулкадәр искиткеч кызык кебек тоела!

— Ипи тәмен дә тоймыйсыңмы? — дип сорыйм моңардан.
— Юк, — ди ул мина, моңсу гына елмаеп.
— Исен дә сизмисенме? Нинди тәмле бит!..
Исним.
— Юк, — ди ул.

Без урамга чыгып киттек. Чиләкләп-чиләкләп яңгырява иде... Исәрләнгән сыман, кулларымны як-якка җәеп, яңгырны кочмакчы булам. Эре-эре яңгыр тамчылары чәчемне, йөземне чылата, иңбашларымнан аяк очларыма агып төшә. Шулкадәр рәхәт, рәхәт нигәдер!

— Яңгырны да сизмисеңме? — дим.

Ройка дәшми. Үзе шулкадәр моңсу инде!

Уянып киттем. Караватка утырдым да, уйга калдым. Нәрсә булды бу? Төшем әле күптән түгел генә караган кинофильмны хәтерләтә. Николас Кейдж башкаруында персонаж (төшемдә Ройка башкарды бу рольне) — кешенең гомерен алырга килүче фәрештә. Кем артыннан килә, фәкать шуның гына күзенә күренә ала ул. Шулай ук ис тә сизми, тәм дә тоймый — барча хис-тойгылардан мәхрүм, әмма мәңге яшәүче зат...

Ройка шушы фәрештә сыйфатында яныма килгән булып чыга түгелме соң?

Бу төшне озак вакыт беркемгә дә сөйләмәдем: якыннарым өчен курыктым. Үзем, сабыр гына, нәтиҗәләр чыгарырга тотындым. Иртә әле! Ай-һай иртә! Берни эшләргә өлгермәгәнмен бит, дип уйлап куйдым. Китәсе килми икән әле... Хәер, беркайчан да китәсе килмидер инде ул. Гадәттәгедән озаграк вакытка туган авылыңа кайткач та, әти-әниеңнән, чишмә-тугайларыңнан, тау-елгаларыңнан аерыла алмыйча интегәсең: китәсе килми! Ә монда ике дистә ел (ни дисәң дә, каникулларга кайтудан күбрәк бит!) яшәп, кинәт кенә — ишек шакыйлар да, автобус кötә, тизрәк җыенырга кирәк, диләр...

Озаграк торган саен китәсе килмәү көче ныграк, чөнки озаккарак сузылган һәр мизгел, һәр көн, һәр ел китәргә кирәк булган вакытны якынайта.

Яшәргә ияләнеп беткәндә генә — китәргә кирәк!

**4**

Сабан туенда бик моңсу йөрде ул...

Юк, үләчәген алдан сизенгәндәй моңсу йөрде дип әйтәсем килми — алай булмагандыр. Кем үзенең үләчәген алдан белсен инде?

Сабан туе мәйданы — клуб каршында гына. Мәйданда көрәшкәне — көрәшә, көч сыный, көрәшмәгәне — таллар астында аракы эчә... Хәер, алай карасаң, тегесе дә, бусы да көч сыный инде...

Мин, ни эшләргә белмичә, аптырап йөрим. Таныш-белешләр күп, ә кирәк кеше — юк дәрәҗәсендә. Булганы да йә парлашып — егет белән кыз — узып китәләр, йә балалары белән тундырма кибетенә чират торалар. Кыскасы, Башлачевның бер җырындагы кебек «сплошной духовный неуют»...

Уемны укыгандай, әллә каян тузан туздырып, шәмәхә-зәңгәр ВАЗ 2106 яныма килеп туктады: Федя белән Рустик төшкән. Федя горур гына машина ишеген япты да мине кочты:

— Нихәл, брат?
— Ярый...
— Әйдә, бик скушныга охшаган мында, киттек, Өшеңгә төшәбез...

Рустик күбрәк русча сөйләшә, шуңа күрә безнең әңгәмәне әллә ни

игътибар белән тыңламады – барыбер аңламам, дип уйлагандыр. Гәрчә машина аныкы һәм шофер – ул булса да.

– Әйдә, – дидем мин. – Кемнәр төшә соң?

– Син, мин, Рөстәм төшә...

Рөстәм – шул ук Рустик инде.

Ул арада әллә каян гына Салават килеп чыкты, аның да Шөнгә барасы килә икән. Бераздан минем әле генә Ройканы күреп алганым искә төште. Дөрес, ул сөйгәне белән иде шул. Әһә... Әнә ул!

– Киттек... – диде Ройка битараф кына.

– Талаштыгызмы әллә?

– Юк, нормально.

Шулай да, талашканнар иде бугай... Юкса болай тиз генә ризалашыр идеме ул?

Киттек... Юл озын түгел. Шөн дигәнебез – күрше авыл гына. Дөрес, авылгача асфальтның әсәре дә юк. Тузан иснәп төшәсе... Мондый компания, яхшы кәеф һәм кесәдә акча булганда, анысына гына күнегәсең ул.

Ройка пистолет чыгарды.

– Син нәрсә?! – дим мин каушап.

– Хәзер моннан башка йөрмим. Казанда тотып типкәләгәннәр иде...

Пистолеты – пневматика гына югыйсә.

– Кемнәр? – димен.

– А хрен их знает! Таладылар...

Мин Ройкага карап алдым: битендә бер-ике төзәлеп бетмәгән ярасы да бар иде шул...

– Пычак беләнме әллә? – димен, шул яраларга күрсәтеп.

– Кастет, – диде ул.

Бераздан рульгә Федя утырды. Арабыздан «права»сыз ул гына иде бугай, шуңар күрә моның өше форсатны ычкындырасы килмәде аның, билгеле: сугыш вакытыннан бирле бернинди үзгәреш кичермәгән юлларда данлыклы һәм гадел гаишниклар очрамаячагы көн кебек ачык иде. Ә көн ачык иде, чыннан да...

Бераздан без Шөнгә төшеп җиттек. Машинаны куеп, мәйданга юл алдык. Ярты Толлы биредә икән! Әйтәм җирле үзебездә «скушны» иде шул. Йә берсе исәнләшеп узып китә, йә икенчесе белән үзебез исәнләшәбез. Сыра алдык, сыра янына – кипкән бәрәңге. Рустик сок белән чикләнде. Эчәбез... Әйе, искиткеч гүзәл табигать! Бер-ике стаканнан соң минем башыма әллә нинди мингерәү уйлар килә башлады: ә нәрсәгә төштек соң әле без монда?

– Ничек инде, мында күңеллерәк ич, – диде Федя, минем чыннан да мингерәү соравыма исе китеп. – Батырга бүләкләр дә әйбәтрәк. Кызлар да чибәррәк.

Мин дәшмәдем. Әлбәттә ки, арабыздан һичкемнең дә көрәшергә, яки этәч артыннан куарга яки, һичьюгы, капчыкта чабышырга теләге юк иде. Нигә Федя бүләкләрне телгә алды – аңламадым. Кызлар да искитәрлек түгел. Күрше күркәсенә караганда үз тавыгымны якынрак күрүчеләрдән... Тавык дигәннән, ул арада югалып торган Салават та пәйда булды. Үзе белән шашлык һәм ике егет алып килгән. Молодец, шашлыксыз нинди Сабан туе инде! Егетләрнең юанрагы кул суза:

– Ришат.

– Рүзәл.

– Ришат.

– Раил...

– Ришат.

– Фидәрис. – Федя һәрвакыт үзенең чын исемен әйтеп таныша иде.

– Ришат.

– Рустам.

– Фирдүс.

– Рүзәл.

Һәм шундый ук тәртиптә Фирдүс белән күрешеп чыктык. Кәркәвеч егетләренең Толлыга төшәргә исәпләре бар икән. Тик... машинабызда урын юк шул. Салават фотоаппаратын чыгарып, шалт-шолт күзләрне чагылдырып алды. Ул да Федя белән бер фикердә иде булса кирәк: «мында» чыннан да шәп...

Егетләрнең тәкъдиме игътибар җәлеп итмәслек түгел: сыраны үзебез белән алып, кире туган авылыбызга юл тоттык.

Авылга төшеп житү белән, Ройканы кызы култыклап алды.

– Ройка, – дидем мин. – Бушагач кил. Үзем Резедага – аның сөйгәненә борылдым, янәсе, җибәрерсең бит?

Ройка елмайды:

– Юк, житәр.

Бүтән мин аны күрмәдем... Исән-имин килеш соңгы тапкыр очрашуыбыз иде бу.

Хәзер мин бергә төшкән фотоларга – Ройканың соңгы фотоларына! – карыйм. Әйе, Сабан туенда Ройка монсу иде...

## 5

Бераздан мин ниндидер сюрреалистик, мозаикадан гына торган төшләр күрә башладым.

Мина йә этләр ташлана, имеш, йә бүреләр куа...

Йә баш өстемнән өер-өер үләксә козгыннары кычкырып очып китә...

Йә ярканатлар өстемә ябырыла...

Мин аларда Ройканы сизә идем – ачулы иде кебек ул миңа. Моны аңлату кыен, әмма ул бу төшләрдә бар иде... Белмим, бүре өрүеме, каш астыннан карап тын алуымы, кошларның кычкыру тавышымы, тирә-юньме – Ройканыкы, дөресрәге – Ройка үзе иде.

Мин төн уртасында куркып, тунып уяна башладым.

Эссе жәйдә – тунып! Юрганым манма тиргә батып, сыгып алырлык була иде. Кузәнәкләр, әйтерсең, һәрберсе – аерым организм һәм һәркайсының эчендә үз йөрәкләре тибеп, канны мигә куалар, мин исә бу кадәр басымга түзә алмыйча, күз алларым караңгыланып, егыла идем, калтырана идем...

Мин йоклап китүдән курка башладым...

Мин төннән курка башладым...

Ялгызлыктан курка башладым...

Энекәшен үтереп, үз шәүләсеннән куркып йөргән Кабилгә әйләндем мин. Һәрбер гайре табигый тавыш, яфрак селкенүе, адымнар (бигрәк тә төнлә!) куркыта иде мине... Әмма, Кабилдән аермалы буларак, гаебемнең нидә икәнлеген аңлый алмадым...

## 6

Ройка Себердән кайткан иде. Абыйсы һәм энекәше белән бергә әтиләре безнең авылга – игез сыңарына тәрбиягә алып кайтты аларны.

Күптән иде инде бу...

Беренче сыйныфка бергә кердек. Озак еллар бер партада утырдык. Аннары, тугыздан соң, китте ул. Ташчы булырга укырга кергән иде – кан басымы уйный икән – төзү эшенә яраксыз булып чыкты, мәктәпкә кире кайтты. Янәдан янәшә утыра башладык...

Ройканы моргтан алып кайтканнар иде инде.

Алар капкасы турында халык мыж килә. Кырыйдан караганда — берәрсенең туе гөрли диярсең! Әмма чыр-чу көлү урынына һәммәсе буыла-буыла, үкси-үкси елый иде.

Туганнарын, якын кешеләрен юатырга ашыгучылар да шактый:

— Сащуствую...

— Нык булыгыз инде, берүк... Бик кызганыч.

Мина, нишләптер, бу сүзләр бер дә юату булып ишетелмәде. Алар, киресенчә, язгы боз сөнгеләре эреп төшеп яшь, йомшак туфракны тишкәләгән сыман, минем дә йомшак, ә бу вакытта үтә дә йомшак һәм үтә дә тиз җәрәхәтләнергә мөмкин йөрәгемә тамып-тамып, аны, мескенемне, тишкәлиләр иде.

Бу кешеләргә ачу белән карадым. Битлек кигән убырлар ясалма сагышлана төсле иде...

Мин, башымны игән килеш, өйгә уздым.

Ройка, беркемгә дә үпкә сакламаган һәм берничә дә ачуы калмаган кебек, зал уртасында ап-ак кәфенлеккә төренеп, тын гына ята иде. Битендәге кастет эзләре шәмәхәләнеп чыккан. Йоклый... Күзгеләрне каплаганнар. Гүя, Ройка үзен көзгедән күреп курыкмасын өчен, махсус шулай иткәннәр иде. Әлбәттә: үзенне кәфенлеккә төрелгән килеш күрү бер дә күнелле хәл түгел.

Мин кулларымны күтәрдем, баш ягыннан аякка таба өч тапкыр йөртеп, кабатладым:

— Бисмилләһир-рахмәнир-рахим... Бисмилләһир-рахмәнир-рахим... Бисмилләһир-рахмәнир-рахим...

Аның белән хушлашырга теләүчеләр күп иде. Тышка чыктым. Сыйныфташлар җыелган икән: Ләйсән, Рафил, Дамира... Фәләнчә еллар буе күрмәгән Зөлфия дә күренде. Безне Ройка очраштырды булып чыга, урыны җәннәттә булсын... Югыйсә кызыйның төс-битен оныткан идем инде.

Көн кызу.

Без, күз алдыннан югалып, машина артына — күләгәгә юнәлдек.

— Нәрсә булган соң анда?

— Чумган да, чыкмаган диләр...

— Берүзе булганмыни?

— Котү белән булганнар!.. Шунын алдыннан ярты сәгатьтән артык кызы белән сөйләшкән...

— Бичара...

— Салган баштанмы?

— Канында алкоголь тапмаганнар бугай...

— Киемнәре белән баткан бит ул! Менә ин анлаешсызы... Водолазларны да берәр сәгать үткәч кенә чакыртканнар.

— Ничек инде?

— Шулай.

— Ройка йөзә белми иде! Аннары, салган баштан булса да, ул дурак што ли киемнәре белән кереп китәргә?.. Шәһәр буйлап шул кием белән кайтасы бар бит әле...

— Әрәм иткәннәр инде, алайса.

— Бли-и-и-н...

— Уеннан уймак диләрме әле?

— Кем белсен...

— Ярар, гайбәт сатмыйк инде. Ройкага барыбер хәзер...

— Алла сакласын!

Берникадәр вакыттан соң, без, әңгәмәне тәмамлап, ачык капкага бактык: Ройканы алып чыгалар иде...

Зиратка кергәч, аны чирәмгә куйдылар. Мулла тәһарәтле булганнарны үз янына чакырды. Ун-унбишләп кеше җыелгач, Коръән чыкты, арттагыларга борылып:

– Рамил малае Раил әйбәт кеше идеме? – дип сорады.

– Әйбәт кеше иде, — диеште арттагылар.

Мина кабатлау мәҗбүри булмаса да, мин дә эчемнән генә: «Әйбәт кеше иде», — дип кабатладым...

Әйбәт кеше идеңме соң син, Ройка? Дөресен әйттемме мин синең турыда? Мөгаен, әйедер. Һәр адәм баласына хас вак-төяк гөнаһ-фәләнне кертмәгәндә – әйедер. Минем алдарга күнекмәгәнне беләсең. Болай, шаярып булса гына инде. Әмма бу очракта нинди шаяру?

Әйбәт кеше иде!

Ройканы кабергә төшерделәр... Минем сулышым ешайды: йөрәк дөп-дөп, хәзер менә чыгып китәрдәй тибеп канны кызуырак йөгертә башлады, хәл китте, баш әйләнде. Ройка кап-кара туфрак өстендә ап-ак кәфенлектән ята иде... Коточкыч авыр иде миңа. Кинәт баш ике чигәдән кысып, үтереп-үтереп авырта башлады...

Ярабби!

Минем күз алдымда ләхетне томалап, Ройканы бушлыкта, караңгылыкта һәм... куркыныч ялгызлыкта (караңгыдагы коточкыч куркыныч ялгызлыкта!) үзен генә каплап калдырырга керештеләр... Башта аяклары капланды, аннары – гәүдәсе, башы... Мин, җилдә атынган тере карачкыдай, ул-буны аңламый торганда, кабер өстенә туфрак ишелә башлады. Бер уч — бер уч кына атып башлаган авылдашлар бераздан көрәккә тотынды... Тагын да бераздан Ройка юк иде инде.

Ничек микән ул, үле килеш анда, аста, беркемнең дә буе җитә алмаслык аста, юештә, салкында берүзең ятуы?!

Көннән-көн яңа кояш туачак, көннән-көн ул һаман бернидән дә канәгать булмаган адәмнәрнең ачуын чыгарып, кыздырачак, һәр көн таң туып, кич җитәчәк, ә Син – юк! Барысы да бар, барысы да үз урынында: чәчәкләр, таулар, агачлар, елгалар, йортлар! Ә син – юк! Син генә юк! Һәркөнне кешеләр каядыр ашыгачак, кем кемнәр беләндер талашачак, балалар тәпи йөрергә өйрәнәчәк...

Һәр көз саен җиһан алтынсу төскә һәм пычракка батып, һәр кыш ап-ак, сөт кебек, аклыкның үзе кебек ап-акка күмеләчәк. Һәр яз саен бөреләр шытып, язын ялангач калган каен кызлары, усаклар, читенсенеп кенә, киемгә төренәчәк, елгалар ташып агачак, ә син – юк...

Дөнья шулкадәр матур һәм бәхетле булыр өчен сиңа бик аз, бик аз нәрсә җитәр иде! Бары... булу, исән булу җитәр иде...

Әмма... син юк... Барысы бар, барысы үз урынында! Ә син юк. Һәм, бәлки иң куркынычы: син генә юк...

Сәдака өләшеп чыктылар. Аннары, мулла тагын бер кат дога кылды да без, зираттагылар, төркем-төркем өйгә таба кузгалдык. Кемдер сигарет кабызды. Җирәнгеч татлы ис борынны кытыклап, күзләрне яшьләндерде...

Ройка тартуын ташлыйсы килеп йөргән иде...

Өлгердеме икән?

## 7

Кыш азаклары...

Кин басу, имеш. Без баеп баручы кояшка таба атлыйбыз. Нәрсәдер сөйләшәбез дә бугай. Күпмедер узганнан соң, мин туктап калдым, бераз дәшми генә миннән ераклашып баручы Ройкага карап торганнан соң:

— Ройка, шулай да, нигә керәсең син минем төшләремә? — дидем.

Ул да туктады. Жилкәсе аша гына карап, җавап бирде:

— Чөнки син...

Һәм хет үтер инде — ишетмәдем нәрсәгә икәнен! Ул, башка бер сүз дә чыгармыйча, юлын дәвам итте. Мин калдым...

Калдым! Алып китмәде үзе белән...

Мин уяндым — йөрәк тагын дөп-дөп, дөп-дөп, дөп-дөп...

**8**

Бик-бик дуслар идек.

Күмәк хуҗалык эшләренә дә бергә йөрдек, бергә уйнадык. Мотоциклда йөрергә ярата иде ул. Кара күзлекләр, күн курткалар, пистолетлар — кыскасы, кәттә «кырку» егет булырга ярата иде...

Берсендә урам буйлап котырып, ап-ак карга батып, этешеп-төртешеп-егышып кайтканда әбисе — Энҗүдә апа — ачуланды безне:

— Сез туганнар бит, сугышмагыз алай, тату булыгыз! — диде ул.

Туганнар! Беренче тапкыр ишетүебез! Бу яңалык тагын да якынайтты безне.

Бик матур рәсемнәр ясый иде. Бер рәсеме миндә әле дә саклана...

Сөйгәнен ярата иде ул... Бик нык — мотоцикллар-пистолетлар яраткан кебек, «кырку» булуны яраткан кебек — ярата иде аны.

«Өйләнешер идек — яшь бит әле ул, әти-әнисе рөхсәт итмәс», — дип көрсенгәнен хәтерлим.

— Минем шаһитем — син булачаксың! — диде беркөнне.

Мин бик шат идем, канәгать елмайдым:

— Әлбәттә.

Язмаган, нишләтәсең...

Шөндәге Сабан туенда мәрхүм дусларыбызны искә алып, мин: «Яшисе дә яшисе иде бит әле аларга!» — дип сөйләнеп утырганда, Ройка тирән сулыш алып:

— И Алла... — дип кушыла бирде һәрдаим.

И Алла!

Яшисе дә яшисе иде бит әле Ройкага да!

Рәхәтләнеп яшисе дә яшисе иде!

Рауза карчык Аллаһка әйтергә теләгәнен әйтеп бетерде кебек. Битен сыпырды ул, аннары, торып, иңнәремнән какты.

Әни җибәргәнгә генә килүем: бар, Раил дога сорыйдыр, юкка кермәс, дип көндерде... Аның фикеренчә, Ройка миннән нибары ничәдер сум сәдака гына сорый иде. Артыгы түгел.

Мин, рәхмәт әйтеп, тышка чыктым. Көн һәрвакыттагыча аяз иде: һәрбер йолдыз аермачык күренеп тора. Буен житсә, Рауза карчыкның таягы белән бер-икесен бәреп төшерергә дә мөмкин иде кебек. Мин түбән очка таба атладым. Менә бер йортны узып барам, менә икенчесен. Менә Ройка яшәгән йорт турына җиттем: Ройканың бүлмәсендә ут яна...

Ул көнне шулкадәр изелеп, шулкадәр рәхәтләнеп йокладым мин.

Бернинди төш кермәде.

## Карт белән малай

Нурмый карт авылга таба күз ташлады — әнә ул, авыл: еракта, тау астында рәхәтләнеп җәелеп яткан. Әнә аның ике күле — зәп-зәңгәр күлләр, ике күзе кебек... Шундый ук зәп-зәңгәр күккә бакканнар.

Әнә аның урманы — куе урманы, караңгы урманы.

Әнә аның басу-кырлары — мәгърибтән мәшрикъка, офыктан — офыкка сузылганнар.

Әнә — зират.

Әнә кечкенә генә бер казык кебек мәчет манарасы күренә.

Әнә аның инеше — йөгерә-йөгерә анасы куенына — Нократка ашыга.

Әнә, икенче якта — Нократ үзе. Эченнән генә нинди дер сагышлы да, монсу да булган көйне көйләп, халкының бөтен бар булган моңын гасырдан-гасырга илткән, буыннан-буынга тапшырган елга.

Һаман да шул җырын җырлый ул.

Халык ул җырны ишетә...

Нурмый карт та ул җырны ишетә...

Мененче, ун мененче елын бу ярларны юып, кәефе яхшы чакта — тыныч кына, кәефе начар вакытта — дулый-дулый аларны ишеп, әмма үз язмышына барыбер тугры калып — әлеге моң чылбырын өзмичә, заманнан-заманга, дәвердән-дәвергә илтеп — ага да ага ул... Сугышлар артыннан сугышлар кабына, империя артыннан империяләр җимерелеп, яңалары төзелә тора; кавемнәр, халыклар бернинди эзен калдырмыйча юкка чыга, кырыла, эри, ә ул — ага да ага һаман...

Үз ярында урнашкан кечкенә генә авылны һәр дулкыны белән сәламләп, таннан-кичкә кадәр юлдаш булып аңа, татлы йокыга озатып аны, ага...

— Нурмый бабай, исәнме!..

Гади генә, әмма чиста-пөхтә киенгән кечкенә малай карт янына йөгерә иде. Икенче сыйныфта укый ул. Берүзе.

— Ә-ә-ә, исәнме улым! Кая кил әле монда, утыр әле...

— Ю-у-к, утырмыйм, чирәм салкын инде хәзер, әни шулай дие. Утырсам, ачуланачак ул мине.

Карт елмаеп куйды:

— Әниең юк бит әле монда, кил, утыр...

— Юк, ярамый... Алайса, Алла бабай күреп, әнигә әйтә дә, әни мине барыбер ачулана.

— Кил, алдыма утыр, алайса...

— Ә әни ачуланмасмы соң?

— Ачуланмас. Нәрсә, ничә икеле алдың бүген?

— Берне дә түгел.

— А-а-а, малай, син вабше әшәкеләнеп беткәнең бит. Икеле дә алмагач аны. Менә мин синең жәштә-ә-ә...

— Алдама, әни әйтә, Нурмый абыең бик акыллы ул, дие. Җиде класс бетергән, дие... Ул вакытта бик әзләр укыган, дие.

Нурмый карт кабат елмайды:

— Балам, әниең алдалыйдыр. Ничек мин, туксан яшьлек карт, сине, җиткән жегетне, оялмыйча алдалап торыйм дие инде?!.

— Әниләр беркайчан да алдаламый алар!

Нурмый картның әлеге җаваптан бик канәгать калуы йөзенә чыккан иде:

— Дөрес, улым, маладис. Мә, тот бу алманы шуның өчен...

— Рәхмәт, бабай.

Бераздан куакларны сыйпаган җил тавышына малайның шартлатып алма кимергән тавышы кушылды.

— Атаң ничек соң, иярләнәм диме?

— Иярләнәдер инде. Безгә бик авыр: әнигә авыр, әбигә авыр, миңа авыр... Абый да сирәк кайта, апа да. Бик сагынам.

— Нишләтәсең, китәләр бит. Эш жук, диләр. Эше булса, акчасы жук, диләр...

— Рамилнең әтисе дә китте. Минеке Казанга гына әле, аныкы Себергә үк бит! Минем әти кайткалый әле, аныкы — яздан бирле күренми инде. Рифат абыйныкы да, Йолдызныкы да. Кичә шалтыратты әле: сина бик күп кучтәнәчләр, китаплар алдым, дие. Әйбәт укысаң, алып кайтырмын, дие. Менә сине тынлап икеләләр алсам, ул мина китап алмас иде!

Карт, малайның башын сыйпады:

— Син маладис улым, синең белән була...

— Әти дә шулай, дие. Тагын алман юкмы, бабай?

— Өйгә кайткач бирермен. Икене бирермен.

— Өчне бирәсенме соң? Берсен — Рамилгә.

— Дүртне бирермен, алай булгач. Киттек, кузгалыйкмы?

— Әйдә.

Алар тау итәге буенча, елга ярыннан, авылга таба юл алды. Һәр адымнары аларны елгадан ерагайтып, авылга якынлаштыра иде.

— Бабай, матур безнең елга, име?

— Матур, улым...

— Авылыбыз да матур, име?

— Авылыбыз да матур...

— Ә нигә, алайса, «бетә» диләр аны? Ничек авыл бетә ала инде?

— Кем әйтә?

— Бөтен кеше әйтә.

— Курыкма, улым, синең белән без икәү бар бит әле. Без булганда бетмәс.

— Әни, Алла бирса, диергә куша.

— Дөрес әйтә, улым, Алла боерса.

— Бабай, ә безнең авылны хан заманыннан билгеле, диләр. Бу күптәнме?

— Бик күптән.

Малай очкын тулы күзләрен картка төбәде:

— Динозаврлар яшәгән вакыттанмы әллә?

Карт кеткелдәп көлеп җибәрде:

— Жук, алай ук түгел инде, бераз соңрак.

— Безнең авылны тол кеше нигезләгән, диләр, шул дөресме соң?

— Дөрестер, улым, риваяте шундый.

— Аңа кадәр авылда чирмешләр генә яшәгән, диләр...

— Анысы да бардыр.

— Сөйлә әле миңа шунын турында.

— Нәрсә турында?

— Менә шулар турында. Авыл турында.

Карт малайга борылды:

— Үзең дә беләсең бит әнә.

— Юк, мин тулысы белән белмим, тулысы белән сөйлә!

— Нәрсә сөйлим соң? Китап авылның салынуын бик борынгыдан күрсәтә...

— Динозаврлардан соң...

Картның иреннәре елмайгандагы кебек хәрәкәт итеп алды:

— Әйе. Казан ханлыгы чорында... Кайчандыр монда, чыннан да, әз генә йортлы чирмеш авылы булган, дип сөйлиләр. Моны үткәндәге чыганаклар да раслый...

— Ә «чыганаклар» — нәрсә ул?

— Китаплар, язулар дигән кебегрәк инде...

— Ә-ә-ә...

— Авылның ул вакыттагы исеме безнең көннәргәчә килеп житмәгән.

Чирмешләрдән соң бу урынга җиде ир балалы тол хатын килеп утырган, дие. Шуннан Толлы киткән инде. Тол хатынлы, җәнәсе... Отыры, исем, авылда татарлар яшәгәнне аңлатыпмы, Татар Толлысына әйләнгән... Тол хатын урынына тол карт булган, диючеләр дә бар. Шуннан киткән инде менә безнең авыл. – Нурмый карт малайга борылды. – Бәлки, шул тол турыдан-туры синең бабаң булгандыр?

Малай шаккаткан күзләрен картка төбәп:

– Чынлапмы? – дип сорады.

– Бик мөмкин, – диде карт аңа.

Малай уйга калды:

– Шул авыл миңа килеп җиткәч бетәрме инде?

– Нишләтәсең... Дөнья шундый. Берни дә мәңгелек түгел.

– Безнең авыл матур бит!

– Матур.

– Урманы да матур!

– Матур.

– Нократ та матур!

– Матур...

– Нигә соң, шулай булгач...

Карт, җавапка бер сүз дә әйтми генә, инеш аркылы сузылган басмага аяк басты:

– Саграк бул, абалана күрмә...

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

# ТАУЛАР БИЕКЛЕГЕНДӘ

АВАР ШАГЫЙРЕ РӘСҮЛ ГАМЗАТОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Заманында Рәсүл Гамзатов Тукайны таулардагы ут сакчысы белән чагыштырган иде. Борынгы заманда Дагстанда шундый вазифа булган. Халык рухын якты учакка тиңләсәк, сүндермәс өчен ана ара-тирә утын өстәргә, җил-давылдан ышыкларга, янгырдан, силдән сакларга кирәк. Рәсүл Гамзатов авар халкының рухын күтәрүче иде, дөресрәге, ул үзе үк аның рухын гәүдәләндерде. Туган иле Дагстанны егерменче гасырда дөньякүләм танытучы да шагыйрь Рәсүл Гамзатов булды дисәк, хакыйкатькә хилафлык китермәбез.

Үз илен чын күңелдән сөйгән кешенең йөрәге киң була. Рәсүл Гамзатовның иҗаты Дагстан белән генә чикләнеп калмады, чөнки зур шагыйрь йөрәгенә бөтен дөнья сыя. Ул татар әдәбиятының да дусты иде. «Татар телен белмәгәнемә үземне ярлы итеп тоям, шул ярлылыгым өчен үз-үземне кызганам» — дигән сүзләрне Рәсүл Гамзатов мөнбәрдән риялык белән әйтмәгәндер.

Советлар Союзында Рәсүл Гамзатовның дәрәҗәсе зур иде. Ирексездән Хәсән Туфанның «Гамзат ич безнең рәсүл» дигән шаян юллары искә төшә. Андрей Вознесенский да ул заманда «Член президиума Верховного Совета товарищ Гамзатов, встаньте!» дип ачыргаланган иде.

Рәсүл Гамзатовның илкүләм танылуына Мәскәүнең ул вакыттагы «милли сәясәте» дә күпмедер роль уйнады, билгеле. Кайбер аз санлы халыкларның әдәбият вәкилләрен учка салып сикертеп алулар булды ул заманнарда. Әмма Рәсүл Гамзатов алар арасында аерылып тора иде. Үткен телле, зирәк, үз дәрәҗәсен һәрвакыт югары тотарга тырышкан тау кешесе. Дөрес, ул да кайчакта иманына каршы барырга мәҗбүр булгандыр — империя шагыйре булу җиңел түгел! — әмма хәзер, вафатыннан соң шактый вакыт үткәч, ачыклана: абынулары да, алданулары да самими булган аның, һәм йөрәктән саркылган кан, шигырьләргә күчеп, бүген Тәңредән кичерү сорый. Шигърият — күңел кичерүе. Шагыйрь безне дә кичерү сорарга һәм кичерергә чакыра.

Рәсүл Гамзатов Дагстанны дөньяга танытса, Дагстан да үз шагыйрен дөньяга күрсәтерлек итеп өскә күтәрде. Сибгат Хәким сокланып та, аз гына көнләшеп тә:

*Рәсүлнең артында таулар,*  
*Биек-биек таулар ич,*  
*Таяныч кирәк язганда,*  
*Кайда безнең таяныч?*

— дип юкка гына язмагандыр.

Безнең республика җитәкчесе Фикрәт Табиев шагыйрьләрне «иждивенецлар» дип сүккән заманнар иде бу. Кимсетелгән, кимсенгән кешедән биек, кыю шигырьләр туа аламы?

Әлбәттә, Рәсүл Гамзатов шигырьләре безгә урыс теле аша таныш. Хәбәрдарлар аның аварча ак шигырьләр генә (ягъни кафиясез) язуын тәкрарлый. Бик ихтимал. Авар телен кемдер тау бөркетләренең гцк-гцк дип кычкыруына охшаткан. Бөркетләрнең үз авазы, үз вәзене...

Әлеге шигырьләр Дагстан шагыйренең киң сулышын татар киңлекләренә күчерү ниятеннән тәрҗемә ителде.

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

## Рәсүл Гамзатов

### Шөлдерле лачын турында җыр

Күк куерды, әйтерсең лә йонлач куйлар
Юл бирмәде бер-берсенә һич кенә.
Утырды тын — газиз кыялардан ерак —
Кызыл лачын ак бияләй өстендә.

Маһир кошчы тотты аны, шөлдер элде,
Алтынланган балдак аңа кидерде.
Канатларын күтәрде ул көтмәгәндә —
Көмеш аваз дөнья буйлап йөгерде.

Ак бияләй гүя тәхет, кунган шуңа,
Ашаталар, әйтерсең ул йорт кошы.
Тик төшендә болытларны кисеп үтә,
Төшкә керә таулардагы очышы.

Кузгалды ул — чең-чең килде көмеш шөлдер.
Кызыл лачын, туган идең яшьнәргә!
— Кичерегез, илгә кайтам хәзер, — диеп
Кычкырды ул ерак карендәшләргә.

Күк күкрәде, аваз килде кыялардан,
Колак салды кызыл лачын тын гына:
— Алтынланган балдак безне буып тормый,
Кызыкмыйбыз көмеш шөлдер чыңына.

Без ирекле, яшен тама канатлардан,
Ямь табабыз җил-давыллар эчендә.
Син ят безгә, кирегә оч, килмә кабат,
Утыр шунда ак бияләй өстендә.

***

Һич тә золым түгел тәүге хата,
Тәүге үпкәләү дә онытыла,
Тәүге курку бары шурләүгә тиң.
Бик тә мөмкин: әгәр берәр көнне
Кыерсыта калса дустың сине —
Гаепләмә, кичер дустыңны син.

Бер тапкыр да юлдан язмаганны,
Күңеле бер тапкыр да азмаганны
Табып булмас җирдә, без эзләмик.
Әгәр дусның томаланса күзе,
Ишетелсә сиңа яман сүзе —
Бу хыянәт түгел, бер хата тик.

Сыңар ялгышымны сүгә–сүгә
Йөз чөергән дуслар! Минем өйгә
Ишек ачык һәрчак. Йә, керегез!
Бергә–бергә күпме еллар үткән,
Һәммәгезне мин кичердем күптән.
Сез дә мине, зинһар, кичерегез.

## Әңгәмә

— Әйт әле син, гомереңне барлап,
Кайсы вакыт иң әйбәте иде?
— Иң бәхетле көннәр истә бар да,
Ул чакларда иркәм мине сөйде.

— Әйт әле син, гомереңне барлап,
Булдымы бер үзәк өзелгәне?
— Иркәм онытты да булдым харап,
Һәм яшәвем миңа сизелмәде.

— Ник яраттың? Мәхәббәтсез генә
Яшәү җайлы, көн итүе җиңел.
— Ул шулайдыр. Тик шунысы менә —
Андый көннәр минем истә түгел.

## Сәгать белән сөйләшү

Тик икәү без өйдә. Сәгать һәм мин.
Сәгать санап ятам аңгы–миңге.
— Нигә йокламыйсың? — дип сорады
Уникене сукты да ул төнге.

— Гөнаһлы бер хатын гаебе бу:
Ул авыр сүз әйтте миңа кичен.
Йөрәгемә тиде дә кинәсе,
Йоклый алмый ятам шуның өчен.

Аваз салды сәгать тын бүлмәдә:
— Борчылма син, шулай булган мәңге.
Теге хатын йоклый инде. Төштә
Күрә булыр синең интекканне.

Тик икәү без өйдә. Сәгать һәм мин.
Сәгать санап ятам аңгы– миңге.
— Нигә йокламыйсың? — дип сорады
Уникене сукты да ул төнге.

— Нахак сүзем белән рәнҗеттем мин
Сөеклемне бер гөнаһсыз килеш.
Шул үкенеч җанны кыйнаганда
Ничек хәзер мин йокларга тиеш?

— Кыйналмасын җаның. Тормыш бит бу —
Ирләрнең еш йокылары кача.
Гафу ителгәнне белмәгәнгә
Таша күңел, булмый һич башкача.

Тик икәү без өйдә. Сәгать һәм мин.
Төн чыгабыз качып яман күздән.
Кеше рәнҗетүдән сакла, тәкъдир,
Һәм арала мине нахак сүздән.

## Шагыйрьне коткарган хатын турында баллада

Көн җилдереп үтте, Гомәр-Хаҗи,
Ял итеп ал; тыңлый алсаң түзеп,
Бер вакыйга сөйләмәкче булам,
Һич әкияти түгел ләкин үзе.

Син, кавказлы, әле кайчан гына
Пиаладан шәраб эчкән якта,
Әҗәл көтеп яткан карт бер шагыйрь
Хастаханәдәге бер ятакта.

Затлы хатирәләр бер-бер артлы
Газапларын бүлеп төшкән искә:
Хәтта чаптар атын яндырганы
Сөйгәненә ашыккан бер кичтә.

Тын чатырга иңгәч, караңгыда
Балкыган йөз, нәкъ тулган ай төсле.
Хәзер нәрсә... көчсез, зәгыйфь карт ул,
Кулында тик гәрәбәдән дисбе.

Бик күп икән хәлен белүчеләр,
Гади халык хөрмәт иткән аны —
Татлы чишмә суын китергәннәр,
Әчкелтем бал, тауда җыелганны.

Кайсысыдыр ерак юлга чыккан,
Ниндидер бер Тибет табибыннан
Тылсымга тиң дару алып кайтып
Әҗәл көткән карт кулына сонган:

— Шуны эч тә кабат яшәрерсең,
Элеккечә дәртле тибәр йөрәк. —
Карт баш тарткан:
— Җыр җырланды, булды,
Вакытында җирдән китү кирәк.

Кабер караңгысы иңгән чакта
Җир йөзенә акрын, бер хатын-кыз
Хастаханә ишегеннән кергән,
Үзе чибәр, көләч, япа-ялгыз.

Әйткән хатын:
— Хәзер карт шагыйрьгә
Тик мин генә итә алам ярдәм!
Төн кунарга калам, теләсәгез
Терелүен аның сез әгәр дә.

Сүрән, серле яктылыкка тиңдәш,
Мәңгелек яшь — ай сылуы кебек,

Өрфиядәй ак күлмәген киеп
Шагыйрь янына ул киткән кереп.

Нишләткәндер аны хатын төнлә,
Салкын канга нинди ут йөгерткән...
Әҗәл көткән шагыйрь таң алдыннан
Хатын белән бергә качып киткән.

Син ышансаң ышан, Гомәр–Хаҗи,
Ышанмасаң, торма теш агартып.
Хәйран калырлык эш... Терелткән бит
Гади хатын әҗәл көткән картны.

Өметләнеп куйдым әле мин дә,
Соңгы сулышымда бер хатын–кыз
Килеп керсен иде кара төндә,
Чибәр,köләч булып, япа–ялгыз.

## Кашлар

Киң аландай маңгаең иркен,
Ә аңардан бераз түбәндә
Ике күл бар, ике Севан күк
Сагышланып миңа төбәлә.

Шушы ике күлнең буенда
Ике төлке ята — чем кара.
Аралары ерак та түгел,
Гомергә тиң әмма ул ара.

Хәйләгә чос та соң үзләре,
Берничек тә булмый алдалап:
Күзгә–башка аучы күренсә,
Үлгән сыман алар тын кала.

Мин гадәти аучы түгел шул,
Төлкеләр дә моны шәп белә.
Мин уйнаган көйне ишеткәч,
Алар кинәт өскә чөелә.

Җәя кебек тартыла алар
Минем канны юри кайнатып.
Ачулансаң әгәр син миңа,
Үтерерләр сыман ук атып.

А, бу серле, назлы ишарә!
Ымсындыргыч... Синең истәме?
Җыерыла алар кайчакта
Якын килмә, диеп, кисәтеп.

Һәркем белә булыр, төлкеләр
Хәйләкәрлек белән данлыклы.
Ләкин болар... бу ике төлке
Юләр иткән күпме халыкны.

Алданасын белсә дә алдан,
Һәркем әсир шушы уенда.
Ике төлке ята — чем–кара,
Ике көләч күлнең буенда.

Мин гадәти аучы түгел шул:
Һәрбер ымын аңлыйм аларның.
Боерсалар — дөнья яуларммын,
Әмер булса — тынсыз авармын.

Ике күлнең саклап сафлыгын,
Сез һәрвакыт уяу, чаялар.
Ләкин нигә дерелдисез соң
Ерактан ук мине абайлап.

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА *тәрҗемәсе*



Татарстан язучыларының XIV съезды президиумы күренеше. 2002 ел, май.



Кырым җиренең киләчәк хуҗалары. Карасубазар.



*Драматург Хәй Вахит һәм композитор Сара Садыйкова (уртада) Арча районы җитәкчеләре белән. 1971 ел.*



*Рәсүл Гамзатов. Казан.90нчы еллар.*



*Дөньякүләм мәшһүр галим Роальд Сәгъдиев «Идел-Пресс» басмаханәсенә кунакка килгән. Сулдан уңга: «Идел-Пресс» басмаханә комплексының генераль директоры Ислам Әхмәтҗанов. Татарстан Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров, академик Роальд Сәгъдиев, Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчесе Ренат Закиров, Казан дәүләт университеты ректоры Мәгъзүм Салахов. 2008 ел.*

# ЯЗМЫШНЫҢ ХИКМӘТЛЕ КУЛЫ

НИЯЗ ДАУТОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Күпчелек укучыларыбызга «ЖЗЛ» аббревиатурасы астында, ягъни «Жизнь замечательных людей» сериясендә нәшер ителүче китаплар яхшы таныш дип беләм. Бу серияне нәшер итү нияте әле СССРга нигез салынган елларда ук мәшһүр язучы Максим Горькийда барлыкка килә. Хәер, бөек шәхесләрнең тормыш сәхифәләрен барлау һәм алар хакында китаплар язу — әдәбият яралганнан бирле киң таралган күренеш.

Һәртөрле геройлар, дәүләт эшлеклеләре, атаклы хәрбиләр, рәссамнар, галимнәр, композиторлар, философлар һәм шагыйрьләр халыкның игътибарын һәрчак тормыш мәшәкатьләреннән югарырак торган хыял-омтылышлары, жете төсләргә бай иҗат дөньясы белән җәлеп иткәннәр. Болардан тыш, күренекле кешеләрнең тормышы, кылган гамәлләре, идея, ачышлары безгә Тарихны тоемларга һәм шушы тоемлау аша бүгенге яссылыгында үз урыныңны билгеләргә дә ярдәм итә. Евтушенко язганча: «Тарих ул — кеше гомерләренең бәйләнеше».

Вакыт-вакыт тормыш театр кебек тоела миңа. Анда чыннан да тамашада катнашучы актёрлар һәм сәхнәдә барган вакыйгаларны күзәтеп утыручы тамашачылар бардыр кебек. Ләкин болай фикерләү үз-үзеңне алдау гына, чөнки асылда без — тамашачы да, актёр да. Берьюлы. Һәм һәрберебезнең тормыш фабуласы сәер дә, мавыктыргыч та уртак бер сюжетны тудыруга хезмәт итә.

Образлы итеп әйткәндә, замандашлар ул — бер урамда яшәп, бер үк һаваны сулаучы кешеләр, алар бер-берсенең тормышына йогынты ясамый кала алмыйлар.

«Ә синең танышларың арасында танылган кешеләр күпме?» дип сорадым мин көннәрдән бер көнне үземнән. Һәм барлап чыктым — чынлап та шактый җыела икән. Кем беләндер очраклы һәм озакка сузылмаган танышлык булса, икенчеләре белән еллар буе аралашып, дусларга ук әйләнгәнбез. Кайсылары үз шәһәрләрендә танылган кешеләр булса, икенче берәүләре — илдә, хәтта дөнья күләмендә дә исеме билгеле шәхесләр. Ләкин бер хакыйкатьне танымый булдыра алмыйм: Маэстро кебек кешене әле очратканым юк иде.

Нияз Курамша улы Даутов... Бу атаклы җырчы һәм педагог, тормыш юлымда очрап, мине Опера театры труппасына чакырды һәм чын мәгънәсендә Остазыма әверелде.

Театрда, бигрәк тә опера өлкәсендә, карьера ясау җиңелләрдән түгел. Читтән караганнарга артык сизелмәсә дә, шактый тынгысыз була сәхнә арты тормышы. Ул азагы юк көрәшкә корылган — роль өчен, сәламәтлек өчен, югарыда торган җитәкчеләр белән конфликт. Ә җитәкчеләр, үзегез беләсез, күп алар.

Маэстрода гаҗәеп бер сәләт бар иде — тирә-юньдәгеләрне рухландыра белү. Аның хуплавын сизәсең дә, үз-үзеңә ышанып җитмәгән чакларда да илһамланасың, авыр хезмәт иҗат шатлыгына әйләнә, ә театрдагы интригалар, эш хакының түбән булуы һәм башка шундый көнкүреш матавыклары вак-төяк кенә булып әверелә. Музыканың, сәнгатьнең илаһи көче күмеп китә барысын да...

Ул бөркегән энергия шулкадәр көчле ки, тирә-юньдәгеләрнең дә шәхесен үзенә күрә бер нур белән өретә, аларга яна яклары белән ачылырга ярдәм итә иде: шулай башлап жырлаучы тенор мәхәббәт каһарманына әверелә, тулы гәүдәле жырчы зифа, нәзакәтле Кармен образына керә, ә исәпсез-хисапсыз жәнҗаллары белән дан тоткан холыксыз примадонна «Мадам Баттерфляй» операсында карусыз, йомшак героиня булып әверелә дә күпне күргән театралларның да күзеннән яшь чыгара...

Маэстроның тормыш сәхифәләрен өйрәнеп, театр һәм ана мәхәббәт белән сугарылган бер гомер хакында роман язарга була. Бәлки, андый роман язылыр да. Ә анарчы дөньяны яхшы якка үзгәртергә теләп яшәгән, янган һәм үз-үзенә беркайчан да хыянәт итмәгән олуг шәхесне әлеге язмабызда искә алыйк.

Нияз Курамшевич Даутов 1913 елда Казанда хәлле гаиләдә дөньяга килә. Аның әтисе ат заводлары һәм сафьян житештерү фабрикасы хужасы була. Нәкъ менә Курамша Даутов һәм аның сәүдәгәр дусларының тырышлыгы нәтижәсендә, 1909 елда Казанда Сәүдә жыены (Купеческое собрание) каршында театр оеша. Хәзер бу бинада Казан яшь тамашачылар театры урнашкан.

Нияз Даутовның хезмәт юлы татар авылларында башлана — мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул авылга укытырга китә. Шушы елларда ук инде аның милли-мәдәни агарту өлкәсендәге эшчәнлеге башлана.

Укытучы булып эшләп алганнан соң, Нияз Даутов Мәскәүгә юл ала, заводка гап-гади эшче булып урнаша. Затлы-зәвыклы мохиттә туып-үссә, тәрбияләнсә дә, ул эшчеләр арасына да бик табигый рәвештә кереп китә. Бу сыйфатын гомере буена саклады Маэстро — эшче хезмәтенә һәм эшчеләргә зур хөрмәт белән карады. Завод та егет алдында бурычлы калмый: Даутов вузга юллама ала. Балыкчылык институты була ул.

Яшь студент көндезләрен тырышып укый, ә кичләрен Мәскәү театрларындагы спектакльләргә йөри. Зур театр, МХАТ, Оперетта театры, Таиров, Мейерхольд, Вахтангов, Станиславский һәм Немирович-Данченко театрлары, концерт заллары — бу аның рухын туендыра торган ижади мохит була студентлык елларында.

Шуна Даутовның Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясенә килеп эләгүе бер дә гажәп түгел. Студияне ул иң яхшы билгеләр белән тәмамлый һәм консерватория студенты булу хокукына ирешә. Нәкъ менә шушы елларда Даутов татар һәм рус музыка сәнгатенең булачак йолдызлары — Фәрит Яруллин, Муса Жәлил, Нәжип Жиһанов, Святослав Рихтер, Мстислав Ростроповичлар белән таныша һәм якыннан аралаша башлый.

Әле студент чагында ук (1941 елда) Даутов Казанга Мәскәүдә узарга тиешле татар сәнгате декадасына әзерлек эшләрен оештырырга кайта. Нәжип Жиһановның «Алтынчәч» операсында Жик-Мәргән партиясен беренче булып башкаручы була ул. Әмма декаданы уздыра алмый калалар, илгә афәт килә — Бөек Ватан сугышы башлана. 1941 елның сентябрендә композитор Фәрит Яруллин фронтка китә.

Ә Даутов 1941 елның ноябрендә Бөтенроссия театр жәмгыяте каршысындагы Фронт опера театры труппасына кабул ителә. Артистлар һәм музыкантлар, биючеләр һәм сүз осталары лагерьдан лагерьга йөреп, сугышчылар алдында концертлар куялар. Еш кына бу концертлардан соң ир-егетләр ут эченә барып кергәннәр, дошман белән күзгә-күз очрашканнар. Даутовның Фронт театрында тоткан беренче зур имтиханы Чайковскийның «Евгений Онегин» операсыннан Ленский партиясе була.

Шулай бервакыт генераль репетиция вакытында Даутовның жырлавын В.И. Немирович-Данченко ишетеп ала. Озак та үтми, яшь артист К.С. Станиславский исемендәге Мәскәү музыкаль театрының солисты булып китә. Монда ул Немирович-Данченко кул астында эшли.

Карьерасы бик уңышлы башлана егетнең — житәкчелек тә үз итә, публика да яратып кабул итә үзен. Даутовның Ленский ролендә төшкән фотопортреты

«Огонёк» журналынын тышлыгын бизи һәм миллионлы тиражлар белән ил буйлап тарала. Язмышның хикмәтле кулы журналның бу санын Свердловск өлкә комитетынын секретаре өстәленә дә кертеп сала. Ә секретарь әфәнде театрга мөкиббән затлардан булып чыга. Һәм 1943 елда, ЦК партия боерыгы буенча, Нияз Даутовка башкаланың затлы сәхнәсеннән аерылып, ерак Уралга — Свердловск шәһәренен опера һәм балет театрын балкытыр өчен китеп барырга туры килә.

Бер карасан, язмышнын бу көтелмәгән борылышы анын карьерасына зыян китерергә тиеш бит инде. Башкала сәхнәсе һәм провинция — аларны чагыштырып буламыни?! Әмма... бу гажәеп шәхес монда да үзен югалтмый, киресенчә, көч жыя, профессиональлеген сынап карый, рухи яктан ныгый.

Башкала рухы! Бу затлы сыйфатны Нияз Даутов беркайчан да югалтмады.

Свердловскида лирик тенор өчен язылган барлык төп партияләрне дә Даутовка тапшыралар. Ул чордагы Свердловск опера һәм балет театры йолдызлар кабыза торган мәдәни учак була. Даутовның кумиры Сергей Лемешев та карьерасын нәкъ менә шушы сәхнәдән башлый. Нияз Даутовка да уңыш шушында килә.

Свердловск киностудиясендә Имре Кальман опереттасы буенча «Сильва» әдәби-музыкаль фильмы төшерелә. Фильмның режиссёры Казанда туган Александр Ивановский булгангамы, безнең героебызның баш очындагы йолдызлар шулай тезелешеп баскангамы, «Сильва»да Эдвин ролен башкарырга Даутовны чакыралар.

Фильмны коточкыч авыр шартларда — бозланып каткан ягылмаган студиядә төшерәләр. Житмәсә, артистлар ярым ач, ә үзләре жиңел, жилбәзәк дворяннар тормышын уйнарга тиешләр.

Илгә Жиңү тантанасын алып килгән 1945 елда экранга чыккан «Сильва»ның уңышы шаккаткыч. Мәһабәт, чибәр Эдвин-Даутовка СССРның күп хатын-кызлары баш жуеп гашыйк була.

...Маэстроның үлеменнән соң күп еллар узгач, миңа Имре Кальманның хатыны Вера белән аралашырга туры килде. Ул миңа иренең — бөек Кальманның фашистлардан азат ителгән Будапештта «Сильва» күрсәтелүе турында ишеткәч, күз яшьләре белән елаганын сөйләде. Кальман Даутовның уенын эталон дип исәпли иде, диде ул.

Сугыштан соң, Даутов илебезнең иң эре театрлары буйлап гастрольләрдә йөри, бу театрлар арасында Мариинка да, Зур театр да була. Бу чорга ул инде миллионннар яратып өлгергән күренекле опера артисты булып житешә.

40 яшендә Нияз Курамшевич үзенең беренче опера спектаклен — «Травиата»ны куя. Бу спектакльдә үзе Альфред партиясен башкара. 50-60 еллар артист тормышындагы иң киеренке дә, ижади яктан иң продуктив та еллар була: ул опера артисты да, жырчы-башкаручы да, режиссёр да...

Казандагы опера театры Ирек мәйданындагы яңа мәһабәт бинага күченгәч, Даутовны Татар дәүләт опера һәм балет театрын житәкләргә чакыралар. 5 ел буе Маэстро Казанда яши һәм ижат итә. Аннан күпмедер вакытка Свердловск опера театрына кайтып эшләп ала да, берничә елдан Чиләбе опера һәм балет театрына баш режиссёр буларак чакырыла. Чиләбедә дә, Свердловскида да, Казанда да ул масштаблы опералар куя, премьералар белән шаулый. Татар композиторлары — Н.Жиһанов, Б.Мөлеков, Х.Вәлиуллин, Р.Гобәйдуллин, Ж.Фәйзи һ.б.ларның опералары һәм музыкаль спектакльләре дә була алар арасында.

1975 елда Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф.Табиев Нияз Даутовны янә М.Жәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына кайтырга чакыра. Мондагы ижади коллективны житәкләү белән беррәттән, Нияз Даутовка татар милли музыка сәнгатенә яңа сулыш өрү, аны тергезеп, жанландырып жибәрү вазыйфасы да йөкләнә. Даутовның беренче куйган операсы Р.Гобәйдуллинның «Жиһангир»ы була.

Гомеренең соңгы 10 елында да Нияз Даутов ижади тынгысызлыгын һәм

активлыгын югалтмый. Рус һәм дөнья классикасыннан тыш, тамашачыга 5 милли опера тәкъдим итә. 5 милли балет куя. Моны әйтүе генә җиңел: 10 ел эчендә театр сәхнәсендә — 10 милли премьера! Болардан кала, ул башкаларның иҗатына карата да бик игътибарлы булуы белән аерылып тора — кирәк урында фикерен белдерә, кирәк икән, тәнкыйтьли, кирәксә, хуплый, ә кирәк чакта — ярдәмгә дә килә.

48 елга сузылган иҗаты дәвамында ул 2 меннән артык спектакльдә катнаша, күпчелегендә төп партияләрне башкара, СССРның төрле шәһәрләрендә 80нән артык операны сәхнәгә куя. Артистның үзе уйнаган опералары да, сәхнәгә куйган әсәрләре дә — зур профессиональлек һәм эстетик зәвык үрнәге.

Нияз Даутовның яшьләргә, аларны барлау һәм үстерүгә ничек игътибарлы булуын да әйтми калдырырга ярамый дип исәплим. Бүгенге көндә Россия һәм дөнья сәхнәләрендә профессиональлек үрнәге күрсәтүче бик күп талантлар үз вакытында Даутовның аталарча җылы мөнәсәбәтен һәм игътибарын тою бәхетенә ирешкән затлар. Аларның зур сәхнәләрдә балкырлык чын осталар булып әверелүендә Маэстроның роле әйтеп бетергесез зур. Даутовның талантлы шәкертләреннән Хәйдәр Бигичев, Зилә Сөнгатуллина, Рафаэль Сәхәбиев, Венера Ганиева, Мөнир Якупов, Руслан Дәминов, Клара Хәйретдинова, Сәет Раинбәков, Айдар Фәйзрахмановларны атап узу гына да җитә.

Бу бөек артистның 100 еллык юбилее аның ватаны — Казанда гына түгел, ә Екатеринбургта, Чиләбедә, Даутовның шәкертләре яшәгән һәм иҗат иткән башка бик күп шәһәрләрдә дә билгеләп үтеләчәк. Димәк, Маэстроның шәхесе һәм иҗаты иксез-чиксез илебезнең барлык почмакларында да диярлек искә алыначак!

**Эдуард ТРЕСКИН,**
*Татарстанның халык артисты.*

# МИНЕМ СӘХНӘ УКЫТУЧЫМ

Ул бик зур җырчы иде. П.И. Чайковскийның «Евгений Онегин»да Ленский партиясе, «Ромео һәм Джульетта»да — Ромео, Вердиның «Риголетто»сында — Герцог партиясе, «Травиатта»да — Альфред, Свердловский киностудиясе төшергән «Сильва»да Эдвин ролен башкарып Бөтенсоюз күләмендә танылды. Нияз Даутовның иҗади тормышы опера сәнгате белән генә түгел, җырлар, романслар башкару белән дә бәйле, аның иң яраткан композиторы П.И.Чайковский була.


*Нияз Даутов һәм Рафаэль Сәхәбиев. Узган гасырның 80нче еллары.*

Бөтен яшәешен опера сәнгате белән бәйләгән әлеге шәхеснең тормыш юлына күз салыйк әле.

Нияз Курамша улы Даутов 1913 елда Казан шәһәрендә дөньяга килгән. 1938 елда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен тәмамлаган. 1939 — 1943 елларда Мәскәү консерваториясендә шөгыльләнгән. 1953 елны Урал консерваториясен бетергән. 1943-1956, 1960-1964 елларда Свердловскида опера һәм балет театрында солист һәм режиссёр, ә 1965-1975 елларда Чиләбе шәһәренең опера һәм балет театрының баш режиссёры булып эшләгән. 1975 елдан 1986 елга кадәр Татар Дәүләт опера һәм балет театрында солист һәм баш

режиссёр булып эшләү белән бергә Казан Дәүләт консерваториясендәге опера жырчылары хәзерләү кафедрасының профессоры һәм аның кафедра житәкчесе булып эшләде. 1957 елда РСФСРның халык артисты, 1958 елда Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты була.

1956-1960 һәм аннан соңгы 1975-1986 елларда Н.К. Даутов М.Жәлил исемендәге Татар Дәүләт академия опера һәм балет театрының баш режиссёры булу белән бергә Казан Дәүләт консерваториясендә дә операга жырчылар әзерләү кафедрасын житәкли, ә 1982 елда — профессор. Татарстанның танылган жырчылары З.Сөнгатуллина, Х.Бигичев, Э.Трескин, М.Якупов, Р.Сәхәбиев, К.Хәйретдинова һ.б. аны зур хөрмәт белән искә алалар. «Ул — безнең укытучыбыз, остазыбыз», - диләр.



*Опера һәм балет театры артистлары белән Тукай клубында очрашу. Алгы рәттә сулдан беренче — Н.Даутов. 1977 ел.*

Нияз Даутов илебезнең күп шәһәрләрендә опералар куйды. Ул куйган опералар арасында Бөтендөнья классикасы әсәрләре «Кармен», «Чио-Чио-Сан», «Богема», «Пиковая дама», «Отелло», «Борис Годунов» һәм шулай ук Ф. Лоуның «Моя прекрасная леди» опереттасы булды. Үзе анда баш рольне башкарды. Аның белән бергә шушы опереттада эшләү бәхете миңа да насыйп булды.

Утыз еллык ижади тормышында ул сиксәнгә якын спектакль куйды. Татар композиторлары язган опералар аның ижатында аерым урын алып тора. Жиһановның «Алтын чәч», Х.Вәлиуллинның «Самат», Р.Гобәйдуллинның «Жиһангир», Б.Мулюковның «Кара йөзләр» һ.б. әнә шундыйлардан.

Без соңгы курсларда, анда укып, бөтенебез бергә театрга эшкә килдек. Минем диплом спектакле «Жиһангир» иде. Н.К.Даутов безнең белән балалар белән эшләгән кебек эшләде. Сәхнәдә үзеңне ничек тотарга, ничек фрак белән йөрергә, тростьны ничек йөртергә өйрәтте. Ул һәр партиянең музыкасын белә иде, шуңа күрә мизансценаларны бик жиңел, безгә жайлы итеп төзеде. Элек режиссёрлар баш рольләрне зур тәжрибәле жырчыларга гына бирәләр иде, шуңа күрә яшь кешеләрне картлар башкара иде. Ә Н.Даутов ышанып, безгә, яшьләргә рольләр тапшырды.

Миңа аның куйган операларында жырларга туры килде. Бәхетемә, Дәүләт имтиханымда Р.Гобәйдуллинның «Жиһангир» операсында Ислам, «Севильский цирюльник»та — Фигаро, «Евгений Онегин»да — Онегин, «Алтынчәч»тә — Хан, «Кара йөзләр»дә — Мулла, Штрауснын «Летучая мышь»та Айзенштайн партияләрен башкардым. Остазыбыз барын күрсәтеп, аңлатып биргәнгә эшләү жиңел булды.

Консерваториядә студентлар аны бик ярaталар, дәресләренә йөрү шатлык иде. Укып бетергәч, аның студентлары театрга килә, ул аларны эшкә ала һәм театрда укыту дәвам итә. Даутов кемгә нәрсә кирәклеген белә, һәм ялгышмый иде. Н.К.Даутовны барыбыз да яраттык, ул безне театрны, операны яратырга өйрәтте. Мәскәү музыкантлары да аны хөрмәт итте. Аның якын дусты энциклопедик белемле, әдәбиятны, музыканы, рәсем сәнгатен яхшы белгән пианист Рихтер иде.

Тышкы кыяфәте, үз-үзен тотышы белән тормышта да ул безнең барыбызга үрнәк булды. Өйдә ул бик тәмле итеп ризыклар әзерли, безне чакырып сыйлый, кызыклы хәлләр турында сөйли иде.

Безгә, яшьләргә Нияз Курамша улы гел ярдәм күрсәтеп торды, гозер белән партия өлкә комитетына да йөри иде. Кемгә фатир, кемгә мактаулы исем, барысына да ул йөрде. Мин отпускада авылга кайтып киткән идем, бервакыт шунда аннан хат килеп төште. «Тизрәк кил, сина фатир турында сөйләштем», дип язган. Мин Казанга кайтып киттем. Мина гына түгел, барыбызны да ул шулай канат астында тота иде. Мәрхүм җырчыбыз Хәйдәр Бигичевны ул коткарып калган иде. Мәскәүдәге бөек пианист Рихтер аркылы сөйләшеп, ана операция ясатты. Гомумән, ул бик ярдәмчел кеше иде. Консерватория тәмамлап килгән яшьләргә кияргә киеме булмаса үз акчасын бирә иде.

Анын тагын бер күркәм эше истә калды. Ул күп еллар буе көндәлек язган, гомумән, ул елларда артистлар көндәлек алып барганнар. Бик кызыклы хат алышу бар иде. Үзенең беренче укытучысы бер апа белән гел хат алышып торган, анда анын эчке хисләре, нәрсә эшләргә җыена, барысы да яхшылап язылган. Ул хатларны, көндәлекләрне безнең җырчы Эдуард Трескин Нияз Даутовнын туган көннәрендә Актерлар йортында укый иде. Музыка астында, бик кызыклы бер спектакль кебек була иде. Хәзер алар барысы да Э.Трескинда саклана.

Нияз Даутовның тагын бер кызыклы ягы турында әйтәсем килә. Спектакль куяр алдыннан ул хор артистларына, солистларга барысын җыеп кереш бер сүз сөйли иде. Бу нинди чорда язылган, халыкта нинди галәтләр булган, художниклар нәрсәләр язганнар, барысына репродукция күрсәтеп, төпләп аңлата иде. Минем башка режиссерлардан андый сүзләр ишеткәнем булмады. Бер кызык хәл истә. Безнең театрда бер яшь режиссер спектакль куйды. Ул «Телефон» — дип атала, анда бер егет сәхнәдә гел бер үзе телефоннан сөйләшә, сәхнәнең икенче ягында кыз кеше, шуларнын сөйләшүе. Спектакльне кабул иткәндә беркемгә дә ошамады. Нишләргә? Премьера шул ук кичне билгеләнгән. Шунда сәхнәгә Нияз Курамшевич керде дә мина әйтә, Рафаэль, мин сина ышанам, менә болай ит, болай ит, кыскасы, үзен теләсә нәрсә эшлә, диде. Мин шулай эшләдем дә, үземә-үзем спектакль куйдым. Спектакльдән сон Камал театры артисткасы Г.Исәнгулова минем янга килеп: «Ай-яй, Сәхәби, шәп спектакль куйгансын», — дип, мактап китте.

Н.К.Даутов 1986 елда, театр каршындагы утыргычта, кулында Ж.Фәйзинең «Башмагым» спектакленен текстын тоткан килеш бакыйлыкка күчте. Даутов талантларны таба, аларга дөрес иҗади юл күрсәтә белә иде. Анын укучылары Россиянен төрле шәһәрләрендә эшлиләр — алар Н.К.Даутовның дәвамчылары.

**Рафаэль СӘХӘБИЕВ,**
*Татарстанның халык артисты*

# Нурихан Фәттах

## ЧЕТЕРЕКЛЕ БУЛДЫ БЕЗНЕҢ ЗАМАН

ИСТӘЛЕКЛӘР

### «Ител суы ака торур»

Кыерсыталар, җәберлиләр дип язуымны да ташламадым, рәсми оешмаларга барып, теләнеп, ялынып та йөрмәдем. Минем өчен бөтен шатлык эш, язу, бары язу гына булды. Халык дошманы итеп мине исемлектән дә сызып ташлый алмадылар, шул ук вакытта күз кырыена да чыгармадылар. Кырык, кырык биш яшькә кадәр мине яшь язучылар, яисә гомумән һ.б.лар рәтеннән санап йөрделәр. Мактау сүзләре бик сирәк эләкте. Җыелышларда призидиумга, йә булмаса съездларга сайлау турында уйлау да юк. Барысы да алдан төзелгән, тиешле оешмаларда расланган исемлек буенча алып барылды. Еш кына Фәттах исемен рәсми отчетларга да кертмәделәр.

Тумыштан көтегрәк телле Әпсәләмов дигән язучы бар иде. Язма теле дә кәтегрәк — ярым русча, ярым татарча. Заманында татарның ин данлыклы, ин «талантлы» язучысы булды. Таланты русча тәрҗемә иткәч кенә беленде. Теге «Сезненчә ничек?»не мактап чыккан Габдрахман Әпсәләмов. Тора-бара монын мина карашы кискен үзгәрде. Күрәсен, рәсми караш тәэсир иткәндер, йә булмаса югарыдан берәр төрле күрсәтмә дә булгандыр. Минем тарихи әсәрләр кирәклеге турындагы, тарих турындагы сүзләрем ничектер моның да колагына чалынып калган. Бервакыт бу «корткычлык эшләре» белән шөгыльләнүче яшьләрне пыр туздырып «Социалистик Татарстан»да мәкалә язып чыкты. «Кайберәүләр чыш-пыш килеп коридорларда «безгә тарихи әсәрләр кирәк, татар әдәбиятында тарихи жанр өстенлек итәргә тиеш», — дигән сүз тараталар», — дигән. Сүзләре төгәл түгел, мәгънәсе шундыйрак.

Алтмышынчы елларда тарих турында коткы сүзләр таратучылар бары бер генә иде. Ул да булса, әлеге дә баягы Н.Фәттах. Әпсәләмовның тузга язмаган сүзләр язып чыгуына минем, билгеле, бик нык ачу да килде, хәтер дә калды. Шулай да Әпсәләмов белән мөнәсәбәтне бозмаска тырыштым. Очрашканда хөрмәт белән ягымлы итеп сөйләшәм. Бервакыт Тукай клубында ниндидер җыелыш алдыннан алгырак рәтләргә таба киттем. Карасам, бер рәттә берүзе Әпсәләмов утыра. Янына барып утырдым. Исәнме-саумы дип сөйләнгәләп утырдык. Безнен янга бүтәннәр дә килә башлады. Кеше күбәеп китте. Шул чакны Әпсәләмов минем яннан читкәрәк күчеп утырды. Мин монын халык алдында минем белән янәшә утырырга теләмәвен сизенеп алдым.

1969 елда «Ител суы ака торур» язылып бетте. Кульязманы «Казан утлары»на илтеп тапшырдым. Укыдылар. Ошаттылар.

Очраган бер кеше бары шул турыда гына сүз ачты. Елмаеп, хуплап сөйләштеләр. Хәтта идарә председателе Ибрай Гази да минем белән ягымлырак сөйләшә

*Дәвамы. Башы 7нче санда*

башлады. Кульязма ин элек проза секциясендә фатиха алды шикелле. Башка әсәрләргә караганда «Ител суы ака торур» бик җиңел китте. Тәнкыйть бөтенләй булмады диярлек. Бары мактадылар да соклану гына белдерделәр. Ерак тарихны чагылдырган роман татарда ят нәрсә. Аннан соң ул вакытта укучы-язучылар чынлыкта Болгар тарихын аннан-моннан ишетеп кенә беләләр. Шуңа күрә романдагы һәр нәрсәне алар чын итеп күз алдына китерәләр. Тәнкыйть итәрләр иде — теш үтми.

Шулай да тәнкыйтьчеләр дә табылды. Иң беренче тәнкыйтьче — Рафаэль Мостафин. Татарча тәнкыйтьләргә батырчылык итмәде, чөнки татар язучылары, журналистлары миңа чын күңелдән теләктәшлек белдерделәр. Р.Мостафин «Волга» журналында язган, аннан соң Мәскәү радиосыннан сөйләгән, диделәр. Үзем укымадым да, тыңламадым да. Имеш, Н.Фәттах ханнар-бәкләр тормышын тасвирлау белән мавыга, хезмәт халкын күрсәтми, фәлән-төгән.

Икенче тәнкыйтьче Атилла Расих булды. Ул да шундыйрак сүзләр язып чыкты. Монысы инде роман басылып берничә ел үткәч булды.

Кыскасы, барыбер «тамыздылар». Әгәр утыз сигезенче, хәтта кырык сигезенче — илленче еллар булса, «ханнар, бәкләр тормышы белән мавыга» дигән сүз ул бик тәэсирле булыр иде. «Идегәй» дастанын бастырып чыгарган, «Түләк батыр» пьесасы язган Нәкый Исәнбәтне халык дошманы дип игълан иттеләр, сөргенгә сөрделәр, озак еллар буена түбәләп йөрттеләр. 1944 елда татар язучыларының ханнар, бәкләр тормышы белән мавыгуының зарарлы булуы турында КПСС Үзәк комитетының махсус карары чыкты.

«Ител суы ака торур»га каршы тәнкыйть бик оста юнәлдерелгән иде. Тик шулай да алар бераз гына соңга калдылар. Брежнев заманы булса да, 1944 елгы карар инде онытылган, һичьюгы аның тәэсире көчсезләнгән иде. Элегрәк тә мин, иң кыен чакларымда да, күпчелек интеллигенциянең, күпчелек укучының сүзсез генә яклавын, миңа теләктәшлек белдерүен белеп яшәдем. Шул миңа көч бирде дә. Күпчелеккә, халыкка таяну, аларга ышану бу юлы тагын да көчлерәк булды. Хәзер инде мине андый тамызулар гына куркытырлык түгел иде.

Шулай да, бу юлы да мин иртәрәк тынычланганмын. «Ител суы ака торур»дан соң Н.Фәттахны күрә башласалар да, аңа карата рәсми караш барыбер үзгәрмәде. Эндәшмәү, танымау, вак-төяк нәрсәдә читкә тибәргә тырышу дәвам итте. 1977 елны «Сызгыра торган уклар» дип аталган тарихи романның беренче китабын тәмамладым. Монысы «Ител суы ака торур» кебек шома гына китеп бармады. «Казан утлары»нда басыла дигәч кире кактылар. Язылып беткәннән соңында дүрт ел буе роман басылмыйча кагылып-сугылып йөрде. Бары тик Язучылар союзы идарәсенең утырышында махсус рәвештә тикшерелгәч кенә «Сызгыра торган уклар», йомшак кына итеп әйткәндә, бюрократия тоткыныннан ычкынып китте.

Иң ахырда бер-ике кеше турында үз фикеремне әйтеп китәсем килә. Язучылар арасына Р.Мостафин Хрущев заманында, алтмышынчы елларда килеп кушылды. Татарча рәтләп белми. Русча яза, русча сөйләшә. Шулай да әкренләп сөйләшергә өйрәнде бу. Моны бик тиз арада югары үрләттеләр. «Казан утлары» журналы редакторы итеп куйдылар. «Артта калган юллар»ны Р.Мостафин бастырды. Ул елларда журнал өчен Рафаэль күп кенә эш башкарды. «Совет Әдәбияты» «Казан Утлары» дип атала башлады. Әкренләп тираж артты. Баштарак ул безгә кыю, прогрессив иптәш булып тоелды.

Әдәбиятта әле ул беркем белән бәйле түгел иде, шуңлыктан һәркемгә бер үк күз белән карый сыман иде. Ләкин күп тә үтмәде, политикада, әдәбиятка, интеллигенциягә карата кире чигенү башланды. Боргычлау, кысу, җәберләү башланды. Шул вакытта Р.Мостафинның да койрыгына бастылар. Соңыннан ишеттем: «Өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин, ахрысы, моңа өстәл сугып җикеренгән, «Син анда Нурихан Фәттахлар сүзенә колак саласың», дигән имеш. Журнал редакциясендәге һәрбер сөйләшүне аңа, имеш, җиткереп кенә торганнар.

Ниндидер зур бер җыелышта Рафаэль шундыйрак фикер әйткән: революциягә

кадәр татарда фәлән газета-журнал чыгарылган, китапларның тиражы фәләнчә булган, бүгенге көндә шулай гына дигән, элеккене мактаган. Революциягә кадәргене[1].

Татар культурасын, татар тарихын бик үк тирән белмәгәнгә күрә, Р.Мостафин кайда нәрсә турында сөйләргә ярагалнлыгын, кайда ярамаганлыгын чамалап житкермәгән, күрәсең. Белсә дә, белмәсә дә әле ул үз культурасы өчен тырыша. Беренче секретарь Табиев, имеш, гадәтенчә, халык алдында моңа кусәк белән төндырган кебек иткән. Шуннан соң алып аттылар Рафаэльне редакторлыктан.

## Марксизим–ленинизм

1955 елда татар әдәбиятында көтмәгәндә бер шагыйрь барлыкка килде. Безнең өчен ул күктән төшкән кебек булды. Кайдадыр читтә, Башкортстанның Калтасы районында Шәрип дигән бәләкәй генә авылда Гамил Афзал дигән шагыйрь яшәп ята икән. Монарчы без шагыйрьләр бары Казанда гына була дип йөри идек. Баксаң, урман арасында адашып калган бер авылда да шигырь язу белән шөгыльләнә торган кеше яши ала икән! Гамил Афзалның иң беренче шигырьләре «Совет Әдәбияты» журналында Сибгат Хәким язган сүз башы белән басылып чыкты. Шигырьләр шәп. Монарчы безнең мондый шук, шаян юмористик шигырьләр укыганыбыз юк иде. Гамил Афзал шундук күзгә чалынды, телгә керде. Шундук өметле яшьләр рәтеннән йөри башлады.

Илле алтыдамы, илле жиделәме, көтмәгәндә минем исемгә Гамил Афзалдан хат килеп төште. Хатында бу үзе турында язган, үзен борчыган нәрсәләрен тезеп киткән. Шагыйрь кешене, әдәбият кешесен нәрсә борчырга мөмкин? Иң беренче чиратта милли мәсьәлә, әдәбият мәсьәләсе. Гамил Афзал да шундыйрак сүзләр язган. Кая бара безнең милләт, нигә безгә юл бирмиләр, киләчәктә нишләр? Әдәбият нигә үсми?

Жиде класс белемле иптәш нәкъ безнең кебек фикер йөртә. Ул вакытта безнең борын югары. Безне, ниһаять, танылылар. Без — язучы! Ләкин танылган язучы булсаң да, тик яту килешми. Дөньяны, политиканы ныграк аңлау өчен марксизм-ленинизм классикларын өйрәнергә кирәк. Университетта ишеткән — бер нәрсә, барысын да үзең укып карарга кирәк. Миңа шундыйрак уй килде. Нәкъ шул елларда Ленинның 35 томлык әсәрләренә, Маркс-Энгельс әсәрләренә язылдым. Берничә томы килде дә инде. Көненә 2-3 сәгать укыйм. Мин Гамил Афзалга озын итеп, акыллы итеп жавап яздым. Милли мәсьәләне, әдәбият мәсьәләләрен шул замандагы рәсми карашларга яраклаштырыбрак аңлаттым. Ахырда киңәш тә бирдем: дөньяны дөрес аңлау өчен Марксизм-ленинизм классикларын укы, бигрәк тә Марксны, Энгельсны, дидем. Ленинны әйтмәдем, ахрысы. Ул чакта әле мин үзем бары Маркс-Энгельс әсәрләрен генә укыган идем.

1957 елда май аенда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы булырга тиеш. Ул декада сугышка кадәр үк булырга тиеш булган да, сугыш аркасында тоткарланып калган. Менә хәзер, сугыш беткәннән соң дистә ел үткәч, татарга да Декада үткәрмәкче булдылар. Бу ун елдан артык вакытта инде барлык союздаш республикаларның декадалары булды. Автономия булгач, безгә генә юк. Үзара сөйләшкәндә, жыелышларда шул турыда әледән-әле сүз чыга: «Безне генә кысалар, безне генә күрмәмешкә салыналар, сугышта әнә безнең күпме кешебез үлде, Советлар Союзы геройларының саны буенча татарлар өченчеме, дүртенчеме урында. Безнең Муса Жәлил үзе генә дә ни тора!

Ул елларда шундыйрак сүзләр сөйләнелә иде. Менә безгә дә Декада ясарга югарыдан рөхсәт булган. Күпмедер акча да бирелгән. Оештыру-әзерлек комиссиясе төзелгән. Көн аралаш диярлек идарә утырышы була. Декадага кемнәрне алып барырга, баргач нәрсә сөйләргә, кайда сөйләргә, кемнәр белән очрашырга, фәлән-төгән. Яшь прозаиклардан күренекле кеше берничә генә: Рафаил Төхфәтуллин,

[1] 1968 елны Татарстан язучыларының VII съездында Р.Мостафин акыллы һәм бик кыю чыгыш ясады. Ред.

Мәхмүт Хәсәнов, Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах. Өлкәннәрнең яза торган, активрак һәм начальниграк булганнары, әлбәттә, барысы да барачак. Яшьләрнең барысы да барырмы-юкмы. Баштарак «сине дә исемлеккә керттек» дигән сүз ишетелеп калган иде. Ләкин соныннан беленде: Нурихан Фәттахны исемлеккә кертүгә Батыев каршы килгән. Батыев — КПСС өлкә комитетының идеология секретаре.

Мине, шулай итеп, алып бармадылар Мәскәүгә Декадага. Мине юл буена тузанга «төртеп ектылар» да, үзләре китеп бардылар шау-гөр килеп, гармуннар уйнап, кыңгыраулар чыңлатып. Бик нык хәтер калды. Башыма суккан кебек булды, аңлый алмадым, аңларга теләмәдем. Ничек алай була соң бу? Роман кадәр роман яз да, әле генә күкләргә чөеп мактасыннар да, кинәт кенә сине бөтенләй күрмәмешкә салынсыннар имеш?

1956 елның көзендә, торыр урын булмау сәбәпле, миңа Язучылар союзының «Аккош күле» дигән җирдәге дачасында торып торырга рөхсәт иткәннәр иде. Кышны мин апа белән, инәкәй белән дачада кышладым. Яз җиту белән дачага чын хуҗалар килә башлый. Мине әлеге дачадан куучы юк. Шунда торып ятабыз. 1957 елның июнь башлары иде, ахрысы, безнекеләр данга күмелеп, тагын да ныграк шау-гөр килеп Мәскәүдән кайтып төшteләр. Газеталарда гел шул турыда язалар. Җыелышлар ясыйлар. Мин, берни күрмәскә-ишетмәскә тырышып, үз эчемә бикләнеп, урман эчендә яшәп ятам. Декадага барып кайткан язучылар белән аралашмаска, күрешмәскә, сөйләшмәскә тырышам.

Шулай бер көнне иртән якындагы күлгә су керергә төшеп бара идем, дача капкасы алдына зур кара машина килеп туктады. Машинадан Ислам Беляев килеп чыкты. Аны бераз белә идем. Озын буйлы чибәр егет. Миңа таба килә бу. Очраштык. Ни әйтер икән дип туктап калдым.

«Сине Батыев чакыра. Машина җибәрде», — ди. Батыев... мине алырга машина җибәргән?! Ник? Нәрсә өчен? Берәү булса, коелып төшәр иде. Бүтән вакыт булса, бәлки, мин дә каушап калыр идем.

Һәркемгә кара машина җибәрмиләр. Җибәргәндә дә тиккә генә җибәрмиләр. Йә утыртып куярга, йә... кем белә аны. Ул көнне мин коелып төшәр дәрәҗәдә түгел идем. Мин инде күптән үземне сугышка ташланырга әзер торган әтәч кебек хис итә идем. Тик миңа ташланырга сәбәп кенә чыкмый иде. «Батыев» сүзен ишеткәч, бөтен усаллык, бөтен хурлану һәм кирелек бер йодрыкка томарланды. Шул Батыев тибеп төшерде ләбаса инде мине дан-шөһрәт арбасыннан! «Миңа Батыев кирәкми. Кирәк булса, үзе килсен», — дидем Ислам Биляевка усал итеп.

Шулай дидем дә, артыма борылып та карамыйча күлгә таба төшеп киттем. Әз генә дә курыкмадым да, үкенмәдем дә. Барыбер үчне алдым. Шулай да соныннан берни булмады. Тиешле җиргә чакыртып та тормадылар, җыелышларда-мазарда тәнкыйтьләп тә тормадылар. Юк, алай ук түгел. Өлкә комитеты секретаре Рәхмәтуллин кайдадыр әйткән: яшь язучылар масаялар, Н.Фәттах секретарь янына килүгә караганда су коенуны артыграк күрә, дигән. Шушы хәл турында кайберәүләр имеш-мимеш кушып, төрлечә мәзәк сөйләп йөрделәр.

Күпмедер вакыттан соң ишетелде (Шәйхи Маннур әйтте, ахрысы), Батыев ул чакта, имеш, миңа квартир бирү мәсьәләсе турында сөйләшмәкче булган. Ни дәрәҗәдә дөрес булгандыр, әйтә алмыйм.

Шул ук илле җиденче елныны, илле сигезенчедәме бер төркем яшьләрне — язучыларны, галимнәрне Батыев янына чакырдылар. Элек еш кына шулай олы йортка чакыртып алалар, төрле темага әңгәмә үткәрәләр иде. Ул «әңгәмә» гадәттәге әңгәмә булмый. Батыев, яисә башка берәү сөйли, башкалар тыңлап утыра. Алар гадәти сүз сөйләшмиләр — бары акыллы сүз генә сөйлиләр, без белмәгән, без аңламаган сүзне сөйлиләр. Болай гына әйткәндә, акыл саталар. Тәнкыйтьлиләр, кычкыралар, кызып китәләр. Кыскасы, эшкәртәләр. Бар курыкканнары — милләтчелек. Теге-бу эшне, теге-бу кешенең фәлән җирдәге сүзен, чыгышын тикшерәләр, туры юлга утырталар.

Әлеге очрашуда да Батыев безне бик озак кыздырды. Почмакта торган сейфын ачты да, шуннан бер төргәк кәгазьләр чыгарды...

«Без сезнең һәр адымыгызны белеп торабыз. Сез язган хатлар менә монда саклана!» — дип кычкырды.

Мина аны элегрәк тә әйткәннәре бар иде. Хәзер Батыев үз авызы белән әйтте. Безнен Гамил Афзал белән язышкан хатны тотканнар, шуннан гаеп тапканнар. Шунын аркасында мине дә, Гамил Афзалны да Декадага алып бармаганнар икән. Хатның копиясе калмаган. Шулай да мин аны яңадан хәрефенә кадәр искә төшердем. Ләкин шул кадәр зурдан кубып гаеп эзләрлек берни тапмадым.

Күрәсең, Марксизм-Ленинизм әсәрләрен укырга өндәвем ошамагандыр дигән фикергә килдем. Мондый фикергә мин үзем дә ышанмадым, ышанмастай нәрсә дә дөрес булып тоелырга мөмкин икән. Аннан соң, шунысы да гаҗәп, бик гаҗәп тоелды: минем аерым кешегә язган хатны тотып алырга, ачып укырга, җитмәсә, шул нигездә гаеп ташларга ни хаклары бар аларның? Чынлап та, ни хаклары бар?!

## Университет. Татар бүлеге

Каранглы, күңелсез бер көн истә калган. Эч пошканнан дусларны, танышларны очратырмын дип университет янына барып чыктым. Шунда көтмәгәндә Ибраһим Нуруллин очрады. Университетта Ибраһим бездән бер курс алдарак укыды. Сугышта булган, аксак — сугыш инвалиды. Студент елларында ук яза башлады, хикәяләре басылды. Бигрәк тә тәнкыйть мәкаләләре белән дан казанды. Заманында ул иң өметле кадрларның берсе саналды. Аспирантурага калды, кандидатлык яклады. Без ана, анын курсташларына хөрмәт белән карадык. Әле дә ул миннән өлкәнрәк кенә түгел, белемлерәк тә, акыллырак та тоела. Ләкин, әйтергә кирәк, Ибраһим Нуррулин белән без әллә ни якынаймадык. Шул читтәнрәк кенә кызыгып, хөрмәт итеп йөргәнбездер. Соңга таба, һәркем үз юлы белән киткәч, юллар, язмышлар шактый ерагайды.

Караңгы, күңелсез көндә очрашкач, Ибраһим әйтә; безнең татар бүлеген ябарга дип Мәскәүдән күрсәтмә килгән, ди. Ул елларда, ул көннәрдә ябарга, чикләргә, кысарга дигән сүзләр-карарлар турында әледән-әле ишетелгәләп тора иде. Әлерәк кенә унынчы классларда татар теленнән, татар әдәбиятыннан чыгарылыш имтиханнарын бетерергә дигән карар килгән икән дигән сүзләр ишетелгән иде. Без мондый карарнын дөрес түгеллеген бик яхшы аңлыйбыз, күңелгә шундук: бу берәр төрле ялгыштыр дигән уй килә, шундук әлеге ялгышны төзәтү, төзәттерү теләге туа. Шулай да ул көннәрдә мин уку-укытудан бигрәк үз кайгым белән күбрәк булаштым. Үз кайгың исә баштан ашкан. Һәрвакыт шулай. Берсе онытылуга икенчесе калкып чыга. Иң кирәге — рәтле торыр урын юк. Кеше кебек, кешечә яшәр өчен җылы, яхшы бүлмә юк. Кием-салым, ашау-эчү.

Университетның татар бүлеген ябу турындагы хәбәр шундук барлык борчуларны онытырга мәҗбүр итте. Шәхси кайгылар кайгы булмаган, менә ул нинди икән чын кайгы! Университет. Татар бүлеге. 1917 елдан соң берничә ел дәвамында университетта күп кенә фәннәр татарча укытыла башлаган. Аерым татар теле-әдәбияты бүлеге булган. Утызынчы елларда, ахрысы, татар телен сөргәннәр университеттан. 1944 елда махсус карар белән тарих-филология факультетында яңадан татар теле бүлеге ачылган. Мин укырга кырык алтынчы елны кердем. Безгә кадәр ике генә курс укыды. Шуннан бирле алты-җиде чыгарылыш булды. Фәндә, әдәбиятта, журналларда, кая карама, безнекеләр эшли. Язучылар, галимнәр, редакторлар. Татар культурасын үстерүдә университетның роле күз алдында. Ничек итеп татар бүлеген япмак кирәк? Аны япкач, без нишләрбез? Бит безнең бар карап торганыбыз, бөтен өметебез шул университетның татар бүлеге.

Күңелгә шундыйрак уйлар килде. Аннан соң шундый уй да килде. Берәр төрле хатадыр бу. Ялгыштыр. Иң югарыдагы кешеләр белеп-аңлап

житкермәгәннәрдер, хәтта берәр дошман кешенен корткычлыгы түгел микән әле? Бу бит ленинчыл милли политиканы бозу була. Бу бит безне кысу, җәберләү, хурлау була.

Мәскәүгә, Хрущев, Булганин, Ворошилов исеменә хат язарга кирәк, дидем мин шундук катгый карарга килеп. Хат язуны үз өстемә алдым. Ибраһим Нуруллин каршы килмәде. Хәзер уйланып, икеләнеп тора торган чак түгел. Ятып калганчы атып калырга кирәк.

Яздым мин хатны. Бер үк эчтәлектә өч хат язылды. Берсе — Хрущевка, берсе — Булганинга, берсе — Ворошиловка. Икенчеме, өченчеме көнне әзер хатны алып университетка киттем, Фәннәр академиясе филиалына, редакцияләргә кердем, дуслар-танышлар белән сөйләштем, хатны укыттым, шулай-шулай дидем, кул куеп Мәскәүгә җибәрергә кирәк, дидем. Ләкин кайберәүләр әйтте, хатны башта җыйнаулашып укырга, кайбер сүзләрен төзәтергә кирәк, диде. Бер көнне Ләлә Зарипова дигән иптәшнең квартирасында җыелдык та, сөйләшеп алдык, фәлән җирен төзәтергә, фәлән җирен шулай язарга, диделәр, мин риза булдым. Хатны яңадан күчереп машинкада баскач, яңадан иптәшләрне күреп, кул куйдырып йөрдем. Барлыгы егерме алты кеше булды. Барысы да татарның яшь интеллигентлары — галимнәр, язучылар, журналистлар...

Безгә, билгеле, бернинди җавап-мазар килмәде. Вакыт уза торды. Татар бүлеген ябу турында башка сүз булмады, ахрысы. Күрәсең, безнең хат тәэсир итте. Шушы вакыйгадан соң күп тә үтмәде, мин тагын бер эш башлап җибәрдем. Күптән инде безнең арада шундый сүз йөри иде: Опера театрына — Муса Җәлил исеме, консерваториягә Салих Сәйдәшев исеме бирергә кирәк. Бу хакта да мин Мәскәүгә, югары оешмаларга хат яздым. Төрле җиргә кереп, күренеклерәк кешеләр белән сөйләшеп, хатка кул куйдырып йөрдем. Өч йөздән артык имза җыелды. Бу хатларны да үз исемемнән, үз адресымны күрсәтеп җибәрдем. Күпмедер вакыттан соң Опера театрына чыннан да Муса Җәлил исеме бирелде, ләкин консерватория әле дә булса исемсез.

Теге вакытта Батыев безне нәкъ менә шушы хатлар буенча чакырткан да иде. Без яшьләр барлыгы егерме алты кеше. Сонынннан безне «26 Баку комиссары» дип атап йөргәннәр. «Ярый әле мин өйдә юк идем, бәхетегез!» — дип кычкырды Батыев. Менә шундагы «әңгәмә»дә сейфыннан бер төргәк кәгазь алып кычкырды да инде ул безгә.

Сиксәненче елларда, әлеге вакыйгалардан соң бик күп вакыт үткәч, мин яңа өйгә үземнең иң якын дип уйлаган берничә кешене кунакка чакырдым. Төп сәбәбе аның Сибгать абыйны чакыру иде. Без аның юбилейларында катнашып, аның ашын ашадык. Минем юбилей әллә була, әллә юк. Булганда да Сибгать абый әллә була, әллә юк. Мөршидә апа белән икесен чакырган идек. Сибгать абый килде, Мөршидә апа чирле диделәр. Яшьтәшләрдән Гарифны, Аязны, хатыннары белән, якташым Нил Юзиевны чакырдык. Тагын Тавил Хаҗиәхмәтов, Вахит Юныс та бар иде шикелле. Кеше күп түгел, 12-14ләп кеше булгандыр. Кунакта гадәттә хуҗаны мактыйлар. Мина, Руфинага карата да мактау сүзләре әйттеләр. Шунда Нил Юзиев болайрак сөйләде. Минем беренче шигырьне Нурихан укып карады, диде. Язарга, әдәбиятны ташламаска да ул киңәш итте, диде. Аннан соң мин аны Казан университетының татар бүлегенә килергә «котырткан-мын» икән. Бу әле Яңавылда очрашкач булган. Нил Ямадыдан Яңавылга ниндидер олимпиадага килгән булган. Шунда сәхнәгә чыгып, үзенең шигырьләрен укыган булган. Мин, имеш, сәхнә артына чыгып, аны күргәнмен дә, аның кулын кысып, коткы сүзләре сөйләгәнмен. Күрәсең, студент чак булгандыр, Казаннан кайткан чак булгандыр.

Мин инде мондый детальләрне бөтенләй онытып бетергән идем. Ләкин әлеге сүзендә Нил икенче бер нәрсәне дә искә төшерде. Университетның татар бүлеген ябарга дигәч, Нурихан хат язып, кул куйдырып йөрде, татар бүлегенең исән калуы турыдан-туры Нурихановның шул эшенә бәйле, диде.

Монысын мин, әлбәттә, онытмаган идем. Мин аны еш кына искә төшерәм

— бүгенге яшьләрнең күп нәрсәне белмәвенә эчем пошкан чаклар да була иде.

Шул чакны Сибгать абый чак-чак кына ризасызлык белән, шулай да тыелырга мәҗбүр булып, Нилгә каршы төште. «Юк, Язучылар союзы исеменнән Фадеевка без хат яздык!» — диде. Табын янындагылар әдәп саклап тынып калдылар. Татар бүлеге турында башка сүз булмады.

Димәк, ул вакытта без генә борчылмаганбыз милли культураның язмышы турында. Бу мәсьәләдә беренчелек, икенчелек турында сүз булырга мөмкин дә түгел. Иң мөһиме шул — университетта татар бүлеген саклап кала алдык. Тик шулай да бу — бүлекне саклап калу гына, башка бик күп нәрсәне саклап калу була алмады. Милләткә, телгә, культурага басым, хәтта турыдан-туры һөҗүм елдан-ел көчәя барды. Монда инде күп нәрсәгә каршы тору безнең көчтән килерлек түгел иде.

## Хрущев заманы

Хрущев заманы илгә күп төрле яңалык алып килде. Иң зур яңалык шул булды — Аллага табынган кебек Сталинга табынып яшәгән халыкның күзе ачылды, Сталинны, шәхес культын фаш итү безгә аяз көнне яшен сукканнан да көчлерәк тәэсир итте.

Без моңа чиксез куандык, хупладык, теләктәшлек белдердек. Болай булгач, зарыгып көткән азатлык, бәхет чоры килде дигән сүз. Сталинны фаш итүдән соң күп тә үтмәде, элек исемнәрен дә телгә алырга ярамаган Галимҗан Ибраһимовлар, Кәрим Тинчуриннар, Шамил Усмановлар һ.б. акланды. Сөргеннән Хәсән Туфан кайтты — әдәбият, культура, милләт өендә дә әзме-күпме ирек җиле исә башлады.

Рус матбугатында кыю-кыю фикерле мәкаләләр басылды. Чит илләр белән аралашу башланды. Шул чакны без дөньяда Һиндстан, Кытай барлыгын белдек, аннан соң әкренләп Америкага да чират җитте. Ел саен гына түгел, ай саен диярлек Хрущев белән Булганин яисә Хрущев үзе генә чит илләргә сәяхәткә чыгып китте. Аннан алар төрле яңалыкларга өйрәнеп кайттылар. Агач баганалар урынына бетон баганалар, бетон коймалар барлыкка килде, ашханәләрдә ашъяулыксыз металл-пластмасс өстәлләр барлыкка килде. Официанткалар юкка чыкты — чит илдәге кебек, кешеләр ашны аш салып торучылардан үзләре ала торган булдылар. Иң күзгә күренгән яңалык шул булды. Аннан соң кукуруза, дуңгыз асрау... Кукуруза басу патшасына гына түгел, политика патшасына әверелде. Кукурузага тел тидерергә батырчылык иткән кешеләрне эшеннән алдылар, дошман тамгасы суктылар. Кукурузаны безнең якта да күпләп чәчә башладылар. Читтән орлык кайтарылды, яңа төр машиналар кайтарылды, игенчеләр көн-төн дигәндәй кукуруза игү серләрен өйрәнделәр. Ләкин безнең якта ул рәтләп үсә алмады. Бер җирдә күкрәп үссә, икенче җирдә тишелеп чыгудан ары китә алмады.

Аннан соң татар авылларында дуңгыз асрау башланды. Көчләп, мәҗбүр итеп асраттылар. Меңәр еллар буена татар дуңгызга җирәнеп караган, аны ишегалдына түгел, авылына да кертмәгән. Безнең Янтыкка кайчагында ерактагы урыс авылыннан адашып дуңгызлар килеп чыга торган булган. Дуңгыз күренү белән, бөтен авыл таяк, күсәк күтәреп «дошман»га каршы ташланган. Татар гомергә мал асраган. Ат, сыер, сарык. Мәҗбүр иткәч, нишләсен, дуңгыз асрый башладылар. Татар авылларында беркайчан булмаган ис, сасы ис килә башлады. Дуңгыз белән Хрущев җинел генә ит мәсьәләсен хәл итмәкче булды. Дуңгыз, имеш, тиз үрчи, итне күп бирә. Хрущевның кайбер сүзләре истә калган. Дуңгыз елына утызлап бала таба икән. Сыер бер генә мәртәбә бозаулый. Дуңгыз файдалырак. «Не красива изба углами, а красива пирогами». Ягъни кешегә иң кирәге тамак туйдыру. Анысы шулай. Иң элек тамак тук булырга тиеш, әлбәттә.

Кукурузаны ничек итеп үстерергә дә, дуңгыз карарга да Хрущев үзе өйрәтте. Хәтта күкәйгә утырган тавыкның ничә көн утыруы турында да фәнни мәгълүмат бирде. Көн саен газеталарда Хрущев доклады, Хрущев речь, Хрущев мәкаләсе, интервьюсы

басылды. Газеталарның беренче битендә такыр башлы, кыска буйлы, зур корсаклы бер иптәш елмаеп торды. Радиолар көн-төн Хрущев сүзләрен тапшырдылар.

Витриналардан, театр афишалары ябыштырыла торган такталардан, стеналардан, коймалардан — һәркайдан Никита Сергеевич кыяфәте карап торды. Сталин культы тиз арада Хрущев культы белән алышынды.

Хрущев 1980 елга СССРда коммунистик җәмгыять төзү планын игълан итте. Бу алтмышынчы елларда булды. Егерме ел эчендә, ягъни. Һәркайда русча язылган «Нынешнее поколение людей в 1980 году будут жить при коммунизме» дигән лозунглар күзгә бәрелеп торды. Урамнарда, бетон баганаларга беркетелгән фанер такталарда 1980 елда җан башына бөтен илдә күпме ит, күпме сөт, металл, күмер һ.б. житештереләчәген күрсәткән саннар, диаграммалар балкып торды. Аннан соң һәркайда «Догоним и перегоним Америку по производству мяса, молока» һәм башка бихисап һәртөрле лозунглар, өндәүләр, акыллы кинәшләр, күпкә-озакка китсә, ачуны китерә башлый. Аны күрәсе килми, укыйсы килми. Коммунизм сүзенә нәфрәт миндә Хрущев заманында туды. Күңел кайту һәм нәфрәт шактый күп булды, чөнки кибетләрдә азык-төлек беткәннән бетә барды, янадан ачлык башланды.

Бу елларда кукурузадан тыш борчакка да игътибар артты. Колхозлар, совхозлар элеккедән дә күбрәк борчак чәчә башладылар. Барысы да өстән, югарыдан кушкан өчен. Элек бездә әз-әзләп төрлесеннән чәчәләр иде. Элек, мәсәлән, шепкән, житен, киндер кебек майлы культуралар, арпа, бодай, карабодай кебек бик борынгы ашлыклар игелә иде. Төп ашлык бездә арыш булды, ләкин бодаен, солысын да онытмыйлар иде. Хрущев заманыннан башлап басуда ике-өч төрле ашлык калды: бодай, борчак, кукуруз. Арыш бик кимеде, карабодай, житен, киндер шепкәнне бөтенләй оныттылар. Тары юкка чыкты.

Житмеш ничәнчедер елны авылга кайткач, таныш колхоз председателен очраттым басуда. Миннән күпкә яшьрәк, Вәрәш кешесе. Үзләре ягыннан кайтып килә. Сөйләшеп киттек. Менә, урыс ягына бардым әле — анда карабодай чәчәләр икән, шуны карап өйрәнеп кайтам, ди. «Урыс ягы» — Пермь өлкәсе. Исен китәр, Янтыкта, имеш, карабодай игә белмиләр! Онытканнар! Әле кайчан гына безнен басулар карабодай чәчкә атканда ап-ак булып утыра иде! Карабодай чәчкә атканда бөтен дөнья гүләп тора, бөтен жирдә бал исе килә. Умартачылар умарталарын карабодай жиренә якынрак күчерәләр. Карабодайның яхшы яклары да, начар яклары да минем канга сенеп калган. Начар ягы булса да, сугыш елларында безне ач үлемнән карабодай кибәге дә коткарды.

Хәер, без инде бернәрсәгә дә исебез китмәскә өйрәндек. Өйрәттеләр. Чәчүлек жир кирәк дип, культуралы көтүлекләр кирәк дип, болыннарны сөрү, әрәмәләрдәге куакларны төпләү, сазларны киптерү шул ук Хрущев заманында башланды. Хосусый милекчелекне бетерәбез дип шәһәр янында мал асрауны тыю да, шәһәрдәге агач өйләрне яндырып, алмаларны, чияләрне кырып шырпы кабы сыман тар, кысан бүлмәле таш йортлар салу да Хрущев заманында башланды. Су тегермәннәрен бетерү, кечкенә авылларны юкка чыгару, басу уртасында бишәр катлы шәһәр йортлары салып кую шулай ук аның заманында башланды.

Безнен өчен иң күңелсезе шул булды: вак милләтләрне кысу, милли телләрне, культураларны бетереп, бер телгә, бер культурага калдырырга тырышу шул ук Хрущев заманында башланды.

Ачлыкка, мохтаҗлыкка без инде күптән күнеккән идек. Базарда, магазинда ит-сөт, балык, яисә җаның теләгән азык булмау, теләсә кайда чиратка барып тәртеләү, буш вакытның яртысы шул ук чиратта үткәрү, талаш-тиргәш — боларга без инде ничектер күнегеп беткән идек. Кыен, бик кыен. Еш кына ачу килә, күңел кырыла, хурланасың, ләкин берни эшләр хәл юк — бөтен ил белән, һәркайда шулай һәм кайчан да булса яхшыга үзгәрәчәгенә дә ышаныч юк.

Ачлык-мохтаҗлык җанга тия, шулай да аяктан екмый. Аяктан екканы — милли мәсьәлә. Безнен өчен, гомерен телгә, әдәбиятка, культурага багышлаган кеше өчен. Ләкин башкалар өчен дә тел-культура, дин чит нәрсә түгел, болар иң якыны, иң газизе. Һәркемнен үз теле, үз культурасы, үз карашлары бар.

Башкалар кагылырга, кимсетергә тиеш булмаган хисләр бар. Милли хис. Ул аерым кешенеке генә түгел — бөтен бер халыкныкы. Мине берәрсе тупас рәвештә сүгеп ташласа, минем монa бик нык ачу киләчәк. Шулай да, мин үземне беткән кешегә санамаячакмын, ләкин кемдер чит кеше уйламый-нитми минем халкымны кимсетә икән, бу миңа искәрмәстән пычак белән кадаган кебек булачак. Монда инде шәхси ачу-үртәлү генә түгел. Монда инде син үзеңне халкың өчен, меңәр еллар буена бирелеп килгән теле, культурасы өчен җаваплы итеп тоясың. Миллионлаган туганнарыңа, милләттәшләреңә юнәлтелгән кимсетү сүзе синең берүзеңә төшә. Бар ачысы, авырлыгы аның шунда.

Без — рус дәүләтендә, безгә әледән-әле, адым саен дигәндәй рус кешесе белән очрашырга, аралашырга туры килә. Аз санлы милләт буларак, рус алдында безгә болай да бераз гына кимсенергә, бераз гына ялагайланырга яисә бераз гына аны үзеңнән өстен куярга туры килә. Җәмгыять тормышында бу шулай. Үзеңне аз санлы булганлыгыңны белгәнлектән, шәхси, көндәлек тормышта киресенчә горур буласың, өстен буласың, һичьюгы тигез буласың килә. Алай итсәң дә, болай итсәң дә ике арада шиккә, ышанмаучылыкка урын кала. Әгәр инде рус кешесе сиңа чын күңелдән хөрмәт күрсәтсә, синең өчен шуннан да зур бәхет була алмый. Руска карата безнең тарафтан күрсәтелгән хөрмәт тә, бәлки, шундый ук тойгы тудырадыр. Хәер, әйтә алмыйм. Безнең мөнәсәбәтләр шактый катлаулы. Анда яшерелгән дошманлык та, күрә алмаучылык та, шул ук вакытта хөрмәт-ихтирам да бар. Гасырлар буена шулай килгән. Гасырлар буена татар үзенең горурлыгын, кешелек сыйфатларын, милли-дини үзенчәлекләрен сакларга тырышып яшәгән. Гасырлар буена һәркайда бу аны милли-дини мәсьәләләрдә аеруча сизгер булырга өйрәткән. Күрәсең, шуңа күрә дә ул, гасырлар буена Россиянең төрле төбәгендә таралып яшәүгә карамастан, милләт буларак югалып, таркалып бетмәгән. Башкалар арасында йотылып бетүдән татар беркайчан да чын-чынлап курыкмаган, ахрысы. Ул үзенең күп гасырлык культурасына, теленә, диненә таянган. Һәм шуның белән исән калган. Россия империясенең теләсә кайсы ноктасында татар авыллары, татар мәчетләре, мәктәпләре барлыкка килгән. 1948 елда Япониягә каршы сугышта Кытай җиренә барып кергәч, Көнчыгыш Кытай шәһәрләрендә яшәп ятучы, саф татарча сөйләшүче татарларны күреп безнекеләр шаккатканнар. Кытай шәһәрләрендә татар мәктәпләре, татар театрлары эшләп торган. Бу хакта 51нче елда язучы Абдулла Әхмәт сөйләде. 70нче елларда шул ук сүзләрне икенче кешедән ишеттем. Яңа урынга, Ягодный урамына күчеп килгәч, яңа күршебез, элекке подполковник Шәриф абый Еникиев сугыш вакытында Кытайда чагында шундый хәлгә юлыгуы турында сөйләде. Хәзер инде газеталарга да яза башладылар: татар төньякта, Финляндиядә, Румыниядә, хәтта Америкада, Австралиядә, Япониядә да бар икән. 1951 елда Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшләгәндә, Мәскәүдән нәшриятны тикшерергә бер әрмән кешесе килде. Ничектер сүз ара сүз чыгып, ул бер вакыйга сөйләде. 50нче елларда Мәскәүгә Америкадан туристлар килгән. Туристларның бер төркеме татар булып чыккан. Ирләре-хатыннары искечә татарча киенгәннәр ди. Башларында кәләпүш, калфак ди. Боларга инглизчә белүче гид биргәннәр. Ләкин болар инглизчә белмиләр. Бары татарча гына һәм русча гына беләләр икән. Бөтен Мәскәүдә шул турыда сөйләделәр, ди әрмән кешесе. Шул ук 50нче елларда поездда Бөгелмә ягына барганда, купеда бер агай белән туры килдек. Татар агае. Алты-җиде яшьлек кызы да бар. Мурманск ягыннан туган якларына кайтып баралар. Мурманскида торалар икән, кызлары шунда туган. Әтисе белән саф татарча сөйләшә. Ул чакта ук миңа бу гаҗәп тоелган иде. Мурманскидан, Америкадан килүчеләр татарча сөйләшә, бездә, Татарстанда, Татарстан дип аталган автономияле республикада исә...

Ачлык, мохтаҗлык турында иркенләп сөйлисе килмәгән кебек, тел, культура, милләт турында да иркенләп, җәелеп сөйлисе килми. Бу үзеңнән-үзе аңлашыла кебек. Бу — шеш. Яра. Канлы яра. Ярага кайсы яктан кагылсаң да авырта, якын килсәң дә, хәтта шул турыда уйласаң да авырта. Сызлый, әрни. Туктаусыз үзен сиздереп, сулкылдап тора.

Безгә ирек, азатлык, тигезлек һәм һәртөрле мөмкинлекләр вәгъдә иттеләр. Вәгъдә ителгән азатлык, тигезлек өчен безнен ин яхшы кешеләребез утка-суга керделәр, корбан булдылар. Чыннан да, безгә Республика бирделәр, Конституция, флаг-герб бирделәр. Дүрт йөз елга якын коллыктан сон, ниһаять, татарнын үз дәүләте оешты. Тулы хокуклы суверен дәүләт булмаса да заманына, шартларына күрә ул безнен өчен ин кулай дәүләт булды. Ләкин Ленин үлү белән без автономиянен дә, Конституция, флаг-гербларнын да буш сүз, күз буяу, ялган икәнлеген күрә башладык.

Хокуксыз чагында безнен үз язуыбыз булган, күп итеп һәртөрле хокуклар биргәч, язуга күнегеп кенә килгәндә, анысын тагын гамәлдән чыгардылар. Русча хәреф белән татарча язарга-укырга өйрәнеп кенә житкәч, рус хәрефен түгел, татар телен юкка чыгара башладылар.

Дөньяда, күрәсен, бер генә милләт тә шундый мыскылга, шундый кыерсытуга, түбәнсетүгә дучар ителмәгәндер. Билгеле, татар язмышын татыган башка ирекле республикалар язмышын исәпкә алмаганда.

Утыз жиденче, утыз сигезенче елларда ниләр булганы һәркемгә диярлек билгеле. Ләкин билгеле булмаганнары да житәрлек. Татар интеллигенциясен, белемле, анлы татар кадрларын юкка чыгару, мәктәпләрне, газета-журналларны ябу, татарча нәшрият, радионы кыскарту барысы да шул елларда кереп китте. Сугыш алдыннан бу беркадәр тынып торды, ләкин тулысынча тукталмады. Бары тик сугыш вакытында гына, безнең татар икәнлекне, димәк, «буржуаз милләтче» икәнлекне, дошман икәнлекне онытып тордылар. Чын дошман, көчле дошман монда түгел, көнбатышта иде. Ничек тә шул дошманны юк итәргә кирәк иде. Һәм шул чагында фронтларда татарча газеталар чыга башлады. Татар батырларын мактау да, аларга Герой исемнәрен бирү дә гаеп эш саналмый башлады. Ин зур дошман жинелеп, ачыктан-ачык сугышырга жай калмагач, без янадан «дошманга», «милләтчегә» әйләндек. Янадан безне эт кебек талый башладылар. Хрущев заманында бу аеруча көчәеп китте.

Ләкин Хрущев заманы да бертөсле генә булмады. Баштарак әзме-күпме ирек, либерализм тенденциясе сизелде. Илле жиденчедә Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасынын үткәрелүе шунын бер чагылышы булды. Декала-концертлар, очрашулар Мәскәү татарларын канатландырып жибәрде. Мәскәү татарлары башкалада татарча театр ачылуын таләп иттеләр, имзалар жыеп, югары оешмаларга кадәр барып життеләр. «Ачалар икән» дигән сүзләр ишетелде. Юк, ачылмады. Соңыннан Батыев каршы килгән икән, Мәскәүдә татар театры ачылса, Казан театры артистлары Мәскәүгә китеп бетәчәк дип әйткән икән дигән сүзләр ишетелде. Шулай итеп, Батыев «гаепле» булып калды.

Шул ук илленче елларда бөтен союз күләмендә милли мәсьәләләрне тикшерү башланды. Үзәк газеталарда, Казан газеталарында төрле фикерләр, теләкләр, тәкъдимнәр белән мәкаләләр басылды. Безнен күнел күтәрелеп китте. Без инде чыннан да безгә дә, ниһаять, хокуклар, мөмкинлекләр булыр дип өмет иттек. КПСС өлкә комитеты каршында нинди дер комиссия төзелде. Шул комиссия кешеләре халыкнын фикерен өйрәнделәр. Язучылар союзына Гыймадиев килде. Фәннәр Академиясе филиалында тарихчы. Ул елларны татарнын ин күренекле тарихчысы. Беркөнне мине анын янына чакырдылар. Нинди теләкләрен, тәкъдимнәрен бар — әйт, сөйлә, диде. Мин сөйләдем, татарлар белән башка халыклар арасында чыннан да тигезлек булсын өчен Татарстанга союздаш республика статусы бирелергә тиеш, яслеләрдә, бакчаларда татар балалары татарча тәрбияләнергә, югары уку йортларында татар бүлекләре булырга тиеш, дидем. Бу турыда инде күптән саташып йөри идем. Татарстанны союздаш республикага әйләндерүне сорап мин инде иң югары дәрәжәләге житәкчеләргә хатлар язган кеше. Нинди дер жыелышта Профсоюз урамындагы укытучылар клубында алдан язып барып, шул ук темага бер шау-шулы чыгыш та ясаган кеше мин. Студент чагында ук татарча киностудия кирәк дип шулай ук Мәскәүгә «петиция» жибәргән кеше. Ул чакта Өлкә комитетынын идеология секретаре Рәхмәтуллин дигән иптәш иде. Нәрсәдер сөйләде, анлатты да, юмалап чыгарып жибәрде.

Татар интеллигенциясе — язучылар, журналистлар, сәнгать кешеләре, укытучылар Татарстанның, татар теленең, татар культурасының, хокукларын кинәйтүне теләделәр. Ләкин газеталарда башка төрле фикерләр дә әйтелде. Без коммунизмга барабыз. Коммунизмда бер тел булачак, барлык милләтләр берләшергә тиеш, хәзердән үк русча укытуга күчәргә кирәк, фәлән-фәсмәтән. Рус теленнән башка берни эшләп булмый, эшкә һәркайда рус теле кирәк...

«Халык фикерен өйрәнү» чынлыкта спектакль генә булып чыкты. Безнең фикергә, гадәттәгечә, колак салучы булмады. Без янә дә милләтче булып калдык. Ясалма ыгы-зыгы, шаукым узгач, зур җыелышларда безнең тетмәне тетә башладылар, минем фикерне белергә килгән Гыймадиев ниндидер пленумдамы, ниндидер җыелыштамы, Нурихан Фәттах исемен телгә алып, «ул хәтта яслеләрне, балалар бакчаларын татарлаштыруны таләп итә» дип мине «фаш итеп» чыкты.

Шулай итеп, Хрущевның сиксәненче елга коммунизм төзү планы тормышка ашырыла башлады. Бер-бер артлы татар мәктәпләре ябылды, берән-сәрән калган яслеләр, бакчалар ябылды, тоташ татар районнары булмасын өчен, районнар эреләндерелде, чикләр үзгәртелде.

Районнарда татар газеталары русчаның тәрҗемәсе рәвешендә чыгарыла башлады. Хәтта республика газетасы «Социалистик Татарстан» да «Советская Татария»нең дубляжына әверелде. Казанда чуаш телендә республика газетасы чыгып килә иде, аны да яптылар. Татарстан Китап нәшриятының планы елдан-ел кими башлады, газеталарда «милләт», «татар» сүзләре бөтенләй диярлек төшеп калды. Радио андый сүзләрне гомумән кулланмаска тырышты. Кыска вакытлы концертларның яртысы татарча, яртысы русча итеп аралаштырылып бирелә башлады. Бервакыт Татарстан Җыр һәм бию ансамбле концертына баргач, җырчыларның әле татарча, әле русча җырлауларын тыңлап, бик нык кәеф кырылып кайтты. Җырны, музыканы гомумән буташтырырга ярамый. Бит кеше, тыңлаучы ул бөтен күңеле белән алдан ук бертөрле көй тыңларга җайлаша. Мин еш кына рус концертларын да, чит ил концертларын да тыңлыйм. Яратып, бирелеп тыңлыйм. Ин якыны, әлбәттә, үз көең, үз моның. Ләкин тиешле кәефкә җайлангач, теләсә нинди халык музыкасы да үз көең кебек үк ләззәт һәм канәгатьләнү бирә. Буташтыру, бер көйне икенчесе белән бутау бары ачуны гына китерә.

Академия театрына баш режиссер итеп каяндыр Григорьев дигән рус кешесен китереп куйдылар. Ул, билгеле, телне дә белми, тетарның традицияләрен, тарихын да белми. Татарча язылган пьеса кульязмаларын ана тәрҗемә итеп бирә торган булганнар.

Хрущевның яңалыклары күп булды. Казанда багана башларына, кеше күп йөри торган җирләргә репродукторлар куйдылар. Иртәннән башлап төн урталарына кадәр бөтен тирә-якка кычкырып радио сөйли. Мәскәү радиосы. Казанныкы иртән бер ярты сәгать чамасы концерт бирә дә тынып кала, кич тагын шулай — бер сәгать чамасы татар сүзе, татар музыкасы ишетелә. Шәһәрдә генә түгел, авылларда да урам уртасына шундый ук репродукторлар куелды. Көн-төн музыка, көн-төн агит-пропаганда. Алга барабыз, Американы куып җитәбез. Фәлән миллион сум табыш, дөньяда булмаган зур җиңү, фәлән-төгән. Радионы, музыканы мин үзем генә тыңларга яратам. Әкрен генә, кычкыртмыйча гына. Урамдагы музыка, сүз, берөзлексез тавыш, шау-шу ачуны гына китерә. Кеше үзе генә кала алмый, уйлана, фикер йөртә алмый. Җәй көннәрендә авылга кайткач магазин ягыннан килгән радио тавышын ишеттемме, ял тойгысы, онытылу тойгысы юкка чыга. Йокы кача, тынычлык кача. Башыңа бертуктаусыз дөмбәсләп торган музыка хәтта үзеннеке булса да бары кире тойгы гына тудыра. Бер мәртәбә түзмәдем. Янтыкның радиоузелына бардым — нишләп туктаусыз кычкыртасыз ул багана башындагы радионы, дидем. Болар миңа югарыдан килгән приказны күрсәттеләр. Анда турыдан-туры әйтелгән — «сөйләтергә», дигән. Без инде үзебез дә җиләп беттек аннан, диделәр. Шулай берничә мәртәбә туктатып караганнар икән, кемдер шундук Яңавылга хәбәр иткән. Боларга шелтә белдергәннәр.

Ул елларда хәтта газеталарга яздылар бу көн-төн сөйләгән радиолар турында. Репродукторларга якынрак йортларда яшәүче кешеләр йоклый алмый интегәләр, укучы балалар укудан арттa кала башлаганнар икән.

Колак салдымы берәрсе? Юк, салмады. Шул ук вакытта газеталарда урамдагы, завод-фабрикадагы шау-шуны бетерү, нервы авыруларын дәвалау, стресслар турында туктаусыз сүз барды.

Ә безнең турында, вак милләтләр турында, аларның теле, культурасы турында аваз булмады. Безнең кайгы-борчуларны тынлаучы да булмады, без әкренләп йомыла, кысыла, үз кабыгыбызга бикләнә бардык. Ул елларда һәр яңа көн безнең өчен күңелсез хәбәр китерде. Нәшриятка, Язучылар союзына барсаң, янадан-яна нәрсә ишетәсең, йөрәгең бозылып, йөзең үзгәреп кайтасың.

Безнең сәламәтлек турында, безнең тынычлык турында, әлбәттә, беркем кайгыртмады. Коммунизм, һәртөрле муллык, культура үсеше...

Ләкин безнең өчен түгел. Кемгәдер коммунизм, безгә — үлем. Хәл кылынган, программа теркәлгән. Киләчәктә бер тел булачак. Пропаганда туктаусыз шуны тукый.

Бер көнне Матбугат йортына баргач, шундый яңалык ишеттем. Татарстан республикасын бетерергә исәплиләр икән. Ышанмадым, ышана алмадым. Шулай да күңелгә шом салынды. Хәзер, шул көннәрдән соң егерме, егерме биш еллар вакыт үткәч, хатын әйтә: кайчагында мин уйлап куя торган идем — әллә бу ычкынды микән соң, дип, ди. Чынлап ычкыныр хәлдә идек без ул чакта.

1962 елда исә мин чыннан да ычкына язып калдым. Беркөнне авылга кайткач, урамда Фәннине очраттым, тарих укытучысын. Гомергә Янтыкта яшәде, балалар укытты. Миннән бер-ике яшькә зуррак. Авылда барып-килеп йөри торган, тегесен-монысын сөйләшеп була торган дусларның берсе. Мәктәпне урысчага әйләндермәкче булалар бит әле, диде бу. Үзе шунда ямьсез генә бер сүз әйтеп куйды, сүгенү сүзе. Янтык (Яңа Уртавыл) мәктәбен, без укыган, безнең өчен туганнан да кадерлерәк булган мәктәпне, безнең авыл мәктәбен...

Димәк, чыннан да бетәчәк, юкка чыгачак бөтен нәрсә. Ник, ни өчен? Безнең ни гаебебез бар? Без нинди җинаять эшләдек тә, кемнең юлына аркылы төштек?

Мин Фәннигә берни әйтә алмадым. Чит кешеләр кебек шундук аерылышып киттек. Тау башындагы, чыршылыктагы бәләкәй генә өйгә кайттым да, урынга егылдым. Өч көн баш калкытмый ятканмын. Йокы басты. Күзне ачып булмый, аяк-кулны күтәреп булмый. Өченче көнне шулай да тордым. Карасам, бөтен тән кып-кызыл тап белән капланган. Үзе кычыта. Соңыннан ачыкланды — экзема дигән нәрсә икән. Ике-өч ай буе туктаусыз дәваландым. Кызыл таплар бетте, кычытыну бетте, ләкин хуры калды. Курку калды. Калды гына түгел, йөрәккә, бавырга төште.

*Ахыры киләсе санда*

# БОЛГАРГА ТОТАШКАН ТАМЫРЛАРЫБЫЗ

Тегe яки бу халыкның этногенезына (килеп чыгышына) һәм этник тарихына бәйләнешле проблемалар, табигый ки, аеруча унышлы булып төрле фәннәр һәм милли культура ядкәрләре үзара очраша торган уртак җирлектә генә хәл ителә ала. Безнең темага мөнәсәбәтле тарихи фольклор да, һичшиксез, халкыбызның этник тарихына бәйләнешле культура мирасына керә.

Фольклорның аерым жанрлары, бигрәк тә риваятьләр һәм легендалар, аеруча кыйммәтле чыганак булып исәпләнә, чөнки алар гасырлар тирәнлегеннән килә торган бай мәгълүматлар белән сугарылган. Һәм бу табигый дә. Риваятьләр — халыкның буыннан-буынга тапшырыла килгән тел-авыз иҗаты елъязмасы. Аларның төп вазыйфасы — борынгы мөһим вакыйгалар һәм шәхесләр турында халыкның хәтерен-истәлекләрен саклау һәм житкерү, аларга тарихи-эстетик бәя бирү.[1] Легендалар да, риваятьләр кебек үк, дөреслеккә дәгъва итә торган, заманында сөйләүче тарафыннан да, тыңлаучы ягыннан да булган хәл итеп кабул ителгән һәм кайчакта хәзер дә шулай булып кала торган эпик хикәятләр. Ләкин, риваятьтән аермалы буларак, легендаларда гадәттән тышлык, хыял-фантастика, уйдырма һәм кайчакларда хәтта мифологик башлангыч та катнаша. Тик шулай да легендалар да вакыт-вакыт аерым тарихи мәгълүматлар белән үрелеп-керешеп киләләр. Димәк, алардагы шул тарихи орлыкны яки нигезне күрә һәм таба белергә, иң мөһиме — чынны уйдырма катламнан аерып ала белергә кирәк.[2]

Борынгы Болгар дәүләте һәм аның көнчыгыш чигендә урнашкан меңьеллык Алабуга шәһәре белән бәйләнешле тарихи фольклорны фәнни кулланышка керткәндә һәм бәяләгәндә, без әнә шундый таләпләрдән һәм методологик принциплардан чыгып эш итәргә тиешбез. Бүгенге көндә безгә Алабуга турында һәм, руслар биргән атама белән әйткәндә, «Шайтан каласы» («Чертово городище») хакында берничә риваять һәм легенда билгеле. Аларның иң борынгыларында сүз Кама (Чулман) елгасы буендагы әлеге «кала»да заманында канатлы зур елан-сазаган яшәгәнлеге турында бара һәм җирле халыкның шуңа бәйләнешле ышанулары китерелә. Бу мәҗүси-мифологик легендалар безнең көннәргә Казан ханлыгында әсирлектә булган исеме билгесез кеше язып калдырган «Казанская история» (XVI йөз) һәм Шәрәфетдин Болгари-Мөслими язган «Тәварих-и Болгария» (XVIII йөз) кебек чыганаклар аша килеп җиткәннәр.[3] Шул ук легендаларның аерым вариантлары шулай ук XIX йөз галимнәре П.Рычков, Н.Рычков һәм Ф.Эрдман хезмәтләре аша да мәгълүм.[4]

XIX йөзнең ахырында тарихи мәгълүматларга таянып Платон Заринский ачыклавынча һәм соңрак профессор А.Халиков раславынча, канатлы елан-сазаган образы Болгар дәүләте чорында һәм, өлешчә хәтта Казан ханлыгы дәверендә дә әле, җирле халык тарафыннан изгеләштерелгән һәм саклаучы-яклаучы мәҗүси-мифик зат итеп күз алдына китерелгән.[5] Ата-бабадан килгән бу традициянең, ягъни илаһилаштырылган сазаган культының башы болгарлар һәм татарлар составына субстрат (субстрат — иң борынгы катлам мәгънәсендә) һәм этник компонентлар булып кергән һун-гуннар, сувар-хазарлар, угызлар һәм кимак-кыпчакларга барып тоташа. Ачыклап әйткәндә, кытай язмаларында Үзәк Азия һуннарының Лун-сы («Елан-ләү храмы») дигән гыйбадәтханәдә күккә (Тәңрегә) багышлап корбан бирүләре, патша-шаньюйлар мәетен ак елан-сазаган сурәте төшерелгән кара ефәккә чорнап күмүләре турында тарихи мәгълүматлар теркәлеп калган.[6] Себердәге төрки каганат идарәчеләре Билге-каганның һәм Күл-тегинның каберләре өстенә исә ләү-

сазаган ясалган ташлар куелган булган.[7] Ә менә болгарларның бер кабиләсен тәшкил итүче савир/суварлар Төньяк Кавказда яшәгән вакытта муеннарына алтыннан һәм көмештән елан-сазаган сурәте ясалган бөти-амулет тагып йөргәннәр.[8] Янә килеп, көньяк далаларда яшәгән кыпчаклар канатлы елан-сазаган сурәтен кылыч-хәнҗәр сапларына, садакларына — ук савытларына һәм ат дөрбия-сбруйларына ясый торган булганнар, һәм, Мурад Аджиның тикшереп ачыклавынча, әлеге яклаучы-саклаучы образ кыпчакларның этник символы булып әверелгән (сүз бара торган мифик образ исеменен кыпчак-куман телендәге һәм Идел буе болгарларындагы вариантлары: сазаган/саруган/шарукан).[9] Боларга өстәп тагын шуны әйтергә кирәк: Дон буе кыпчакларының башында 150 ел буена «елан-сазаган халкы»ннан чыккан Шаруканнар династиясе-нәселе торган һәм аларның Шарукан исемле шәһәре дә булган.[10] Безнең карашыбызча, «саз»/«шар» тамырыннан ясалган әлеге сүзләрнең этимологиясе сак диалектларында «елан» мәгънәсен белдергән sazda, sausda сүзләренә барып тоташа булса кирәк.[10a]

Яна тикшеренүләр күрсәткәнчә, сазаган образы хәтта борынгы болгарларның һәм кыпчак-кимакларның күмү йолаларында да яклаучы-саклаучы мифик зат буларак катнашкан. Бу очракта мин, барыннан да элек, Дунай буе Болгар дәүләтенең беренче башкаласы Плиска янында Аспарух (VII йөз) каберлегендә табылган сазаган сурәтен күздә тотам.[11] Кубрат хан династиясенең тамга-мөһере булып исәпләнүче жиз тәңкәгә ясалган әлеге мифологик образ, безнең уебызча, хан каберенә йола таләп иткән өчен генә түгел, ә теге дөньяда хуҗасын яклау һәм саклау өчен дә күмелгән булырга тиеш.

Икенче мисал IX йөздә Көнбатыш Себердә барлыкка килгән кимаклар дәүләте территориясендә — Иртыш буенда ачылган Зевакин каберлеге белән бәйле. Безнең темага кагыла торганы — байбикә хатын күмелгән әлеге каберлектә табылган рун язмалы бронза көзге (рун — төрки бабаларыбызның борынгы шрифт-язу төре). Утыз хәрефтән торган бу ике юллык төркичә язманы археолог Ф.Арсланова белән тюрколог С.Кляшторный, текстта күрсәтелмәгән сузык авазларны үзләре фараз иткәнчә ачыклап укыганнар. Аларча тәрҗемәсе: «Знатная женщина освобождается от своего [чувства] зависти (гнева). Ее счастливый удел (ее благость) наступает». «Ябчи — рыжий (вар. огненно (ярко)-красный) ... дракон».[12]

Мин бу укылыш һәм әлеге тәрҗемә белән килешмәдем, текстны тартмый-сузмыйча, башка сузыклар белән үземчә укыдым. Түбәндәге гыйбарә һәм мондый кызыклы мәгънә килеп чыкты. Беренче юл: «Байбикә кояшыннан аерыла, рухы (җаны) ташлап китә»; икенче юл: «Якла (каплачы) дошманнан, изге лү (сазаган)».

Мисаллардан аңлашылганча, сазаган образы, димәк, һуннардагы кебек үк, кыпчак-кимакларда да яклаучы-саклаучы буларак хәтта теге дөньяга озата барган булып чыга. Безнең бу нәтиҗәбез Себердә атаклы Аржан курганын казыганда бер төрки кабереннән рун хәрефләре белән «lü» дип язылган бронза аел табылуы белән дә раслана.[13] Каеш аелындагы бу сүзнең лү-сазаганның яклавына һәм саклавына исәп итеп язылганлыгы, безнеңчә, шиксез.

Борынгы төркиләрдә изгеләштерелгән ләү-сазаган образлары мифологик ышанулар, легендалар даирәсендә генә торып калмаган, ә борынгы төркиләрнең төрле сәнгать төрләренә, шаман догаларына һәм героик эпос-дастаннарына да үтеп кергән. Мәсәлән, кыргызларның атаклы «Манас» дастаны баштан алып ахырга кадәр елан-«айдагар» культы белән сугарылган (төрки телләрдәге айдагар, аждар, аждарһа, аждаһа — ираннарның өч башлы елан-баскак патша Ажи-Дахака исеме нигезендә ясалган сүзләр). «Бер башлы житмеш колачлы айдагар» анда төрки-кыргызларны яклаучы буларак хәтта яуда катнаша.[14] Шулай ук кыргызлар, казакълар һәм Себер татарлары арасында билгеле булган «Йиртөшлек» дастанында да геройга теләктәшлек итүче елан-аждаһалар патшасы Ак елан образы тасвирлана. (Каюм Насыйри сүзләрен исегезгә төшерегез: «Барлык еланнар кара төстә булып, еланнар патшасы ак була. Ак елан татарны яклый, ярата, алдан хәбәр биреп, төрле файдалар китерә»).[15] Себер-Алтай шаманнарының чакыру догаларында да «алтмыш колачлы аждар» шаманның ярдәмчесе-булышчысы итеп сурәтләнә. Янә килеп, борынгы «Угыз-наме» дастанының Стамбулда Топкапу китапханәсендә саклаучы хәзерге

купләргә билгесез версиясендә дә үзенең сихри-магик куәте белән яхшы һәм гаепсез кешеләрне бәла-казалардан һәм гарип-горабалыктан коткаручы-савыктыручы (ә явыз һәм гөнаһлы-гаепле кешеләрне ашаучы) изге елан-сазаган тасвирлана.[16] Әгәр боларга янә Идел буе Болгар дәүләте биләмәләрендә табылган канатлы елан-сазаган сурәте төшкән мөһерләрне, бакыр акчаларны, алтын йөзекләрне[17] һәм бил каешына тегелгән шундый ук сурәтле тәңкәләрне дә китереп кушсаң, әлеге мифик образ культының элек никадәр нык таралган булуы тагын да тулырак төс ала. Һәм шушы ук гамәли сәнгать ядкәрләреннән болгарларның бу образны ни өчен изгеләштергәнлекләрен, нинди максатта кулланганлыкларын да чамаларга була.

Инде Алабугадагы «Шайтан каласы»на бәйләнешле елан-сазаган образына әйләнеп кайтыйк. Сүз барган легендаларда әлеге илаһи-мифик көч тә үзенә табынучыларга карата ярдәмчел-булышучы зат итеп тасвирлана. Тирә-яктан аңа төрле үтенеч-сораулар белән туктаусыз кеше агылып тора, хәтта әсирләр исәбеннән аңа корбаннар да китерәләр. Канатлы елан-сазаган аларга сихри-илаһи көче белән ярдәм итә: чир-авырулардан котылдыра, Кама елгасы кискен борылыш ясаган куркыныч-бусагалы урыннан көймә-корабларын исән-имин үткәреп җибәрә, күрәзәлек итеп, киләчәк язмышларының нинди булачагы турында җаваплар бирә. Үзе белән исәпләшмәүчеләрне һәм ризалатмыйча үтеп китәргә теләүчеләрне исә һәлак итә, көймәләрен капландыра.[18] Иң мөһиме — болгар мифологиясендә һәм аңа барып тоташучы татар хикәятләрендә елан-сазаган Болгар дәүләтенең һәм соңрак Казан ханлыгының чикләрен саклаучы һәм яклаучы көч булып күз алдына баса.[19]



*Казан гербы.*

Менә монда инде без сазаган образының тагын бер функциясенә — дәүләт иминлеген, чик буйларын саклау вазыйфасына барып чыгабыз. Заманында канатлы елан образының чик буйларын саклау функциясенә күренекле фольклорчы В.Я.Пропп игътибар иткән булган.[20] Археолог А.Х.Халиков үзенең хезмәтендә «Шайтан каласы»ндагы сазаганга менә шул сыйфатның да хас булуына басым ясый. Һәм шунысы характерлы: ил чиген саклаучы әлеге мифологик образ традицион ышану, дәвамлылык рәвешендә Болгар чорыннан Казан ханлыгы дәверенә дә күчә. Аерым алганда, «Казанская история»дә теркәлгән һәм Н.П.Рычков, Ф.Эрдман язып алган легендаларда Болгар дәүләтенең «мәлиге»/«илтәбәр»е дә, шулай ук Казан ханлыгының ханы да (бер легендада әлеге идарәче Сөембикә итеп бирелә) монголлар яки руслар яу белән килер алдыннан: «Кем җиңәчәк — монголлармы (соңрак варианты: руслармы), әллә безме?» — дип сорарга Алабугадагы елан-сазаган янына үзләренең вәзирләрен җибәрәләр. Һәр ике очракта да әлеге елан: «Минем инде сезне сакларга көчем бетте, бу җирләр басып алучылар кулына калачак», — дип җавап бирә һәм, һавага күтәрелеп, юкка чыга.

«Казанская история»дәге легендада янә бер мәгълүмат игътибарны җәлеп итә. Ачыклап әйткәндә, анда «Шайтан каласы»нда яшәүче елан-сазаган руслар килер алдыннан мәҗүси таш гыйбадәтханәдән түгел, ә мәчеттән очып чыгып киткән итеп тасвирлана. Безгә шулай ук исеме билгесез урта гасыр рәссамының әлеге фактны Казан яулап алынуга бәйләп ясаган рәсеме дә билгеле. Белүебезчә, анда да мәчеттән очып чыгып китүче канатлы елан сурәте төшерелгән. Бу мисалларны кайбер галимнәр гадәттә бабаларыбыз тоткан ислам динен мыскыллау өчен руслар уйлап чыгарган ялган итеп карыйлар. Минемчә, бу дөрес үк караш түгел. Әгәр елан-сазаганны мәчет белән бәйләп күрсәтү, чыннан да, мыскыллау һәм ялган икән, ул чагында Төрекмәнстанның башкаласы Ашхабадтагы атаклы Анау мәчете (XIV йөз) порталының

як-ягына канатлы ике сары елан-сазаган сурәте ясалган булуын ничек аңлатырга?![21] Йә булмаса Кытайдагы мәчетләрнен стеналарына төшерелгән канатлы елан сурәтләрен ничек аңларга?![22] Үзеннән-үзе соралып торган җавап бер: мәҗүси ышанулар калдыгы булган һәм безнен көннәргә килеп җиткән әлеге образлар элек-электән үк аерым объектларны, шул исәптән дини храмны-мәчетне саклаучы мифологик зат итеп тә күзалланганнар. Моннан тыш, этнографларның һәм архитекторларның ачыклавынча, Татарстан территориясендә тәрәзә өслекләренә агачтан кырып өй саклаучы елан-сазаган сурәтләре эшләү традициясенең яшәп килгәнлеге дә билгеле.[23] Бу, әлбәттә, Болгар чорыннан ук башлангыч ала торган традициянең дәвамы.

«Шайтан каласы»ндагы елан-сазаганның заманында нәкъ менә мәчетне һәм үзе яшәгән тирәлекне саклаучы итеп күз алдына китерелгәнлеге турындагы караш А.Халиковның археологик тикшеренүләре белән дә раслана. Ул «Шайтан каласы»ндагы борынгы бина нигезенең кыйбла ягына яраштырып төзелгән булуын һәм шунда ук михраб эзе дә саклануын ачыклап, әлеге корылма элек, чыннан да, мәчет булган, шул ук вакытта ул Болгар дәүләте чиген саклаучы кальга-ныгытма вазыйфасын да үтәгән дигән нәтиҗәгә килде.[24] Бу нәтиҗә көньяк гарәп илләрендә элек берьюлы мәчет тә, кальга да булып хезмәт иткән корылмалар салыну традициясе булганлыгы белән дә туры килә һәм раслана.

Борынгы Урта Идел-Кама буе легендаларында елан-сазаган образының әнә шулай дәүләт һәм дин иминлегенә бәйләп сурәтләнүе унае белән бу урында урынлы нәтиҗә соралып тора: безнең бабаларыбыз болгарлар һәм кимак-кыпчаклар, димәк, үзләренең яклаучысы һәм саклаучысы итеп гади җанварны түгел, ә борынгы ышануларыннан килә торган иң куәтле һәм дәһшәтле итеп күз алдына китерелүче мифологик затны сайлаганнар. Илаһи һәм һәлакәтле куәткә ия булган әлеге образ аларның дошманнарында, сугышып яшәгән күршеләрендә һәм, гомумән, явыз ниятле рухларда яки каршы көчләрдә курку-өркү тойгысы тудырырга тиеш булган. Елан-сазаганның ачуыннан һәм зыян китерүеннән хәтта бабаларыбыз үзләре дә курка, шикләнә торган булганнар һәм табыну, корбан бирү исәбенә аның күңелен табарга, ризалатырга һәм үзләренә хезмәт иттерергә тырышканнар. Болгар-кыпчак һәм соңрак өлешчә татар мифологиясендә канатлы елан-сазаганның аерым объектларны, кеше аягы басмаган җирләрне һәм чик буйларын саклаучы илаһи көч булып чыгыш ясавы һәм дә Болгар дәүләте илә Казан ханлыгының этник тамга һәм герб рәвешендәге билгеләре булып китүе[25] менә шуның белән аңлатыла да.

Янә килеп, заманында елан-сазаган сурәтләре төшерелгән һәм шамаил кебек гарәп хәрефләре белән чигеп-нәкышләп язылган ефәк-тукыма байраклар, шулай ук уртасына канатлы елан уелган бакыр һәм тимер штандарт-флаглар булганлыгы да, һичшиксез, әлеге образның дәһшәтле һәм куркытучы-саклаучы табигате белән бәйләнгән. Мондый байраклар, флаглар турындагы мәгълүматларга без Мәскәү Кремлендәге кораллар палатасының һәм Россия кораллар музееның элекке архив материаллары исемлеге белән танышканда юлыктык.[25а] Күңелдә табигый рәвештә «Болар Казан ханлыгының А.Курбский язмасында телгә алынган трофей-ганимәт «патша байраклары» түгел микән?» дигән сорау туды. Үзенең истәлек-мемуарларында Курбский Казан байлыгын талаулары турында менә ничек язып калдырган бит: «И приказал (Государь) воеводам во граде огни гасити, и многие сокровища казанские велел всему воинству имети. На себя же Государь велел имети ...царя Едигерь Магмета и знамена царские, да пушки».[26] Аерым чыганакларга караганда, сазаган сурәте төшерелгән байраклар үз заманында хазарларда һәм Анатолийны яулап алган сәлҗүкләрдә дә булган. Кем белә, архив материаллары исемлегендә күрсәтелгән һәм бабаларыбыздан калуы ихтимал булган андый байраклар бәлки бүген дә Мәскәүдәге алда телгә алынган музейларның саклагыч подвалларында беркемнең дә кызыксындырмыйча ята торгандыр...

Бу урында төрки халыкларның хәтта ислам диненә күчкәннән соң да традицион мәҗүси ышануларыннан тәмам баш тарту юлына басмауларын, ә кушма-синкретик төстә дәвам итүләрен угызлар мисалында да анализлап китү кызыклы. Билгеле булганча, Сыр-дарья буйларында һәм Каспий диңгезеннән төньяк-көнчыгышта яшәгән угызларның бер өлеше VIII йөздә үк ислам динен кабул итә. 1040 елда

Сыр-дәрья угызлары мөселман ыруы-династиясе сәлҗүкләр житәкчелегендә Төрекмәнстан жирләрен яулап ала, һәм сәлҗүкләр гаскәрендә хәрби житәкчеләр булып хезмәт итүче Артуклар йортынын кабилә тотемы һәм нәсел гербы сазаган була.[27] 1071 елда сәлҗүкләр Кече Азиягә үтеп керәләр һәм Византия императоры Роман IV нең армиясен тар-мар итәләр. Безнең өчен иң игътибарга лаеклысы — алар үзләре белән бергә Византия территориясенә сазаган культын да алып киләләр.[28] XII йөздә инде Диярбакер каласынын Алеп капкасы түбәсендә сазаган сурәте пәйда була, дөресрәге, 1183 елда язмага андый сын-сурәт булганлыгы теркәлә.[29] (Бер унайдан Ашхабад янындагы Анау мәчетенең порталына-алгы өлешенә угыз-төрекмәннәр тарафыннан ясалган канатлы сазаган сурәтләрен дә кабат искә төшерик.) Госманлы төрекләре арасында сакланган Ахи Эврен (эврен — зур елан) турындагы борынгы легендада геройнын исеменнән һәм әсәрнең эчтәлегеннән елан-сазаган культы беленеп тора һәм хәтта (кызыкнын да кызыгы!) сазаганга тинләштерелүче каһарман Эврен Мөхәммәд пәйгамбәрнең көрәшчесе итеп бирелә. Аерым алганда, легендада герой болай тасвирлана: «В одной руке держал он знамя, даренное пророком Мухамедом, а в другой меч и поражал врагов, как дракон».[29a] (Сүз унаенда татар дастаны «Идегәй»дән дә бер тәнгәл мисал китерик: «Шаң-шаң иткән шам кылыч — Идегәйнең кылычы... Аждаһадай сулаган ул кылычнын сулышы».)[30] Моннан тыш, сәлҗүкләрнең аерым байракларында сазаган сурәте булуы һәм төрекләрнең элек басу-кырларны саклаучы елан («тарла-бекчиси») образын изгеләштергәнлекләре дә[31] угызларда елан-сазаган культынын, болгарларда һәм кыпчаклардагы кебек үк, заманында шактый нык таралганлыгы һәм хәтта этнос һәм этнокультура билгесе буларак кулланылганы турында сөйли.

Һинд-европа халыкларына, шул исәптән руслар-славяннарга килгәндә исә, алар, киресенчә, тарихта билгеле була башлаган чорларыннан ук елан-сазаганга һәм үзләре жирлегендә туган аждаһага дошман мөнәсәбәттә булганнар[32] («аждаһа» — иранnарнын өч башлы еланны белдерүче «ажи» сүзеннән һәм Иранны яулап алган елан кыяфәтле баскак патша Ажи-Дахака исеменнән). Алай гына да түгел, моннан берничә мен ел элек үк инде аларда елан-аждаһага каршы көрәшүче алла образы (сонрак алмашчысы — изге патша һәм мифоэпик герой) барлыкка килгән. Ул һинд-европалыларга бәйләнешле барлык этник культураларда да түбәндә, жирсуда яшәүче елан-аждаһаны утлы уклары яки утлы ташлар белән ээзрлекләүче, ана каршы көрәшүче яшен алласы итеп күзалланган.[33] Күпчелек Европа халыклары тота торган христиан динендәге «Сатана» («Дьявол») да, Библиядә тасвирланганча, коточкыч елан-аждаһа итеп күз алдына китерелгән.[34]

Һинд-европалылар һәм славяннар-руслар антихрист-дәһриләрне, мифик кара көчләрне генә түгел, ә үзләренен реаль дошманнарын, шул исәптән күчмә яки утрак тормыш белән яшәүче борынгы төрки кабиләләрне һәм татарларны да елан-аждаһа белән тинләштергәннәр.[35] Мона, билгеле, аталган халыкларнын елан-сазаганны изгеләштерүләре дә сәбәп булгандыр. Мәсәлән, Владимир Мономах XII йөз башында кат-кат яу белән килеп Дон буе кыпчакларын кыйраткач, «бог избавил нас от врагов наших и сокрушил им головы змеиные» дип белдергән.[36] Русларнын «Казан елъязмасы»нда исә татар ханлыгынын, бабаларыбызнын мәркәзе булган Казан «гнездо змиево» дип исемләнә[37] һәм, Казанга килгәч, шушы ук атаманы татарларга карата Петр Беренче дә куллана. Хәтта үзләренен союздашы булган Касыйм ханы Ибраһимны да руслар үзләренен бер риваятендә «Змий Горыныч» дигән кушамат белән атыйлар.[38]

Белүебезчә, татар легенда-риваятьләре арасында Казаннын еланлы урынга һәм Елан-тауга салынуы, монын өчен ул жирләрнең башта яндырылуы, еланнардан чистартылуы турындагылары да бар. Шуларнын берсе 1774 елда сәяхәтче Георги Иоган Готлиб соравы буенча борынгы татар кульязмасыннан тәржемә иттерелеп немец телендә теркәлгән, икенче шуңа охшаган риваять исә Сәид Вахитов тарафыннан Татарстаннын Спасс кантонында язып алынган.[39] Платон Заринский әлеге еланнарнын патшасы ике башлы «аждаһа» да үзе яшәгән төбәкне (бу очракта «кеше аягы басмаган искиткеч гүзәл» Кабан буйларын) саклаучы мифик зат итеп күзалланган дип карый һәм, янгында исән калгач, шәһәр коручылардан үз оясын туздырганнары, рәнжеткәннәре өчен үч ала башлаган дип исәпли.[40] Әмма мина

калса, әлеге легендаларны реаль чынбарлык белән бәйләргә дә нигез бар. Аерым фактлардан аңлашылганча, яна жирләрне үзләштергәндә элек кешегә күп еланлы урыннарга да килеп төпләнергә, еланнарны төрле юллар белән юк итәргә туры килгән. Һәм, һичшиксез, бабаларыбыз килеп утырган Елан-тау һәм Кабан буйлары да шундый урыннарның берсе булган булса кирәк.

П.С.Паллас та үзенең юлъязмаларында Иртыш белән Обь елгалары арасында «Елан-тау» дип атала торган тау булуы турында яза һәм аның ни өчен шулай аталуының сәбәбен болай аңлата: «Сия гора получила название свое от множества змеев, которые здесь находили как прежде, так и первые годы построения заводов».[41] Казан корыла башлаган жирнең дә еланнар кайнашып торган таулы һәм урман-суга бай урын булуы халык фантазиясендә аның нәкъ менә аждаһа саклаган серле төбәк итеп күзаллануына китергән булса кирәк. Ләкин легендаларда Казан халкының котын алып торучы әлеге жыелма образ борынгы болгарлар һәм кыпчаклар изгеләштергән сазаган кебек бер башлы итеп түгел, ә тискәре, явыз елан-аждаһа сыман ике башлы итеп тасвирлана. Ричард Фрейнын һәм А.Х.Халиковның бик дөрес ачыклавынча, мондый төр аждаһа һәм аңа каршы көрәш сюжеты төрки халыкларга һәм татарларга иран телле халыклардан кергән.[42] Шулай ук безнең әкиятләрдә каһарманның корбан таләп итүче күп башлы явыз аждаһаны үтереп патша кызын коткаруы турындагы сюжетны да (сюжетлар типологиясе буенча АТ 301 мотивы), һичшиксез, һинд-европа халыкларының, бигрәк тә ираннарның йогынты нәтижәсе итеп карарга кирәк.



*Бил каешына беркетелүче көмеш калай өслегенә ясалган бер башлы канатлы елан-сазаган. Зур Тигәнәле каберлеге. Археолог Е.А.Халикова раславынча, бу каберлектә табылган байтак әйберләр IX-X йөзләрдәге борынгы болгар культурасына карый.*

Күп башлы аждаһа турында сүз чыккач, монда елан-сазаган образына бәйләнешле янә бер мөһим аерманы күрсәтергә кирәк. Тарихи мәгълүматларга караганда, һуннар, борынгы төркиләр һәм болгар-кыпчаклар изгеләштергән бер башлы елан-сазаган/ләү образы һинд-европалылар, ираннар аша кергән күп башлы аждаһадан тышкы кыяфәте белән дә шактый аерылган. Безнең бабаларыбыз мифологиясендә һәм гамәли-кулланма сәнгатендә әлеге илаһи образ кош яки бүрегә охшаган бер башлы һәм кош кебек канатлы, божра рәвешендә бөгәрләнеп-уралып торган гәүдәле һәм балыкныкы кебек икегә аерылып яки чукланып тора торган койрыклы гибрид зат итеп күз алдына китерелгән, димәк, өч тирәлектә: күктә, жирдә һәм суда яши ала торган тереклек иясе итеп күзалланган. Шул ук вакытта сазаганның канатлы зур ак елан (варианты — сары елан) рәвешендә фараз ителгәне дә булган. Монда, билгеле, рус һәм сарай геральдистлары татарны һәм аның ата-бабалардан килгән тарихи символикасын мыскыл итеп ясаган әтәч, каз һәм личинка-суалчан кыяфәтле мәхлүк «аждаһалар» керми. Әтәч кыяфәтле һәм елан койрыклы «аждаһа» образында, мәсәлән, әтәч салган йомыркадан яралган дип фараз ителүче һәм үзенең ачуы, хәтта карашы, сулышы белән бар нәрсәгә һәлакәт, үлем китерүче Василиск дигән коточкыч явыз елан күздә тотылган.[43]

Ахыр килеп, тагын бер мөһим искәрмә: изгеләштерелгән бер башлы елан-сазаганнан аермалы буларак, күп башлы явыз елан затын, бабаларыбыз «сазаган», «ак елан» яки кытайлардан кергән алынма сүз белән «ләү» дип түгел, ә ираннардан кергән һәм күбесенчә кире мәгънә белдергән атама белән «аждаһа» дип йөрткәннәр. Һәм кайбер очракларда (мәсәлән, кыргызларда һәм казакъларда) хәтта унай образ булган канатлы һәм бер башлы елан-сазаганны «айдагар», «аджидаар» дип атаган тәкъдирдә дә, бабаларыбыз аны һинд-европалылар, ираннар йогынтысы аша килгән күп башлы дошман аждаһа белән бутамаганнар. Бу инде канатлы елан образлары, бигрәк тә аларның аталышы иран тәэсирендә күпмедер дәрәжәдә каршылыклы төс алуына карамастан, төркиләр, шул исәптән кыпчак тел семьялыгына керүче халыклар һәм татарлар хәтерендә яклаучы һәм саклаучы елан-сазаган образы барыбер сакланып калган дигән сүз.

Ләкин йогынты, һичшиксез, ике яклы булган. Аерым алганда, русларга болгарлар һәм кыпчаклар йогынтысы аша, шулай ук Казан ханлыгы юк ителгәндә кулларына төшкән трофей-ганимәтләр сыйфатында елан-сазаганга бәйләнешле сәнгать ядкәрләре, төрле мифологик образлар һәм мотивлар үтеп кергән. Тарихчы В.Н.Татищев борынгы елъязмаларга таянып, 1219-1230 елларда Владимир-Суздаль кенәзлегендә ак ташлардан салынган Георгий храмының авторы-архитекторы турында мондый мәгълүмат китерә: «Князь Святослав церковь построил новую, вельми дивную резаным камнем; мастер был болгарский».[44] Б.А.Рыбаковның тикшереп ачыклавынча, бу оста храмның таштан кырып эшләнгән рәсем-бизәкләренә Идел болгарларының мәҗүси ышануларын һәм мифологик образларын да кертеп җибәргән икән. Томшыгына «шарик», дөресрәге бер чеметем җир капкан үрдәк образын галим шуларның бер үрнәге итеп карый.[45] Утызынчы елларда храм диварлары архитектурасын өйрәнү белән шөгыльләнгән Австрия галиме Ф.Халле Идел-Кама болгарларының мифология элементларын 1194-1197 елларда Владимирда төзелгән Дмитрий соборы бизәкләрендә һәм кабарынкы-рельефлы итеп эшләнгән аерым хайван сурәтләрендә дә күрә.[46] Ләкин сүз бара торган Георгий һәм Дмитрий соборлары фасадындагы һәм диварларындагы барс, бүре һәм башка образларны эченә алучы сурәтләр-бизәкләр арасында әлеге галимнәрнең игътибарыннан читтә калган сазаган образлары да бар. Без рус-славяннар өчен чит, дошман булган әлеге образларны да болгардан килгән дип исәплибез. Бу инде, димәк, болгарлар ата-бабаларыннан ук дәвам итүче елан-сазаган сынын, башка образлары белән бергә, үзләренең кул тамгалары һәм этник мөһерләре рәвешендә рус храмнары диварларына да уеп калдырганнар дигән сүз.

Яки хәзергә киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган икенче бер кызыклы мисал. Англия сәяхәтчесе Антоний Дженкинсонның язуына караганда, Иван Грозный оештырган тантаналы кабул итү мәҗлесендә ул алтын кубоклар һәм кечкенә көмеш мичкәләр арасына аеруча кыйммәтле экспонат рәвешендә куелган «берничә манаралы, өске өлешендә сазаган башлары ясалган алтын әйбер»гә игътибар итә.[47] Палата уртасындагы махсус өстәл-күперчек өстенә урнаштырылган әлеге антиквар әйбер дә, безнең уебызча, Казанны алганда руслар кулына төшкән трофей байлыгы. Ник дигәндә, әлеге кабул итү мәҗлесендә Казан ягыннан Сөембикәнең әсирлектәге улы Үтәмешгәрәй дә катнаша һәм ул да асылда Мәскәүнең Казанны җиңүен күрсәтү-демонстрацияләү өчен җанлы экспонат итеп Иван Грозный янына утыртылган була. Явыз Иван үзе исә күргәзмә экспонатлар фонында башына кигән «татар стилендәге таҗ»да көязләнә.[48] Хәзерге вакытта Кораллар палатасында саклаучы һәм «Казан бүреге» дип аталучы әлеге таҗның да трофей экспонат булуы шиксез. Татар галимнәренең фикеренчә, асыл ташлар белән бизәлгән һәм саф алтыннан эшләнгән әлеге таҗ-бүрек Казан ханнарыныкы булган.

Әгәр без татар фольклорында, дөресрәге — «Дәфтәре Чыңгыз-намә» җыентыгында (XVIII йөз) борынгы чыганакка нигезләнеп теркәлгән тагын бер үзенчәлекле елан булуына тукталмасак, елан-сазаган турындагы җирле архаик мәгълүматларыбыз тулы булмас иде. Бу хакта җыентыкның икенче бүлегендә болай диелә: «Барадж халкының әүвәл замандагы борынгы төп йорты ошбу Зәй тамагында булыр иде (Зәй — Каманың сул кушылдыгы. — М.Б.). Алыплар заманы иде. Бер Барадж дигән аждаһа елан килде. Ул шәһәр халкына көч-зыян кыла башлады. Чыгып аждаһа белән сугыштылар, җинә алмадылар. Ахыры үзләре шәһәрен салып качтылар. Болгар шәһәре якынына барып Бүләр суының өстенә йорт салдылар. Ул шәһәрләрен һәм Бүләр (Биләр) дип атадылар. Ул сәбәптән халыкны Барадж халкы диер иделәр. Оранннары Барадж иде».[49]

Аерым галимнәр (мәсәлән, Әмир Нәҗип) тарафыннан әкият, чеп-чи фантастика итеп кенә каралган әлеге риваятьнең дә, безнеңчә, югарыда саналган легендар фактларныкы кебек үк, реаль җирлеге булырга тиеш. Кемнәр соң алар Зәй буенда пәйда булган елан исемен алган барадж халкы? XII-XV йөзләргә караучы фарсы чыганакларында Барадж Нух углы Яфәснең төрле төрки кабиләләргә нигез салучы унбер улының берсе итеп бирелә, ягъни эпоним сыйфатында телгә алына.[50]

Әмма, безнең карашыбызча, бараджыларның башта яшәгән җирлеген Зәй буе белән генә бәйләп калдыру урынсыз. «Дәфтәре Чыңгыз-намә» җыентыгындагы

Зәйдә пәйда булган Бараж еланы турындагы легенданы Мәхмүд Кашгари, әл-Мәрвәзи, Гардизи мәгълүматлары белән бәйләгәндә, безнеңчә, бараж халкын кимак-кыпчаклар берләшмәсендәге елан кабиләсе белән мөнәсәбәттә карарга нигез бар. Кашгари сүзлегендә мондый кызыклы мәгълүмат теркәлеп калган: «Бука — большая змея. В пословице говорится: «У змеи семь голов». Иногда этим словом называют героев, подобно тому, как называли одного из видных людей, ябаку Бука Будраж — с ним сражался Арслан-тегин — завоеватель с 40 тыс. мусульман, а неверных было 700 тысяч».[51] Тарихчы С.Ахинжанов Бука Будраж житәкчелек иткән әлеге халык жиде кабиләдән торучы кимаклар һәм кыпчаклар берләшмәсе булган дип исәпли һәм «у змеи семь голов» дигән әйтем еланга табынучы шул кабиләләр союзына карата кулланылган, ди.[52] Тарихи чыганаклардан аңлашылганча, Кашгари үзенең язмасында әлеге берләшмә халкының Көнчыгыш Төркестан һәм Жидесу төбәгендәге караханилар дәүләте хөкемдары Арслан-хан Сөләйман ибн Йосыф гаскәрләре белән бәрелешүе турында сүз алып бара. Еланга табынучы мәжүси кимакларның һәм сазаганны изгеләштерүче кыпчакларның X йөз уртасыннан ук ислам кабул иткән караханилар (карлуклар) белән оппозициядә булулары, Жидесуның төньяк-көнчыгыш регионында һәм Иртышның югары өлешендә кышлаулары, ә жәйләрен аерым кыпчак-кимак ыруларының көтүлекләре белән Болгар дәүләте чикләренә, шул исәптән Каманың / Ак Иделнең түбән агымына кадәр барып житүләре тарихчыларга билгеле.[52] Мәхмүд Кашгари сүзлеге аша шулай ук Арслан-ханның кимак-кыпчаклар белән бәрелеше турында эпик әсәр өзекләре дә килеп житкән. Аерым строфаларда караханиларга каршы яу белән килгән яки үзара союздаш булган кабиләләрнең исемнәре дә атап күрсәтелә. Сан ягыннан күп булсалар да, әлеге сугыш аларның жиңелүе белән тәмамлана.

*Будрач/ж йәмә кудурды,*
*Алпагутын агырды,*
*Сүсин йана калырды,*
*Кәлгәли-мәт иркишүр.*

*Басмыл сүсил камылты,*
*Барча кәлиб йумытты,*
*Арслан таба әмитти,*
*Коркуб башы тәзгинүр.*

*Әртиш сувы йәмәки,*
*Сытгаб тутар биләги,*
*Күрмәт аның йүрәги,*
*Кәлгәлимәт иркишүр.*

*Качан көрсә аны түрк*
*Будун анга айдачы:*
*«Мунар тәгир улуглук»,*
*Мунда нару кәслинүр*

*Т ә р ж е м ә с е:*

*Будраж янә ашкынды,*
*Батырларын данлады,*
*Гаскәрен янә борды,*
*Килергә жыенадыр.*

*Басмил гаскәре бирелде,*
*Барчасы да жыйналды,*
*Арсланга юнәлделәр,*
*Куркып башлар әйләнәдер.*

*Иртыш суы йәмәкләре,*
*Сызганылган беләкләре,*
*Ялкынлыдыр йөрәкләре,*
*Килергә жыена(лар)дыр.*

*Күргәннән соң [шунда] аны,*
*Әйтер төрек халкы ана:*
*«Моңа олуглык насыйп булды»,*
*Шуннан арысы тәмамдыр.*[53]

Без килгән нәтижәгә караганда, XI йөзнең башында һәм урталарында, мөгаен, нәкъ менә Кашгари язган һәм шулай ук башка чыганакларда чагылган бәрелешләр һәм күчешләр аркасындадыр инде, кимак-кыпчакларның бер өлеше «Дәште кыпчак» һәм Жидесу биләмәләреннән Каманың сул (төньяк) кушылдыгы булган Зәй буйларына да басып кергән булырга тиеш. «Дәфтәре Чыңгыз-намә» әсәрендә легендар формада тасвирланган Бараж еланы, минем фикеремчә, менә шул читтән кергән елан халкын гәүдәләндерә. Һәм әлеге елан атамасы шактый дәрәжәдә Бука Будраж исеме белән дә тәңгәл килә. Соңыннан инде «бараж» жиңүчеләрнең исеме-эпонимы буларак жирле халыкның да исеменә һәм оранына әверелә.[54] (Оран/уран — сугышчан кычкыру-чакыру авазы, кабиләнең пароле).

Моның чыннан да шулай булуына, ягъни Баражның Болгар жиренә үтеп кергән елан халкын (reconstr. кимак-кыпчакларны) белдергәнлегенә ышану өчен, тарихи чыганаклардан төрле дәлилләр китерергә мөмкин. Шундыйлардан Ризаэтдин Фәхретдин архивында сакланган һәм тарихчы Миркасыйм Госманов тарафыннан тикшерелгән барaж ыруының (кабиләсенең) шәҗәрәсе аеруча игътибарга лаек.[55] Анда — баражлыларның (белүебезчә, Бараж еланы турындагы риваятьтә алар «алыплар заманында», ягъни Болгар чорында Биләр шәһәренә нигез салучылар итеп күрсәтелә) Инсан-бәк шәхесе белән бәйле шәҗәрәсендә — Жадаш-бәктән башланган 20 буын конкрет кеше исемнәрендә (антропонимнарда) санап күрсәтелә. Егерме буын ул һәр буынга уртача 25-әр ел куеп исәпләгәндә 500 ел дигән сүз, һәм әлеге санны «Дәфтәре Чыңгыз-намә»нең якынча язылу чорыннан — 1650 (±25) елдан чигергәндә 1150 еллар тирәсенә туры килүче ел исәбе килеп чыга. Әгәр инде баражлыларның Буләр/Биләр буенда ныклап төпләнүләренә дә берничә буын гомере китәргә тиешлеген исәпкә алганда, соңгы сан тагын да борынгырак чорга чигәчәк, ягъни бараж халкының Зәй буеннан күченеп китүе XI йөзнең башына яки уртасына туры киләчәк. Бу дата гаҗәеп дәрәҗәдә караханилар идарәчесе Арслан-хан Сөләйман ибн Йосыф гаскәрләренең Мәхмүд Кашгарида күрсәтелгән Бука Будраж белән сугышуы һәм, фикеремчә, елан яугирләренең, җиңелгәч, өлешчә булса да Зәй буена үтеп керүләре вакытына туры килә. Менә Кашгари сүзлегендәге ул урын: «Всевышний обратил их в бегство в тот день, когда с ним сразился Арслан-тегин».[56]

Ике арадагы әлеге сугыш-бәрелешнең датасын шактый дөрес итеп казакъ тарихчысы С.М.Ахинжанов исәпләп чыгарган: «Согласно Кашгарскому, народ змей двинулся в поход при Арслан-тегине, т.е. где-то в промежутке между 1032-1057/58 гг., временем правления Арслан-хана». «Точная дата выплывает при сопоставлении информации Махмуда Кашгарского с данными Абу-л Фараджа. В послании несторианского митрополита Самарнада католиксу, отправленном в 1046 г., говорится о появлении в Караханидском государстве неведомого до этого многочисленного кочевого народа. Всадников было якобы 700000 под командованием семи царей».[57]


Димәк, Жидесу төбәгенә үтеп кергән елан кабиләләре (кимак- кыпчаклар) белән караханилар арасындагы сугыш үз чиратында Болгар жиренә баражлыларның (елан кабиләсенең) чынлап та бәреп керүенә китергән булып чыга түгелме?! Баражның Болгарга керү вакыты белән бараж шәҗәрәсе яшенең үзара ярашуы да, шулай ук әлеге уртак датаның Жидесу жирендә елан кабиләләренең караханилар белән орышу вакыты белән тәңгәл килүе дә әнә шундый зарури нәтиҗәгә китереп чыгара. Менә шуна күрә дә 20 буынлы (!) шәҗәрәләре сакланган баражлыларны без, шәҗәрәгә бәйле легендада Аксак Тимернең дә телгә алынуына карап кына (безнеңчә, бу кычкырып торган анахронизм — даталар, вакыйгалар буталышы!) Алтын Урда дәверенә чигермичә, Болгар дәүләте чоры белән бәйләп карау чын дөреслеккә туры килә дип исәплибез.

Безнең нәтиҗәне куәтли торган охшаш, хәтта турыдан-туры тәңгәл килүче башка төрле дәлилләр дә юк түгел. Мәсәлән, «Ви-пасанк» дигән әрмән эпосында да Мидиянең еланга табынучы жирле халкы алмаш этноним белән «мар» дип исемләнә (мар — халык этимологиясе буенча һәм фарсыча «елан»), патшалары исә Аждахак дип атала һәм ин характерлысы — әлеге эпос Тигран II-нең мидиялеләргә каршы сугышына мөнәсәбәтле тарихи вакыйгаларны гәүдәләндерә.[58] Яки менә турыдан-туры кыпчаклар һәм алар белән бер федерациядә булган кимаклар белән бәйләнешле мисал. Сыр-дәрьяның түбән агымы буенда яшәүче жирле халыктан язып алынган риваятьтә XI йөздә Урта Азиядәге угызлар дәүләтен тар-мар иткән кыпчаклар һәм каи-кимаклар шулай ук еланга тиңләнә һәм Сыр-дәрья тамагындагы Джанкент (Янкент/Янгикент=Яңакент) шәһәре еланнар явыннан һәлак булды дип күрсәтелә.[59] Кимаклар кабиләсе «имәк»/«йемәк» атамасының алтайча һәм «каи» сүзенең монголча мәгънәләре дә «елан» дигәнгә туры килә һәм бу исем белән аталучы халыкның этник тамгасы да «елан» була.

Италия сәяхәтчесе Марко Полоның кульязмаларында теркәлгән мәгълүмат буенча (XIII йөз), безгә кыпчакларның Натигай исемле мәҗүси алласы булганлыгы да

билгеле.[60] Себер татарларында әлеге исем «нацагай» рәвешендә сакланган, күктән елан шикелле бөгәрләнеп яки чатлы-ботлы булып төшкән яшенне белдерә.[61] Казан татарлары телендәге «нажагай» (варианты — «ажаган») сүзе дә шул ук тамырдан, игеннәр өлгергән вакытта төннәрен офыкта уйный торган яшенне, белүебезчә, шулай диләр. Бу сүзләрнең һәм шуларга бәйләнешле ышануларның нигезе дә төрки бабаларыбыз изгеләштергән елан-сазаганга барып тоташа. Чөнки әлеге канатлы һәм чуклы яки балык койрыклы илаһи зат күк һәм яшенне, явым-төшем һәм сулыкларны бергә бәйли торган образ итеп тә күз алдына китерелгән. Борынгыдан калган сынамышларны искә төшерик: а) Мәхмүд Кашгарида: «Ләү елы килсә, явым-төшем һәм уныш күп буладыр, чөнки ул суда яши»[62]; б) халыкта: «Салават күперенең (гетг. күк еланының) ике башы да суга төшсә, яңгыр булыр».

Ләкин кыпчак-кимакларның Болгар җиренә монголлар явына кадәр үк үтеп керүен исбатларга ярдәм итә торган ин ышанычлы күрсәткеч, әлбәттә, тел. Менә монда инде безгә Болгар чорына бәйләнешле тел катламын нечкәләп һәм чагыштырып тикшергән Р.Г.Әхмәтҗанов, Ф.С.Хәкимҗанов һәм Д.Г.Мөхәммәтшин кебек күренекле телчеләрнең хезмәтләре җитди таяныч була ала. Үзләренең тикшеренүләрендә алар барысы да Болгар дәүләтенең үзәк шәһәрләре һәм көньяк, көньяк-көнбатыш биләмәләре монголлар килгәнче үк инде кыпчаклашкан булганнар дигән уртак нәтиҗәгә киләләр. Менә әлеге галимнәрнең хезмәтләреннән аерым өзекләр:



*Казан ханлыгы флагы. Әлеге сурәт Карлус Алярдның 1705 елда Амстердамда басылган һәм 1709 елда рус теленә тәрҗемә ителгән китабында бирелгән.*

а) Р.Г.Әхмәтҗанов: «Племена, говорящие на языках кыпчакского (небулгарского) типа, были уже в составе булгарских племен, пришедших в Среднее Поволжье из Приазовья». «Вышеприведенный комплекс западнокыпчакских, куманских слов, распространенных в Среднем Поволжье уже мусульманской Булгарии, говорит о том, что кыпчакоязычные предки татар жили в древней Булгарии и оказали огромное влияние на культуру местного населения». «Возможно даже, что центры Булгарского государства — города Булгар, Сувар и Биляр — к XII в. уже оказались кыпчакизированными». «В основной, заволжско-закамской части Булгарии к началу XIII в. кыпчакское население доминировало... Монгольское завоевание привело к еще большему усилению кипчакского элемента в Среднем Поволжье».[63]

б) Ф.С.Хәкимҗанов, Д.Г.Мөхәммәтшин: «Проникновение западных кипчаков в Волжскую Булгарию [происходило] с начала XI века (отдельные небольшие группы, видимо, были еще раньше в составе булгарского союза племен), которые занимались ремеслами, торговлей, земледелием и нанимались в армию. В летописях, например, имеется такой факт: во время похода русских князей на Великий город (то есть на Биляр) в 1183 году уже на булгарских землях к ним присоединились «емяковы половцы» во главе с булгарским князем. Это были йемеки, одно из тюркских племен, входившее ранее в кимако-кипчакскую федерацию на севере Центральной Азии». «Считается, что к XII веку сформировался обобщенный тип речи более высокого порядка — булгарское наддиалектное койне общетюркского характера... Его устная форма сложилась при подавляющем преимуществе кипчакских элементов, и она была созвучна с деловым языком Золотой Орды».[64]

Димәк, телчеләрнең мондый нәтиҗәләре легенда-риваятьтәге Бараҗ еланының кимак-кыпчакларны гәүдәләндерүе турындагы безнең карашны тагын да нигезләрәк, ышанычлырак итә. Безнең караш исә, үз чиратында, телчеләрнең нәтиҗәләрен куәтли. Дөрес, әлеге галимнәрнең концепциясендә без килешми торган эклектизм элементлары, нигезсез фаразлар да юк түгел. Мәсәлән, Р.Г.Әхмәтҗановның «татар

этносының нигезе» Болгар дәүләте чорында ук барлыкка килгән дип раславы һәм Алтын Урда чорына бәйләнешле монгол-татар (кыпчак) нигезе»н икенче планда калдырып, татар халкының барлыкка килүендә әлеге ике катламның да бердәй роль уйнавын танымавы. Ләкин әлеге галимнәрнең карашлары болгар теле белән кыпчак-татар теле арасында тигезлек билгесе куймаулары, иске татар телен болгар теленең (ягъни «г — телнең», чагыштырыгыз: хер — кыз, жүр — йөз, тухыр — тугыз, отур - утыз) турыдан-туры дәвамы итеп карамаулары белән көчле. (Ә бит «болгарчы» галимнәр һәм, гомумән, «болгарчылар» моның нәкъ киресен исбатларга һәм татар телен дә, татарларны да турыдан-туры болгарлардан чыгарырга тырышалар!) Һәм өстәп әйтергә кирәк: алда исемнәре аталган галимнәрнең Болгар дәүләтендә, болгар этнос-кавеменнән тыш, кимак-кыпчаклар һәм өлешчә угызлар да булганлыгын танулары һәм иске татар теленең чишмә башын шул телләргә үк илтеп тоташтырулары, һичшиксез, халкыбыз һәм телебез тарихына иң дөрес якын килү булып санала ала. Менә шушы принципиаль аерманы аңламыйча, яңа буын галимнәренең Болгар дәүләте чорын халкыбызның тернәкләнү-этногенез этабыннан чыгарып ташларга маташулары бер читтән икенче читкә ташланудан башка нәрсә түгел.

Болгар дәүләтенең көньяк һәм көньяк-көнбатыш биләмәләрендә болгар теле татар-монголлар явына кадәр үк инде кыпчаклашканга күрә дә, рус елъязмаларында «у кипчаков с болгара язык и род один» дип билгеләнүе бик табигый. Һәм ассызыклап әйтергә кирәк, кыпчакларның болгарлар белән берләшеп-кушылып китүе археологик табылдыклар һәм тикшеренүләр белән дә раслана. Бу турыда археолог Фаяз Хужин, соңгы вакытта ясалган ачышларга таянып, менә ничек яза: «В последние годы появились интересные археологические факты, свидетельствующие о заметном участии кыпчакского компонента в формировании этноса и культуры волжских булгар XI – начала XIII в.» *[История татар с древнейших времен. – Казань, 2006. – Т.1. – С. 138].*

Билгеле, болгар кабиләләре белән угыз-кыпчаклар кушылуы җирлегендә формалашкан татар халкының сөйләмендә болгарлар белән уртак булган сүзләр дә сакланып калган, чөнки алар асылда архаик диалектта сөйләшүче төрки халык булган. Шул ук вакытта Болгар чорыннан ук килүче аерым милли-этник традицияләр, мәсәлән, язгы кыр эшләре алдыннан үткәрелүче Сабантуй бәйрәме килеп җиткән. Әлеге бәйрәмнең тамырлары болгар кабиләләренең Төньяк Кавказда һәм Азов диңгезе буенда яшәгән чорына ук барып тоташа. Кавказ халыкларында Сабантуй бәйрәме кебек ат чабышларын, төрле ярышларны эченә алган һәм ел да зурлап үткәрелә торган Беренче буразна бәйрәме булуы мәгълүм. Аны бездәгечә диярлек «Сабан бәйрәме», «Сабанга чыгу», «Басу туе» кебек төрле исемнәр белән атап йөртәләр.Һәм аерып әйтергә кирәк, балкарларда һәм карачайларда тимер төрәнле агач сука «сабан» дип атала да. Чувашларда исә Сабантуе Акатуй яки Яка яшки дип йөртелә *[Чурсин Г.Ф. Праздник «выхода плуга» у народов Дагестана // Изв. Кавказского историко-археологического музея. – Тифлис, 1927. – С.87-89; Булагова А.Г. Идеологические представления аварцев, нашедших отражение в празднике первой борозды // Мифология народов Дагестана. – Махачкала, 1984. – С.82-98].*

Тагын бер җитди өстәмә. Телчеләрдән академик Н.А.Баскаков белән Г.М.Гарипов татарларның килеп чыгышында кимак-кыпчаклар берләшмәсенә керүче йемәкләр аеруча зур роль уйнаган дип исәплиләр.[65] Р.Г.Әхмәтҗанов ачыклавынча, фарсы телле чыганакларда «йемәк» һәм «татар» вакыт-вакыт бер-берсен алмаштырып килгәннәр һәм, кардәш телләр буларак, көнбатыш кыпчак теленә бик якын торганнар.[66] Моңа гаҗәпләнергә кирәкми, кыпчаклашкан кимак кабиләләре (баштагы исемнәре — кай, каи) заманында «татар» исемен йөртүче халыктан чыккан булганнар. Кимаклар шулай ук себер татарларының да төп нигезен тәшкил иткәннәр. Күренекле телче Әмир Нәҗипнең бер үзенчәлекле тикшеренүе дә шушы ук рәткә килеп ялгана. Ул Әсир əд-Дин Әбү-Хайян исемле гарәп кешесе тарафыннан Мисырда төзелгән борынгы сүзлектә, «кыпчак»ныкы һәм «угыз»ныкы дигән язулардан тыш, бериш сүзләр янында «болгар», «татар», «токсуба», «уйгыр» дигән билгеләмәләр булуына

игътибар итә. Шунда ук «токсуба — кыпчак татарларының кабиләләре» («племена из кыпчакских татар») дигән үзенчәлекле гыйбарә булуын да күрсәтә. Галим чыгарган нәтиҗә кызыклы: «Это объяснение в свою очередь позволяет предполагать, что издавна в Дешти-кыпчак жили какие-то племена, которые называли себя татарами. Если так, то прибывшие в Египет во время правления султана Бейбарса (1259-1277) татарские эмиры (имена которых явно татарские — Кучкар Муган, Тангри-берди, Алабай) являлись коренными жителями кыпчакских степей. **Следовательно, племена, носившие название татар, жили в Дешти-кыпчаке и до прихода монголов на эту территорию»**[67] (аерып язу безнеке — **М.Б.**). Бу инде, димәк, югарыдагы мәгълүматлар монгол-«татарлар»га кадәр үк Болгар җиренә кыпчак-кимак (кимак / йемәк) кабиләләре составында татар исемен йөртүче кавем-этносның да үтеп керү ихтималына юл калдыра дигән сүз. Ләкин «татар» атамасының җыелма этноним буларак кыпчаклашкан болгарларга, шулай ук Идел-Кама буена кат-кат килеп төпләнгән кыпчак-кимакларга һәм алар белән кушылган башка кавемнәргә карата да кулланыла башлавы, һичшиксез, монгол-«татарлар»дан соңгырак чорга туры килгән һәм гомумхалык исеме буларак акрынлап урнашкан. Һәм әйтергә кирәк: ерак бабаларында болгар каны да катнашканлыгын таныган аерым шәхесләр вакыт-вакыт архаик атама буларак «болгар» этнонимын да тәңгәл рәвештә кулланып килгәннәр.

Без сүзебезне, дөресрәге Болгар чорына бәйләнешле дәлилләребезне Алабугадан башлаган идек. Ахырда тагын бер кат шул төбәккә мөрәҗәгать итик һәм бу юлы Алабуга шәһәренең атамасына тукталыйк. Минем карашымча, әлеге атама да борынгы ышанулар һәм мифологик легендалар дөньясына алып бара. «Алабуга» сүзен гадәттә русча «окунь» дигән мәгънә белдерүче балык исеме белән бәйләп карыйлар, йә булмаса, җитдирәк фикер йөрткәндә, бу сүзне үгез мәгънәсен белдерүче сүзгә кайтарып калдыралар: димәк, Алабуга атамасы «ала үгез» дигәнне белдерә булып чыга. Ләкин, минем карашымча, тәкъдим ителә торган әлеге мәгънәләрнең берсе дә ышандырырлык түгел, чөнки алар тарихи һәм географик реалийлар белән ярашмыйлар. Хәтта сүз барган балыкның башы үгез башына охшаган һәм шуңа «алабуга» (ала үгез) дип аталган тәкъдирдә дә ни өчен әлеге атаманың шәһәр исеме булып китүе аңлашылмый.

Минем фикеремчә, Алабуга — борынгы ике төрки сүздән ясалган катлаулы-кушма исем. Аның «ала» дигән беренче өлеше элек Үзәк һәм Урта Азиядә, Кавказда яшәгән һун-болгар бабаларыбызның телендә үк булган һәм соңрак чордагы төрки халыкларда сакланган. Ачыклап әйткәндә, Ашина ыруының беренче башлап чыккан төбәгенең исеме — Алашань[68]: Әлеге атаманы төзүдә катнашкан һун-төрки сүзе «ала» да, кытай сүзе «шань» да тау мәгънәсен белдерә. Кыпчак семьялыгына керүче үзбәкләрдә, казакъларда һәм кыргызларда «ала» лексемасының борынгы мәгънәсе шулай ук «тау», «калкулык».[69] Кытай оронимы Тяньшаньның төрки атамалары Ала+таг, Ала+тоо, Ала+тау шушы ук сүз катнашында ясалган; димәк, әлеге кушма исемнәрнең һәр ике яртысы да тау төшенчәсенә туры килә булып чыга. Аерым сүзләрнең баштагы эчтәлеге тоныкланган яисә онытылгач, аларга шул ук мәгънәле башка сүзләрнең катлы-катлы булып ялгануы борынгы топономик атамалар өчен, гомумән, гадәти күренеш ул. Алтай тавы, Памир системасына керүче Алай сырты, Төркия җирендәге Алаҗадаг, Алаҗаһөйүк исемле тау тезмәләре, Әрмәнстан территориясендәге әрмәнчә Араган, төрекчә Алагеоз дип йөртелә торган тау-калкулык исемнәре дә шул ук тамырдаш атамалар исемлеген дәвам итә. Моннан тыш, төрекмәннәрдә өсте тигез калкулыкны белдерүче «ала+н», тауны белдерүче «ала+нг» сүзләре бар. Һәм, әлбәттә, Алтай телләренә керүче тунгус-манчжурларда калкулыкның — «ала», монголларда тауның «ола» дип йөртелүе дә, һичшиксез, шушы ук рәткә, уртак тамырга килеп тоташа. Ләкин бу очракта иң әһәмиятлесе шунда: безне кызыксындырган Алабуга атамасы составында да, ягъни аның «ала» өлешендә, минем ышануымча, гасырлар тирәнлегеннән килүче шул ук сүз-тамыр һәм «тау» мәгънәсе ята.

Билгеле, «ала» сүзенең «пегий» дигән борынгы мәгънәсе дә юк түгел. «Алабуга» сүзенең «окунь» балыгын белдерүче вариантында ул нәкъ шул мәгънәдә килгән дә.

һәм әйтергә кирәк: Пермь һәм Чиләбе өлкәләрендәге Алабуга дип йөртелүче күлләр дә үз атамаларын, һичшиксез, суларында шул исемдәге балык булуына карап алынган булырга тиеш. Ә менә сулыкның түгел, ә Кама буендагы шәһәрнең балык исеме белән аталуы аек акылга сыймый. Шуңа күрә дә без «Алабуга»ны кушма исем итеп карыйбыз да һәм географик атамаларның мотлак рәвештә тарихи чынбарлык белән ярашырга тиешлегеннән чыгып, әлеге сүзнең икенче яртысын да жирле фактлар белән бәйләү — иң дөрес юл дип исәплибез.



*Алабуга каласындагы мәчет-кальганың бүгенге көннәргә кадәр сакланып калган манарасы. Уң якта өчпочмак рәвешендә мәчетнең михраб урыны.*

Ачыклап әйткәндә, Алабуга сүзенең икенче яртысы — буга / бука өлеше, алда XI йөз галиме Мәхмүд Кашгаридан китерелгән өзектә күрсәтелгәнчә, «зур елан» дигән мәгънәгә туры килә. Бука сүзе заманында Арал дингезе буенда, Дон елгасының түбәнге өлешендә һәм Төньяк Кавказда яшәгән болгар һәм кыпчак кабиләләре аша Көнбатыш Дагыстандагы аерым халыкларга да бераз үзгәргән формада үтеп кергән. Мәсәлән, аварларга якын торучы тиндаль/тиндин телендә «бека» — елан, ахвак телендә бека — елан, бежтин телендә «бекела» — елан, чеченнарда «бцха — шулай ук елан. Монда без борынгы чор өчен гадәти күренеш булган к һәм г (к=г) авазлары чиратлашуы белән очрашабыз. Чагыштырыгыз: баку/багу, арку/аргу — тау үзәне, йатак/йатаг, бу көн/бүген, аулак өй/аулагый. Әлеге күренеш болгар чорындагы кабер ташы язмалары өчен дә хас: йекет/егет, токыр/токыз/тугыз, битик/битиг — язма, бәлүк/белегъ — билге. Болардан инде без тикшерә торган «буга» сүзенең «бука» белән аваздаш булуы, аның фонетик вариантын тәшкил итә алуы турында нәтиҗә чыгару кыен түгел. Телче тюркологлар хәтта әлеге охшаш яки тамырдаш сүзләрнең килеп чыгышын бергә бәйләп карыйлар һәм гомумалтай телләрендә «буга» лексемасы үгезне генә түгел, ә кыргый яки ерткыч жанварны да белдерү өчен кулланылган дигән карашта торалар.[70] Болгар, Казан жирлегендә дә үгез белән елан-сазаган образларын бергә бәйләгән мифологик легенда булганлыгы мәгълүм. Без монда Казан салыначак урында яшәгән ике башлы аждаһаның бер башы үгезнеке, ә икенчесе еланныкы дип сөйләнелгән легенданы күздә тотабыз. [71]

Монда урынлы сорау туарга мөмкин: зур еланны белдерүче сүз Мәхмүд Кашгарида вькд/бүкә рәвешендә бирелгән бит, ә Алабуга исемендәге — «буга» калын әйтелешле — мондый күчеш-үзгәрешне ничек анларга? Безнең карашыбызча, бүкә халык телендә, һичшиксез, бука/буга рәвешендә дә йөргән булырга тиеш. Татар телендә һәм аның көнбатыш диалектында балаларны куркыту өчен кулланылган әлеге архаик сүзнең бүкәй/бүки һәм букай/мукай вариантларында сакланып калуы шуны раслап тора. Шушы ук сүз бука, мокай һәм мохай рәвешендә, ягъни калын әйтелештә рус, алтай һәм якут телләрендә дә сакланган. Бу дәлилләр, димәк, «ала» тамырына әлеге лексема нәкъ менә бука/буга формасында ялганган дип карарга ышанычлы нигез була ала. Аннары бу очракта төрки телләргә хас сингармонизм күренешен дә исәптән чыгарырга ярамый. Мәсәлән, без «Алла бирсә» димибез, ә баштагы калын әйтелешле сүзгә ияреп «Алла бирса» дип сөйлибез. Кыскасы, бука/буга сүзенең калын әйтелештә дә булганлыгы яки була алуын раслау өчен дәлилләр житәрлек дип уйлыйм.

Шулай итеп, без Алабуга атамасы ике өлештән, ягъни борынгы ике төрки сүздән тора дигән нәтиҗәгә киләбез. Аларның беренчесе, ала сүзе — «тау», икенчесе, буга

сүзе исә «елан» («зур елан») дигән мәгънәләргә туры килә, димәк, икесе бергә «Тау-елан» яки «Елан-тау» дигән мәгънәне белдерә булып чыга. (Сүз тәртибе үзгәрә-алмашына торган гыйбарәләргә мөрәҗәгать итегез: Тимер-хан — Хан-тимер, Тан сылу — сылу тан, көн озын — озын көн, язамын — мин язам). Бу, әлбәттә, шактый борынгы, архаик гыйбарә, мәгънәсе буенча ул соңгы дәверләрдә кулланыла торган «Елан-тау» (Елан тавы) атамасына туры килә. Димәк, «Алабуга» сүзенең без тәкъдим итә торган мәгънәсе-этимологиясе тулысынча тарихи һәм географик реалийлар белән үзара ярашып тора, ягъни ул «Шайтан каласы»нда яшәгән елан-сазаган турындагы легендага да, шулай ук әлеге каланың шактый текә тау өстенә урнашкан булуына да һәм, әлбәттә, еланны изгеләштергән болгар һәм кимак-кыпчакларның уртак мифологик карашларына да тәңгәл килә.

Инде төп нәтиҗәне ясыйк. Сөйләгәннәрдән күренгәнчә, тарихи фольклорыбыз һәм тел фактлары безне турыдан-туры яки урау юллар белән Болгар җирлегенә илтеп чыгара. Бу, һичшиксез, халык хәтеренең тарихи аңның Болгар дәүләте тарихына һәм культурасына тоташуы белән бәйле. Алай гына да түгел, безнең этногенетик тамырларыбыз һәм этник аңыбыз да шунда тоташкан, кендегебез өлешчә булса да шунда берекккән. Чөнки Болгарның көньяк һәм көнчыгыш биләмәләренә үтеп кергән кимак-кыпчаклар һәм алар кыпчаклаштырган болгарлар татар этносының һәм иске татар теленең тернәкләнә башлавы өчен иң борынгы җирлек булганнар. Бу инде, димәк, Идел-Кама буенда яшәгән бабаларыбызның иң тәүге буыннары тарихы һәм дәүләтчелегебезнең беренче этабы Болгар дәүләте чорына туры килгән дигән сүз.

### Кулланылган әдәбият


1 В.К.Соколова. Русские исторические предания. — М.: Наука, 1971. — С. 27.

2 Л.С.Толстова. Исторические предания Южного Приуралья. — М.: Наука, 1984. — С. 19.

3 Казанская история. Историческая повесть XV в. — М.-Л.: Изд. АН СССР, 1954. — С. 194; М.А.Усманов. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв. — Казань: Изд. КГУ, 1972. — С. 113,165.

4 П.П.Рычков. Опыт Казанской истории древнейших и средних времен. — Спб., 1767. — С. 45-46; Н.П.Рычков. Журнал и дневные записки путешествия по разным провинциям Российского государства 1769 и 1770 годов. — Спб., 1870. — Ч. I. — С. 60-67.

5 Платон Заринский. Сборник исторических и археологических исследований о Казанском крае. — Казань, 1880. — С. 76, 83; А.Х.Халиков. О времени, месте возникновения и названии города Казани // Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. — Казань: Тат. гос. изд., 1976. — С. 3-19.

6 С.П.Мелиоранский. Об орхонских и енисейских надгробных памятниках с надписями // Журнал министерства народного просвещения. — Спб., 1898. — Ч. 317. — С. 269.

7 С.И.Руденко. Культура хуннов и Ноинулинские курганы. — М., Изд. АН СССР, 1962. — С. 205.

8 А.В.Гадло. Этническая история Северного Кавказа IV-X вв. — Л.: Изд. ЛГУ, 1979. — С. 145; Мовсэс Каланкатуци. История страны Алуанк. — Ереван: Изд. АН Арм. ССР, 1984. — С. 127.

9 Мурад Аджи. Полынь половецкого поля. — М.: ТОД «Пик-контакт», 1994. — С. 87, 335-336.

10 С.М.Ахинжанов. Кипчаки в истории средневекового Казахстана. — Алма-Ата: «Наука» Казах. ССР, 1989. — С. 133-135.

10а Восточный Туркестан в древности и раннем Средневековье - М.: Наука, 1992. — С. 76.

11 Фирдаус Салихова. Родословная дракона // Идель. — Казань, 1990. — №9. — С. 32-33.

12 Ф.Х.Арсланова, С.Г.Кляшторный. Руническая надпись на зеркале из верхнего Прииртышья // Тюркологический сборник. — 1972. — М.: Наука, 1973. — С. 306-315.

13 С.Г.Кляшторный. Рунические надписи из Кургана Аржан II // Первобытная археология Сибири. — Л.: Наука, 1975. — С. 184.

14 Манас. — Фрунзе: Гилем, 1958. — 368 б.; Манас. Киргизский героический эпос. Великий поход. — М.: Гос. изд. художест. лит-ры, 1946. — С. 372.

15 Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1975. — Т. 2. — 46 б.

16 Рашид ал-дин Фазлаллах. Огуз-наме. — Баку: Элм, 1987. — С. 19, 83-84.

17 С.М.Шпилевский. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губерне. — Казань, 1877. — С. 281.

18 Казанская история. Историческая повесть XV и. — М.-Л., Изд. АН СССР, 1954. — С. 91-92.

19 Платон Заринский. Алда күрсәтелгән хезмәт, 73-74 б.; А.Х.Халиков. Алда күрсәтелгән хезмәт, 13-14 б.

20 В.Я.Пропп. Исторические корни волшебной сказки. — Л.: Изд. ЛГУ, 1986. — С. 219.

21 Анау // БСЭ. — Т. 1. — С. 578; Г.А.Пугаченкова. Мечет Анау. — Ашхабад, 1959. — С. 58.

22 А.М.Решетов. Дракон в культурной традиции китайцев // Материальная культура и мифология. — Л.: Наука, 1981. — С. 87.

23 Е.П.Бусыгин, Н.В.Зорин, Л.С.Токсубаева. Декоративное оформление сельского жилища в казанском Поволжье. — Казань: Тат. кн. изд., 1986. — С. 82-83.

24 А.Х.Халиков, Р.Ф.Шарифуллин. Исследование комплекса мечети // Новое в археологии Поволжья. — Казань, 1979. — С. 27-28; А.Х.Халиков. Алабуга — Елабуга. — Елабуга, 1997. — С. 32.

25 Ф.Х.Валеев. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. — Йошкар-Ола: Мар. кн. изд., 1975. — С. 101.

25а Опись Московской оружейной палаты. Знамени, прапоры, значки, флаги и штандарты.

— Спб., 1884. — Ч. III (Кн. I). — С. 130.
26 А.М.Курбский. Сказание о покорении Казани. — М., 1902. — С. 104.
27 Г.А.Пугаченкова. Алда күрсәтелгән хезмәт, 46 б.
28 В.А.Гордлевский. Что такое «босый волк»? // Известия АН СССР. Отд. лит-ры и языка. — М., 1947. — Вып. 4. — С. 326-337.
29 В.А.Гордлевский. Избранные сочинения. — М.: Изд. вост. лит-ры, 1960. — Т.1 — С. 164.
29а Шунда ук, 203 б.
30 Идегәй. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. — 153 б.
31 Мифы народов мира. Энциклопедия. — М.: Советская энциклопедия, 1987. — Т. I. — С. 449.
32 История Европы. — М.: Наука, 1999. — Т. 1. — С. 109; Вс.Ф.Миллер. Очерки в связи с древнейшей культурой. — М., 1876. — Т. 1. — С. 161.
33 Мифы народов мира. Энциклопедия. — Т. 1. — С. 529-530.
34 Толковая Библия. — Пб., 1904-1907. — С. 24-27; Мифы народов мира. Энциклопедия. — Т. 2. — С. 159.
35 Б.А.Рыбаков. Язычество древней Руси. — М.: Наука, 1987. С. 544-545.
36 Полое собрание русских летописей. — Спб., 1841. — Т. 1. — С. 279.
37 В.П.Адрианова-Перетц. Очерки поэтического стиля древней Руси. — М.-Л., Изд. АН СССР, 1947. — С. 94.
38 С.Б.Адоньева. Особенности структуры и семантики змееборческого сюжета в фольклоре и письменной традиции // Русский фольклор. — Л.: Наука, 1989. — С. 104.
39 Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. Төзүчесе С.М.Гыйләҗетдинов. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1987. — 50-53, 302-303 б.
40 Платон Заринский. Алда күрсәтелгән хезмәт, 83-84 б.
41 П.С.Паллас. Путешествие по разным местам Российского государства. — Спб., 1786. — Ч. II. кн. II. — С. 330.
42 А.Х.Халиков. О времени, месте возникновения и названии города Казани, с. 17-18.
43 Большой энциклопедический словарь. Мифология. — М.: Большая Российская энциклопедия, 1998. — С. 116.
44 В.Н.Татищев. История Российская. — Спб., 1877. — Т. 3. — С. 226.
45 Б.А.Рыбаков. Алда күрсәтелгән хезмәт, 629 б.
46 Г.К.Вагнер. Скульптура Древней Руси. — С. 27-28.
47 Английские путешественники в Московском государстве в XVI веке. — Л., 1938. — С. 87-88.
48 Шунда ук, 88 б.
49 Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар, 31-32, 297 б.; М.А.Усманов. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв. — Казань: Изд. КГУ, 1972. — С. 113.
50 Шунда ук, 293-294 б.
51 Мәхмүд Кошгари. Дивану луготит түрк. — Тошкент: Узбек. ССР ФА нашр., 1963. — Т. 3. — 247 б.
52 С.М.Ахинжанов. Из истории движения кочевых племен евразийских степей в первой половине XI в. // Археологические исследования древнего и средневекового Казахстана. — Алма-Ата: Изд. «Наука» Каз. ССР, 1980. — С. 50-51; его же: Кыпчаки в истории средневекового Казахстана. — Алма-Ата: «Наука» Каз. ССР, 1989. — С. 184-185; В.В.Бартольд. Сочинения. М.: Наука, 1970. — Т. II. — С. 46.
53 И.В.Стеблева. Развитие тюркских поэтических форм в XI веке. — М. Наука, 1971. — С. 129-130, 253.
54 Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар, 32 б.
55 М.А.Усманов. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв. — Казань: Изд. КГУ, 1972. — С. 174-178.
56 Мәхмүд Кошгари. Алда күрсәтелгән хезмәт, 247 б.
57 С.М.Ахинжанов. Кипчаки в истории средневекового Казахстана, с. 184-185; его же: Из истории движения кочевых племен евразийских степей в первой половине XI века, С. 53.
58 Мифы народов мира. Энциклопедия. — Т. I. — С. 50.
59 С.М.Ахинжанов. Кипчаки в истории Казахстана, с. 188-189.
60 М.П.Алексеев. Сибирь в известиях западно-европейских путешественников и писателей. — Иркутск: ОГИЗ, 1941. — С. 35.
61 Ф.Г.Валеев. Западно-Сибирские татары. — Казань: Тат. книжн. изд., 1980. — С. 199.
62 Мәхмүд Кошгари. Алда күрсәтелгән хезмәт. — Т. 1. — 330 □.
63 Р.Г.Ахметьянов. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков. — М.: Наука, 1978. — С. 220, 239-240.
64 Д.Г.Мухаметшин, Ф.С.Хакимзянов. Эпиграфические памятники города Булгара. — Казань: Тат. гос. издат., 1987. — С. 91-93.
65 Т.М.Гарипов. Махмуд Кошгари и кыпчакские языки Урало-Поволжья // Советская Тюркология. — Баку, 1972. — №1. — С. 48-49.
66 Р.Г.Ахметьянов. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков, С. 21, 239.
67 Э.Н.Наджип. Тюркоязычный памятник XIV в. «Гулистан» Сейфа Сараи и его язык. — Алма-Ата: Изд. «Наука» Каз. ССР, 1975. Ч. I. — С. 45-46.
68 Н.Г.Гумилев. Этничекая история Тибета в I тыс. н. э. в связи с историей сопределенных стран // Центральная Азия и Тибет. — Новосибирск: Наука, 1972. - С. 75.
69 Т.Жанүзак. Казак ономастикасы. — Алматы: Дайк-Пресс, 2007. — 283 б.
70 Э.В.Севортян. Этимологический словарь тюркских языков. — М.: Наука, 1978. — С. 230-232, 237.
71 А.Х.Халитов. О времени, месте возникновения и названия города Казани, С. 9.

**Марсель БАКИРОВ,**
*филология фәннәре докторы, КФУ профессоры*

# КАНАТЛЫ БИЮЧЕ

Әгәр халкыбызның шанлы һәм фаҗигале үткәнен күз алдына китереп карасаң, күңелгә моңсулык белән бергә ихлас горурлык хисләре дә кереп тула, чөнки милләтебезнең озын юлында бик күп асыл затлар килеп киткән. Алар кояш кебек җиһанны яктырткан, яшәешкә өмет, ышаныч уяткан, мәгыйшәтне мәгънәле иткән. Шөкер, олы шәхесләр, талант ияләре безнең көннәрдә дә мәйданга чыга тора. Гаять күркәм, көмеш тавышлы Альбина Шаһиморатова матур тавышы, җырлары белән дөнья халкын таң калдырды. Матбугатта хәбәр ителгәнчә, хәзер аны үз сәхнәләрендә күрер өчен галәмнең иң күренекле опера театрлары чират тора икән.




Вакыт ягыннан бераз алдарак балет сәнгатенә даһи биюче Рудольф Нуриев килде һәм дөньяда беренче биюче дәрәҗәсенә иреште. Табигый, аның буй җитмәс таланты күпләрне, шул исәптән әдипләрне дә кызыксындыра. 2008 елда Равил Вәли аның турында «Канатлы татар» дигән роман язып бастырды *(«Казан утлары», 2008, № 2-4)*. Үткән ел Рабит Батулланың «Бию җене кагылган егет» романы дөнья күрде *(Казан: Татар.кит.нәшр., 2012. – 391 б. 2500 данә)*. Сәнгать дөньясы Батуллага яхшы таныш һәм якын. Ул үзе сәхнә серләрен нечкә тоючы профессиональ артист та, драматург та, Сөембикә, Тукай образларын романнарда җанландырган әдип тә. Өлкән улы Нурбәкне бәләкәй чактан ук балет спектакльләренә йөртә, күңелендә сәнгатьнең шушы төренә карата кызыксыну уята, Казан хореография училищесына укырга бирә. Хәзер Нурбәк Петербург консерваториясендә балетмейстер белгечлеге буенча белем ала. Миңа берничә тапкыр аның ут яндырып биюен күрергә туры килде. Ә менә төпчеге Байбулатка балетка кереп китәргә киңәш итми. Шулай да Байбулат мөстәкыйль рәвештә бию сәнгате өлкәсен сайлый. Ул Казан хореография училищесының халык биюләре бүлегендә укып чыга. Кыскасы, Батуллага әлеге хаятне романда яктырту шөгыленә тотыныр өчен сәбәпләр аз түгел. Өстәвенә Рабит белән Рудольф — яшьтәшләр дә бит әле: икесе дә 1938 елның март аенда дөньяга килгән, 2013 елда аларга 75 тула. Аеруча рухландырганы, әлбәттә, бөек шәхескә ихлас хөрмәт, аның тиңсез сәнгатенә соклану булгандыр.

Батулла ошбу әсәренең үзенчәлеген «Рудольф Нуриев тормышының кайбер мизгелләре» дип билгеләгән. Ул мизгелләр, беренчедән, тирән мәгънәле, мавыктыргыч, икенчедән, киеренке эчтәлекле тоташ сюжетны барлыкка китерәләр.

Биюче образы барыннан да бигрәк биюендә ачыла. Ләкин Батуллага типик оста артистны сурәтләү генә җитми. Аңа гадәттән тыш биючене күрсәтергә кирәк. Батулла Рудикның сабый чагыннан ук бию белән чамадан тыш кызыксынуын, мавыгуын, бернәрсәгә дә карамыйча, шушы өлкәгә омтылуын, теләгенә ирешүдә нык торуын тасвирлый.

Күренекле хореограф Фәйзи Гаскәров җитәкчелегендәге артистлар кон-

Батулла Р. Бию җене кагылган егет.—Казан: Татар. кит. нәшр.; 2012.—391б.

цертын сабый Рудик исе китеп карап утыра, түзми, тамаша барышында ук бию хәрәкәтләрен кабатлап бара, өенә кайтып барышлый дәвам иттерә. Кешеләр бу балага шаккатып, яратып, ләззәтләнеп карап торалар, хуплыйлар, дәртләндерәләр, концертларга чакыралар. Тик бар кеше дә бердәй куанмый. Фронттан кайткан әтисе, майор Хәмит Нуриев бию сәнгатенең мәгънәсен, рухи кыйммәтен аңламый, төпчегенең омтылышын әһәмиятсез мавыгу дип саный. Файдалы эш белән шөгыльләнүне таләп итә. Ул Рудиктан артиллерия офицеры ясарга тели. Малайның омтылышына каршы төшә. Биюгә артык игътибар иткәне өчен, аны тәпәләп тә ала. Күрәсең, халык аваз иҗатында киң таралган такмак аның күңеленә тирән кереп урнашкан булса кирәк:

*Бие, бие, Хәйбулла,*
*Биегән кеше бай була,*
*Биегән кеше бай булганчы,*
*Карт алаша тай була.*

Биюченең даны таралган саен каршылык та арта бара. Әмма боларның берсе дә, язучы сурәтләгәнчә, Рудикны тыеп кала алмый, белгечләр аның биюен могҗизага тиңлиләр, укырга киңәш итәләр. Рудик күренекле педагоглардан дәресләр ала, осталыгын арттыра бара. Укытучы Ләйсән Ичиновна Хәмит Нуриев белән әңгәмә вакытында «Сезнең улыгыз тумыштан биюче» ди, малайны хореография училищесында укырга димли. Ләкин әти кеше үз карашында кала. Рудольф Ленинград хореография училищесына качып китә.

Батулла Рудик яшәешен даими көрәш итеп сурәтли. Бәрелешләр төрле киеренкелектә, төрле шәкелдә бара. Еш кына олы талант эргәсенә вакчыллык, хөсетлек килеп сырыша. Яна биеклеккә күтәрелгәндә искергән, чикле тәртипкагыйдәләр аяктан тота. Бөеклек белән түбәнлек аралаша, янәшә бара.

Ленинград училищесы – мәртәбәле уку йорты. Анда күренекле остазлар балет серләренә өйрәтә. Нуриев боларның һәммәсен дә күңеленә сеңдерә бара. Кайбер алымнарны, хәрәкәтләрне иптәшләреннән дә көчәреп ала. Ул һәркөн үзенә яңалык өсти. Моның өчен ана тулай торак режимына да беркадәр үзгәреш кертергә туры килә. Рудик кичләрен балет спектакльләрен карарга чыгып китә. Ул румын иптәше белән бергә «Отелло»ны инде дүртенче тапкыр карый. Спектакльдән соң артист хәрәкәтләрен өзлексез кабатлый. «Дон Кихот», «Спартак» партияләрен яттан өйрәнә. «Мастерларның биюен карау да дәрес» дип саный ул. Әмма бәгъзе тар карашлы адәмнәргә бу тәртип бозу булып күренә. Моның өчен егеткә җавап бирергә туры килә. Тиңсез талант, камиллеккә чиксез омтылыш кына киртәләрне атлап чыгарга ярдәм итә.

Балетны җиңел, төгәл башкару, сәхнәдә очып йөрер өчен ныклы физик әзерлек, көч-куәт булуы да лазем. Әсәрдән күренүенчә, Ходай Тәгалә Рудикка тырышлык, түземлекне дә кызганмый биргән. Ул сәгатьләр буена, җан тирләре чыкканчы күнегүләр ясый, коллегалары инде хәлдән тая, бу һаман күнегүләрне дәвам иттерә. Ошбу образда талант белән тырышлык, үҗәтлек бергә кушыла.

Традицион костюмнарга карата да аның үз карашы бар. Әгәр кием хәрәкәтләнергә, сикерергә комачаулый икән, никадәр затлы материядән тегелгән булмасын, Рудик аннан баш тарта, кыскарта, үзе төзегән эскиз буенча яңаны тектерә.

Кыскасы, Батулла үз героен шактый катлаулы, билгеле бер дәрәҗәдә каршылыклы характер иясе, сүзендә нык торучы, ниятенә ирешүче зат итеп сурәтли. Шуңа күрә тирә-юньдәгеләрнең ана мөнәсәбәте дә төрлечә. Тамашачылар аның осталыгына бердәм соклана, белгечләр, артистлар Рудикның балет сәнгатенә керткән җитди яңалыкларын, мөһим детальләрен хуплый, ә сәләтсез бәндәләр кимчелекләр эзли. Мастер исә үз юлыннан бер карыш та тайпылмый.

Әсәрдә билгеләп үтелгәнчә, Нуриев хореография училищесын җитлеккән, профессиональ артист дәрәҗәсендә тәмамлый. Аны СССРның Зур театрына, Станиславский һәм Немирович-Данченко театрларына солист итеп чакыралар. Ул Ленинградның Мария опера һәм балет театрын сайлый. Белгечләр аның биюен балет өлкәсендәге революция, балетта яңа эраны башлаучы дип бәяли.

Театр коллективы гастрольгә Парижга юнәлә. Капиталистик илдә артистларга төркемнән аерылырга, ялгызы гына

кунакханәдән чыгып йөрергә рөхсәт ителми. Әмма Рудик мондый чикләүләр белән килешми. Ул берүзе чыгып китеп кибетләрдә йөри, чит ил артистлары белән очрашып әңгәмә кора, балет серләре турында сөйләшә, спектакльләр карый. Аның болай иркенләп йөрүе хакимият әһелләренә ошамый. Парижлан соң труппа Лондонга очарга тиеш була. Әмма Нуриевка анда бару тыела. Аны Мәскәүгә кайтарып җибәрмәкче булалар. Рудольф моның Рәсәйдә Колымага озату, аны төрмәдә черетергә җыену, балеттан аеру икәнен яхшы аңлый. Аның өчен бу — үлемгә тиң.

Бу мизгелләр Батулла әсәрендә дә, Равил Вәлидә дә сюжетның иң киеренке ноктасын тәшкил итә. Ошбу ситуациядә Рудик үткен кылыч йөзенә басып йөргәндәй күренә. Ул бер гөнаһсыз Колымага сөрелергә, төрмәгә ябылырга теләми. Парижда калырга тели, ярдәм, киңәш сорап француз дусларына мөрәҗәгать итә. Алар аэропорт полициясенә кереп ситуацияне аңлата. Полицейскийлар ярдәм итәргә ризалык белдереп, нишләргә кирәген аңлаталар. Нуриев, КГБ агентларының кордонын өзеп, теге полицейскийлар ягына чаба. «Стрижевский белән икенче агент та аның артыннан йөгерде. Алар Нуриевка барып ябышты. Француз полицейскийлары өлгеррәк булып чыкты. Алар Нуриевны тегеләр кулыннан йолкып алды. Агентлар тагын Нуриевны тартып алырга омтылганнар иде, өлкән полицейский:

— Сто-оп! — дип кычкырды да, якасын ачып, значогын күрсәтте. — Бу сезгә Россия түгел! Бу — Франция!» — диде.

Моннан соң әсәрнең стиле дә беркадәр үзгәрә төшә. Моңа кадәр тырнак астыннан кер эзләү бер кирәксез конфликтлар чыгарып килә. Яна шартларны яктыртканда исә иҗат ачышлары, шәхси бәйләнеш-мөнәсәбәтләр алгы планга чыга. Үзгәреш бәгъзе сәнгать коллективлары хәятенә дә кагыла. Таралу алдында калган кайбер театрлар, Нуриев килеп кушылгач, иркен сулап җибәрә, аягында нык басып тора башлый.

Әдип хикәяләвенчә, Рудик билгеле бер күренекле артистлар мәгыйшәтенә дә үзенчәлекле йогынты ясый. Данлыклы балерина Марго Фонтейн аны Лондондагы гала-концертына, балет сәхнәсе белән хушлашу кичәсенә чакыра. Әлеге кичәдә бергә биегәннән соң, Марго Фонтейн кабат сәхнәгә кайта, алар 700 спектакльдә бергә бииләр, барлык илләрнең, корольләрнең, президентларның сөекле артистларына әвереләләр. Америка Президенты Кеннеди Рудикка көмеш рельслы поезд бүләк итә. Моның мәгънәсе шунда: заманында майор Хәмит Нуриев гаиләсенә бик еш күчеп йөрергә, юлда булырга туры килә. Рудольф шулай йөргәндә, поезлда туа. Рудик үзе дә уенчык поездларны бик ярата торган булып китә, алар белән әвәрә килә. Президент бүләге — әнә шуңа ишарә.

Рудик һәм Марго Фонтейн спектакльләре һәр илдә зур уңыш белән бара. Тамашадан соң аларны егерме, кырык, Австралиядә сиксән тугыз тапкыр чакырып алкышлыйлар, кул чабулар бер сәгатькә сузыла. Алар арасында ялкынлы мәхәббәт кабына. Әгәр бу артистлар бер-берсен өзелеп яратмаса, сөю хисен сәхнәдә шул тикле нәфис, нәзакәтле итеп чагылдыра алмаслар иде, дип фикер йөртә тамашачы.

Бәләкәй чакта ачлыктан интеккән, ямаулы чалбар киеп йөргән Рудик торабара балет артистлары арасында иң бай шәхескә, утраулар, бер дигән виллалар хуҗасына әйләнә.

1987 елда Рудикның әнисе Фәридә кинәт каты авырып китә. Рудик, илгә кайтып, аны күреп калырга тели. Ләкин хәтәр куркыныч бар. Совет суды аны, фактларга нигезләнмичә, җиде елга төрмәгә ябарга дигән карар чыгара. Рәсәйгә килеп төшү белән зинданга бикләп куймасләрмы? Бу мәсьәлә халыкара масштабта тикшерелә. Ахырда аны саклап йөрер өчен Франция хөкүмәте вәкиле месье Местр белән импрессарио Жанин Ренги бара. Әмма әнисе инде улы белән сөйләшерлек хәлдә булмый. Рудикка монда кырык сигез сәгать тору рөхсәт ителгән була. Ул, туганнарына мул бүләкләр биреп, күп акча калдырып, кайтыр юлга чыга. КГБ шулай да ана кагылырга җөрьәт итми, Нуриев — дөньякүләм билгеле шәхес, күрәләтә аңа карата явызлык кылсаң, бөтен җиһанда шау-шу кубуы ихтимал.

Батулла Рудикның күп сәнгать тармаклары буенча яхшы оста икәнлеген раслый. Рудик бер дигән музыкант, дирижер, балетмейстер, режиссер, рәссам, әдәбият белгече. Йөз егерме балет

партиясен башкара. 1992 елның май аенда үткән классик балет фестивалендә П.И.Чайковскийның «Щелкунчик», С.С.Прокофьевның «Ромео һәм Джульетта» балеты музыкасына дирижерлык итә. Ул Франциянең Шәрәфле Легион ордены һәм Сәнгать-әдәбият Командор ордены кавалеры, Австриянең шәрәфле гражданины. Коммунистик администрация дә аны игътибардан читтә калдырмый. КГБ даими күзәтү астында тота. Күзәтүчеләре – сәнгать белгечләре түгел, шымчылар. Аларны балетның камиллек дәрәҗәсе кызыксындырмый, бәлки биюченең йөреш-торышын, сулышын, кемнәр белән очрашып әңгәмә коруын күзәтәләр.

Совет хөкүмәте биючегә мактаулы исемнәр бирүне кирәксенми. Суд карарын чыгару житә дип саный, күрәсең. Талантка рәсми мөнәсәбәт шуннан гыйбарәт. 1993 елның 5 гыйнварында бөек биюче Рудольф Нуриев вафат була. Үлеменнән соң дүрт ел узгач, инде төрмәгә ябу перспективасы калмавын аңлагач, Россия Югары суды аны жиде елга зинданга утыртырга дигән карарны юкка чыгара.

Батулла болай яза: «...Атаклы биючене бөтен дөнья жирләде. Аның матәме кара тәнлеләрне дә, кызыл, сары, ак тәнлеләрне дә бергә жыйган иде. Болай итеп корольләрне, патшаларны һәм изгеләрне генә озаталар». Аның жәсәде Парижның Сент-Жермен-де-Буа зиратында жирләнгән.

Рабит Батулла Рудольф Нуриевны әдәби әсәрдә терелтә, аның тынгысыз көрәштә, киеренке мохиттә яшәвен, сәнгатьтә югары кимәлгә күтәрелүен күрсәтә. Романның герое – реаль шәхес. Әмма тормыш фактларына тугрылык язучының иҗат фантазиясен чикләми. Хәер, бу очракта бәлки фантазия дип әйтү дә бик үк урынлы түгелдер. Бирелә тормыштагы фантастиканы әдәби әсәргә күчерү турында гәп йөртү дөресрәк булмас микән? Чынлыкта Рудольф Нуриев үзе фантастиканы хәтерләтә бит. Аның образын гәүдәләндерүдә художестволы арттыру, күпертүләргә ихтыяҗ юк сыман. Әлеге шәхеснең гадәттән тыш мәгыйшәте, гамәле язучыга менә дигән сәнгатьчел сурәт булып хезмәт итә, әсәргә эстетик энергия өсти. Инде персонажының күңел дөньясына күчкәндә Батулла төш алымына, күз алдына китерүгә, хыялга мөрәҗәгать итә.

Автор модерн, башваткыч, тел яшерүләр белән мавыкмый. Башка күренекле язучыларыбыз кебек, классик ачык стильдә бәян итә. Ул үзенең героен житез зиһенле, тапкыр, үткен, жае белән тәмле телле, югары интеллектлы итеп сурәтли. Нуриев сәнгатьнең күп тармаклары буенча профессиональ дәрәҗәдә фикер йөртә. Биюче философ булырга тиеш, дип саный ул.

Шулай итеп, күренекле әдип тулы канлы, жанлы образ барлыкка китергән, кызыксынып, мавыгып укырлык әйбәт роман язган, канатлы биючегә лаеклы әдәби һәйкәл иҗат иткән. Рудольф Нуриев хәяте белән танышканда күз алдына, аның белән янәшә, икенче бер бөек зат – скрипкада уйнау техникасына борылыш керткән виртуоз башкаручы Никколо Паганини (1782-1840) килеп баса.

Шунысын да әйтеп үтик: Батулла сценарие буенча Рудольф Нуриев турында тулы метражлы документаль фильм төшерелде һәм тамашачыларның, белгечләрнең зур ихтирамына лаек булды.

**Фәрит ХАТИПОВ**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

### Актаныш

Актаныш эшчеләр бистәсе – Актаныш районы үзәге. Ул Казаннан 381 чакрым ераклыкта урнашкан. 1980 елларда Актаныш авылы янындагы тау өстенә биек йортлар салып, аны сельхозтехника – РТС дип йөртә башлыйлар. Хәзер тау өстендәге Яңа Актаныш район үзәге исәпләнә. Актаныш утырган тауның бер өлешен Ирмәш, икенче өлешен Текә тау дип атап йөртәләр. Агыйдел ягыннан караганда Актаныш кайсы ягы беләндер очарга канат каккан аккошны хәтерләтә. Яшеллеккә төренгән күп катлы ак биналар менә-менә зәңгәр күккә ашар кебек.

Тау астында, Урал таулары итәгеннән юл алган Агыйдел елгасы ага. Аның матурлыгы турында бик күп җырларда җырлана, хикәяләрдә сөйләнә. Актаныш районын үтеп беркадәр акканнан соң, Агыйдел Камага килеп кушыла.

Актаныш авылы исә район үзәгеннән 10 чакрымда, Нефтекамск шәһәреннән 65 чакрым ераклыкта утырган. Хәзер аны Иске Актаныш дип йөртәләр. Иске Актаныш белән Яңа Актанышны озын баскыч тоташтыра. Ул баскыч тау битендә булганлыктан, ерактан караганда аеруча матур булып күренә.

Район 1965 елда төзелгән, республиканың көнчыгыш өлешендә урнашкан. Үзәге – Актаныш авылы. Районның көньягыннан Минзәлә-Уфа автомобиль юлы уза.

Актаныш исеменең килеп чыгышына карата мондый риваять бар. Актаныш авылы территориясенә кешеләр моннан 300 – 400 ел элек күчеп утырганнар. Авыл башта хәзерге Норкә урманының көньяк-көнчыгыш өлешенә урнашкан булган. Аның исеме авыл эченнән ага торган Актаныш елгасы исеменнән алынган.

Бер кешегә каяндыр кунак килә. Өй хуҗасы үзенең ындыр табагында ашлык суккан чак була. Килгән кеше, хуҗаның кечкенә малаен капка төбендә очратып, әтисенең кайда икәнен сорый һәм әтисен чакырып килергә куша. "Мина синең әтиең таныш бит", – дигән сүзне дә әйтә. Малай әтисенә барып: "Синең бер ак танышың килгән, сине чакыра", – ди. Килгән кунак хуҗаның яхшы ук дус кешесе була, һәм ул ак чырайлы булган, күрәсең. Шуннан хуҗа кеше, дусты янына килеп, исәнлек-саулык сорашкач: "Минем малай сине "ак танышың килгән, сине чакыра" дип әйтте, – дип көлеп сөйләгән, имеш. Шуннан соң бу малайга "Ак таныш" кушаматы бирелгән.

Ул вакытта елгада су тегермәне булып, шактый тирән буа була. Берникадәр вакыттан соң су коенганда шушы "Ак таныш" кушаматлы малай буада батып үлә. Буаны "Актаныш буасы" дип йөртә башлыйлар, тора-бара бу исем елгага да күчә, аннары авыл да Актаныш дип атала башлый.

Икенче риваять буенча, имеш, Актаныш аккошлар иле булган. Ә аккошлар табигатьнең иң чиста, изге һәм матур урыннарын сайлыйлар. Ихтимал, бу риваятьтә хаклык бардыр.

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

Актаныш Агыйдел һәм Иске Идел елгалары буена утырган. Актаныш авылы уртасыннан Актаныш елгасы ага. Ул зур түгел, авылны икегә аера.

Иске Актаныш – зур авыл. Анда элек мәчетләр, мәдрәсәләр һәм кибетләр күп булган.

Актаныш төбәге – республикабызның беренче президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең туган ягы.

Бу төбәк республикабыз тарихына керерлек күп күренекле кешеләр биргән. Аннан 5 Советлар Союзы Герое, артистлар Мөхтәр Мутин, Нәсимә Җиһаншина, Әлфия Авзалова, Газинур Фарукшин, Асаф Вәлиев, язучылар Гамил Афзал, Риза Ишморат, шагыйрь Нур Баян, композиторлар Илгиз Закиров, Инсаф Хәбибуллин, баянчы Кирам Сатиев һ.б. чыккан.

## Мәмәшир

Мәмәшир авылы Кукмара районында, Кукмара эшчеләр бистәсеннән 32 чакрымда, Вятка Аланыннан 22 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл зиратында XVII йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташлары табылган.

Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Мәмәшир авылы халкы күршедәге Салкын Чишмә авылы белән бергә июнь ахырында Мәмәшир җыены үткәргән.

Мәмәшир авылына кайчан нигез салынуы анык кына билгеле түгел. 1929 елда авылда көчле янгын булган, дин әһелләре алып барган елъязма тарих шунда юкка чыккан.

Олылар авыллары оешу тарихын болай сөйли. Мәмәшир авылы урыны элек тоташ урман белән капланып алынган булган. Казан ханлыгы Явыз Иван тарафыннан тез чүктерелгән заманнарда ат урлауда гаепләнеп хөкемгә тартылган, ләкин гаиләсен алып качарга өлгергән Томакай исемле бер кеше шушы урынга килеп утыра. Бераз яшәп, әйләнә-тирә белән танышкач, ул үзеннән ерак та түгел башка милләт халыклары яшәгәнне белеп ала.

Идел, Кама елгалары буйлап элекке Болгар якларыннан бу тирәләргә тагын бер кеше килеп чыга. Аны халык Болгар бабай дип атый. Болгар бабайның урнашкан урыны Томакай бабай алачыгыннан ерак булмый.

Елганың каршы як ярына гаиләсе белән Мөхәммәтшәриф исемле кеше килеп урнаша. Торган урыннары бер-берсеннән ерак булмаса да, бу өч кеше бер-берсен белмиләр.

Язгы көннәрнең берсендә, елганың ташыган чагында, Болгар бабай судан агып килүче йомычкалар күрә, урман эченнән күтәрелгән төтенгә дә игътибар итә. Бөр елгасы буенча көймә белән өскә таба, төтен тарафына менеп китә. Агымга каршы бераз йөзгәч, ярга чыга һәм Мөхәммәтшәриф гаиләсен таба. Күрешеп-сөйләшкәч, Мөхәммәтшәриф йомычкаларның югарыдан агып килүен әйтә. Алар киңәш-табыш итәләр һәм якын-тирәдә башка кешеләр дә яшәргә тиеш дигән нәтиҗәгә киләләр. Болгар бабай көймәсендә алар икәүләп елга буйлап тагын бераз күтәреләләр. Алар хәзерге Мәмәширнең Түбән оч урамында качкын Томакайның җирне казып ясаган куышын табалар. Куе, кара урман арасында ялгыз яшәү куркыныч булганга, болар берләшергә уйлыйлар. Томакай бабай урынын яшәү өчен уңайлы дип саныйлар. Мөхәммәтшәриф һәм Болгар бабай гаиләләре белән шушы урынга күчеп килә. Авылга шулай нигез салына. Мөхәммәтшәриф зиһене, үткенлеге, сүзгә тапкырлыгы белән башкалардан аерылып торган. Шуна күрә авылга Мөхәммәтшәриф исеме куела. Еллар үтә. Мөхәммәтшәриф исеме җыйнаклана, кыскара торгач, авыл атамасы Мәмәширгә әйләнә.

Мәмәшир авылы җирләре өч яктан Киров өлкәсенә уелып кереп утырган. Монда Кукмара районының да, Татарстан республикасының да төньяк чикләре. Авыл янындагы болынның ун ягында Бөр елгасы ага. Бөрнең теге як ярында Киров өлкәсе башлана.

Бөр елгасы бөгелешләр ясый-ясый тау тезмәләре итәген юып килә дә, Нократка кушыла. Авыл басуларында елга-инешләр, сазлык-баткаклыклар һәм күлләр дә бар. Түбән оч белән Югары очны аерып торучы елганы Усман елгасы дип атыйлар.

Елга янындагы таллыкта, авыл кешеләре сөйләве буенча, Усман исемле качкын качып яткан. Авылны урталайга ярып Инеш үтә. Бу инеш янындагы чишмәне Мир чишмәсе дип атыйлар. Бөтен авыл халкы чәйгә суны чишмәдән ала.

## Байкал (Яңа Тазлар) авылы

Кызганыч, соңгы елларда республикабызда шактый гына тарихи авыл атамалары алмаштырылды. Татарстанның Арча районындагы Иске Тазлар һәм Яңа Тазлар исемле авыллар булган. Алар әле дә бар, ләкин исемнәре алмаштырылган. Иске Тазлар авылы хәзер Ташчишмә, Яңа Тазлар авылы Байкал дип үзгәртелгән. Ташчишмә хәзер Әтнәгә, ә Байкал Арча районына керә.

Байкал авылы район үзәге Арчадан 52 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Шурабаштан – 4, Казаннан 110 чакрымда утырган. Ташчишмә авылы район үзәге Олы Әтнә авылыннан 12 чакрымда, җирле үзидарә советы үзәге Күңгәрдән – 6, Арчадан – 38 чакрымда, Казаннан 85 чакрым ераклыкта урнашкан.

Тарихи чыганакларда авыл Яңа Тазлар исемендә беркетелеп калган.

А.Артемьев бастырып чыгарган тарихи белешмәдә авыл Ломба (Яңа Тазлар) дип искә алына. Шура суы буена утырган бу авылдагы 55 йортта 260 ир-ат һәм 273 хатын-кыз яшәгән, мәчет эшләгән.

Яңа Тазлар (Байкал) авылы халкы июль башында Шура, Шурабаш, Яңа Сәрдә, Яңа Әтнә, Югары Оры, Түбән Оры, Чымбулат, Мамыш, Кышлау, Югары Шашы, Түбән Шашы, Яңа Шашы, Күңгәр, Иске Әҗем, Яңа Әҗем, Иске Тазлар (Ташчишмә), Олы Әтнә, Кече Әтнә авыллары белән Мокшо-Мукшы тавы җыены үткәргән.

Марсель Әхмәтҗанов фикеренә караганда, «XIX гасыр халкыбыз тарихында иң тыныч дәверләрнең берсе була, көчләп чукындыру басыла: мәгърифәт, сәүдә, һөнәрчелек, сәнгать үсү өчен мөмкинлекләр туа, татар халкы кулында мал туплана башлый. Арча төбәгенә кергән татар зиратларында матур бизәкләр, язулар белән нәкышләп эшләнгән каберташлар куела. Алар аеруча сәүдә үзәкләрендә (Түбән Оры, Яңа Кенәр, Иске Кенәр, Яңа Тазлар яки Байкал), мануфактуралы һәм мәгърифәтле Кышкарда, атаклы мәдрәсәле Ташкичүдә күп. Башка авылларның зиратларында XIX гасырның икенче яртысында куелган каберташлар очраштыргалый. Шундый биш таш Яңа Тазлар (Байкал) авылы зиратында табылган.

Авыл зиратында борынгы татар традициясе буенча корылган, кирпечтән эшләнгән зур төрбә калдыклары да сакланган».

Менә шушы Ламба суының борылышына салынган авыл «Ламба инеше ярына утырган авыл» (русча «Деревня по речке Ломба») дип аталып йөргән. Авылда йортлар саны 40тан арткач, зур янгын чыгып, барлык каралты-кура янып бетә. Урман да яна. Халык яңа йортлар торгыза һәм авылда ике урам оеша. Авылны халык Яңа Тазлар исеме белән йөртә башлый. Ике урам уртасыннан су ага. Бу су авылны чыккач болыннарга җәелеп урман кырыена кадәр барып җитә. Шушы суның югары агымына бер су тегермәне, аннан бер чакрым чамасы түбәндәрәк тагын бер су тегермәне төзелә. Югары агымдагы тегермән Бәдри бай тегермәне, түбәндәгесе – Габделвәли бай тегермәне дип йөртелә. Яз көне бу су янына аккошлар килеп бала чыгара, көзен алар җылы якларга күчеп китә торган булганнар. Авыл янындагы суда чуртан, алабуга, чабак, шыртлака балыклары күп үрчи. Чуртаннарның 10 килограммнан да авырраклары очрый.

1931 елда күмәк хуҗалыклар төзелгәч, авыл халкы балык сатып шактый зур керем ала. Нарат чырасына ут кабызып, кешеләр елгадан балыкны төнлә сәнәк белән чәнчеп тотканнар. Халык моны Себердәге Байкал күле белән чагыштырган һәм авылларын Байкал исеме белән алыштырып та куйган... Кызганыч, әлбәттә, чөнки Тазлар атамасы борынгылыкка ук барып тоташа.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# Р

**РӘМИЕВ** Сәгыйть Лотфулла улы[1] (12.2.1880, Оренбург губернасы Акман (Ибрай) ав. — 16.3.1926, Уфа ш.), шагыйрь, драматург, прозаик, журналист, публицист, тәрҗемәче, театр белгече. Р. нең шәҗәрәсе шагыйрь-философ Дәрдемәндкә (Закир Рәмиев) барып тоташа.

Р. әдәби иҗатын өч чорга бүлеп карарга мөмкин: Казан, Әстерхан, Уфа. Төрле идея-эстетик юнәлешләрне берләштергән (соц. һәм модернистик) Казанда яшәгән һәм иҗат иткән 1906-10 еллар иң бай чор дип санала.

Дөньяга карашларында кискен үзгәрешләр тудырган «Таң вакыты» (1907) шигыре б-н Р. иҗатының модернистик шигърият белән бәйле сәхифәләре ачылып китә.

Р. мәхәббәт лирикасына да байтак урын бирә. Аның «Ул» (1908), «Син» (1908), «Кайвакытта уйлыймын мин» (1908), «Минутлар» (1908), «Бер кеше» (1909), «Җәмилә» (1909) кебек шигырьләрендә пантеистик суфичылык поэзиясендәгечә сөйгән ярны илаһи образ-символ дәрәҗәсенә күтәргән романтик мотивлар өстенлек итә.

Этик идеал һәм бәхет символы рәвешендә сурәтләнгән, жир һәм илаһи мәхәббәт темасы «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» (1907) романтик драмасының да үзәген тәшкил итә.

Дөньяга карашларда, сәнгатьчә фикерләүдә яңачалыкка (модернизмга) йөз тоткан елларда Р. Ж.-Ж.Руссо фәлсәфәсе тарафдары да була: ул авыл табигатенең сафлыгын, авыл кешеләренең әхлакый пакълеген романтикларча идеаллаштыра («Авыл», 1908); А.С.Пушкинның «Пророк» — «Пәйгамбәр», 1909; М.Ю.Лермонтовның «Перчатка», 1910 шигырьләрен татарчага тәрҗемә итә. 1909 елда «Нәҗметдин агай бәйрәме», «Галәветдин хажи корбаны — Жаек Хәдичә» исемле хикәяләрен, «Ул исерек түгел иде» исемле повестен иҗат итә.

1910-14 елларда Р. Әстерханда яши, «Идел» газетасында сәркәтип, соңрак рәсми булмаган фактик мөхәррир вазифасын башкара. Иҗатының Әстерхан чорында рус кызы Татьянаның татар егете Хәмиткә мәхәббәтен сурәтләгән «Кабакта мәхәббәт» исемле шигъри романтик драмасын иҗат итә (1910, басылмаган); Л.Толстой истәлегенә багышлап мәкаләләр циклы һәм «Ул үлде» (1910) исемле шигырен яза, аның «Живой труп» («Тере мәет», 1910) драмасын татарчалаштыра. Р. чакыруы буенча бер ай дәвамында Әстерханда шагыйрь Тукай кунак булып китә. 1914 ел башында хакимияткә каршы юнәлтелгән мәкаләләре өчен «Идел» газетасы ябыла, «сәяси яктан ышанычсыз» дип игълан ителгән Р.кә тиз арада Әстерханнан китәргә әмер бирелә. Шагыйрь Уфага күчеп китә. 1915 елда Уфада «Сәгыйть Рәмиевнең яңа шигырьләре һәм әүвәлгеләре» исемле җыентыгы дөнья күрә.

1918-19 елларда Ваһапов посёлогында ревком сәркәтибе вазифасын башкара, Оренбург губернасы Верхнеуральск өязе Магнитка станицасында халык мәгариф бүлеге мөдире була. 1920-22 елларда РКП(б)ның Верхнеуральск шәһәр к-ты мөселман секциясе б-н җитәкчелек итә, Чиләбедә милләтара эшләр буенча инспектор булып эшли. 1922 ел ахырында Уфага кайта, Башкортстан АССРның жир эшләре буенча халык комиссариатында нәшрият бүлеге б-н җитәкчелек итә, Башкортстанны өйрәнү җәмгыяте эшендә катнаша, башкорт мәктәпләре өчен дәреслекләр әзерләү буенча Академүзәк әгъзасы була, башкорт теле орфографиясенең беренче проектын төзи h.б.

Р. һәр каләм иясенең иҗатта ирекле булуга хокукын яклады, озак гасырлар дәвамында көйлелеккә таянып үскән, тигез иҗекләр санына корылган силлабик шигырь төзелешен интонацион лириканың төрле төсмерләре һәм дөньяви яңгырашлы өр-яңа эчтәлек б-н баетты. Яңа ачышлар б-н тулы Р. шигърияте бүген дә татар халкының рухи яңарышка омтылышына һәм шәхес азатлыгына гимн булып яңгырый. Р. озакка сузылган каты авырудан вафат була.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1962; Таң вакыты. К., 1980; Сәгыйт Рәмиев. Шәехзадә Бабич. Әсәрләр. К., 2005.

[1] Журнал варианты

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

Әдәб.: Садретдинов Ш. Сәгыйт Рәмиев иҗаты. К., 1973; Зарипова-Четин Ч. «Уйласам уй, сызлый күңлем, сызлый җан...» К., 2005; Халит Г. Многоликая лирика. К., 1990; Ганиева Резеда. Сәгыйт Рәмиев — гыйсьянчылык романтизмы шагыйре // Татар әдәбияты: традицияләр, бәйләнешләр. К., 2002; Зарипова-Четин Ч. Проблема демонизма в творчестве С.Рамиева в контексте восточно-европейской эстетики. К., 2003.

*Р.К.Ганиева.*

**РӘФЫЙКОВ** Мәҗит Мәгъсүм улы (17.4.1925, Башкортстан АССРның Зилаир кантоны Күгәрчен ав. — 24.1.1986, Казан), язучы, тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1956). 1956-65 елларда Татарстан кит. нәшриятында тәрҗемәче һәм мөхәррир, «Совет әдәбияты» ж-лында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1966 дан әдәби иҗат белән генә шөгыльләнә. Бөек Ватан сугышы елларыннан ук башкорт һәм татар матбугатында басылып килә. Шигырьләр, лирик хикәяләр, повестьлар һәм очерклар авторы. «Илһам авазы» (1966), «Сиңа ничә яшь?» (1970), «Су башы» (1975), «Изге мизгелләр» (1985) җыентыклары бар. Р.ның үз тәрҗемәсендә «Родник Хабира-Соловья» (1972), «Ишкильды» (М., 1975), «Школа на взгорке» (М., 1976) хикәя-повесть җыентыклары рус телендә басылып чыга. Р.ның әсәрләре, нигездә, тормыштан алып язылган, документаль характерда. Аның геройлары яшьлекләре сугыш чорына туры килгән буын вәкилләре. Р. шулай ук әдәбият тарихына, татар поэзиясендә әдәби тәрҗемә мәсьәләләренә караган публицистик мәкаләләр авторы да. Ул рус теленә Г.Тукай, Ш.Камал, Н.Дәүли, М.Әмир, Х.Сарьян, И.Гази, Ә.Еники әсәрләрен тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша, медальләр белән бүләкләнә. 1950 дә репрессияләнә, 1956 да аклана.

Әд.: Вәли-Бәрҗылы М. Якты һәм җылы бөркелә... // Казан утлары. 2005. №4.

**РӘФЫЙКОВ** Сөббух Һади улы (15.7.1913, Уфа губ. Минзәлә өязе Нөркәй ав. — 21.11.1971, Зәй пос.), язучы. 1931 дән «Колхоз газетасы» әдәби хезмәткәре, 1932 дән «Комбайн» исемле Сарман район г-тасы мөхәррире урынбасары. 1934 тән Казанда: «Кызыл яшьләр» г-тасында бүлек мөдире, бер үк вакытта, Татарстан кит. нәшриятында мөхәррир, Казан пед. ин-ты студенты. 1937-47 елларда Төньяк Себергә сөргенгә җибәрелә, хөкем срогын тутыргач та аңа туган ягына кайтырга рөхсәт бирелми, 1951 дә кабат элекке «җинаятьләре» өчен хөкем ясап, әдип Красноярск өлкәсенә гомерлек сөргенгә озатыла; 1956 да гына аклана. Сөргеннән кайткач, Зәй шәһәрендә төпләнеп, 1966 га кадәр «Социалистик Татарстан» г-тасының үз хәбәрчесе булып эшли. «Соңгы талпыну» (1932) һәм «Үсмерчак» (1937) дигән хикәяләр, «Ак төннәр» (1957) исемле шигырь җыентыклары, «Беренче яз» (1962; 3 басма 1979), «Авыл иртәсе» (1966), «Тын елга буенда» (1972) исемле романнары бар. Романнарында 1920-30 елларда татар авылы кичергән социаль үзгәрешләр, күмәк хуҗалыкка күчү процессындагы каршылыклар, производство мәсьәләләре турында сүз бара. Соңгы романы — Зәй гидростанциясен төзүчеләр тормышыннан.

Әд.: Шәрәфетдинов Р. Чагыл тау сагына // Мәйдан. 2003. №1.

**РӘХИМ** (Габдрәхимов) Гали Мөхәммәтшакир улы (4.11.1892, Казан — 3.3.1943), язучы, әдәбият галиме. Чыгышы б-н сәүдәгәрләрдән. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә (Казан) укый. Казан коммерция уч-сен (1913), Мәскәү сәүдә ин-тын (1917) тәмамлый, үзлегеннән гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнә. 1917 елдан соң Казанда яши, Югары сәяси курсларда (1920-21) татар әдәбиятын, Шәрекъ академиясендә, Шәрекъ педагогия ин-тында (1921-22) татар әдәбияты һәм фольклоры тарихын укыта. 1909 елда Г.нең «Җир йөзе» исемле география буенча беренче китабы басылып чыга. 1913-15 елларда ул «Бикчәнтәй угылы» тәхәллүсе б-н «Ак юл» журналында балалар өчен хикәя һәм әкиятләрен бастыра. Соңыннан алар башлангыч сыйныфлар өчен дәреслекләргә кертелә, 1923 елда «Кызыл гөлләр» исеме б-н аерым китап булып чыгалар. 1913-15 елларда «Ан» журналында аның олылар өчен хикәяләре басылып чыга («Галия», «Исемсез хикәя», «Сабирҗан хәзрәт»). Ирония б-н татар байлары тормышын тасвирлаган «Дача кайгысы» (1914) һәм «Җанвар» (1919) комедияләре, революциягә кадәрге татар зыялылар яшәешен күрсәткән «Идел» (1921) повесте авторы. «Татар әдәбияты тарихы» (т.1-2, 1923-27) китабы авторларының берсе. 1923-30 елларда Татарстанны өйрәнү җәмгыяте эшендә, фольклор экспедицияләрендә катнаша; татар тел, әдәбият белеменә, фольклорына, тарихына, археографиясенә багышланган мәкаләләр яза. 1931-34, 1938-40 елларда репрессияләнә, вафатыннан соң аклана.

Әсәр.: Халык әдәбиятымызга бер караш: Җырлар. К., 1915; Каюм Насыйриның монарчы басылмаган әсәрләре һәм йөзьеллык бәйрәм материаллары. К., 1926;

Авылны өйрәнү: Татар авылларын монография ысулы белән өйрәнү өчен жентекле кулланма-программа. К., 1930; Сайланма әсәрләр. К., 2004.

Әдәб.: Азизова-Хөснетдинова Г.А. К., 2005; Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиографик сүзлек. К., 2005; Гали Рәхим: Тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык. К., 2008.

**РӘХИМ** (Рәхимов) Кәшиф Валиәхмәт улы (18.12.1905, Самара губернасы Бөгелмә өязе, хәзерге Ютазы р-ны, Бәйрәкә а. — 13.11.1989, шунда ук), язучы. Туган авылы мәдрәсәсендә укый. 1925 елдан Казанда яши. «Авыл яшьләре» журналы редакциясендә, Татарстан китап нәшриятында (1931-34) эшли. 1934 елда контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнеп кулга алына, 5 ел сөргенгә хөкем ителә (1957 елда реабилитацияләнә). 1938 елдан туган авылында яши, урта мәктәптә укыта. «Буразналар берләшкәндә» (1931) повесте, «Тозсызлар» (1932), «Шатлыклы көз» (1933) хикәя җыентыклары авторы.

*Ә.М.Шәрипов.*

**РӘХИМ ГӘРӘЙ** (псевд., чын фам. һәм исеме Родионов Григорий Васильевич) (15.7.1941, Шөгер р-ны Федотовка ав. туа), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986), РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (2007), ТРның халык язучысы (2011). Казан ун-тын (1967) һәм А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курслар (Мәскәү, 1981) тәмамлый. 1967 елдан «Татарстан яшьләре» редакциясендә әдәби хезмәткәр, 1968 дән Татарстан кит. нәшриятында балалар-яшүсмерләр әдәбияты мөхәррире. 1972-77 дә ТАССР Язучылар берлегендә әдәби консультант, 1978-79 да «Казан утлары» ж-лында проза бүлеге мөдире. 1979-87 елларда Мәскәүдә: РСФСР Язучылар берлегендә милли әдәбиятлар эше буенча консультант, Идел буе һәм Урал төрки әдәбиятлары комиссиясенең җаваплы сәркатибе. 1987-92 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары, аннары «Шәһри Казан» г-тасы редакциясендә бүлек мөдире. 1992 дән ТР ДСның мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр к-тында (2007дән ТРның 1-классны дәүләт киңәшчесе). Р.Г. әдәбиятка 1960 еллар уртасында килеп кереп, халык җыры традицияләренә якын үзенчәлекле шигъри интонациясе, лирик кичерешләр, фәлсәфи уйланулар, шул ук вакытта публицистик янгырашлы һәм нечкә юморга корылган шигырьләре белән җәлеп итә. «Вәгъдә» (1967), рус теленә тәрҗемәдә «Цветочная калитка» (М., 1973), «Зирекләрнең кара бөдрәләре» (1976), «Мәхәббәтем турында җыр» (1982), рус теленә тәрҗемәдә «Напевы курая» (М., 1983), «Моннарым» (1987), «Үз җиремдә, үз җырым» (1987), «Замандашларыма ачык хат» (1999), рус теленә тәрҗемәдә «Сабантуй моей мечты» (2003) исемле шигъри җыентыклар; балаларга атап язылган «Чәчәк такыя» (1981), «Тимер торна» (1993) китаплары билгеле. Аның чәчмә әсәрләре, юмористик хикәяләре, публицистикасы «Көннәр язга авышкач» (1978), «Туган йортта» (1983), «Иптәшләр үзебезнеке» (1988), «Татлы сагышларым» (1991) җыентыкларына тупланган. Р.Г. М.Гафуриның «Кара йөзләр» әсәре буенча «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсының либреттосы (Б.Мөлеков муз., Татар опера һәм балет т-рында 1981 дә куела; Г.Тукай исем. ТАССР Дәүләт пр., 1984), төрки халыклар тарихын чагылдырган күп серияле «Борынгы Болгарны сагыну» («Сага древних Булгар», 2005) исемле нәфис кинофильм сценарие, «Татар балалар поэзиясе антологиясе»н (1980) төзүчеләрнең берсе, «Татар поэзиясе антологиясе»н (1-2 кит., 1992) төзүче, «Литературный энциклопедический словарь»ның (М., 1987) татар һәм башкорт әдәбияты өлешләренең авторы. М.Львов, Д.Кәгелтдинов, Р.Бикбаев әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Үзенең әсәрләре рус, инг., нем., венгр һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән. 1999 дан ТР Язучылары Әдәби фонды рәисе. ТАССР, Литва ССР, Башкортостан Респ-сы ЮС Президиумнары Почёт грамоталары белән бүләкләнгән (1980; 1984; 1997).

Әсәр.: Птица радости. М., 1986; Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 2001-02.

Әд.: Фәйзуллин Р. Нурлы һәм моңлы шигырьләр // Сайланма әсәрләр.К., 1998. Т. 4; Галиев М. Чын исеме — Гөргери // Казан утлары. 2001. № 7; Филиппов А. Гөргери // Казан утлары. 2006. №3.

*Г.М.Габделхакова.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Николай
Гоголь

# БОРЫН

## I

Мартның егерме бишләре тирәсендә Петербургта гайре табигый хәл булды. Воснесенск проспектында яшәүче чәчтараш Иван Яковлевич (фамилиясен беркем дә белми, ишек өстенә эленгән тактада янагына күбек сөртелгән ир кеше ясалган һәм «Кан алдыру» дип язылган) гадәттәгедән иртәрәк уянып китсә, борынына яңа пешкән ипи исе килеп бәрелде. Түшәгеннән калкына төшеп караган иде, хатыны, кофе дигәндә үлеп китә торган олпат кыяфәтле ханым, мичтән ипи алып ята икән.

— Прасковья Осиповна, бүген мин кофе эчеп тормам инде,— диде Иван Яковлевич,— суганлап кайнар ипи ашыйсым килә.

(Иван Яковлевич кофеның да, ипинең дә кимен куймас иде, әмма ләкин икесен дә өмет итү һич мөмкин эш түгел, чөнки Прасковья Осиповнаның талканы коры, мондый капризга ирек бирмәячәген бик әйбәт белә ул.) «Бу юләр ипи ашап куансын әйдә, үземә кофе күбрәк калыр»,— дип эчтән генә уйлап, хатыны бөтен ипине ачу белән өстәлгә ыргытты.

Иван Яковлевич әдәп йөзеннән күлмәге өстеннән фрак киде дә өстәл янына утырды, тоз, ике баш суган әрчеп куйды, кулына пычак алып, чыраена җитдилек биреп, ипи кисә башлады. Ипине урталай кисте дә уртасында агарып торган нидер күреп аптырап калды. Иван Яковлевич пычак очы белән чак кына чокыгандай итте дә бармагын тидерде. «Каты күренә, ни булыр икән бу?» — дип, үзе эчтән генә сөйләнде.

Бармагын ипи эченә батырды да... борын!.. тартып алды. Иван Яковлевич коелып төште, күзләрен кат-кат сөртеп капшап-капшап карады: борын дигәч борын инде! Таныш та кебек әле үзе. Иван Яковлевичның күзе маңгаена менде, коты очты. Ләкин бу куркуы хатынының ярсуы белән чагыштырганда берни түгел иде әле.

— Хайван, каян кисеп кайттың син ул борынны? — дип тузынды хатыны тиресеннән чыгардай булып.— Карак! Исерекбаш! Полициягә үзем барып әйтәм хәзер. Кара син аны, башкисәр! Мин өч кешедән ишеттем инде, сакалларын кырганда борыннарын тартасың-йолыккалыйсың икән, көчкә түзәләр ди.

Иван Яковлевич ни тере, ни үле кыяфәттә басып тора бирде. Бу борын коллежский асессор Ковалев борыны лабаса, атнаның һәр чәршәмбе һәм якшәмбесендә ул аның сакалын кыра иде.

— Прасковья Осиповна, тукта әле! Мин аны чүпрәккә төреп берәр җиргә куйыйм: торып торсын шунда, бераздан алып чыгып китәрмен.

— Әйтмә дә, сөйләмә дә! Көтеп тор, өемдә өзелгән борын яшереп ятам ди, хәзер!.. Как сөяк! Пәке кайраудан бүтәнне белмисең, ирлек бурычыңны үтәрлек тә рәтең калмас инде тиздән, бәдбәхет! Полициягә сине яклап

авызымны да ачмыйм!.. Их, син, шапшак, күзле бүкән! Юк ит хәзер үк, духы булмасын, күземә күрсәтмә!

Иван Яковлевич каккан казык кебек тора бирде. Күпме генә уйланмасын, башына юньле фикер килмәде.

— Ничекләр булды икән бу тамаша? — дип көчкә телен әйләндереп әйтте ул бераздан, колак артын кашый-кашый.— Кичәгенәк исерек кайттыммы соң, айнык микән, һич хәтерли алмыйм. Бөтенләй тузга язмаган хәл инде: пешкән ипи — бер нәрсә, борын бит ул — бүтән.

Иван Яковлевич тәмам аптырашта калды. Менә-менә полиция кешеләре килеп керерләр дә борынны эзләп табарлар һәм аны гаепле калдырырлар дигән уй һушын алды. Инде күз алдында көмеш белән чигелгән алсу яка, шпага чагыла башлагандай булды; каз тәне чыгып, дер-дер калтырый башлады. Түзмәде, чалбарын, аяк киемен тартып чыгарды, шул иске-москыны өстенә элде дә Просковья Осиповнаның тозлы-борычлы үгет-нәсыйхәтләрен тыңлый-тыңлый, борынны чүпрәккә төйнәп, урамга чыгып китте.

Исәбе борынны кая да булса аулаграк урынга — койма баганасынамы, йә булмаса үзе дә сизмичәрәк берәр яры төшереп калдырып, тыкрыкка борылу иде. Әмма, күрәчәге булгандыр, юлында әледән-әле танышбелешләре очрый торды, берсе дә «Кая барасың?» «Таң тишегеннән кемне кырындырасың?» кебек сүзләр кушмыйча аерылмыйлар иде. Шулай итеп, Иван Яковлевич йомышын йомышларга һич кенә дә жай китерә алмады. Берзаман бөтенләй кулыннан ук төшереп жибәрде, ләкин сакта торучы полицийскийерактан ук таягын сузып: «Әйберең төште, иелеп ал!» дип кисәтү ясады. Иван Яковлевич борынны алырга һәм кесәсенә яшерергә мәжбүр булды. Берәм-берәм кибетләр ачыла башлап, урамда халык ишәйгәч, өмете бөтенләй өзелде.

Менә ул, Нева суына тондырып булмас микән дигән исәп белән, Исакиев күперенә таба атлады. Бу урында шуны искәртергә тиеш табам: Иван Яковлевич кебек бөтен яктан килгән мөхтәрәм зат турында моңарчы берни дә сөйләми торуыма үземне бераз гаеплерәк сизәм.

Иван Яковлевич, рус кәсепчесенә хас булганча, айнымас бер исерекбаш иде. Һәр бирмеш көн әллә кемнәрнең сакал-мыекларын кырып яшәсә дә, үзенең яңагына кырыну пәкесе тимәгәнгә мең былтыр. Иван Яковлевичның фрагы (Иван Яковлевичнын үз гомерендә сюртук кигәне юк) ала-кола төстә иде; ягъни мәсәлән, ул заманында кара булган, әмма аны көрән-сары һәм соры таплар чуарлап бетергән, якасы майланып ялтырап тора, ә өч төймәнең өчесе урынында да жеп асылынган. Иван Яковлевичның оятсызлыгы да житәрлек иде; коллежский асессор Ковалев кырыныргa килгәч, кайчакта: «Иван Яковлевич, кулыннан ис килә бит!» — дип тә әйткәли иде. Иван Яковлевич моңа каршы: «Каян килгән ди ул ис?» — дип сорау бирә.

Коллежский асессор: «Каян килгәнен белмим, туганкаем, ну ис килүе хак!» — ди. Иван Яковлевич борын тәмәкесен исни дә шул сүзләре өчен аның бөтен яңагын, борын асларын, колак артларын, сакал төпләрен күбеккә батырып бетерә, карарлыгын калдырмый.

Иван Яковлевич Исакиев күперенә дә килеп житте. Башта ул тирәягын тикшерде, аннан култыксага иелеп, балыгы күп микән дигәндәй, күпер астына күз салды һәр борын төйнәлгән чүпрәген суга тондырды. Өстеннән авыр йөк төшкәндәй, бердән жиңеләеп китте, хәтта елмаеп та куйды. Шуннан чиновникларның сакал-мыекларын кырырга барасы урында, берәр стакан пуншка өметләнеп, «Ашау-эчү» дип язылган йортка таба атлады. Шулчак күпер очындарак чигә сакаллы, өчпочмаклы эшләпә кигән, шпага тоткан күркәм генә кыяфәтле надзирательны күреп алды. Ул тораташтай катып калды; надзиратель бармагын изәп:

— Кил әле монда, сөеклем! — дип үз янына чакырды.

Иван Яковлевич ерактан ук картузын салып җәһәт кенә килде дә:

— Исәнлек телим, галиҗәнап әфәнде! — диде.

— Юк, туганкай, галиҗәнап түгел, әйт әле, күпердә нишләдең?

— Валлаһи, сударь, сакал-мыек кырырга барган җиремнән, елга кызу агамы икән дип, карарга гына тукталган идем.

— Алдашма! Ялганлап котыла алмассың. Сораганга җавап бир!

— Мин Сез галиҗәнапларны атнасына ике тапкыр, юк, өч тапкыр берсүзсез кырырга әзер,— диде Иван Яковлевич.

— Юк, дус кеше, аның ише вак-төяккә алданмыйм! Мине өч чәчтараш кырындыра, әле бик зур дәрәҗә санап. Йәле, сөйләп бир, күпердә нишләдең?

Иван Яковлевич агарып катты... Ләкин шушы урында әлеге вакыйга билгесезлек томанына урала, алдагы хәлләрдән без бихәбәр.

## II

Коллежский асессор Ковалев йокысыннан иртәрәк уянды да, иреннәрен бөрештереп: «брр...» — дип куйды, уянгач ул гел шулай итә, гадәтенә сеңгән, ләкин сәбәбен әйтеп бирә алмый. Ковалев киерелде-сузылды да өстәлдәге бәләкәй көзгене алып бирергә боерды. Ул кичә борынындагы чыккан бетчәне карамакчы иде, әмма... борын урынында... тап-такыр буш урын! Ковалев, коты чыгып, су сорап алды һәм сөлге белән күзләрен сөртте: борын ... һаман юк иде! Ул, йокламыйм микән дип, калтыранган куллары белән үзен капшап-тотып карады: йоклаганга да охшамаган. Коллежский асессор Ковалев караватыннан сикереп торды да селкенгәләп алды: әмма борын юк иде!.. Шундук үзен киендерергә әмер бирде һәм обер-полицмейстерга чыгып чапты.

Бу урында безгә Ковалевның үзен, аның нинди коллежский асессор булуын сөйләп китү мәгъкуль булыр. Коллежский асессорларның төрлесе була. Гыйльми аттестатлар ярдәмендә бу дәрәҗәле исемне алган коллежский асессорларны Кавказда билгеләнгән коллежский асессорлар белән чагыштырырлык та түгел. Болар бөтенләй икесе ике төрле дәрәҗә. Гыйльми коллежский асессорлар... Ләкин Россия искитмәле ил бит ул, әгәр бер коллежский асессор турында сөйли башласаң, Ригадан Камчаткага хәтле булган бөтен коллежский асессорлар да үзләренә кабул итәчәк. Шул ук фикер бөтен дәрәҗә һәм чиннарга да кагыла. Ковалев Кавказ коллежский асессоры иде. Аның бу чинны алганына әле ике генә ел, шунлыктан аны бер генә минутка да оныта алмый; ә инде үзенә затлылык төсмере, абруй өстисе килсә, үзен бервакытта да коллежский асессор дип түгел, ә майор дип таныштыра. Урамда манишкалар[1] сатып торучы берәр хатын-кызны күрсә: «Тыңла әле, күгәрченкәем, син минем өемә кил, яме, минем фатирым Садоваяда, майор Ковалев кайда яши дип сорасаң, кем дә әйтеп бирер»,— ди ул гадәттә. Чибәррәк хатын-кызны очратса: «Син, җаныкаем, майор Ковалев фатирын сораш»,— дип әйтмичә калмый. Шуңа күрә дә без аны алга таба коллежский асессор дип түгел, майор дип йөртәчәкбез.

Майор Ковалев һәр бирмеш көн Нева проспектында йөрергә гадәтләнеп китте. Манишкасының якасы һәрвакыт чиста һәм крахмалланган булыр. Чигә чәчләре аның губерна һәм өяз землемерлары, архитекторлар һәм полк табиблары, төрле полиция вазифаларын башкаручылар, гомумән, бик шәп итеп бостон[2] уйнаучы, чиртсәң кан чәчрәп чыгардай таза, янып торган битле ирләрнеке кебек яңагының уртасыннан башланып борынына хәтле җиткән. Майор Ковалевның асылташлы һәм гербле, чәршәмбе,

---

[1] Манишка — ирләр күлмәгенә тегелеп йә кигезелеп куела торган ак күкрәкчә.

[2] Бостон — кәрт уены.

пәнҗешәмбе, дүшәмбе дип язылган мөһерле балдаклары да бихисап. Майор Ковалевның Петербургка килүе дә тикмәгә түгел — чинына лаек эш урыны эзләп йөрүе иде: уң килсә, вице-губернатор, инде бер дә булмаса, абруйлырак департаментта хуҗалык эшен алып баручы чиновник урыны булмасмы дип өметләнә иде. Майор Ковалев өйләнергә дә каршы түгел, ләкин моның һичшиксез үтәлергә тиешле шарты бар — кәләш өчен бирнәгә ике йөз мең мәһәр акчасы биргән очракта гына риза ул. Ярыйсы гына матур, уртача зурлыктагы борын урынына күнел кайткыч шома тигезлек күргән майорның хәле ничек икәнен укучы үзе чамаласын инде хәзер.

Үч иткәндәй, урамда ник бер извозчик очрасын; плащына ныграк төренеп, борыныннан кан киткәндәге кебек йөзен кулъяулык белән каплап җәяү китми чарасы калмады. «Әллә ялгыш күрдемме соң, борынның тик торганнан юкка чыгуы ахмаклык бит» дигән уй белән ул көзгедән карарга дип махсус татлы ашамлыклар кибетенә керде. Бәхетенә, кибеттә беркем дә юк иде; кайбер кибетче малайлар бүлмәләрне акшарлыйлар, урындыкларны урнаштыралар, кайсылары, йокыдан айныр-айнымас килеш подноска салып, кайнар бөккәннәр чыгаралар; өстәл-урындыкларда кофе түгелгән кичәге газеталар аунап ята. «Аллага шөкер, беркем дә юк икән әле,— диде ул эченнән, — әйбәтләбрәк карарга була. Күргән, ишеткән хәлме инде бу?! — диде ул төкеренеп.— Ичмасам, берәр нәрсә үссен иде, буш булганчы!..» Үртәлүеннән иреннәрен кысып, кибеттән чыкты да, гадәтенә хас булмаганча, беркемгә дә күтәрелеп карамаска һәм елмаймаска тырышты. Кинәт ул бер йортның ишеге төбендә каккан казыктай тукталып калды; күз алдында әйтеп-аңлатып булмый торган гаҗәеп күренеш иде: ишек төбендә карета туктады; каретаның ишекләре ачылды; мундир кигән бер әфәнде иелеп сикереп төште һәм баскычтан йөгереп менеп китте. Каушау катыш гаҗәпләнүдән Ковалев гаҗиз булды: бу бит — аның үз борыны! Әлеге сүз белән аңлатып булмастай хәлдән әйтерсең бөтенесе асты өскә килде; ул көч-хәл белән аягында басып торды; алай да, бөтен гәүдәсе белән калтырана-калтырана, кире чыкканын көтәргә булды. Бер-ике минут үткәндерме-юкмы, борын кире чыкты. Ул алтынлап чигелгән зур утыртма якалы мундир, замша чалбар кигән; янбашына шпага элгән. Каурыйлар белән бизәлгән эшләпәсенә караганда, ул статский советникка охшап тора. Аның кем беләндер күрешергә килгәнлеге көн кебек ачык. Ул як-ягына каранды да: «Бире кил!» — дип кучерга кычкырды һәм утырып китеп тә барды.

Мескенкәем Ковалев чүт кенә акылдан язмый калды. Мондый ике ятып бер төшенә дә кермәгән вакыйга турында ул ни дип уйларга да белмәде. Күргән, ишеткән хәлме инде бу?! Әле кичә генә үз урынында тик кенә утырган борын мундир киеп йөрсен әле?! Майор карета артыннан чапты. Анысы әле ярый ерак китмәде, Казан соборы янына барып туктады. Майор Ковалев соборга таба атлады. Яулыкларын ике күзен генә ачык калдырып бәйләгән хәер сорашучы карчыклар арасыннан кысыла-кысыла үтте дә чиркәүгә керде. Гыйбадәт кылучылар әллә ни күп түгел иде, һәммәсе ишек төбендә таптаналар. Ковалевның күңеле үз урынында түгел, дога кылуының рәте-башы булмады, күзләрен алан-йолан йөртеп, теге әфәндене эзләде. Ниһаять, ул аны бер кырыйда басып торган хәлдә күреп алды. Борын йөзен зур утыртма яка эченә яшергән дә тәкъва кыяфәттә догага оеган иде.

«Янына ничек кенә барыйм икән? — дип баш ватты Ковалев.— Мундирына, эшләпәсенә караганда, статский советникка охшап тора. Ничекләр итеп янына барыйм икән?!»

Ул якынрак килеп ютәлләп тә карады; әмма борын, һаман шул дөньядан кучкән кыяфәттә, иелә-бөгелә догада булды.

— Хөрмәтле әфәндем... — дип сүз башлады Ковалев үзен эчтән дәртләндерергә тырышып,— хөрмәтле әфәндем...

— Ни кирәк сезгә? — дип, борын әйләнеп карады.

— Бик гаҗәп бу, хөрмәтле әфәндем... минемчә... Сез үз урыныгызны белергә тиеш. Бөтенләй уйламаган җирдә таптым мин сезне — чиркәүдә. Килешәсездер...

— Гафу итегез, ни сөйлисез сез, һич төшенә алмыйм... Аңлатыбрак әйтегез.

«Ничегрәк итеп аңлатыйм икән?» — дип, Ковалев беравык уйланып торды һәм бар кыюлыгын җыеп:

— Билгеле, мин... ягъни, мин — майор. Миңа борынсыз йөрү һич килешә торган эш түгел. Урамда сатып утыручы хатыннарга, әнә Воскресенск күперендә әфлисун сатып утырырга борын кирәкмәскә дә мөмкиндер; әмма миңа килсәк... күпме таныш-белеш бар, статская советница Чехтарева, мәсәлән... Үзегез күз алдына китереп карагыз... белмим инде, хөрмәтле әфәндем. (Шулай дип майор Ковалев җилкәләрен сикертеп куйды.) Гафу итегез... Әгәр дә мәгәр шушы хәлгә бурыч һәм намус күзлегеннән карасак... Сез үзегез дә төшенерсез...

— Берни дә аңлый алмыйм,— диде борын.— Фикерегезне ачыграк әйтә алмассызмы?!

— Хөрмәтле әфәндем... — диде Ковалев үз бәясен белеп, — мин сезне аңлаудан гаҗизмен... Монда бөтенесе уч төбендәге кебек ачык... Сез бит минем шәхсән үз борыным!

Борын, кашларын җыерып, майорга карады.

— Ялгышасыз, әфәндем. Мин үземә үзем хуҗа. Безнең арада андый тыгыз бәйләнешнең булуы мөмкин түгел. Вицмундирыгызның төймәләренә караганда, сез икенче ведомствода хезмәт итәсез.

Борын, сүзен тәмамлап, янә дога кылырга тотынды. Ковалев коелып төште, ни эшләргә һәм ни уйларга белмәде. Шулчак сизелер-сизелмәс хатын-кыз итәге җилфердәгән тавыш ишетелде; итәк-җиңе, якалары челтәр белән кайmaланган күлмәк кигән өлкәнрәк яшьтәге ханым белән билләре өзелеп торган ак күлмәктән, салам төсендәге җиңел эшләпәдән зифа-нәзек ханым килеп керде. Артларына мул бакенбардлы һәм дистәләп алмаш якалар тоткан озын буйлы гайдук килеп басты да тәмәке савытын ачты.

Ковалев аларга якынрак елышты, манишкасының батист якасын күрсәтебрәк чыгарды, алтын чылбырын рәтләде, як-ягына каранып, юка гәүдәле ханымга елмайды. Тегесе, язгы чәчәктәй җиңелчә генә баш иеп, үтә күренмәле нәзек бармаклы ап-ак кулын маңгаена куйды. Ханымның эшләпәсе астыннан күренеп киткән түгәрәк ап-ак ияген, язгы роза чәчәген хәтерләткән йөзен күргәч, Ковалевның авызы колагына җитә язды. Ләкин шундук, утка пешкәндәй, читкә тайпылды. Борынсыз булуы исенә төшкәч, ирексездән күзенә яшьләр килде. Мундир кигән теге әфәндене статский советник кыяфәтенә кереп кыланып йөрүен, чынлыкта исә бер алдакчы һәм кабахәт булуын, аның бары тик борын гына икәнлеген йөзенә бәреп әйтергә дип борылган иде... Ләкин борыннан җилләр искән, мөгаен, тагын берәрсенә визит белән киткәндер.

Ковалев өметсезлеккә бирелде. Ул чыгу ягына таба барды да, колонналар янында тукталып, борын күренмәс микән дип тирә-юньне энә күзеннән үткәрде. Майор аның каурыйлы эшләпәсен дә, алтын белән чигелгән мундирын да әйбәт хәтерли; ә менә шинелен искәрмәгән; каретасының, атларының төсе дә, кузладагы лакейның барлыгы-юклыгы да, ливреенын нинди булуы да исендә юк. Житмәсә, кареталар тыз да быз чаба, күз иярмәле түгел, таныган очракта да туктатып калырмын димә. Көн гаҗәеп матур һәм кояшлы иде. Нева проспектында халык ташкыны агыла; Полицейскийдан Аничкин күперенә хәтле, бөтен тротуарны иңләп, чәчәк шарлавыгыдай ханымнар сибелгән. Әнә каршына таныш надворный

советник килә, кайчагында, аеруча кеше алдында, ул аңа подполковник дип эндәшә. Менә монысы — Ярыгин — сенатта бүлек начальнигы, дус кеше, кәрт уенында ремиз[3] өчен гел оттыра ул. Әнә Кавказда асессор дәрәҗәсе алган бер майор, янына чакырып кулын изи...

— Их, шайтан алгыры! — дип әйтеп куйды Ковалев.— Әй, извозчик, обер-полицмейстерга алып бар!

Ковалев тарантаска утырды да извозчикка: «Җилдән җитез элдерт әйдә!» — дип кычкырды.

— Обер-полицмейстер бармы? — дип сорады ул өйалдына кереп җитәр-җитмәс.

— Юк ул,— диде ишек сакчысы.— Әле янарак кына китте.

— Менә сина мә!

— Шулай,— дип өстәде ишек сакчысы,— яна гына чыгып китте. Бер генә минут алданрак килгән булсагыз да, өйдә тота идегез.

Ковалев, кульяулыгы белән һаман йөзен каплап извозчикка утырды да:

— Киттек! — дип үртәлеп кычкырды.

— Кая? — дип белеште извозчик.

— Туры бар!

— Кая туры барыйм. Монда бит борылыш: унга борылыйммы, сулгамы?

Әлеге сорау Ковалевны уйланырга мәҗбүр итте. Бу хәлендә аңа иң беренче нәүбәттә Әхлак управасына мөрәҗәгать итеп карарга кирәк булгандыр, мөгаен. Аның полициягә турыдан-туры катнашы булганга түгел, бәлки, әлеге управаның карарлары бүтәннәренә караганда тизрәк тормышка ашырылганга; борын хезмәт иткән урыннан гозереннән үтәлүен көтү акылсызлык галәмәте булыр иде, чөнки борынның баягы сөйләшүеннән ачык күренде: аның өчен намус төшенчәсе юк дәрәҗәсендә, ул баягынак бу әфәндене күргәнем дә, белгәнем дә юк дип ялганлаган кебек, әлеге очракта да күзен дә йоммый алдаячак. Шулай итеп, Ковалев Әхлак управасына барырга дип боерырга авыз ачам дигәндә, башына янә бер уй килде: бу алдакчы хәйләкәр, жае чыкса, шәһәрдән чыгып таярга да күп сорамас, ул вакытта бөтен эзләүләрең җилгә очты дигән сүз, яки, Ходай сакласын, ай буена да сузылырга мөмкин. Ниһаять, уйлана торгач, миен яшендәй бер фикер яктыртып алды. Ул газетага мөрәҗәгать итәргә һәм, озын-озакка сузмыйча, кыяфәтен, килеш-килбәтен сурәтләп белдерү бирергә исәп кылды. Очраткан кеше, шундук аны танып, үзенә алып килсен, инде бер дә булмаса, кайда күргәнен хәбәр итсен. Шундый катгый карарга килеп, майор извозчикка газеталар экспедициясенә барырга боерды, үзе юл буе: «Тизрәк, хәсис! Тизрәк, адәм актыгы!» — дип, йодрыгы белән извозчикның аркасын төйде. Извозчик, башын чайкый-чайкый, дилбегәсе белән болонко кебек озын йонлы атын камчылап: «Их, барин!» — диюдән узмады.

Тарантас, ниһаять, туктады. Ковалев, ухылдап, бәләкәйрәк кабул итү бүлмәсенә килеп керде. Искерәк фрак кигән, күзлекле, чал чәчле чиновник, каләмен теш арасына кыстырып, өстәл янында бакыр акчалар санап утыра иде.

Ковалев килеп керә-керешкә:

— Белдерүне кем кабул итә? — дип кычкырды.— Ә-ә, исәнмесез!

— Рәхим итегез! — дип, чал чәчле чиновник бер генә мизгелгә башын күтәреп карады да янә өстәлдә таралып яткан тиеннәргә төбәлде.

— Мин белдерү бастырмакчы идем...

— Әз генә көтеп торыгыз,— дип, чиновник бер кулы белән кәгазьгә цифр язды, сул кулы белән счетның ике төймәсен тартып куйды.

[3] Ремиз — кайбер кәрт уеннарында: тиешле взятканы җыя алмаган өчен штраф.

Аксөякләр йортында хезмәт итүе килеш-килбәтеннән үк күренгән бер лакей кулында язулы кәгазь тотып өстәл янында басып тора һәм, көткән арада ләм-мим бер сүз дә әйтмәүне яхшысынмыйча, сөйләнә иде:

— Килешәсездер, сударь, көчек сигез гривна тормый бит инде, ягъни мин аңа дүрт тиен дә бирмәс идем, ә графиня үлепләр китә шуның өчен, билләһи газыйм, үлә: тапкан кешегә йөз сум вәгъдә итә бит! Ни генә әйтмә, һәр кешенең үз зәвыгы шул. Аучы икәнсең, легавый[4] этен асра син, йә пудельне; биш йөзенне дә җәлләмә, мен сум түлә — аның каравы этең менә дигән булсын.

Чиновник итагать күрсәтеп, игътибар белән тыңлый-тыңлый, сметаны исәпләп чыгарды, ягъни мәсәлән, белдерүдә ничә хәреф икәнен санады. Бүлмәгә кулларына белдерү тоткан карчык-корчыклар, приказчиклар һәм урам себерүчеләр тулган иде. Бер белдерүдә айнык күчерны хезмәтчелеккә биреп торуларын язганнар, бүтәннәрендә — 1814 елда Париждан кайтартылган яңа коляска; кер юа белүче һәм бүтән эшләргә дә маһир унтугыз яшьлек асрау кыз; бер рессоры булмаган, ләкин әле ныкча гына тарантас; унҗиде яшьләр чамасындагы яшь, кызу канлы алмачуар ат; Лондоннан кайтартылган шалкан һәм редис орлыклары; атлар өчен ике аранлы абзары һәм каен-чыршы агачлары үстерердәй җир биләмәләре дә булган дача тәкъдим ителә; шулай ук иске аяк киемнәре табаннарын сатуалу өчен көн саен иртән сәгать сигездән өчкә хәтле чакыру да бар иде. Шушы хәтле халыкны сыйдырган бәләкәй бүлмә һавасының нинди булуын чамалыйсыздыр; ләкин коллежский асессор Ковалев ис-посны тоярлык түгел, чөнки ул йөзен кульяулык белән каплаган, һәм дә борынының кай тарафларда сәфәр кылып йөрүе дә мәгълүм түгел бит әле.

— Хөрмәтлем, сорарга мөмкин булыр микән... Бик кирәк иде,— диде майор, түземе төкәнеп.

— Хәзер! Хәзер! Ике сум да кырык өч тиен! Бер генә минут! Бер сум да алтмыш дүрт тиен! — дип сөйләнә-сөйләнә чал чәчле әфәнде карчык-корчыкның, урам себерүчеләрнең язуларын йөзләренә ыргытты да Ковалевка карап: — Йомышыгыз ни? — дип сорады.

— Мин үтенәм... — диде Ковалев,— караклык дип атаргамы моны, хыянәт дипме, ничек әйтергә дә телем әйләнми. Мин басып чыгаруыгызны гына үтенәм, шул кабахәтне тотып китергән кешене буш итмәм.

— Фамилиягезне әйтмәссез микән?

— Юк, фамилияне кыстырмыйк монда. Фамилияне күрсәтергә һич ярамый. Танышларым дөнья хәтле: Чехтарева, — статская советница, Палагея Григорьевна Подточина — штабс-офицерша... Танулары мөмкин, Алла сакласын! Сез коллежский асессор дип кенә языгыз, майор чинындагы дисәгез тагын да шәбрәк булыр.

— Качкын дигәнегез Сездә асрау булып тордымы?

— Нинди асрау булсын? Андый гына хыянәт ярый әле ул! Миннән бит борыным... качты...

— Кем! Бик сәер фамилия бу! Зур сумма белән качтымы инде ул Борынов әфәнде дигәнегез?!

— Борын... ягъни... Сез бөтенләй икенче әйбер уйлыйсыз! Мин шәхсән үз борынымның юкка чыгуын әйтәм. Җен алыштырдымы шуны?!

— Ничек юкка чыгарга мөмкин соң ул? Һич башыма барып җитми.

— Ничек икәнен мин үзем дә белмим, ләкин аның статский советник булып бөтен шәһәр буйлап йөрүе хак бит. Менә шуңа күрә аны тоткан кеше тиз арада миңа кайтарсын дип белдерү бирүегезне үтенәм. Үзегез уйлап карагыз, шундый мөһим әгъзасыз мин ничек кеше күзенә күреним инде? Аякның чәнти

[4] Легавый — ау этенең бер токымы.

бармагы түгел бит ул, итек киеп кенә яшереп булмый аны. Һәр атнаның пәнҗешәмбесендә мин статская советница Чехтареваларга барам; штабс-офицерша Подточина Палагея Григорьевнага да барып-килеп йөрим, ә аның сөйкемле генә кызы бар... Хәзер мин аларга йөри алмыйм дигән сүз бит бу!

Чиновник иреннәрен кысып уйга калды.

— Юк, мондый белдерүне мин газетада бирә алмыйм,— диде ул озак кына эндәшми торганнан соң.

— Ник? Ни өчен?

— Шулай менә. Газета дәрәҗәсен төшерергә мөмкин. Әгәр бөтен кеше борыным качты дип яза башласа... Әле болай да газетагыз җыен тузга язмаганны бастыра дип тукып торалар.

— Ник тузга язмаган булсын? Монда шаккатырлык берни дә юк.

— Сезгә генә шулай тоела ул. Әле үткән атнада мондый хәл булды. Бер чиновник сезнең кебек белдерү тотып килгән. Тиешле акчасын да түләде: ике сум җитмеш өч тиен. Кара пуделе качкан дип язылган иде белдерүендә. Бер караганда, гадәти хәл. Ә чынлыкта пасквиль[5] килеп чыкты: пудель дигәнебез казначей булган икән бит, хәзер инде хәтерләмим кайсы оешмадан икәнен.

— Мин бит пудель турында түгел, ә шәхсән үз борынымны язам, үземне язган кебек бит инде ул.

— Юк, мондый белдерүне газетада урнаштыра алмыйм.

— Борыным юкка чыкканны белә торыпмы?!

— Югалса, анысы бит табиб кайгысы. Арада шундый осталары бар, теләсә нинди борын тегеп куярлар. Сез үзегез дә бик шаярта торган кешегә охшап торасыз.

— Билләһи дип әйтәм, ант менә! Алайга китсә, күрсәтәм хәзер.

— Мәшәкатьләнмәгез! — диде чиновник борын тәмәкесен исни-исни.— Хәер, әгәр бик мәшәкать димәсәгез, күз төшереп алырга була,— диде ул, кызыккан кыяфәт чыгарып.

Коллежский асессор йөзеннән кульяулыгын алды.

— Дөрестән дә, гаҗәеп хәл бу! — диде чиновник,— урыны шоп-шома, әле генә табадан төшкән белен диярсең. Ничек шулай тигез булырга мөмкиндер!

— Инде хәзер дә бәхәсләшеп торасызмы?! Белдерүне басарга кирәк икәнен үзегез дә күрәсез. Мин сезгә чиксез рәхмәтле булачакмын; әлеге хәл уңаеннан танышырга мөмкинчелек чыгуга шатмын...

Майор, күрәсең, бераз төрттереп алырга теләде булса кирәк.

— Белдерү язу әллә ни кыен эш булмас анысы,— диде чиновник,— ләкин мин сезнең өчен бер файда да күрмим монда. Әгәр бик теләсәгез, берәр остарак яза торган кешегә сөйләгез дә, шушы четерекле хәл турында мәкалә язып «Северная пчела» газетасында бастырсын (бу урында ул тагын тәмәке иснәп алды), яшүсмерләргә файдасы тимәсме (бу урында ул борынын сөртеп алды) йә кызыксындырмасмы.

Коллежский асессор үртәлүдән нишләргә белмәде. Ул карашын түбән иде һәм газетаның аскы өлешендә спектакльләр турында хәбәр күреп алды; сөйкемле генә бер актрисаның исемен очраткач, йөзе елмайгандай итте, кулы да, зәңгәр ассигнацияне[6] үзем белән алдым микән дип кесәсенә кереп китте, чөнки, Ковалев фикеренчә, штабс-офицерлар кәнәфидә утырырга тиешләр,— шулчак, борыны исенә төшеп, кәефе шундук кырылды!

Ковалевнын нәүмизләнүе чиновникка да тәэсир итми калмады.

Хәленә кереп, җылы сүз кушарга ниятләде:

---

[5] Пасквиль — берәр кешене мыскыл итү өчен язылган яла ягулы, кимсетүле әсәр.

[6] Ассигнация — 1769—1843 елларда Россиядә йөргән кәгазь акча исеме.

— Мондый мәзәк хәлгә калуыгыз бик аяныч. Тәмәке иснәп куегыз әле! Ул баш авыртуын да баса, күнелне дә ачып жибәрә...

Шулай дип, чиновник тәмәке савытының эшләпәле ханым сурәте төшерелгән капкачын, житез генә ачып, Ковалевның йөзенә якынайтты.

Бу уйланмаган кыланыш Ковалевны чыгырыннан чыгарды.

— Мондый шаяртуыгыз урынсыз дип уйлыйм,— диде ул гасабиланып,— күрмисезмени, мин ничек, ни белән иснәргә тиеш аны? Күз алдымнан юк итегез тәмәкегезне! Минем хәзер аны күрәсем дә килми, әтрәк-әләм березинский сортын гына түгел, рапенын үзен тәкъдим итсәгез дә.

Ул пыр тузып, ачуына чыдаша алмыйча, газета экспедициясеннән чыкты да шикәр дигәндә тәкатьсез булган шәхси приставка китте. Приставның өйалды да, аш бүлмәсе дә таныш-белеш купецлар алып килгән шикәр каплары белән тулган иде. Приставның пешекчесе хужасының озын кунычлы казна итекләрен салдырып ята; шпага һәм шуның кебек хәрби кораллары почмакларга элеп куелган: өчпочмаклы эшләпәсенең киң кырыйларын өч яшьлек малае тарткалый-йолыккалый башлаган, пристав үзе, ызгышлы-тиргәшле хөкүмәт эшеннән соң, тыныч өй мохите рәхәтенә тиенергә өметләнеп тора иде.

Ковалев килеп кергәндә, ул, киерелеп-сузылып, тамагын кырды һәм: «Их, бер-ике сәгать йоклап алыйм әле!» — дип сөйләнеп алды. Коллежский асессорның вакытсыз йөрүен шушы хәлдән чамалавы кыен түгел. Әгәр ул бу чакта берәр кадак чәй йә постау алып килсә дә, ачык йөз белән каршы алуга исәп тота алмаган булыр иде. Шәхси пристав сәнгать әсәрләрен һәм мануфактура әйберләрен хуп күрсә дә, дәүләт ассигнациясенә бөтенләй биһуш иде. «Менә ичмасам әйбер,— дип әйтергә ярата иде ул,— моннан әйбәтрәк нәрсәнең булуы мөмкин түгел: ашарга сорамый, күп урын алмый, күпме булса да кесәгә сыя, төшерсәң — ватылмый».

Пристав Ковалевны шактый коры каршы алды һәм төшке аштан соң тикшерү эше башлауның мәгъкуль түгеллеген, ашап-эчкәннән соң бераз ял итеп алуны табигать үзе кушуын (моннан коллежский асессор борынгы акыл ияләренең хикмәтле сүзләре приставка таныш икәнен күрде), тәртипле кешенең борынын өзеп алмаячакларын, дөньяда майорларның төрлесе булуын, юньле кием күрмичә, әшәке жирләрдә ышкылып йөрүче майорларның да житәрлек булуын тәфсилләп аңлатты.

Ягъни мәсәләнең, аңлаган кешегә аңларлык булды. Ковалев гаять үпкәчел адәм иде. Үзе турында ни генә сөйләмәсеннәр, кылы да селкенми, ә менә чинына, дәрәҗәсенә кыеграк сүз әйтсәләр, гомердә кичерәсе юк. Театрларда спектакль-тамашалар уйнаганда обер-офицерларга кагылышлы кире сүзләр ычкынса, колагына элмәскә мөмкин әле, иллә мәгәр штабс-офицерларга беркем сүз тигермәскә тиеш дип саный ул. Приставның шулай кабул итүенә аның хәтере калды, башын чөеп һәм кулларын бераз жәя төшеп, горур гына: «Әйтергә мәжбүрмен, мондый рәнжетүдән соң минем бүтән әйтер сүзем юк...» — диде дә чыгып китте.

Ул, аягын көчкә сөйрәп, өенә кайтып егылды. Кичке эңгер-меңгер чак иде. Көне буена сузылган уңышсыз килеп-сарып йөрүләрдән соң фатиры бигрәк шыксыз, күңелсез тоелды. Алгы бүлмәдә лакее Иван пычранып беткән күн диванга аркан яткан да түшәмгә төкереп уйный, төкерегe лач итеп гел бер урынга барып төшә. Аның шундый битарафлыгы хужасын чыгырыннан чыгарды; маңгаена эшләпәсен бәреп: «Син, дуңгыз, һаман юләр сатып ятасыңмы?» — дип жикеренде. Иван сикереп торды да плащын салдырам дип хужасына барып тотынды.

Майор, бүлмәсенә кергәч, эттәй арып һәм кара кайгыга батып кәнәфиенә барып ауды да уф-пуф килеп бераз яткач:

— Йа Раббым! Йа Ходам! Минем башка гына төшкән нинди бәхетсезлек

бу? Аягым йә кулым булмасын иде ичмасам; колаксыз калсам, начарлыкка начар да, ләкин түзәр идем; әмма борынсыз йөрү... Борынсыз кешене кем дип тә әйтеп булмый: кош дисәң — кош түгел, адәм дисәң — адәм түгел, тот та тәрәзәдән ат үзен! Сугышта йә дуэльдә өзеп алсалар, йә үземнең гаеп белән булса, бер хәл; югыйсә тик торганда, бер сәбәпсез борының юкка чыксын әле!.. Юк, тиктомалдан югалмас,— диде ул бераз уйланып торгач.— Борынның юкка чыгуы мөмкин хәл түгел; берничек тә аңлатып булмый моны. Йә төш күрәм, йә саташып ятам инде; әллә соң, су дип ялгышып, кырынганнан соң сөртенергә торткан аракыны эчтем микән?

Үзенең чынлап та айнык икәненә ышанырга теләп, майор нык итеп чеметеп алган иде, авыртуына чыдый алмый кычкырып җибәрде. Авыртуны тойгач, өнендә, чынбарлыкта икәненә инанды. Әкрен-шыпырт кына көзге янына килде дә, борын үз урынында түгел микән дигән яшерен уй белән башта күзләрен чытырдатып йомды; шундук ачты да:

— Хурлык, билләһи! — дип читкә тайпылды.

Бик четерекле эш, ни дип тә аңлатып булмый моны. Әгәр инде сәдәптер, көмеш кашык йә сәгать мазар югалса, бер хәер әле; менә борын хәтле борынның үз фатирында юкка чыгуы — башка сыймаслык хәл!.. Майор Ковалев, шушы вакыйгага бәйле булырдай сәбәп-хәлләрне үлчәү тәлинкәсенә салып фикерли-зиһенли торгач, башына бер уй килде: монын сәбәпчесе, һичшиксез, штабс-офицерша Подточина булырга тиеш, бу ханым бит аны кызына ничек өйләндерергә белми йөри. Ул үзе кыз белән ара-тирә очрашып йөрергә каршы түгел, ләкин эшне зурга җибәрүдән кача. Ә инде штабс-офицерша кызын аңа кияүгә бирәсе килүен туп-туры белдергәч, ул матур сүзләр әйтүдән туктап, үзенең яшьрәк булуын, кырык ике яшь тулганчы, биш еллап хезмәт итәргә тиешлеген сылтау итеп әкрен-әкрен читләшә башлады. Менә шуңа күрә дә штабс-офицерша үчлектән берәр сихерче карчыкны яллагандыр, алайса борынның киселүен берничек тә аңлатып булмый: бүлмәгә беркем дә кермәде; чәчтараш Иван Яковлевичта ул чәршәмбе көнне үк булды, чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрне борыны урынында иде — моны ул төп-төгәл хәтерли һәм белә; һич булмаса авыртуы сизелер иде, аннан соң яра алай тиз генә төзәлми дә, белен кебек шома да булмый бит. Ул план кора башлады: штабс-офицершаны рәсми рәвештә судка чакырыргамы, әллә өенә барып фаш итәргәме?! Ишек ярыкларыннан саркып кергән шәм яктысы уй йомгагын шул урында өзде — алгы бүлмәдә Иван шәм кабызган икән. Бүлмәне шәм нуры белән яктыртып, Иван үзе дә чыкты. Баринын сәер хәлдә күреп бу тиле-миле аптыраштта калмасын дип Ковалев кулъяулыгын ялт кына чыгарды да кичә генә борын булган урынны каплады.

Иванның эт оясыдай үз бүлмәсенә чыгып китүе булды, алгы бүлмәдә:

— Коллежский асессор Ковалев монда яшиме? — дип сорашкан чит тавыш ишетелде.

Ковалев сикереп торды да тизрәк ишекне ачып:

— Керегез. Майор Ковалев монда,— диде.

Мәһабәт кыяфәтле, тулы чырайлы, коңгырт чигә чәчле, теге чакта Исакиев күперендә басып торган полиция чиновнигы килеп керде.

— Сез борынығызны югалткан идегез бугай?

— Әйе шул.

— Табылды ул.

— Чынмы? — дип кычкырып җибәрде Ковалев. Сөенеченнән ул телсез калды. Калын иреннәрендә һәм йөзендә шәм яктысының шәүләсе уйнаган квартальныйга карап катты.— Ничек таптыгыз?

— Юлга чыгарга җыенган чакта эләктердем. Ригага китмәкче булып дилижанска да утырган иде инде. Паспорты да күптәннән бер чиновник

исеменә язылган булган. Иң сәере шул: баштарак мин аны бер әфәнде дип торам. Бәхетемә күрә, ярый әле янымда күзлегем бар иде, борын икәнен шундук танып алдым. Мин бит күрә карау, менә сез каршымда басып торсагыз да, йөзегезне тоташ кына чалымлыйм: борыныгызны да, сакалыгызны да аера алмыйм. Хатынымның әнисе дә ерактан күрми.

Ковалев үзен кая куярга белмичә, үрсәләнеп:

— Кайда соң ул? Кайда? Хәзер янына барам! — диде.

— Борчылмагыз. Мин аның сезгә кирәген белеп, үзем белән алып килдем. Иң гаҗәбе шул, Вознесенск урамындагы теге мошенник чәчтарашның һичшиксез катнашы бар монда, мин аны да кулга алдым. Кыек юлда йөридер бу дип шикләнә идем аны, дөрес булып чыкты. Әле өченче көн генә бер ларектан сәдәпләр урлаган икән. Менә, борыныгызга берни дә булмаган, нәкъ үзе.

Шулай дип, квартальный кесәсенә үрелде һәм кәгазьгә төрелгән борынны чыгарды.

— Шул үзе! — дип кычкырып җибәрде Ковалев.— Нәкъ үзе! Бүген миңа чәйгә рәхим итегез.

— Бик рәхәтләнеп риза булыр идем дә, бер дә вакытым юк: кайтышлый мәҗбүри хезмәт белән төзәтү йортына сугылып чыгасым бар... Азык-төлеккә бәяләр күтәрелеп китте бит әле... Миндә әби дә яши, ягъни хатынымның әнисе, бала-чага да җитәрлек, олысы бигрәк тә сәләтле күренә, башлы малай, бик укытасы, кеше итәсе килә, тик акча җиткерәлми интегәм...

Ковалев, моның тел төбен аңлап, өстәлдән кызыл ассигнацияне алды да надзирательнең кулына сонды, тегесе, үкчәләрен бәреп, башын иде дә саубуллашып чыгып китте, икенче мизгелдә инде тавышы урамда ишетелде: арбасы белән бульварга барып кергән томана бер мужикка үгет-нәсыйхәт укый иде.

Квартальный киткәч, коллежский асессор кисәк сөенечтән беравык аңсыз булып торды, күпмедер вакыттан гына нидер күрә һәм тоя алырлык хәлгә килде. Борынны иплəп кенә учына алды да игътибар белән карыйтикшерә башлады.

— Шул үзе, нәкъ үзе! — диде майор Ковалев.— Әнә сул ягында кичә чыккан бетчәсе дә бар.

Майор шатлыгыннан чүт кенә кычкырып көлеп җибәрмәде.

Бу дөньяда берни дә мәңгелек түгел, сөенеч дигәненнең тәэсире икенче мизгелдә кимегән була, бераздан ул тагын да сүлпәнләнә төшә һәм күңелнең гадәти халәтенә әйләнә: суга ыргытылган вак таш ясаган боҗралар кебек, тора-бара шома су өслегенә кушылып бетә. Ковалев, уйлана торгач, әле куанырга иртәрәк икәнен фикерләде: борын табылды-табылуын, ләкин бит әле аны ябыштырасы, урынына куясы бар.

— Әгәр дә ул ябышмаса?

Үз-үзенә биргән сораудан Ковалев агарынып китте.

Әйтеп-аңлатып булмый торган курку хисе белән ул өстәлгә ташланды, борынны кыек куя күрмим дип көзгене якынрак китерде. Куллары дер-дер калтырый иде. Иплəп кенә, сак кына тотып, борынны элеккеге урынына куйды. Йа Хода! Борын ябышмады!.. Ул борынны авызына китерде, сулышы белән җылыткандай итте һәм тагын шома урынга куйды: ләкин борын урынында тормады.

— Йә, әйдә инде! Ябыш, имгәк! — дип әйтеп-үгетләп тә карады. Ләкин борын агачка әйләнгән диярсең, шап итеп өстәлгә килеп төште. Майорның йөзе, көзән җыергандай, чалшаеп кыйшайды.— Ябышмас микәнни? — дип сөйләнде ул коты чыгып. Ләкин борынны үз урынына кат-кат куеп караса да, эш пешмәде.

Ул Иванны дәште дә, шул ук йортның өске катындагы яхшырак фатирда яшәүче табибны чакырырга кушты. Табиб дигәнебез дегеттәй кап-кара матур чигә чәчле, күрер күзгә күркәм генә ир кеше иде (хатыны да үзенә иш: яныш торган таза ханым), ул һәр иртәдә алма ашый, авызын гел тазалап тота, иртәдән көн саен чайкый, төрледән-төрле биш щетка белән чистарта иде. Табиб шундук кереп тә житте. Бәхетсезлекнен кайчанрак булуын сорашып, Ковалевнын ияген нән күтәрде, элек борын булган урынга баш бармагы белән чирткәч, майор үзе дә сизмәстән башын артка чөйде, баш чүмече белән чек итеп стенага килеп бәрелде. Табиб, берни дә булмагандай, ана стенадан читкәрәк авышырга кушты, башын уң якка кыйшатырга боерды да, элек борын булган урынны капшап: « Һм!» — дип куйды. Аннан башын сул якка борырга әйтте дә тагын: « Һм!» — диде, ахырда баш бармагы белән янә чирткәч, авызын ачып тешләрен тикшергәндә ат башын ничек чөеп жибәрсә, майор Ковалев та шулай итте. Шундый тикшерүләр уздыргач, табиб башын чайкап:

— Юк, куеп булмас моны. Борынсыз йөрүегезне мәслихәтрәк күрәм, югыйсә бөтенләй бозылыр гына. Аны, билгеле, ябыштырырга мөмкин; мин аны хәзер ябыштыра да алам, ләкин, дөресен әйтәм, начар гына булыр,— диде.

— Борынсыз калыйммыни инде мин? — диде Ковалев.— Моннан да мөшкел хәлгә төшкәнем юк иде. Адәм хуры булдым бит! Ни йөзем белән кеше күзенә күреним хәзер?! Менә бүген кичкә мин ике йортка чакырулы. Таныш-белешләрем житәрлек: статская советница Чехтарева, штабс-офицерша Подточина... Хәер, мондый этлегеннән соң, полиция аша гына эш йөртергә туры килер әле аның белән. Мине бу хәлдә калдыра күрмәгез,— диде Ковалев ялварып,— берәр жаен табыгыз, ничек булса да ябыштырыгыз; бик яхшы чыкмаса чыкмас, эләгеп торса ярар, төшә-нитә күрмәсен дип тотыбрак йөрермен. Мин бит биемим, саксыз кыланып зыян китерү куркынычы юк. Килүегезне буш калдырмам, анысына борчылмагыз, хәзинәдә барынча тырышырмын...

— Ышанасызмы,— диде табиб артык көчле дә, йомшак та булмаган, ләкин гажәеп үзенә жәлеп итә торган тавыш белән,— мин бервакытта да файда өмет итеп дәваламыйм. Минем гадәтемә ят нәрсә ул. Кире кагып үпкәләтмим дип кенә алыштыргалыйм. Билгеле, мин сезнең борынны урынына куя алам; ләкин, әгәр инде сүземә ышанмыйсыз икән, намусым белән әйтәм, үзегезгә начаррак булачак. Шулай табигый хәлендә калсын. Салкын су белән ешрак юыгыз, ышаныгыз сүземә, борыныгыз булмаса да, элеккеге кебек үк сәламәт булырсыз. Ә борыныгызны спиртлы банкага салырга киңәш бирер идем, шуна ике аш кашыгы көчле аракы белән жылытылган уксус өстәсән, тагын да яхшырак — бу юл белән ярыйсы гына акча да эшләр идегез. Әгәр бик кыйммәт сорамасагыз, мин үзем дә сатып алам.

— Юк, юк! Сатаммы соң? — дип ярсып кычкырды майор Ковалев,— бозылсын лутчы!

— Гафу итегез! — диде табиб, саубуллашып,— файдам тимәсме дигән идем... Ярый соң! Минем тырышканны үзегез күреп тордыгыз.

Әйтәсен әйтеп, табиб гәүдәсен төп-төз тотып чыгып китте. Ковалев хәтта аның йөзенә дә күтәрелеп карамады, битараф кыяфәттә тора бирде, кап-кара фрагының жин очыннан чыгып торган кар кебек ап-ак чиста күлмәк жиңнәре генә күзенә чалынып калды.

Икенче көнне ул, жалоба жибәргәнче, алган әйберен тавыш-тынсыз гына кире кайтармасмы дип, штабс-офицершага хат юлламакчы булды. Хат мондый эчтәлектә иде:

«Мөхтәрәм ханым

Александра Григорьевна![7]

---

[7] Н. Гоголь алда «Палагея Григорьевна» дип язган иде.

Сезнең тарафтан кылынган бу гайре табигый хәлне аңларга башым житми. Ышаныгыз, мондый юл белән сез берни ота да, мине кызыгызга өйләндерә дә алмаячаксыз. Минем борынга кагылышлы әлеге күңелсез хәлнең төп сәбәпчесе сез, бары тик сез генә булуыгыз көн кебек ачык. Көтмәгәндә урыныннан кубып, качып китүе һәм маскировкаланып бер чиновник кыяфәтендә йөрүе, аннан үз төсенә кире кайтып төшүе шәхсән үзегезнең йә булмаса шикле эшләр белән шөгыльләнүче ахирәтләрегезнең сихерчелек галәмәтедер. Мин үземнең яктан сезне кисәтеп куярга тиеш табам: әгәр борын бүген үк үз урынында булмый икән, мин закон яклавына һәм ярдәменә мохтаж булачакмын.

Сезгә тирән ихтирам белән Платон Ковалев».

«Хөрмәтле әфәндем

Платон Кузьмич!

Хатыгыз мине чиксез гаҗәпләндерде. Мин, чын күңелдән әйтәм, сезнең тарафтан мондый гаделсез гаепләүләрне һич көтмәгән идем. Сезгә шуны хәбәр итәргә тиешмен, мин өемдә сез әйткән чиновникны маскировалаган килеш тә, чын үз кыяфәтендә дә кабул иткәнем булмады. Дөрес, мина Филипп Иванович Потанчиков килгәләде. Ул — яхшы тәрбияле һәм зур гыйлемгә ия зат — кызымның кулын да сораган иде, ләкин мин өметләндерердәй берни дә вәгъдә итмәдем. Сез тагын борын турында әйтәсез. Әгәр сез мине кызымны сезгә бирүдән рәсми төстә баш тарта дип уйлыйсыз икән, бу тагын гаҗәпләндерә, киресенчә, сез үзегез бит араны өзү ягында, бу мәсьәләгә минем фикерем сезгә мәгълүм, әгәр яучы җибәрергә уйласагыз, мин шундук риза булачакмын, чөнки минем иң зур теләгем шул. Өметләр баглап, сезгә изге теләктә калучы

Александра Подточина».

Ковалев, хатны укып чыккач: «Аның бер гаебе дә юк. Жинаять кылган кеше мондый хат язалмый.— Коллежский асессор бу өлкәдә хәбәрдар иде, чөнки ул Кавказда берничә тапкыр тикшерү эшләрендә катнашты.— Ничек аңларга соң бу башка сыймаслык хәлне? — диде ул, түшенкелеккә бирелеп.

Әлеге искиткеч вакыйга турында имеш-мимешләр кайбер өстәүләр белән бөтен шәһәргә таралды. Андый гадәттән тыш хәлләрне көтеп кенә торалар бит: мәсәлән, күптән түгел генә магнетизм тәэсире буенча тәҗрибәләр бөтен дөньяны шаулатты. Конюшенная урамындагы биюче урындыклар турындагы вакыйга да әле онытылып бетмәгән, шуңа күрә коллежский асессор Ковалевның борыны Нева проспектында инде өч сәгать сәяхәт кылып йөри икән дип сөйләүләргә халыкның һушы китмәде. Мажараны күрәсе килгәннәр урамга агылды. Кемдер әйткән, имеш, янәсе борынны Юнкер кибетендә күргәннәр: кибет янындагы этеш-төртешне, ыгы-зыгыны полиция килеп тыйды. Театр ишек төбендә төрледән-төрле тәмле-томлы сатып торучы бер елгыр алыпсатар бик матур, нык агач эскәмия ясап куйды да кеше башына сиксәнешәр тиеннән басып карарга чакыра башлады. Бер полковник өеннән махсус иртәрәк чыгып, халык төркемен көч-хәл ера-ера килгән иде дә, ләкин борын күрәм дип йөрүе бушка булды, кибет тәрәзәсеннән йон фуфайка кигән һәм оегын рәтләп маташкан кызны агач артына посып күзәтеп торучы кыска сакаллы, жилет кигән франтны сурәтләгән, литография ысулы белән эшләнгән, инде ун ел буе шунда эленеп торган картинаны гына күрде. Бер читкәрәк китте дә: «Шундый тузга язмаган имеш-мимешләр белән кеше башын катыралар бит!» — дип ачуланып сөйләнде.

Берзаман майор Ковалевның борыны Нева проспектында түгел, ә Таврия бакчасында сәфәр кылып йөри икән дигән хәбәр чыкты; ул анда күптән иялләнгән, имеш, әле Хөсрәү Мирза яшәгән вакытларда ук, янәсе. Моны ишетеп, Хирургия академиясенең кайбер студентлары шунда юналде. Шәһәр

күләмендә танылган, хөрмәткә лаек бер ханым бакчага күз-колак булып торучыга махсус хат язды; мондый сирәк могҗизаны балаларга күрсәтергә, мөмкин булса, яшүсмерләргә үгет-нәсыйхәт, гыйбрәт-сабак булырлык итеп аңлату эшләре алып барырга кирәк диелгән иде ул хатта.

Мондый күз күрмәгән, колак ишетмәгән гадәттән тыш вакыйгаларга бигрәк тә югары җәмгыять вәкилләре, төрле табын-мәҗлесләргә йөреп, телләреннән саескан очырып хатын-кызларны шаккатырырга һәвәс кешеләр бөтенләй мөкиббән китте. Ә кайбер югары әхлаклы мөхтәрәм затлар бу көтелмәгән хәлләрне өнәмәделәр. Бер әфәнде әле зарланып: хәзерге алга киткән заманда шундый тиле-миле хәбәрләрнең таралуына гаҗәпләнүен, шуңа хөкүмәтнең битараф калуына аптыравын сөйләп торды. Ул да, күрәсең, хатыннары белән көн дә була торган ызгыш-талашны да хөкүмәт хәл итәргә тиеш дип көтеп торучылар исәбеннән иде. Менә шуннан соңгы вакыйгалар билгесезлек томанына урала, ни булган, ничек булган — бу хакта берни дә мәгъдүм түгел.

III

Дөньяда кеше ышанмастай хәлләр була да тора. Әлеге очракны аңлатырга да сүз табуы кыен: әле күптәнме статский советник чинында йөргән һәм шәһәрдә тине булмаган шау-шу куптарган әлеге дә баягы борын көннәрдән бер көнне берни дә булмагандай үз урынына, ягъни майор Ковалевның ике бит уртасына барып кунаклаcын инде. Бу хәл апрельнең жиделәрендә булды. Майор иртәнчәк уянып үзе дә сизмәстән көзгегә караса, күрә: борын! — шап кулы белән — борын шул! «Әһе!» — Ковалев сөенечennән бүлмә буйлап чүт кенә яланаяк тыпыр-тыпыр биеп китмәде. Иван кереп кенә комачаулады. Ул шундук юынырга әзерләргә боерды һәм юынганда басып көзгегә текәлде: борын бар. Тастымал белән сөртенгәндә тагын көзгедән карады: борын урынында!

— Иван, карале монда, борыныма бетчә чыккан бугай,— диде ул, ә үзе: «Бетте баш, Иван, юк, әфәндем, бетчә дә юк, борын да юк!» дисә, нишләрсең дип эчтән генә уйлады.

Иван исә:

— Бетчә юк, борыныгыз чип-чиста! — диде.

«Әйбәт бу, рәхмәт төшкере!» — дип үзалдына сөйләнде майор һәм бармакларын шартлатып куйды. Шул вакыт каймак урлап тотылган песи кебек мескен кыяфәттә чәчтараш Иван Яковлевич ишекне ачып карады.

— Алдан ук әйтеп куй, кулың чистамы? — дип кычкырды Ковалев аны күрү белән.

— Чиста.

— Алдашасың!

— Билләһи газыйм, чиста, сударь!

— Кара аны, кирәгеңне бирермен.

Ковалев утырды. Иван Яковлевич аның өстенә япма бөркәде дә «ә» дигәнче сакалын һәм ярты битен күбеккә батырды.

«Кара син аны! — дип, үзалдына сөйләнде Иван Яковлевич, борынга күз төшереп, башын кыегайтып, кырыйдан да карады.— Менә, уйламассың да...» — дип, озак кына текәлеп борынны күзәтте. Ниһаять, мөмкин хәтле иплә кенә, сак кына борынның очыннан тотарга дип ике бармагын күтәрде. Иван Яковлевичның өйрәнелгән, канына сеңгән гадәте иде бу.

— Әй, әй, әй, кара аны! — дип кычкырып җибәрде Ковалев.

Иван Яковлевич коелып төште, аның болай бервакытта да унайсызланганы юк иде. Ниһаять, бераздан иягеn сак кына кыра башлады; бу рәвешле, ягъни борыннан тотмыйча гына кыру унайсызрак иде, билгеле, ләкин кытыршы баш бармагын яңагына һәм аскы казналыкка терәп тырыша торгач, исән-имин бу эшен очлап чыкты.

Кырынып бетергәч, Ковалев тиз генә киенде дә, извозчик яллап тәмлетомлы ашамлыклар кибетенә китте. Керү белән: «Малай, бер чынаяк кайнар шоколад китер!» — дип әмер бирде дә ялт кына көзгегә күз төшерде: борын урынында иде! Күнеле булып тирә-юньгә күз салды һәм күзләрен кыса төшеп мәсхәрәле елмаю белән ике хәрбине күзәтте: берсенең борыны өстендәге жилет сәдәбеннән әллә ни зур түгел иде. Шуннан ул вице-губернатор, һич югында хуҗалык эшләрен алып баручы чиновник урынын юллап бер департаментның канцеляриясенә китте. Кабул итү бүлмәсеннән узганда тагын көзгегә карады: борын урынында иде! Аннан чыккач, ул бер таныш майор — коллежский асессор янына китте. Кешедән көләргә һәвәс бу чәнечкеле телгә: «Теленә шайтан төкергән!» дип әйткәли иде ул. Юлда уйлап барды: «Әгәр майор мине күргәч көлә-көлә бөгелеп төшмәсә, борын урынында дигән сүз!» Коллежский асессор шикле күренмәде. «Әйбәт, бик әйбәт әле бу, шайтан алгыры!» — дип күнеле булып, Ковалев уйлап куйды. Юлда ул кызын иярткән штабс-офицерша Подточинаны очратты, баш иеп исәнләште, тегеләре шатланып ах-вах килделәр: димәк, кимчелекле бер жире дә юк. Майор алар белән озаклап сөйләшеп торды, тәмәке савытын чыгарып, махсус алар алдында борынының ике тишегенә дә ашыкмый гына тәмәке тутырды һәм янәсе: «Менә сезгә, тавык мие эчкән нәмәрсәләргә! Кызыңа өйләнергә уйламыйм да әле». Хәзер инде майор Ковалев Нева проспектында, театрларда берни дә булмагандай, иркенләп йөри торган булды. Борыны да, әле күптәнме кайдадыр читтә йөргәнен сиздермичә, майорның битендә утыруын белде. Шушы хәлләрдән соң майор Ковалевны гел, чибәр-чибәр ханымнарның берсен дә игътибарсыз калдырмыйча, шаян сүзләр әйтеп көлдерә торган, кәефле, шат күңелле итеп очрата иделәр; хәтта бер тапкыр Гостиный двор янындагы бәләкәй кибеттә ниндидер орден тасмасы сатып алганын да күрделәр, нигә алганы гына билгесез булып калды, чөнки аның гомерендә орден кавалеры булганы юк бит.

Менә шундый искитмәле хәлләр булды бит әле иксез-чиксез илебезнең төньяк башкаласында! Дөресе-ялганы буталып беткән шушы вакыйгалар белән танышкач, тузга язмаган хәлләр дә була икән дип куясың. Борынның хуҗасыннан аерылып китеп, статский советник кыяфәтендә төрле урыннарда сәяхәт кылып йөрүен газетада бастыруның үзе бер мәгънәсезлек икәнен майор Ковалев ничекләр аңламады икән? Мин моны газетада белдерү бастыру өчен күп акча түләргә кирәк икәнен күздә тотып әйтмим: ул бик вак мәсьәлә, мин андый карун, акчага хирыс түгел. Бу — кеше алдында килешми торган, әдәпкә сыймый торган гадәт. Борынның пешкән ипи эченнән табылуы, моңа Иван Яковлевичның ниндидер катнашы булуы һич башка сыймый торган хәл инде менә! Әмма тагын да гаҗәбрәге, авторның шул хәлне әсәр сюжеты итеп алуы... Монысы инде бөтенләй сәер... Кеше ышанмастай хәлне чын булса да сөйләмә дигән сүз дә бар бит әле. Беренчедән, моны бәян итүдән илгә нинди файда? Икенчедән... Икенчедән дә бернинди файда юк... Бу очракта ни дип әйтергә дә белмим инде...

Хәер, мондый көтелмәгән хәлләр чынбарлыкта булмас дип кем кистереп әйтә ала?.. Төптәнрәк уйлап карасаң, дөреслек орлыгы яшеренеп ятуын инкяр итеп тә булмый, дөньяда мондый гайре табигый хәлләрнең булуы бик мөмкин, сирәк булса да, булмый тормыйдыр.

*1835—1842*

**Люция ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА** *тәрҗемәсе*

## Төшләренә дә кермәде

Якыннан танышкан беренче зур язучым Габдрахман Әпсәләмов иде минем. Егерменче гасырның илленче еллары ахырында талантлы әдип белән Маяковский урамындагы йорт фатирында чәй эчә-эчә сөйләшеп утырган идек. Радиода эшли башлаган чагым гына. Нииндидер вакыйга уңаеннан Габдрахман абыйдан интервью алырга куштылар. Ул магнитофон тасмасына язылмый. Чөнки тумыштан кайбер авазларны йотып, сакаурак сөйләшә иде. Шулай да беренче очрашуыбызда ук гаҗәеп дәрәҗәдә матур тәэсир калдырды. Тәскә-биткә гаять чибәр, йомшак телле, шаян сүзле, киң күңелле зыялы зат белән танышу журналистика дигән тылсымлы дөньяга бер аяк бармагы да ныклап басарга өлгермәгән авыл малае өчен чиксез горурлык, зур мәртәбә, гомергә онытылмас куаныч, хәтта, әйтер идем, мактанырлык нәрсә дә булып чыкты. Журналистикага мәхәббәтне бик нык арттырды.

— Йомышын төшкәндә тартынма, кил, мин чибәр егетләрне яратам, — дип рухымны күтәреп, үстереп җибәрде үземне.

Ун көн саен диярлек мин бу фатирның бусагасын атлап керә башладым. Дуслыгыбыз ныгыганнан-ныгый. Безнең Шәлене да күреп килергә теләге бар икән. Алдан сөйләшеп куйсак та, колхоз председателе Фәйзрахман Сафин үз урынында юк. Урамда бер төркем ир-егетләр көтә аны.

Фәйзи абый соңга калып булса да, идарәгә кайтты. Питрәчкә ашыгыч киңәшмәгә чакырган булганнар. Утырыш озакка сузылган.

Без ул көнне Шәледә кундык, мунча кердек, кәрәзле бал белән чәй эчтек. Габдрахман абый, инфарктлар кичергәч, кулына да алмый иде инде шайтан суын.

Безнең пред. Сафин һәм атаклы язучы Әпсәләмов шушы көнне дуслашып калдылар.

...Берчакны Фәйзрахман Сафинның Габдрахман абыйга колхоз эше буенча йомышы төшә. Вакыт шактый соң — кичке 11. Әпсәләмов дан пигына күтәрелгән еллар иде. КПСС съездына барып кайта, СССР Верховный Советы депутаты. Мондый мәртәбәле кешене төн уртасында борчу килешми дә, унайсыз да. Шулай да без батырчылык иттек. Колач җәеп каршы алды ул безне. Маһинур апа табын да җәеп куйган. Төнге өчкә кадәр утырдык. Икенче көнне безнең председательнең эше Габдрахман абый ярдәме белән жиренә житкерелә.

Шул төндә Габдрахман абый сөйләгән бер мәзәкнең гомергә исемнән чыгасы юк.

— Татар авылына колхозчылар җыелышына райкомның беренче секретаре килә. Трибунага күтәрелә: «Сез быел район өчен күп эшләдегез: иген уңышы, ит, сөт, йон, йомыркагыз күршеләрегезнекеннән күпкә артык. Партия моны онытмый. Кызыл Байрак лаеклы эшләрегез өчен бирелде. Мине бер нәрсә борчый — клуб сала алмыйсыз. Бәйрәмнәрне кайда үткәрәсез, гыйлемле лекторларыбызны тынлар җирегез юк, артистлар концерт-спектакльләр белән килә алмый. Мин, колхозчылардан акча җыеп, клуб төзергә киңәш итәм. Ризалашабызмы?

— Юк, юк, — дип кычкыралар беравыздан авылдашлар.

Секретарь инбашларын жыерып куя да, урынына утыра. Трибунада районнан килгән икенче кеше — исполком председателе — болай ди:

— Мин сезнең хәлегезне аңлыйм. Унышлардан кемнең генә башы әйләнми? Партия сезгә авылыгызда культураны күтәрү өчен файдалы эш тәкъдим итә. Ә сез каршы торасыз. - Тавышын күтәреп һәм янаган тон белән: «Клуб салырга акча жыясызмы, юкмы? — дип кычкыра.

Зал тагын:

— Юк, юк, — дип бердәм җавап бирә.

Ниһаять, колхоз партия оешмасы секретаре баса, залның тынычлануын сорап кулын күтәрә.



*Габдрахман Әпсәләмов, аның җәмәгате Маһинур ханым һәм Мәгъсүм Гәрәев. 3 ноябрь, 1961 ел.*

— Хәтерегездәдер, Мәфтуха карчыкның туй алдыннан оныгына әйткән сүзләре.

— Онытмадык, онытмадык, — диләр залдагылар.

— Шулай булгач, клубка акча жыярга кирәктер.

— Жыябыз, жыябыз!..

Жыелыш тәмамлангач, кичерәк кенә мәҗлес ясап алалар.

— Сине райкомга алырга кирәк, — ди беренче секретарь колхоз башлыгына. — Шулай да әйт әле, Мәфтуха карчык оныгына нәрсә дигән?

— Аны авылда барысы да белә. Кызый туй буласы көнне әбисе янына килә: «Иремә уңай булсын өчен, аңа кайсы ягым белән ятыйм, әбекәй?» — ди.

Зирәк акыллы Мәфтуха әби: «Кайсы ягыңа борылсаң да, ул барыбер үзенекен эшли», — ди.

— Бу вакыйга Шәледә була. Ә тапкыр һәм мәгънәле сүзле колхоз партоешмасы секретаре, Мәгъсүм энекәш, синең җизнәң Гайсаров Гали иде, — дип йомгак ясый Габдрахман Әпсәләмов.

## Бәтиләр исән...

Фронтовик шагыйрь Мәхмүт Хөсәен туган якларын — казакъ далаларын әйләнеп кайта. Шуннан соң хикәяләр һәм очерклар тупланган «Чирәм җирләр сулышы» дигән җыентыгын бастырып чыгара. Китап белән яхшылап танышканчы ук язучылардан берсе:

— Синең, Мәхмүт, чирәм җирләргә баруың чынмы ул? — дип шаяртмакчы була.

— Син ялгышасың, — ди телгә беткән Мәхмүт. — Мин анда бармадым, кайттым. Аннары баруым-кайтуымның яңа китабым чыгуга нинди мөнәсәбәте бар?

Тегесе:

— Чын әдип үзенең нәрсә турында язуына ышанырга тиеш! - ди.

Ачуы чыкканда Мәхмүтнең теле түн җирне дә тишәрлек итеп әйләнә:

— Татар халык әкиятендә соры бүре кәҗә бәтиләрен ашый. Олы кәҗә ерткычны эзләп китә һәм таба. Мөгезе белән сөзеп, бүренең корсагын яра һәм бәтиләр һәммәсе дә исән-сау, тегенең эченнән сикереп чыгалар. Син менә да ихлас күңелдән ышанасың икән, алайса! — дип каләмдәшен телсез калдыра Мәхмүт.

## Әйдә, киттек мунчага!

КПСС Өлкә комитетыннан Мәгъсүм Гәрәевкә күрсәтмә:

— Иптәш Гәрәев, бүген кунак килә, Франциядән. «Татарстан» поездыннан каршы алу, урнаштыру, ашату-эчертү, республиканы күрсәтү һәм культура программасын үтәү сиңа йөкләнә. Машинаны безнең гараждан аласың...

Мин гадәттә поезд белән килгән чит ил журналистларын «Волга» кунакханәсенә фатирга кертәм. Каршылау, озатып җибәрү уңай, вокзал каршында гына.

Люкска кереп урнашты ул. Юлдан килгән кешене чәй эчертеп алырга кирәк. Анысы аста, ресторанда. Официантлар белән татарча: «Исәнмесез! Хәерле көн!» — дип исәнләште ул. Мин гаҗәпкә калдым. Дөньяның төрле илләреннән килгән журналистлар урысчаны яхшы белә. Француз татарчаны да сукалый. Кунак — Франциянең атналык «Монд» газетасы күзәтүчесе Филипп Болдан. Вокзалда очрашканда ук французның юморлы кеше булуын чамалаган идем инде, ялгышмаганмын.

— Кыяр су ярата. Аның янына 100 грамм урыс аракысы кирәк булыр бит, — ди официантка Филиппка.

— Чит илдән гадәттә СССР Журналистлар союзы аша киләләр иде. Аннан безгә хәбәр итәләр. Ә сез турыдан-туры, — дим кунакка.

— Мин хәзер ял итәм. Рәсми кешеләрне борчымыйча, ел саен үзем генә юлга чыгам. Туристларча җиңелчә һәм уңай киемнәрдә, — ди.

Мәй һәм чәй эчкәндә, Татарстанга килүнең максаты да ачыклана.

— Ә татарчагыз кайдан? — дип кызыксынам.

— Мин урыс милләтеннән. Санкт-Петербургта туганмын. Үткән гасырның егерменче еллары башында гаиләбез Франциягә күчеп китә. Мин эмигрант, саф татарларны күреп сөйләшергә килүем. Франциядә шушы көнгә кадәр сезнең милләтне кыргый итеп күрсәтү гадәте бар. Янәсе, татарлар, бер кисәк чи итне ияр астына куеп, атны тирләткәнче чаптыралар да, аннары аннан төшеп, шул чи итне ашыйлар. Бездә моны «татарский бифштекс» дип атыйлар. Мин урамда уйнап, пычранып кайткач әнием ачулана иде үземне: «Кемгә охшап шундый шапшак булдың син? Синең няняң гыйлемле, бик чиста һәм гадел татар хатыны иде!» Исәнләшү сүзләрен Мәскәү татарларыннан сорап язып алдым. Миңа чын татарларны күбрәк күрсәт!

«Бәхете алга барганның әтәче дә күкәй сала», — дигән мәкаль бар бит әле татарда - Филипп та шундый кеше. Җәлил театрында композитор Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсы куелган көннәр. Кич белән шунда киттек. Спектакльнең музыкасын да, җырларын да ошатты ул. Каршыдагы ложада партия өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табиев утыра. Бу турыда кунакка тәнәфестә әйттем.

— Сез спектакль барышында газета эше буенча аны чакырып чыгара аласызмы? — дип сорый Болдан, демократияне беләсе килеп.

— Бу вазифа редакторга йөкләнгән, — дим. Ә сездә ничек?

— Барып президентның сакчыларына үземнең кем икәнемне әйтеп, документымны күрсәтәм. Алар шул минутта ук моны президент кинәшчеләренә житкерәләр. Чыга де Голль. Мин иртәгә басылачак мәкаләмдәге проблеманы аңа әйтәм, 2-3 минут сөйләшеп алабыз.

— Чыкмаса?..

— Үзенә начар. Мәкаләмдә президент де Голль бу мәсьәләдә фикерен яшерә! — дип язам газетага. Дәрәҗәсе бик нык төшәчәк аның...

Опера тәмамлангач, төнге Казанны карап, кунакханәгә җәяү кайтырга булдык (Ул чорда урамнар тыныч, хулиганнар кешегә бәйләнеп йөрми иде).

— Татарстан хөкүмәтендә татар министрлары бармы? — ди кунагым.

— Ник булмасын, һәммәсе диярлек татар. Урыс булган очракта - беренче урынбасары татар. Татарстан АССР Конституциясендә шулай каралган, — дип җавап бирәм.

— Иртәгә шулар белән очрашып булмасмы?

Мин өлкә комитет секретаре белән сөйләшәчәгемне, каршы килмәячәкләрен әйтәм.

Иртәгесен бу хакта өлкә комитетының идеология секретаре Мөҗәһит Вәлиев белән киңәшәм. Төштән соң Актерлар йортында җыелырга булдылар. Ул чакта министрлары кем иде бит! ЮНЕСКОның көнчыгыш илләре буенча консультанты Мирза Мәхмүтов — мәгариф министры, Нәкый Исәнбәтнең үги малае, күп еллар «Литературная газета»да эшләгән журналист Булат Гыйззәтуллин — культура министры, сәүдәнеке — Мирза Исмәгыйлев... Француз министрларыннан һич тә ким түгел болар. Очрашалар, сөйләшәләр, әмма дә ышанмый кунак боларның татар булуларына:

— Исбатлагыз! — ди Филипп.

Мөҗәһит Вәлиев югалып калды:

— Йөрисең шунда юк-бар эш белән. Нишлибез? — ди бу миңа.

— Моны хәл итү бик җиңел, — дим мин. — Горький паркында зур кунаклар өчен Хөкүмәт резиденциясе бар ич. Анда мунча һәрчак ягылган була. Шунда мунча керәбез.

Ун министрны ияртеп киттек. Барысы да ачыкланды. Ышанды француз. Мунчага керүебез әкияттәге шикелле килеп чыкты.

Француз журналисты Филипп Болдан үзе дә сөннәтле икән ләбаса!

## Акылга сыя, законга сыймый

Берзаман без, язучылар, көтүебез белән Азнакай тарафларына барып төштек. Район һәм шәһәр хакиме шагыйрь Әнәс Исхаков әдәбият сөючеләр белән очрашырга чакырган иде.

Эшне «старшой» сайлаудан башладык. Гәрәй Рәхим дигән тел бистәсе бар бит. Бригадир иттек. Килешә үзенә. Масаеп, көязләнеп китте, властен күрсәтергә маташа. Миннән узып бер сүз әйтү юк, дип текелди. «Соң, Гәрәй, ник алай кәпрәясең? Югыйсә кул күтәрәбез дә, начальниктән «выжт» үзеңне. Гәрәйне Гәрәевкә әйләндереп куюы бик җиңел», — дим.

Кичәне ачып җибәрә дә, безнең белән киңәшеп-нитеп тормыйча, букчасыз «министрыбыз» тотына сибәргә «Фанты, фантомас һәм мин» дигән шигырен.

Кичке очрашуга 50 шешә фанты алып килгән бу. «Фантомасның агач наганын тотып басмагансыңдыр бит берәр киоскны?» — дим. «Гәрәй Рәхим икәнемне белгәч, сатучылар бушка бирә миңа «фантыны», — дип кәпрәя Гәрәй. — Кем дә кем бүген фанты эчеп исерәсе килә, кул күтәрегез. Юк, юк, бу кадәр үк түгел. Илле генә кешегә җитә. Алфавит буенча исемлек төзегез! Күрәсез, мин Гәрәй, Гәрәев түгел, нинди бай, юмарт. Биш елга бер китабым чыккан иде, гонорары 50 шешә фантыга җитте дә... шуның белән вәссәлам!»

— Җитте, күп телеңә салынма! Бүтәннәр дә сөйләсен, — диләр залдагылар.

— Ярый, килешәм. Шагыйрь Илдар Юзеевны тыңлагыз.

Ул монда килер алдыннан гына «Озак яшисең килсә» дигән шигырь язган икән. Җырларга өнди Юзеев: аек чакта да, исергәндә дә, кайгыдан да, шатлыктан да, бала туса да, әби үлсә дә...

«Чү, Шәмсия, синме бу? Күптән көткән идек үзеңне. Син дә тегеләр шикелле - шигырьме? Кирәкми. Җырла син безгә!» Шагыйрә Җиһангирова шаян җырлар белән күңелен күтәрде залның.

Чират минеке. Шигырь, җыр, сорау-җаваплар булды. Нидән башлыйм икән? Прямо аптыраш. Арткы рәттән бер әү күтәрелә: «Мәгъсүм Гәрәев, син безгә фәкать булган хәлләрне генә сөйлә. Шәмсия сөю хисләребезне кузгата башлаган иде».

— Сезнеңчә гыйшык-мыйшык булсын инде,— дим. — Азнакайның бер елгыр егете безнең Казанда, институтта, сынау бирә. Билет ала, өч сорауның берсенә дә җавабын белми.

— Профессор әфәнде! Гадел булсын әле. Мин дә Сезгә өч сорау биреп карыйм. Берсенә генә җавап бирсәгез дә мин икеләтә риза. Өченчесенә дә җавабыгыз юк икән, димәк, миңа бишле! Шәп бит, ә?!

— Йә, ху-уш. Тыңлыйм, сөйләп бак.

— Беренче сорау — законга сыя, акылга сыймый; икенчесе — акылга сыя, законга сыймый; өченчесе — законга да сыймый, акылга да.

Аптырый профессор, башын кашый. Бишле куярга мәҗбүр. Студент чая, таш астыннан чыккан. Җавапларга күчә.

— Профессор әфәнде, Сез инде картайган, әмма хатыныгыз бик яшь, чибәр. Бу — законга сыя, ләкин акылга сыймый. Яшь, матур хатынның сөяркәсе булу бик табигый. Монысы акылга сыя, законга сыймый. Сез багалмагызның сөяркәсенә, ягъни миңа — бишле куйдыгыз. Болары законга да, акылга да сыймый, — дип, профессорга рәхмәт әйтеп, чыгып шыла.

— Азнакай кызлары турында да берәр кызыклы хәл сөйләгез әле! — дигән тавыш ишетелә залдан.

— Тырышып карыйм. Монысы сезнең кызларга гына хас түгел. 17 яшьтә кызлар Африка кебек кызу була. 18дә — Америка кебек кырыс, үзсүзле. 20дә — Европа кебек тапталган. 25тә Арктика кебек салкын. Безнекеләр: «Африка, Аф-ри-ка!» дисезме. Килешәм. Кызларыгыз һаман шулай кайнар булсын. Кызлар — мәһабәт кыя алар, берсенә менсәң, икенчесенә үрмәлисе килә. Гәүдәгә кечкенә булсалар да, үзләре чикләвек төше генә», дип җырласын егетләре.

## Гел бушлай сөйләттем

Май урталары иде. 1998 елныкы. Казанга Михаил Жванецкий килде. Шаян, үткен, зәһәр сүзнең тәмен татыган, Одесса юморының асылын аңлап яраткан тамашачы Жванецкийның тапкырлыгына тәкатьсез. Мине аны театрда тыңлау гына канәгатьләндерми. Интервью алу, сатирик язучы белән очрашуны укучыга сөйләү ялкыны дөрли җанымда.

Әмма ләкин... Аның белән әңгәмә кору дүрт йөз сум тора. Фотога төшерәсең килсә, янә дүрт йөз сумыңны чыгарып сал! Мәшһүрләргә гонорар түләү тәртибе шундый. Мондый очрашулар өчен кесәң калын булсын. Ә минем кесә буш та, тишек тә. Жванецкий кичәсенә билет бәяләре — 180—300 сум. Хәер, бу мәсьәләдә минем проблема юк. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында, директор рәтендә, үземә беркетелгән махсус урыным бар.

Оста белән гәп корасы килү дәрте сүнми миндә. Утырам мин теге һәвәснең сәясәтчеләргә, хөкүмәт җитәкчеләренә, төрле түрәләргә тозлап-борычлап сибә торган зәһәр сүзләрен тыңлап. Зал рәхәтләнеп кул чаба, мин дә, әлбәттә. Вакыт-вакыт Жванецкий белән икәү генә тын бер бүлмәдә сөйләшеп утырабыз шикелле тоелып китә.

Тамаша тәмам. Яһүди язучысын журналистлар сырып алды.

— Үләрлек булып арыдым, бер сүз дә көтмәгез! — дип кырт кисте бу.

Мин өметне өзмим. Бүлмәсе ишеген ачканда:

— Жванецкий әфәнде, Сезгә хур кызы кебек хатын бүләк иткән татар халкына әйтер сүзегез юкмыни? — дим.

Йөзе балкыды моның.

— Әйе, минем хәзерге хатыным Венера татар кызы. Бик матур улыбыз үсә. Исеме — Мәгъсүм, гарәпчәдән мәгънәсен беләсендер, гөнаһсыз бала. Венерам аны татар малае ди. Мин яһүди дим. Сүз белән мавыгып киттем бугай. Бүлмәгә рәхим итегез, сөйләшеп утырыйк!

Кырык минутлап гәп саттык без дингез офицеры Жванецкий белән. Хатыны Венерадан татарның гореф-гадәтләрен, әкиятләрен, легендаларын, бәетләрен кызыксынып өйрәнүен дә яшерми сөйләде кунак. Казанда күрсәткән программаның Венера идеясе булуын да әйтте. Истәлеккә фотосын да бүләк итте.

Мин җиде кат күктә очам. Яһүди язучысын тәки бушлай сөйләттем бит!

Жванецкийга карап: «Халыкның: «Где татарин, там еврею делать нечего!» — дигән сүзләренең бик тә хак булуына төшенденме инде, брат», - дим сатирикка. Авызы ерылды. Ошатты бугай. Хәйләкәр көлемсерәвеннән шул сизелә иде.

### Без... Сарманнан

Камал театрында СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеровның 75 яшьлек юбилей кичәсе (1 ноябрь, 2003 ел) бара. Драматург Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы буенча куелган спектакль тәмам. Сәхнәгә бөек талантыбызны котларга Минтимер Шәймиев күтәрелә. Юбилярга Илбашының искиткеч матур, гаять зур букеты тапшырыла.

— Ике ай инде Шәүкәт Биктимеровка нәрсә бүләк итик икән дип баш ваттык. Уйладык-уйладык та шундый карарга килдек: шәһәрнең ул теләгән жиреннән фатир сайладык! Үтенечемне дә әйтим. Аның адресын, зинһар, Әҗәл — Равил Шәрәфиев белә күрмәсен, — дип шаярта Президент.



*КДУ студенты Сәмбел Мостакыймова Равил Шәрәфиевтән интервью ала. 2008 ел.*

Зур бүләкнең икенчесен «Нур-1» юл төзү җәмгыяте җитәкчесе, Биектау районының Әлдермеш авылы егете Мәннаф Сәгъдиев тапшыра.

— Рәхмәт, Әлмәндәр карт — Шәүкәт абый, авылыбызны бөтен дөньяга таныттың. Спектакльдә Хәмдебану апага өйләнеп өлгерә алмадың. Утыртып алып кайтырга машинаң булмады бугай. Мә, ал, ачкычын үзем бүләк итәм.

Мин чын тормышта Әлдермеш геройларының бер-берләрен коткарып калган очракларны да беләм. Әйтик, Шәүкәт Биктимеровның Равил Шәрәфиевны Ташкентта «зур бәладән» йолып алуын. Егерменче гасырның җитмешенче еллары уртасында менә болай була бу хәл.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистларының Үзбәкстандагы гастрольләре тәмамлана. Безнең театр труппасы Ташкенттан Бакуга очарга тиеш. Артистлар аэропортка киләләр. Самолетка утырганчы

байтак вакыт бар икән. Равил Шәрәфиев, Хәлим Җәләй һәм Рәшит Шамкай күлмәкләрен салып куялар, чалбарларын тезгә хәтле сызганалар да, аэропорт тирәсендәге арыкларда су ерып йөриләр. Чәчләре дә кырып китәрелгән боларның. Үзләренең авыз колакта. Милиционерларга шикле кешеләр шикелле тоела татар артистлары: берәр төрмәдән качмаганнармы?

Аэропорттагы милиция бүлмәсенә алып керәләр. Комиклар һаман көлә дә көлә, үзләрен милиционерларның күнелен ачарга алып кергәннәр дип уйлыйлар. Тегеләр исә чын-чынлап, җитди рәвештә сорау ала башлый:

— Сез кайдан? Кайсы төрмәдән качтыгыз?

Равил һаман шаярталар дип белә әле. Уйлап-нитеп тормый.

— Без кайданмы? Кайдан булыйк, Сарманнан, — ди.

Милиционерлар төрмәләр урнашкан шәһәрләрнең исемлегеннән эзлиләр Сарманны. Юк!

— Шаяртмагыз, дөресен әйтегез, документларыгыз кайда?

Равилнең күзләре сәгатенә төшә. Инде самолет очар вакыт җитеп килә.

— Без, татар артистлары, җибәрегез, самолетка соңга калабыз, — дип ялварырга тотыналар.

Тегеләр селкенми дә. Шулчак ишектән Шәүкәт Биктимеров килеп керә. Кулында — артистларның паспортлары.

— Уяулыгыбыз өчен бүгенгә гафу итегез. Башка җирдә җитдиерәк булыгыз. Югыйсә бүтән чакта өегезгә кайтып җитә алмавыгыз мөмкин. Хәерле юл, уңышлы гастрольләр сезгә, артист дуслар, — дип озатып кала Ташкент милиционерлары «Сарман артистларын».

**Мәгъсүм ГӘРӘЕВ**

---

## «Казан утлары» елъязмасы



*Журналыбыз 1922-1930 елларда «Безнең юл», 1930-1932 елларда «Яналиф» һәм «Атака», 1933-1965 елларда «Совет әдәбияты», 1965 елдан «Казан утлары» исеме белән дөнья күрә.*

**Сентябрь**

**85 ел элек (1928)** «Безнең юл»да Шәриф Камалның «Төеннәр» исемле пьесасы;

**80 ел элек (1933)** «Совет әдәбияты»нда Шамил Усмановның «Легион юлы» повесте;

**70 ел элек (1943)** «Совет әдәбияты»нда Мирсәй Әмирнең «Мөстәкыйм карт йокысы» хикәясе;

**65 эл элек (1948)** «Совет әдәбияты»нда Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романы;

**60 ел элек (1953)** «Совет әдәбияты»нда Мирсәй Әмирнең «Ялантау кешеләре» романы;

**55 ел элек (1958)** «Совет әдәбияты»нда Әмирхан Еникинең «Йөрәк сере» повесте;

**50 ел элек (1963)** «Совет әдәбияты»нда Чыңгыз Айтматовның «Беренче мөгаллим» повесте;

**45 ел элек (1968)** «Казан утлары»нда Сажидә Сөләйманова шигырьләре, Илдар Юзеевның «Соңгы сынау» драматик легендасы дөнья күрде.



# Гөлгенә Кәримова

## Сан алганда

**Сынау тотар**
**Сәгать сукты**
**И, татарым!!!**
**КЕМ диеп соң**
**Милләтеңне**
**Син атадың?!**

**«Татар», — диеп**
**Чәчрәп торыйк**
**Сан алганда.**
**Хилаф итми**
**Борынгыдан**
**Танылганга.**

**Татар булыйк**
**Саналганда**
**Сыналмыйча,**
**Яшик бергә**
**Ялгышлардан**
**Кыйналмыйча.**

**Милли төркем**
**Генә булу—**
**Безгә түгел!**
**Бөтен булып,**
**Бергә калу**
**Мөһим бүген!**

**Без — күпсанлы,**
**Бай тарихлы**
**Бөек халык!**
**Таркалмыйча,**
**Бүленмичә**
**Бердәм ТАТАР**
**Булып калыйк!**

## Кайтыйк әле...

**Бик сагынып кайтып киләм**
**Авылым урамын,**
**Төшләремә керден бит син —**
**Елап урармын.**

**Әнкәм дә юк, әткәм дә юк,**
**Юк күрше-күлән.**
**Капка төбен басып киткән**
**Тик яшел үлән.**

**Чишмә суын эчә-эчә**
**Көч-куәт алдым.**
**Урманымның моңлы җырын**
**Күңелемә салдым.**

Гөлгенә КӘРИМОВА – *журналист, шагыйрә; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Әлмәттә яши.*

**Сагыш басса, бар уйларым**
**Авылыма илтә.**
**Кайтыр әле, кайтыр диеп**
**Балачак көтә.**

**Кайтыйк әле туган якка,**
**Ятсын... мең киртә.**
**Бик күпләрне бит соңгы юл**
**Авылына илтә...**

## Шәҗәрәм

**Типсә тимер өзәр нәселдән без,**
**Бик тирәннән безнең шәҗәрә!**
**Шәҗәрәм! —**
**Алтын йомгак булып киләчәккә**
**Һич өзелми, әйдә, тәгәрә!**

**Динен, телен сатмас нәселдән без,**
**Ата-ана хакы — иң зур хак.**
**Гомер бит ул тик бер генә килә,**
**Һәр мизгелен тоеп яшәр чак.**

**Туган өчен үләр нәселдән без,**
**Исән чакта хөрмәт — төп бурыч.**
**Елап яшәү безнең өчен түгел,**
**Тормыш көлсен өчен бул тырыш.**

**Вөҗдан, намус өстен нәселдән без,**
**Кеше булып яшәү, һай, авыр.**
**Буыннарга күчсен изге нәзер:**
**«Коръән сүзен тыңла, бул сабыр!»**

**Язмышларны төзер нәселдән без,**
**Бай тарихлы безнең шәҗәрә.**
**Шәҗәрәм! —**
**Алтын йомгак булып киләчәккә**
**Бертуктамый, әйдә, тәгәрә!**

***

**Гомер-агач алтын төскә кергән,**
**Яфрак булып оча елларым.**
**Галәмнәрне, дәрьяларны айкый,**
**Узганнәрне барлый уйларым:**

**Гамәлләрем, дуслар, уңышларым,**
**Иман белән үскән балам бар.**
**Үзем үргән, сүткән ялгышларым...**
**Кулын изи, әнә, сөйгән яр.**

**Гомер-агач алтын төскә кергән,**
**Төшми җиргә оча яфраклар...**
**Алла боерса, яшьнәрбез тагын! —**
**Алда еллар, озын юллар бар.**

# «ТЕГЕ СОЛДАТ»
## яки
# ЯХШЫЛЫК ЭШЛӘ ДӘ, СУГА САЛ...

«Казан утлары»нын 5, 6 саннарында «Кырым татарлары фажигасе» дигән зур мәкалә басылды. Анын авторы Хисаметдин Исмәгыйлевкә рәхмәтне әйтеп бетерерлек кенә түгел. Башкортстаннын Эстәрлебаш районында яшәгән, Кара дингез буена ял итәргә барган Хисаметдин, ялын да онытып, бик күп Кырым татарлары белән махсус очрашып, бу халыкны (тулаем!) 1944 елны Кырымнан сөрү вакыйгасын теп-тере итеп күз алдына бастырырлык документаль әсәр язган.

Совет дәүләте өчен хурлыклы булган бу депортациянен пычрагы беркадәр без татарларга да ягылып калды. Мәкерле кызыл хакимият кардәшләребезне сөргә нәкъ менә татар сугышчылары күп булган частьларны тарткан. Шуна күрә мәкаләнең бер татар солдаты турындагы менә бу өлешен мин зур ләззәт кичереп укыдым. Зиләрә ханым авторга менә ни дип сөйләгән:

— Без үзебез нугай татарларыннан булабыз. Картәти дә, картәни дә. Картәниләрне алып китәргә килгән солдат бик яхшы кеше булган. Кешелекле кеше. Картәнигә әйткән:

— Әби, бик алама эшләр. Сезне хәзер бик еракларга алып китәчәкләр. Шуна күрә тормыш көтәргә иң кирәкле һәм иң кыйммәтле әйберләрегезне генә алыгыз, — дигән. — Иң кыйммәтле әйберләрегезне генә алырга тырышыгыз, — дип кабатлап та әйткән. Шуннан картәни алка-йөзекләрен, чулпыларын һәм «Зингер» тегү машинасын төреп ала. Башка өйләргә кергән солдатлар кешеләргә кирәк-ярагын төйнәп алырга да ирек бирмәгән. Өйләреннән мылтык приклады белән төрткәләп чыгарганнар. Кайтырга рөхсәт булгач та картәниләр, картәтиләр күп михнәтләр күреп булса да шул авылларына кайта алганнар. Үз өйләренә түгел инде. Анда читләр яши хәзер. Мин үзем шушында тудым. Олылар сөйләгәннән генә беләм. Куылганнан соң тегү машинасы бик тә ярдәм иткән. Картинәм теге солдатка гомере буе рәхмәтләр укыды.


Кем икән ул «теге солдат»? Сугыштан исән кайтты микән? Исән кайтса да, хәзер исән түгелдер: теге хәлләрдән соң 69 ел үткән инде. Ичмасам, исем-фамилиясен дә белеп булмаячак бит: фәлән авылдан фәлән кешеләрне станциягә фәлән кеше китергән дигән мәгълүмат беркая теркәлмәгән бит инде ул.

Һәм кинәт!.. Мәкалә чыгып күп тә үтмәде, редакциягә Рушания Низамова шалтыратты. Рушания — балалар язучысы, Аксубай районында яши. «Теге солдат» ...анын бертуган абыйсы икән бит! Мәкаләне укуга исенә төшкән, абыйсы ана бу хәл турында сөйләгән булган. Һәм иң сөенечлесе шул: Зәки Низамов исән-сау икән! Әллә кайларда да түгел, Казанда ук, Дәрвишләр бистәсендә яшәп ята икән! Рушания әйткән номерны жыюга телефонда, колакка рәхәтлек биреп, көр, жылы ирләр тавышы янгырады:

— Тынлыйм, туганым!..

Бистәнен Тынычлык урамыннан атлап киләм. Шул исемдәге үк гастрономнан соң агай өйрәткәнчә 250 метрлап баргач, унга борылам. Верандалы искерәк агач

өй. Капка ябылып бетмәгән, веранда ишеге ачык. Табуыма сөендем, ләкин күңелдә борчу-гамь дә бар. Рушания белән һәм агайның үзе белән телефоннан сөйләшкәннән кайбер нәрсәләрне беләм бит инде. Күзе бик начар күрә икән. Хатыны үлгән, үзе генә яши, тик әле менә эчтән сөйләшкән тавышлар ишетелә. Тамак кырам. Йөгереп диярлек бик житез генә бер абзый килеп чыкты. Шушымы инде ул өч атнадан туксанын тутырачак бабай?..



Хәл белергә хәзер Казанда яшәүче авылдашы, алай гына да түгел, күршесе Фоат килгән икән, хатыны Нәсимә белән. Бергәләп өстәл тирәли утырдык та, Нәсимә тиз генә әзерләгән чәйне эчкәләп, әле ничәдер көн элек кенә фантастик бер эш булып тоелган «теге солдат» хикәятен тыңларга керештек.

— 1923 елны Аксубай районының Яңа Дума авылында дөньяга килгәнмен — беренче бала булып. Әнигә ул вакытта — 19, әтигә 28 яшь булган. Бәләкәйдән үк язарга өйрәндем, гарәп хәрефләре белән инде. Әни өйрәтте, әби өйрәтте, әнинең әнисе — ул озак еллар балалар укыткан кеше. Алты яшьтән бардым мәктәпкә, укытучы класска чакырып кертте мине. Аның янында озын чәчле Әшрәф апа басып тора.

— Яз әле, Зәки, үз исемеңне, — диде укытучы.

Тоттым да яздым инде. Укытучы әйтә:

— Менә, күрдеңме, күсәк? Синең ботың буе гына, ә син исемеңне дә яза белмисең!

Иске Ибрай авылында унны бетердем. Ул вакытта медаль бирмиләр иде әле, ләкин аттестатның кырыйлары алтын төсендә иде. Көннәрдән бер көнне директор дәште мине. Таипов Хәсәнне фин сугышына алып киттеләр, 2нче классны укытырга кеше юк, мин синнән укытучы ясыйм әле, ди. Китте РОНОга, аннан пичәтле кәгазь алып кайтты. 17 яшь тулмаган әле, мин инде укытучы! Шул классны укытып кына бетергән идем, сугыш башланды. Мине армиягә алдылар, Богырысландагы авиация училищесы курсанты иттеләр. Ләкин күпмедер укыгач, бу училищены яптылар. Томскига күчкән Ленинград артиллерия училищесында укып, лейтенант булдым...

«Гайжан бабай сөйли, һаман сөйли» дигәндәй, Зәки бабай да күп нәрсәләр сөйләде. Хәтере дә әйбәт икән. Аны иң борчыганы, хәтта ки иң нәфрәтләндергәне — сугышка һаман барып житә алмау була. «Армиягә килдем, сугыш вакыты — чыгармый торалар мине сугышка!» Әле сөйләгәндә дә гасабиланып әйтте ул бу сүзләрне. Төрле мажаралар була. Бер тапкыр муенына пуля килеп тия. Бәреп үк ега. Һич куркып калмый, янә торып баса да, корал мастерын чакырырга куша. Теге кесәсендәге карга борыны белән пуляны суырып чыгара. Шуннан кан атылып чыга башлый. Сөлгесе белән томалый — ул шундук манма кан була. Күршенең сөлгесен, аннан булган бөтен сөлгеләрне каплап, көч-хәл белән генә туктата ала. Бинт-фәлән дә, санитарлар да юк. Дивизионы белән Кырымга да шулай муенына сөлге бәйләгән килеш килеп житә ул. Бер таулырак урынга зенит пушкаларын урнаштырып ике көн дә үтми, тыны кабып дивизион командиры чабып килә. Калганын Зәки абыйның үз сүзләре белән бирик инде: ул сөйләгәннәрнең иң мөһим өлешенә життек хәзер.

* * *

— Дивизион командиры Чубынин, «Форд»ны ал да, станциягә бар, анда Кырым татарларын төйиләр вагоннарга, аларны авыллардан ташырга машиналар житми», — диде. «Форд»та Симферополь станциясенә бардым, таптым бу эш белән шөгыльләнүче кешене. Ул мина, барыгыз менә шул юл белән менә шул

авылга, диде. Мин утырдым да киттем, таптым ул авылны... Бик унайсызланып килдем мин бирегә. Сталиннарның юньсезлеге өчен дә, үзем өчен дә оялып. Сорашам: менә мондый-мондый кешеләр бармы? Монысы монда, тегесе тегендә яши дип күрсәтеп бирделәр. Өйләрнең якынрагына керәсе иттем. Уңайсызланып кына килеп кердем. Исәнләштем. Алар исәнләштеләрме, юкмы — хәтерләмим. 35–40 яшьләрдәге хатын иде өйдә, янында кызы һәм нәни балалары бар. Менә шундый эш, минәйтәм. Аңлаттым инде. Бик каты борчыла, чәбәләнә башлады болар. Әле анда барып бәреләләр, әле монда. Кызы моны алыйк ди, әнисе моны алыйк ди. Ашыкмагыз, минәйтәм, сез бер көнгә генә китмисез бит, озакка китәсез. Нинди нәрсә кадерле бу семьяда, нәрсә иң кирәкле — бөтенесен дә алыгыз. Без алуын алырбыз да, ди хатын. Ләкин безгә бит биш килограмм гына рөхсәт. Әгәр артык булса, башка суга-суга ташлаталар, ди. Күршеләрен алып киткәнне күргәндер инде. Менә тегү машинасы бик кирәкле безнең өчен. Ләкин ул үзе биш кило бар, ди. Алъяпкычлар, күлмәкләр, яулыклар, сабыннар алырга калмый да аны алсаң, ди. Бөтенесен дә алыгыз, дидем мин. Машинаны вагонга терәтеп үк куярбыз да, керерсез дә китәрсез, бер кадерле нәрсәгезне дә калдырмагыз...

Телгә бәйле бер кызыклы нәрсә бар монда. Урысча сөйләшкәннәр алар. Зәки абый менә «кадерле» нәрсәләрне алыгыз дип әйттем диде. «Кадерле» урысча «дорогой» бит инде. Ләкин «дорогой»ны «кыйммәтле» дип тә аңлап була. Шулай аңлаганнар да инде. Зиләрә ханым «тегe солдат»ның сүзләрен болай дип китерә бит: «Тормыш күтәргә иң кирәкле һәм иң кыйммәтле әйберләрегезне генә алыгыз». «Шуннан картәни алка-йөзекләрен, чулпыларын һәм «Зингер» тегү машинасын төреп ала». Кыйммәтле әйберләр тәҗрибәсез яшь-яшь егетнең башына килмәгәндер дә әле. Ләкин ялгыш тәрҗемә дә бик дөрес булып чыга!

— «Зингер» машинасын алабыз алай булгач, диде хатын. Алыгыз, обязательно, дидем. Алып бардым аларны. Нәрсә хәтерлим инде хәзер? Мин кабинада, шофер янында бардым, алар артта утырдылар. Станциядә туктап, шул авылдан килдек, кайсы вагонга, дип сорадым. Әйттеләр: менә бу вагон. Товар поезды инде, кызыл вагон. Ишеге ачык. Арты белән килеп, терәлеп диярлек туктадык. Тегеләр шылт итеп кереп тә киттеләр.

Бик нык хәтерлим ике нәрсәне. Мин әле кабина ишеген япмаган да идем, вагоннан кычкыралар «рәхмә-ә-әт!» дип. Татарча. Ике генә түгел, өч-дүрт хатын. Минекеләр, ахры, сөйләп тә өлгергән. Икенчесе шул. Мин ул чакта партиягә кандидат идем. Инде керергә дә күп калмады. Менә бу хәлләрне күргәч, башыма шик килде. Кара, минәйтәм, партия безнеке, Маркс, Энгельс, Ленинныкы. Ләкин халык та безнеке бит. Нигә аны шулай яшәгән урыннарыннан куптарып, төяп җибәрәләр? Соңрак, сөйләшә-сөйләшә беленде: кухня да булмаган бит ул поездда. Кырым татарларының яртысы юлда үлеп беткән дигән сүз дә колакка чалынды. Гомеремдә беренче мәртәбә уйлап куйдым: үз халкын шулай җәзалый торган нинди партия инде бу? Әллә ташлыйм микән кандидатлыкны? — дип. Ләкин партиягә лач итеп төкерү була бит инде бу. Әле нинди чакта диген — аяусыз сугыш барганда. Ахыры бик яман бетәргә мөмкин иде моның. Юк, кыймадым мин мондый хәтәр эшкә. Күп тынычрак, гадирәк заманда да бик кыйммәткә төшә язды миңа мондый адым. Монысын соңрак, сүз шул вакытка җиткәч сөйләрмен инде...

* * *

Аннары безнең дивизион Сиваш аркылы чыгып, Мелитополь аша туп-туры Көнбатыш Украинага килеп җитте. Дрогобычка килеп урнаштык. Анда Болеслав дигән нефть чыга торган урын бар. Шунда күп итеп пушкалар куелды. Бер кечкенә клуб ягыннан татарча сөйләшкәнне — кызлар тавышын ишеттем. Эзләп таптым бит мин моны. Таныштык инде. Исеме Залифә. Башкорт кызы икән бу, Пермь ягыннан, Бардада туган. Паспорт идарәсе хезмәткәре. Көнбатыш Украина

Мәскәүгә бик баш бирергә теләмәде бит. Аларны Эчке эшләр министрлыгы соравы буенча җибәргәннәр. Кешенең яшәгән урынына барып паспортларын тикшереп йөри икән болар. Хәрби формадан бу, старшина. 58 ел яшәдек шушы старшина белән!

Төрле җирләрдә артиллериядә хезмәт иттем, төрле вазифалар башкардым. Яратып хезмәт иттем мин. Ихластан. Чуаш малайларыннан да, рус малайларыннан да ким буласын, мин татарны сүкмәсеннәр дип тә. Киев хәрби округының командующие миңа шәхси «ТТ» пистолеты бүләк итте. Политакадемиягә керергә кыстый башладылар — шәп хезмәт иткән өчен. «Юк, мин политик була алмыйм, миңа конкрет белем кирәк», — дидем мин. Гомер буена физиканы яраттым чөнки. Аннан Совет дәүләтенең Кырымдагы «политикасы» да истә бит әле. Харьковтагы Радиолокация академиясен сайладым. Каршы килмәделәр тагын. Җинел булмады укуы. Яшәве дә. Кешегә квартирга кереп, бәп-бәләкәй бүлмәдә тордык, балабызны йокларга ләгәнгә сала торган идек. Хезмәткә Германиягә күчкәндә балаларыбыз өчәү иде инде, анда дүртенчесе дә туды. Җиде ел булдык Германиядә. Шунда алтаулап төшкән фотобызны әти белән әнигә җибәргән идек, хәзер миндә саклана ул.



Каунаска полк командиры итеп күчермәкче иделәр. Мин принципиально каршы чыктым, минем файдага хәрәм кертәсез, кирәкми, мин присяга биргән кеше, дип. Полк командиры булыр өчен мин бит ни взвод, ни рота, ни батальон командиры булмадым. Академия бетергән дип кенә мондый урынга кую дөрес түгел ул. Белоруссиягә бар ракета базасы начальнигы булып, диделәр. Зур урыннар бу, окладлар да зур, пенсиян дә шәп булыр, диделәр — кызыкмадым. Моның тагын бер сәбәбе бар иде — туган якка кайтасы килү. Ләкин Казанда сиңа яраклы урыннар юк, диделәр. Алайса, «Личное дело»ны бирегез, үзем табармын, дидем. Бирделәр. Рәис Беляев, бу вакытта комсомолның Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре, миңа чыбык очы туган тия. Шуның киңәше белән мин, гамәлдәге подполковник, «Гражданский оборона»ның Татарстандагы җитәкчесе Гомәр Усманов янына бардым. Бу аның, Министрлар Советы председателенең, өстәмә вазифасы иде. Мәскәүгә барып, СССР «Гражданский оборона»сы башлыгы маршал Чуйков янына кердем, ул раслагач, шул системада эшли башладым.

Хәзер менә теге алдан әйтеп куйган хәлгә җитеп барабыз. Казанга Калининградтан күчкән идем мин. Шундагы квартирны Казанныкына алыштырырга кирәк бит инде. Миңа Калининградтан рәсми кәгазь җибәрәләр. Янәсе, минем квартирым минеке түгел, ул хәрби гарнизон милке икән! Чеп-чи ялган бу! Квартир шәп иде, берәр түрә кызыккан инде мона, бары шул гына... Мин - ике тапкыр присяга биргән кеше. Авиация училищесына һәм артиллерия училищесына укырга кергәч. Һәм ил-дәүләткә яшь-яшь егет килеш биргән антым минем өчен бик кадерле иде, аны беркайчан да бозмадым мин. Тик... нинди дәүләт соң бу? Ниләр генә була алмый икән монда! Кырымдагы тетрәнү: күрче, партия ничек кылана үзенең халкы белән — беркая да китмәгән, күнелнең тирәнрәк катламында еллар аша килә биргән икән. Менә ул кинәт бәреп чыкты.

Гариза яздым: «Мине партия члены итеп санамагыз!» Күпмедер вакыттан Табеев чакыртты. Татарстанның иң зур түрәсе бу. Алыгыз заявлениегезне, Зәки абый, ди. Түләнмәгән айлар өчен взносларны үзебез түләрбез, ди. Булдыралмыйм, иптәш беренче секретарь, дидем. Тагын бер чакырган иде, анысында да нәкъ шулай кырт кистем.

Мона «җавапны» Калининградта алдым мин. Балаларыма, Казанга кайтып урнашканчы өйләнмәгез дә, кияүгә дә чыкмагыз, дип әйткән идем. Олы улым Нәзи тыңламады, Калининградта бер маржага өйләнде. Тегесе исә күпмедер вакыттан моны квартирдан куып чыгарган һәм... алимент түләтә башлаган! Малайны якларга дип шунда киттем. Калининградның паспорт өстәле начальнигы, хатын белән минем уртак таныш, бу гаиләне белә икән. Мин ул хатынны чакырам, сөйләшерсез, килегез, дип хәбәр салды. Килеп керүем булды, милиционерлар ике кулымны артка каерып бәйләп куйдылар да төрмәгә илтеп тыктылар. Аннары психбольницага китерделәр. Озаклап «дәваламакчылар». Башта хатыннан рөхсәт алыгыз, дидем. Тугыз айдан чыгардылар. Теге «паспортчы»дан, нигә болай эшләдегез инде, сез бит безнең якын таныш, дус идегез, дип сорагач, шундый җавап алдым: партиядән чыкмаска иде аны!..

Татарда шундый бер мәкаль бар: яхшылык эшлә дә, суга сал. Халык күрер, халык күрмәсә, балык күрер. Теге билгесез солдатның игелеге дә халыкка аның исеме белән кушылып барып ирешәчәк, ниһаять.

Кырым татарларының фаҗигасе дә көтмәгәндә киң яңгыраш алды әнә. Алар бездән көчлерәк булып чыктылар. Автономия-фәләннәре дә, бездә булган күп нәрсәләре дә юк килеш үзләрен яклап кинофильм эшли алдылар. Без дәшми-нитми генә татарны мыскыллаган «Орда» фильмын карап ятканда бу! Һәм «Хайтарма» дигән әлеге фильм (режиссеры Әхтәм Сәйтәблаев) Кырымда, Украинада гына түгел, Рәсәйдә дә көчле яңгыраш алды. «Комсомольская Правда»да Галина Сапожникованың «Почему правда о войне ссорит нас с крымскими татарами?» дигән зур мәкаләсе басылып чыкты *(18 июнь)*. Әйбәт мәкалә. Анда менә мондый сүзләр дә бар: «Один кадр меня тронул до слез: во всеобщей суматохе старик тащит на плече швейную машинку — оказалось, ту самую, которую успела в последний момент схватить его мама и которая их в Узбекистане спасла от голода!» Тегү машинасына Мәскәү журналисты Елена Ардабацкая да дикъкать иткән: «Люди, пережившие депортацию, принесли с собой на съемки вещи, которые тогда были с ними. В кадре мелькают то швейная машинка, то Коран, завернутый в полотенце...» *(Электронное периодическое издание «MK.ru.)*

Мина «үзгәртеп кору» әле ныгытып башланганчы ук Кырымда, Күктүбәдәге Иҗат йортында украин язучылары белән сөйләшкәләргә туры килде. Алар Кырым татарларының Кырымдагы хәле әйбәт булмауга ут йотуларын, ярдәм итәргә әзер торуларын сиздерделәр. Украина хакимияте бу җәһәттән әллә ни майтармады дип беләм, ярдәме ташка үлчимдер. Ләкин Мәскәү Украина җирендәге Кырым татарларына да һаман әле акаеп карый. Россия Федерациясенең Кырымдагы генконсулы В. Андреев «Хайтарма»ны карарга килгән Мәскәү кунакларына менә болай дигән: «А вы знаете, что народ, к которому вы приехали, поголовно перешел на сторону фашистского режима?» Легендар очучы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Әмәтхан Солтан да хыянәтче була, димәк! (Ул үз гаиләсен могҗиза белән генә коткарып кала). Геройлары барлыгы җидәү. Армиядә сугышмаганнарның 19 проценты партизан отрядларында сугышкан. 1944 елны сөрелгән халыклар бер Кырым татарлары гына түгел. Алар арасында без дә була ала идек. Күренекле тарихчыбыз Миркасыйм Госманов «Казан утлары»нда менә болай дип язды: «Идел буе татарлары да чиратта булган. Ләкин биш миллионнан артык, өстәвенә бөтен СССР буйлап таралган халыкны җыеп алу мөмкин булмый». («Татар язмышына кизәнгән карар» дигән мәкаләдән. Журналыбызның «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китабыннан укый аласыз — 325 б. Китапта шуннан соң ук кырымтатар язучысы Эмиль Әмитнең «Үлемне җиңгән халык турында» дигән зур мәкаләсе килә).

«Хайтарма»ны исә сентбрьдә үк Казанда карый алачакбыз.

* * *

Ничек яши сон отставкадагы полковник Зәки Низамов? Жинел түгел дип беләм анын тормышы. Ул — үз көченә таянып яши торган кеше. Ләкин бөтен нәрсә синнән генә тормый бит. Бер тапкыр 10 яшьлек олы улы белән 7 яшьлек олы кызы биш катлы өйләренең баскыч тоткасыннан шуып уйныйлар да, кызы егыла — башы белән килеп төшә. Әлегәчә украин хирургы Осадчийга рәхмәт укыйм, ди Зәки абый. (Кызы исә кеше башы ай-яй нык икән ул дип әйтеп куя.) Кызы Гөлчәчәкне бик сирәк күрә хәзер Зәки абый. Калининградта эстон егетенә кияүгә чыга ул, һәм хәзер Эстониядә яши. Улы Нәзине исә бөтенләй күрми. Инде Казанда бер маржа кызына гашыйк булып йөри дә, 1993 елны үтерәләр аны. Хатыны Залифә 2001 елны дөнья куя. Шуннан бирле ялгыз яши икән агай. Кызы Тәслимә атна саен килә. Керләрен алып китә, ашарга пешерә. Улы Әнвәр дә Казанда яши, килгәләп йөри икән. Әмма үзләренә ала алмыйлар икән: кызынын — ире, малаенын хатыны каршы... Күршесе Эльмиранын кызы Ләйсән ике көнгә бер аш пешереп кертә икән. Шул Аксубай районынын Иске Ибрай авылыннан сенлесенен улы Равил алып киткәли икән. Быел гына да өч тапкыр алып киткән инде, 4–5 көн, кайвакыт хәтта атна-ун көн дә торгалый икән аларда.Мунчалар кереп. Аннары Яна Думага, сенлесе Рушаниягә илтә икән Равил, анда да 4–5 көн тора.

Дүрт көн рәттән шалтыраттым Зәки абыйга. Ятып кына торам шул әле, хәл юк йөрергә, ди. Инфаркт, инсульт кичергән икән. Аякнын хәле юк, тын алуы авыр, баш әйләнә, ди. Яхшы йоклыйм, ләкин аяк туна, кан юньләп йөрмәгәнгә, ди.

Бу актив табигатьле кешегә ин кирәге аралашу булса кирәк. Теге мин килгән көнне дә бүген ятып кына торам дигән иде. Әйткәнемчә, безнен янда чабып диярлек йөрде. Өйдә күбесенчә ялгыздыр, ләкин дөньяда ялгыз түгел ул. Мин булган ике сәгатьләп вакыт эчендә генә дә 5 кеше шалтыратты ана. Сөенепләр ала телефонны, сөенепләр сөйләшә. Шалтыратучылар арасында авылдашлары да булган.

Туган авылы Яна Дума анын ин олы күнел таянычы булса кирәк. Биредә аны авылдашлары гына түгел, табигать үзе дә беләдер. Тау башында ярты гектарлап «Зәкиулла наратлыгы» бар. Урманчыдан — үсентеләр, МТСтан трактор сорап алып, мәктәп балалары белән 85нче елларда утырткан ул аны. Наратларнын диаметрлары инде 25 сантиметрга житкән. Урманда Урта чишмәгә дә бураны Зәки абый бураткан. Авылда башта агач мәчет, аннары таш мәчет салуда да ул башлап йөргән...

90 яше 3 сентябрьдә тула анын...

**Рәфикъ ЮНЫС**



## «СӘЛӘТ»ЛЕЛӘР – БЕЗНЕҢ КИЛӘЧӘК

Быел икенче тапкыр зурлап үткәрелгән «Сәләт» форумы халыкара статус алды, чөнки аның эшендә Татарстанның барлык район-шәһәрләреннән кала, Австралия, Чехия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре кебек илләрдән дә вәкилләр катнашты. Форумга 5 мең яшүсмер җыелды. Алар һәммәсе дә укуда, эштә, спортта, сәнгатьтә унышларга ирешкән талантлы яшьләр. Җыенга шулай ук яшьләр хәрәкәтендә катнашучылар, иҗтимагый оешмаларда шөгыльләнүче активистлар да чакырылган иде.

Форум елдагыча Биләр каласында үтте. Яшүсмерләр белән очрашуга ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов та килде. «Корылтай» дип исемләнгән чатырга җыелып «Сәләт» яшьләре Президент белән аралашты, аңа сораулар бирде һәм тәкъдимнәрен җиткерде. Илбашы белән очрашуны башлап җибәргән Студентлар лигасы рәисе Тимур Сөләйманов «Сәләт» хәрәкәтенең тарихына тукталды. 1994 елда Арча районында җәйге ял лагеренда 65 сәләтле укучыны җыеп, компьютерлар белән таныштырудан башланган ул. Хәзер инде бу хәрәкәт ел саен 50 проектны тормышка ашырып килә. Бу еллар эчендә 218 смена оештырылган. «Сәләт» ул хәзер талантлы яшьләр белән эшләү системасына әверелде. Әлбәттә, иң беренче чиратта, мәктәп укучылары белән эшләү», — дип сөйләде Тимур Җәүдәт улы. Студентлар лигасы рәисе Президентка «Сәләт»нең үсеш концепциясен тапшырды. Концепциядә алдагы 3-5 елда бу хәрәкәт үз эченә һәрбер мәктәпне алачагы турында әйтелә. Моннан тыш, чит төбәкләрдә яшәүче татар балалары белән дә эшне системага салу кирәклеге искәртелә.

Президент Р.Миңнеханов «Сәләт»нең һәрбер мәктәпне җәлеп итәргә тиешлеге хакындагы фикерне хуплады. «Бу очракта сәләтле балалар белән эшләү тәҗрибәсен кинрәк куллану мөмкин булачак, — диде Илбашы. – Безнең ике зур проектыбыз бар: аның берсе — «Йолдызлык», икенчесе — «Сәләт». Без «Сәләт»не «Йолдызлык» дәрәҗәсенә җиткерергә тиешбез. «Йолдызлык» аша елына 70 мең бала үтә. Моның өчен, әлбәттә, һәрбер районда «Сәләт»нең бүлекчәләре булырга тиеш».

Очрашу барышында яшьләр биредә башка милләт вәкилләрен дә күрергә теләүләрен әйтте. Киләсе елда форумда Халыклар дуслыгы урамын булдыру тәкъдимен Президент та хуплады.

## ТӨМӘНДӘ САБАН ТУЕ

Быелгы XIII федераль Сабан туе Төмәндә үтте. Анда Россиянең 64 төбәгеннән кунаклар катнашты. Сабан туен Төмән өлкәсе губернаторы Владимир Якушев һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ачты.

Президент билгеләп үткәнчә, Сабан туе — татарларның иң яраткан бәйрәме. «Без аны башка халык һәм милләт вәкилләре белән бергә билгеләп үтәбез. Быел Сабан туе Россиянең 55 төбәгендә һәм 23 чит илдә үтте», — диде ул.

Төмән өлкәсе губернаторы Владимир Якушев Татарстанга, бәйрәмне оештыруда ярдәм итүе өчен, рәхмәт белдерде. «Безнең өчен бәйрәмнең әһәмияте тагын шунда: бүген өлкәдә татарлар сан буенча икенче милләт, алар халыкның якынча 8 процентын тәшкил итә. Бу бәйрәм безнең өчен якын, ул ел саен Төмән җирендә уздырыла, ләкин бүген Сабан туе федераль күләмдә үткәрелә, монда татарлар яшәгән бик күп төбәкләрдән вәкилләр килде», — диде ул.

Төмәнлеләр һәм кунаклар алдында Казанның һәм Түбән Каманың артистлары, иҗат коллективлары чыгыш ясады. Стадионда концерт белән бер үк вакытта спорт ярышлары һәм милли уеннар узды.

Федераль Сабан туе 2014 елда Томск өлкәсендә узачак.

## ҖӘЛИЛ БҮЛӘГЕ ИЯЛӘРЕ

16 июльдә Муса Җәлил исемендәге бүләкнең быелгы лауреатлары билгеле булды. Быел әлеге мәртәбәле премиягә Камал театры артисты **Эмиль Талипов** (Ркаил Зәйдулланың «Үлеп яратты» спектаклендә Корбанов, Туфан Миңнуллинның «Мулла» спектаклендә Әсфәндияр рольләре өчен), композитор **Эльмира Галимова** («Сөембикә канаты» арт-операсы, «Изге ядкәр» ораториясе, «Зәйтүнәкәй» музыкаль драмасы өчен), шагыйрьләр **Рүзәл Мөхәммәтшин** («Каралама» китабы өчен) белән **Ленар Шәех** («Җылытасы килә дөньяны», «Дүртенче кат... Бишенче кат...» җыентыклары өчен), Казан технология тикше-

рену университеты профессоры **Николай Улитин** (фәнгә кертккән зур өлеше өчен) һәм «Татармультфильм» берләшмәсе (татар мультфильмнары коллекциясе өчен) лаек булдылар.

### ЯҢА ЖУРНАЛ ЧЫГАЧАК

Татарстанда яңа уку елы башыннан «Гаилә һәм мәктәп» дип аталган яңа журнал нәшер ителә башлый. Ул «Мәгърифәт» газетасы урынына чыгачак. Моннан тыш, «Мәгариф» һәм «Гаилә һәм мәктәп» журналларын берләштерүче яңа филиал барлыкка киләчәк. Әлеге филиалны «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәрриренең элекке урынбасары Илдар Миргалимов житәкли. «Мәгариф» журналы — укытучыларга, ә яңа журнал ата-аналарга атап нәшер ителә, ул гаилә һәм мәктәпкә кагылышлы мәсьәләләрне яктыртыр, рәсемнәргә бай һәм төсле булыр дип көтелә.

### ӘДИПКӘ ҺӘЙКӘЛ БУЛАЧАК

Мәшһүр татар драматургы, прозаик, публицист, дәүләт һәм жәмәгать эшлеклесе Туфан Габдулла улы Миннуллин истәлеген мәңгеләштерү максатыннан әдипнең туган ягы – Кама Тамагы район үзәгендә һәйкәл куелачак. Бу турыдагы күрсәтмәне Татарстан Президенты Р.Миңнеханов имзалады. Әлеге эштә матди ярдәмне «Татнефть» оешмасы күрсәтәчәк.

### ТУГАНЛЫК СӘФӘРЕ

Күптән түгел генә Уфадан изге Болгар жиренә сәфәр чыккан «Башкортстан» теплоходын кунакчыл Казан үз елга портында каршы алды. Әлеге сәфәрнең быелгысы Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевкә тәгаенләп оештырылган иде. Башкортстаннан килгән кунакларны (алар арасында әлеге сәфәрне оештыручы, «Рамазан» милли-агарту оешмасы рәисе, жырчы Марат Шәрипов, Фән Вәлиәхмәтов, Фәнис Фәтхи, Мидхәт Әбделмәнов, Рамил Чурагул, Гөлнара Хәйруллина кебек танылган шәхесләр бар иде) Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, «Халыклар дуслыгы» йорты директоры Ирек Шәрипов, Татарстанның халык язучысы Гәрәй Рәхим, «Мәдәни жомга» газетасы баш мөхәррире шагыйрь Зиннур Мансуров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, язучы-галимә Рифә Рахман, шагыйрь-пародист Ләбиб Лерон, шулай ук Казан кунагы — Никарагуа шагыйре Орнальдо һәм күпсанлы жырчылар, журналистлар каршы алды.

### ЯҢА ПЛАНЕТАРИЙ АЧЫЛДЫ

КФУ каршындагы В.Энгельгардт исемендәге астрономия обсерваториясендә яңа планетарий ачылды.

Аның тантаналы ачылышында ТР Президенты Рөстәм Миннеханов та катнашты. Әлеге объект тиздән барлыкка киләчәк Астропаркның — фәнни-өйрәнү һәм күңел ачу объектының бер өлеше булыр дип күзаллана. Аның төзелеше 2014 елга билгеләнгән. Планетарий көз көннәренә табарак эшли башлаячак. Ә обсерватория элеккеге режимда эшли.

### БЕР ИСЕМГӘ ӨЧ ЙОРТ

Казансу ярында Фатих, Әмир һәм Хан йортлары калкып чыгачак. Төрек төзелеш фирмасы быел Казансуның уң як ярында күккә ашкан өч йорт төзи башларга жыена. Аларның исемнәре Фатих Әмирхан проспекты белән аваздаш булачак. Биек йортлар Кәрәш сарае һәм торак комплекс арасында урнашачак. Фатих йортының беренче ике катын фитнес-үзәк һәм сәүдә мәйданнары алып торса, Әмир һәм Ханның беренче катлары балалар бакчасына биреләчәк.

### ПРЕЗИДЕНТНЫҢ РӘХМӘТЕ

Законнар чыгару буенча күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү комиссиясе рәисе **Миңнуллин Роберт Мөгаллим улына** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Татарлар». **Сергей Широков** картинасы. Рауль Мирхәйдәров коллекциясеннән.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Айгөл Әхмәтгалиева**.

# Яңа китаплар




**Ләбиб Лерон.** Бәхеткә биш минут кала: пьесалар. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 431 б. Тиражы – 2000 данә.

Китапка Ләбиб Леронның төрле елларда язылган ундүрт пьесасы кергән. Алар арасында гадәти күләмдәге әсәрләр дә, балалар өчен язылган кечерәк форматтагы әкият-пьесалар да бар. Кереш сүзне әдәбият галиме, филология фәннәре докторы Әлфәт Закирҗанов язган. Китапның ахырында язучы турында күренекле әдипләрнең фикерләре дә урнаштырылган.




**Гөлзадә Бәйрәмова.** Син һаман шул сандугач: повесть, хикәяләр, публицистик язмалар, әңгәмәләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. – 191 б. Тиражы – 2000 данә.

Язучы Гөлзадә Бәйрәмованың бу китабына соңгы елларда язылган повесть, хикәяләре, публицистик язмалары һәм күренекле шәхесләр белән әңгәмәләре туплап бирелгән. Китапка кереш сүзне Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ язган.



Айгөл Әхмәтгалиева

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)